ТКН ТКИ

# Шаукат Галиёв

# ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В пяти томах

2
ТОМ

ЮМОР – САТИРА,
ВОСПОМИНАНИЯ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Шәүкәт Галиев

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Биш томда

2

ТОМ

ЮМОР – САТИРА, ХАТИРӘЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Г 18

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,
И.Г.Юзеев, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Галиев Шәүкәт**

Г 18 Сайланма әсәрләр. 5 томда, 2 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 496 б.

ISBN 5-298-01195-0
© Татарстан китап нәшрияты, 2002





# ЮМОР-САТИРА

# Гарантияле мәхәббәт

## *Көлегез, көлегез**

(Җыр)

Кояш бөтен кешегә дә
Бертигез көлеп карый;
Көлү бит ул гөнаһ түгел,
Начальникка да ярый.
　　Көлегез,
　　Көлегез,
　　Файдасы күп, белегез!

Сау-сәламәт, таза була
Шаярган, көлгән кеше;
Көлеп эче авыртса да,
Авыртмый бүтән төше!
　　Көлегез,
　　Көлегез,
　　Файдасы күп, белегез!

Көлеп карасын иренә
Кайчакларны хатын да,
Ирләр дә уйлап карасын
Бер елмаю хакында...
　　Көлегез,
　　Көлегез,
　　Файдасы күп, белегез!

* Хөснул Вәлиуллин музыкасы.

Елмаймыйбыз, дип кыстатса
Әгәр йөзе чытыклар,
Күңел кабыргаларына
Бу җыр төртеп кытыклар!
Көлегез,
Көлегез,
Файдасы күп, белегез!

Тырышыйк, зур өлеш кертик
Без көлү өлкәсенә,
Тик үзебез генә калмыйк,
Әй, адәм көлкесенә!..
Көлегез,
Көлегез,
Файдасы күп, белегез!

*Август, 1958*

## *«Оялчан кыз...»*

Егет үрелмәкче булды...
Кыз кычкырды:
— Тимә! — диде.
Күзләренә карады да,
Әкрен генә:
— Ти... Мә! — диде...

*Гыйнвар, 1988*

## Мәхәббәт уставы турында

Өч егет хат язганнар
Һәм киңәш сораганнар:
«Өчебезнең беребез
Кызлар сөя белмибез —
Ничегрәк сүз кушасы,
Ничегрәк танышасы?
Язмассызмы,— дигәннәр,—
Сез «Мәхәббәт Уставы»?»
Әйтерсең лә бу эшнең
Мин мәшһүр бер остасы!
Истә әле сөюнең
Беренче адымнары,
Мәгълүм түгел иде шул
Безгә дә алымнары.
Белмәдек шул сөюнең
Теорияләрен дә,
Кыяр-кыймас әйләндек
Кызлар тирәләрендә.
Безне дә шул әлеге
Уставсызлык йөдәтте.
Мәхәббәт диңгезендә
Компас иттек йөрәкне.
Бигрәк мөһим мәсьәлә
Күтәрәсез, егетләр.
Фикеремне әйтергә
Этәрәсез, егетләр.
Мәхәббәт мең-мең еллык
Стихия, дибез дә,
Вакыттыр шул куярга
Аны фәнни нигезгә!
Сөюнең мөһимлеген
Онытабыз, гадәттә,
Хәтта сөю хаты да
Өйрәтмибез мәктәптә.
Кирәк булыр вузларда
Егетләргә, кызларга
Һәм башка ялгызларга
Мәхәббәт укытырга!

Булсын стратегиясе,
Булсын тактикасы да,
Булсын җәйге айларда
Махсус практикасы да.
Гыйшык хатлары исә
Диплом эше саналсын.
(Ә көндез эшләүчеләр
Кичләрен шөгыльләнсен.
Читтән торып ярату
Мөмкинлеге дә калсын...)

Булмый калмас, билгеле,
Докторлар, кандидатлар;
Бу темага бик күпләр
Диссертация яклар.
Инде болар һәммәсе
Озак диючеләргә
Өч айлык курслар җитәр —
Яныт сөючеләргә...

...Өч егеткә җаваплап
Шуны әйтәм, йомгаклап:
Икәүдән генә туа
Һәр «Мәхәббәт Уставы».
Мондый эшнең беркайчан
Була күрмә остасы.
Бүтән тармакларда без
Кайчак файда күрсәк тә,—
Күңелләргә, хисләргә
Биреп булмый күрсәтмә! —
Качсын төн йокыларың,
Уйлан, борчыл, ян, дустым,
Кояшлы юлларыңда
Очратырсың җан дустың.

Без дә берни белмәдек,
Яшьлек үзе өйрәтте.
Мәхәббәт диңгезендә
Компас ит син йөрәкне!

*Гыйнвар, 1968*

## Хупҗамал

(Сөйдергеч)

Кулымдагы шигыремнең
Исемнәре Хупҗамал,
Бу хәлләрне сөйлимме дип,
Уйлап йөрдем күп заман.

Сөйләп җибәрсәм, Хупҗамал
Авырга алыр төсле,
Сөйләмәсәм, тел кычыта,
Әрәмгә калыр төсле...

*

Матур буласы килми соң
Дөньяда кайсы кызның,
Чибәр күренәсе килми,
Әйтегез, кайсыгызның?

Хупҗамалның да бит үзен
Яраттырасы килә,
Ким дигәндә бер егетне
Караттырасы килә.

Хупҗамалның кара чәчен
Ничек кенә үрмиләр;
Ә егетләр, үч иткәндәй,
Күрмиләр дә күрмиләр...

Казаннардан алып кайткан
Хушбуен сөртеп карый,
Кара кашлар арасына
Зәңгәр миң төртеп карый.

Буяна да ясана гел,
Күзге каршыннан китми;
Баш вата гел, нигә аңа
Беркем игътибар итми?..

«Ферма кызлары шикелле
Кулларым ярылмаган,
Күлмәгенә сырганаклар,
Үләннәр сарылмаган.

Фигурамны да саклыйм бит,
Күтәргән юк чиләк тә;
Кершәнемә он кунар дип,
Тотканым юк иләк тә...»

Яшьләр җырлый:
«Хупҗамалның
Ялгау-ялгау керфеге,
Ничә сумга төшкән икән
Керфегенең бөртеге?»

Матур буласы килми соң
Дөньяда кайсы кызның,
Чибәр күренәсе килми,
Әйтегез, кайсыгызның?

Хупҗамалның да бит үзен
Яраттырасы килә,
Ким дигәндә бер егетне
Караттырасы килә...

Әллә сөйлиләр белмичә,
Әллә сөйлиләр белеп,
Әллә сөйлиләр дөресен,
Әллә сөйлиләр көлеп:

— Бар,— диләр,— күрше авылда
Укымышлы бер әби,
Гыйшык-гашрәт мәсьәләсен
Иллә дә шәп белә,— ди.

— Әбекәем, сөйдерүнең
Мәгълүм сиңа күп сере,
Өйрәтеп җибәрче, зинһар,
Миңа да шуның берен...

— Иртүк торып чишмәгездән
Алып кайт син таң суы,
Сөттәй битләреңә төшсен
Җитмеш таңның алсуы.

Кызарып чыккан кояшка
Карап чәчең тарарсың,
Шушы киңәшләрне тоткач,
Тагын килеп карарсың...

*

Таңнан торып чиләкләрен
Алып китә Хупҗамал,
Чишмә суы болганганчы
Барып җитә Хупҗамал.

Көн саен күрә ул таңны,
Кызылланган күк читен;
Самовар хәтле чиләкләр
Алсулата кыз битен...

Яшьләр җырлый: «Кашың кара,
Ник сөртәсең сөрмәсен,
Бөгелә-сыгыла су ташыйсың,
Күзем тия күрмәсен!»

*

Хупҗамал килә әбигә:
— Җитте микән шул? — диеп,
Әби көлемсерәп куя:
— Түземлерәк бул,— диеп.—

Әгәр килсә бетми торган
Сөйдергеч ясатасың,
Күңелең тарткан кешегә
Икмәк тә ашатасың...

Әмма ләкин бер шарты бар,
Шул шартында бар хикмәт —
Үзең тир түгеп, бил бөгеп
Үстергән булсын икмәк!

Синең үз кулыңда хәзер
Матур булу чарасы,
Шушы киңәшләрне тоткач,
Тагын килеп карарсың...

*

Хупҗамал кайта басудан,
Өс-башы коңгырт тузан,
Битләре янган, кызышкан,
Чәчләр чуалган, тузган.

Килә ул, энҗе тирләрен
Җиңнәре белән сөртеп,
Тик берәү дә көлми аннан
Бармагы белән төртеп!

Бу ни хикмәт, бу ни гаҗәп,
Бар кеше карый сөеп,
Хупҗамал үтә урамнан
Түбәсе күккә тиеп!

*

Үтә көннәр, үсә иген,
Җитә урак өсләре,
Дулкын-дулкын арышларның
Алтын-сары төсләре.

Эшлиләр яшьләр очынып,
Шаярышып, көлешеп;
Хупҗамал, килеш-килбәтең
Тора бигрәк килешеп.

Нигә кирәк кара күзлек,
Күзләрне томаласа,
Кашың карлыгач канаты,
Күзең шомырт лабаса!

Буяусыз да битләреңнең
Алмалары ал икән,
Яратыйм дисәң, кызларга
Эшендә күз сал икән.

Берәү җырлый аңа төбәп:
«Гөлгә үрелдең мәллә,
Матурлык өләшкән чакта,
Алдан йөгердең мәллә?»

Тагын карый, тагын җырлый:
«Агыйдел кичтең мәллә,
Мәхәббәтле булу өчен
Дарулар эчтең мәллә?»

Кояш та, кызга сокланып,
Күз йоммый карап тора,
Йомшак җил, башыннан сыйпап,
Чәчләрен тарап тора.

Сөенеп эшли Хупҗамал,
Онытып аруларын,
Менә нинди була икән
Сөйдергеч дарулары!

Канатланып бара эшкә,
Басулар гизеп кенә,
Күңелендә мәхәббәтнең
Җылысын сизеп кенә.

«Күптән йөрим күз атып», — дип,
Тәмле сүзләр кузгатып,
Күпер төбе Фатих көн дә
Кайта аны озатып...

*

Җитте көзләр, бушады кыр,
Табын тулы сый булды,
Табын тулы сыйлар белән
Ил гөрләткән туй булды.

Әби булды туй түрендә,
Аңа — иң зур хөрмәт тә,
«Сөйдергеч» ясатты бит ул
Хупҗамалга хезмәттә!

— Чын күңелдән,—
ди Хупҗамал,—
Әйтәм рәхмәт сүземне,
Юк-барга ышанган чакта
Ачтың, әби, күземне!

Фатихы да, бик рәхмәт, ди,
Рәхмәт дими, ни дисен:
Табыштырдың, кавыштырдың —
Менә дигән әби син!

...Әбигә мин дә рәхмәт, дип,
Иминлек теләп калам;
Кайбер кызлар кирәксенсә,
Адресын әйтә алам...

*Февраль, 1960*

## *Үч итеп...*

Мин берчакны сүз дәшмәдем
Сиңа үч итеп.
Син соңыннан сөйләшмәдең
Миңа үч итеп.

Мин бүтән кызны озаттым
Сиңа үч итеп.
Син дә егет белән кайттың
Миңа үч итеп.

Мин кызның биленнән тоттым
Сиңа үч итеп.
Син, ә син... кияүгә чыктың
Миңа үч итеп.

Мин дә кайттым хатын алып
Сиңа үч итеп!
...Җибәрдек ахры арттырып,
Җанкай, үч итеп...

*1966*

## Бар икән күрәселәр...*

(Җыр)

Толымнары нинди озын,
Күлмәге чем-чем кара;
Өемне узып киткәнмен,
Артыннан бара-бара.
Бар икән күрәселәр...

Бүген менә, сизәм инде,
Булганмын аңа гашыйк.
Бер егет белән үтте шул,
Калдым башымны кашып...
Бар икән күрәселәр...

Кичен бакчада очраттым,
Йөри ул көлә-көлә;
Артыннан: «Әни, әни!» — дип,
Кызлары йөгереп килә...
Бар икән күрәселәр!..

*Июль, 1958*

## Бозау

Эчтән генә янып йөрим,
Сүз кушарга базалмыйм.
Тел тибрәтеп әйтү түгел,
Хәтта хат та язалмыйм,
Алар урамын һәр кичне
Өч-дүрт кат урыйм, түзмим.
Очрап: «Ни югалттың?» — дисә,
«Менә, дим... бозау эзлим...»
(Күрсәм телем бәйләнә шул,
Әйтер сүзләрем бетә...)
Ә ул көлә: «Әйтәм һаман
Моннан бер бозау үтә!»

*1953*

* Хөснул Вәлиуллин музыкасы.

## *Йөргән идек ике дус*

Гомеренең таңнарын
Кемнәр генә сагынмый!
...Йөргән идек ике дус
Агылый да тагылый.
Икәүләшеп йөрмичә
Безгә һәч тә ярамый —
Беребез дә ялгызы
Кызлар янга баралмый.
Икәү булсак, без кыю,
Чынлап торып без шаян,
Чыгып тора сүз каян,
Икебез дә бик наян.

Көннәрнең берендә без
Бер чибәрне очраттык.
Икәүләшеп сүз каттык.
Икәүләшеп озаттык,
Тик ул кызны күргәчтен,
Дустым әллә нишләде —
Элеккечә көлмәде,
Шаярып сөйләшмәде.
Гомумән, кызкай белән
Боткалары пешмәде.

Ә кыз мине култыклый,
Һаман миңа елыша.
Үзе дуска гел генә
Төрттерергә тырыша.
Моңсулыгын күрә дә:
— Тагын, ди, төшкән томан...
Чырык-чырык көлә дә:
— Бул син,— ди,— дустың сыман!
Иптәш әйтә:
— Кит әле,
Сагыз булып ябышма!

Бер җылы сүз әйтмәде
Чибәр кызга ялгыш та.

Бик ачуы килгәндә
Төрткәләп тә җибәрә.
Җыларга җитешә кыз...
Мин кыз янына киләм,
Гафу сорап дус өчен,
Аңа кулымны бирәм.
Кыз иптәшне шелтәли:
— Бул син,— ди,— дустың сыман!

Күңеле миндә бугай...
Бусын мин эчтән тынам.
Көтеп тә җиткерәлмим
Очрашачак сәгатьне.
Иптәшем һаман дорфа,
Мин һаман нәзакәтле.

Ә беркөнне дус килде
Мине туйга дәшергә:
— Теге юньсез белән,— ди,—
Булдык өйләнешергә.

Дустым өйләнгәннән соң
Төшендем мин шул якны:
Шаян сөйләшмәсәң дә,
Кайчак эндәшмәсәң дә,
Кызлар күзләгән чакны,
Ялгыз булуың яхшы...

*1968*

## Ишерен-батырын түгел...

Баштанаяк модный киенгән кыз
Барсын уздырам дип сөенә.
Ә бит баксаң, бик күптәнге «мода»—
Чишенергә теләп киенә...

*1987*

## *Ник ташлады ул егет?*

...Ул егет белән бергә
Чират тордык билетка.
Егет миңа карады.
Мин карадым егеткә.
Икебез дә елмайдык.
Мин көлдем. Ул күз кысты.
Күз кысты да сүз кушты.
«Чибәр кыз, дигән була,
Исемең кем?» дигән була.
«Хәрби сер, дигән булам,
Үзең кем?» дигән булам.
«Яшь кызлар, Ирис, диләр,
Хатыннар, Идрис, диләр,
Карчыклар, Иблис, диләр...»

Исемнәрне белештек,
Кызык булды. Көлештек.

Ул арада билетка
Җитте чират килеп тә.
Конфет белән кинода
Сыйлап утырды егет,
Караңгыда кулымны
Сыйпап утырды егет.
«Яратасың мәллә?» — дим,
«Яратам бугай шул»,— ди.
«Шаяртасың мәллә?» — дим,
«Шаяртам бугай шул»,— ди.
Бер конфет биргән була,
Соңгысы дигән була.
Бергә тешләп бүлештек,
Ялгыш кына үбештек.
Кызык булды. Көлештек.

Ай күрде, кояш алды —
Шуннан соң ул югалды.
Сагынам, дип тә карыйм,
Ялынам, дип тә карыйм...

Шалтыратып та ардым,
Эш урынына бардым!
Отдел кадрга кердем,
Завкомнарын да күрдем.
Башта ул мине, дидем,
Яратам, диде, дидем.
Инде ташлады, дидем,
Йөрми башлады, дидем.

Шундый, дим, булалармы,
Шулай, дим, сөяләрме —
Таркаталар бит алар
Булачак семьяларны!
Шул эш буенча килдем,
Чара күрегез, дидем.
Өйгә кайттым да көтәм,
Көтекләр булып бетәм.
Күренми бит, имансыз!
Ничек яшәрмен ансыз,
Зурдан иде өметләр...
Бар бит юньсез егетләр!..

*1968*

## *Көзге*

«Сине яратам?» — дисә дә,
Бүтәннән күзен алмый:
Күбрәк яратканы шулдыр —
Гел-гел көзгегә карый!

*1988*

## «Гарантияле мәхәббәт» *

Бер егет минем тирәмдә
Әйләнә дә әйләнә,
Бергә тормыш корыйк, диеп,
Бәйләнә дә бәйләнә.

Синсез һич тора алмыйм, ди,
Тагын ничек ди әле —
Сиңа булган мәхәббәтем
Нык, ди, гарантияле!

Ашыккан ашка пешкән, дим,
Ашыкма, сабыр ит син,
Гарантияле булса да,
Сынау срогы үтсен.

Инде эзе дә күренми,
Моңа нәрсә диясе?
Алты айлык кына булган
Аның гарантиясе!

*Март, 1960*

## Утлы күмер

Мактанасың, кызый, йөрәкләрнең
Яндырдым дип инде ничәсен!
Шуңадыр шул, утлы күмер кебек,
Кулдан-кулга бик тиз күчәсең...

*1962*

* Шамил Шәрифуллин музыкасы.

## Урладылар...

Ахры, бүтән чара тапмый
Сөюдә уңмаганнар,—
Иске гадәтне хәтерләп,
Тагын кыз урлаганнар.

Кич клубтан кайткан чакта
Тотканнар да алганнар,
Толып белән башын каплап,
Чанага да салганнар.

Кыз тартыла, тыпырчына,
Мөгаен, ычкынмакчы,
Бөтен авылны җыймакчы —
Каравыл кычкырмакчы!

Ә егетләр ирек бирми,
Ә егетләр чаялар.
Күрше авыл тарафына
Мыштым гына таялар.

Язмышына буйсыныптыр,
Кайта кыз тыныч кына.
Тик өйдә генә кычкыра:
— Урладылар бит! Урра!

Авыз ерып кайткан кияү
Ник телсез калган шулай?
Аның каравыл кычкырыр
Көннәре алда бугай...

*Ноябрь, 1968*

## *Үкенмим*

Балык шикелле
Тыпырчындың син
Минем кочакта.
Каптым шул чакта
Синең кармакка...

*1966*

## *Җете кызыл...*

Чибәр артыннан кума —
Җете кыз ул тиз уңа!

*1969*

## *Тагып бирү*

Үтмәс товарларны бездә
Бик үткәрә беләләр —
Яңа төймәләргә тагып,
Иске пальто бирәләр.

Кирәк белән кирәкмәсен
Бергә куеп төрәләр —
Авторучка алыйм дисәң,
Чүмеч өстәп бирәләр...

Инде өйләнәм дигәч тә,
Яучылары киләләр —
Чибәр генә бер хатынга
Бала тагып бирәләр!..

*Ноябрь, 1968*

## Мин ничек кәләш сайладым

Бик күп кызлар сайладым.
Әмма сайлый алмадым.
Берсен алсаң, берсе жәл,
Кыен булды минем хәл.

Дүрт дистәне тутыргач,
Озак уйлап утыргач,
Мыекларны бордым мин,
Өйләнергә булдым мин!
Такыр башны кашыдым
Һәм Аллага тапшырдым.
Шунысы да мач булды —
ТТКБ ачылды.
Шулдыр минем тормышны
Яңа юлга борасы:
Табыштыру,
Таныштыру,
Кавыштыру
Бюросы.

Килдем.
Кердем.
Каршымда,
Шома өстәл артында
Бер чибәр кыз утыра
Чәчәкләр арасында.
Бик матур елмайды да,
Йөз сум гына алды да:
— Менә шушы бүлмәгә
Рәхим итегез,— диде,—
Алга үтегез,— диде.—
Язмыш —
Үз кулыгызда,
Уңышлар —
Юлыгызга!

— Рәхмәт! — дидем,
Баш идем.

Бүлмәне ачып кердем
Һәм ике ишек күрдем.
Язу беренчесендә:
«МОНДА — КИЯВЕҢ, ПАРЫҢ».
Язу икенчесендә:
«МОНДА — КӘЛӘШЕҢ, ЯРЫҢ».

Кулны тоткага сузам,
Тизрәк бүлмәгә узам.

Керсәм — янә ике ишек
(Оста уйланган ничек!).
Уң яктагы ишектә:
«САРЫ ЧӘЧЛЕЛӘР» икән.
Сул яктагы ишектә:
«КАРА ЧӘЧЛЕЛӘР» икән.

Күңел тартты сул якка,
Борылдым мин шул якка.

Керүен кердем дә, хуш —
Бүлмәнең бусы да буш.

Ике ишек тагын да,
Язу ике ягында.
Шундый беренчесендә:
«ЗИФА БУЙЛЫ ЯШЬ КЫЗЛАР».
Мондый икенчесендә:
«ТӘҖРИБӘЛЕ ХАТЫННАР
ҺӘМ ДӘ ТОЛЛАР, ЯЛГЫЗЛАР».

Егет көе — хатынга?
Юк, юк, бармыйм якын да,
Әллә соң мин юләрме!
Яшь кызларга юнәлдем.
Бусагадан атладым,
Көткәнемне тапмадым.

Ике ишек янә дә
Һәм язулар янәшә:

Берсе: «ӘТИ-ӘНИЛЕ,
ТУГАННАРЫ КҮП» дигән
Икенчесен хуп күрдем:
«БЕРКЕМЕ ДӘ ЮК» дигән.

Икәү генә яшәсәк,
Булмас талаш һәм ызгыш.
Шушыдыр минем язмыш!

Тоткан идем тотканы,
Бусагада туктадым.
Пар ишек бар. Берсенең
Язуы нинди диген:
«УЕН-КӨЛКЕ ЯРАТА,
ӨЙДӘ ЭШЛӘТӘ ИРЕН!»

Кирәк бит, әй, кешене
Шыр тилегә санарга —
Үземә ямап туйган,
Тагын аңа ямарга?!
Андыйлардан мин качам,
Вәт бусы шәп, ичмасам —
«ҺӘМ ДӘ УҢГАН,
ҺӘМ ДӘ БУЛГАН
КӘЛӘШ» ишеген ачам!

Бүлмәгә кергән идем,
Түр якка төште күзем.
Ишекләрдә язулар...
— Җитте! — дим, бетте түзем.
Шулай да укыйм үзем.
«ТУЛАЙ ТОРАКТА ЯШИ»
Дигән сулдагысында,
«КВАРТИРАЛЫ БАЙ КӘЛӘШ»
Дигән уңдагысында.
Үзегезгә билгеле,
Мөһим мәсьәлә бу да,
Минем урында сез дә
Китәр идегез уңга.

Соң, бай кәләш алмаска,
Мөмкинчелек булганда!

Ачкан идем ишекне,
Килеп чыктым... урамга!..

Каршы алды бер бабай,
Зур гына пакет бирде.

Бусы тагын ни инде?!
Пакетында көзге һәм
Шушы язу бар иде:
«САЙЛАРГА СЕЗ БИК ОСТА.
ӘММА ШУШЫ КӨЗГЕГӘ
КҮЗ САЛСАГЫЗЧЫ БАШТА!..»

...Кәләш таба алмасаң,
Юк баш ватып торасы —
Ярдәм итәр сезгә дә
Табыштыру,
Таныштыру,
Кавыштыру
Бюросы...

*1968*

## *Гашыйк сүзе*

Мәхәббәт җыры күп диләр,
Ышанмыйм күп дигәнгә,
Яхшы җырлар арту кая,
Җитми әле сөйгәндә!

Сүз әйтмәгез шагыйрьләргә,
Түгел алай дияр чак,
Үзегез сөеп оныткач та,
Безнең как раз сөяр чак!

Уртача алганда бик күп
Җыр сыйдыра бер йөрәк,
Һәрбер гашыйк җан башына
Җыр җитештерү кирәк!

*1958*

## Йөрәк эше...

Мәхәббәт турында язу
Яшьләр эше бит, диләр.
Әмма йөрәк хезмәтеннән
Пенсиягә китмиләр.

Карт йөрәкле яшьләр була,
Яшь йөрәкле карт була.
Илаһи илһам сүнмәсен —
Тик бер генә шарт була.

Кемгә күңел канатлары,
Кемгәдер азгынлыгы...
Мәхәббәт белән санала
Гомернең озынлыгы.

*2000*

# Өйдә бөтен шартлар туган

## *Туйда сөйләнгән нотык*

Күптәнге йола булса да,
Өйләнү яхшы гадәт.
Санасын уртак гомерне
Бүләккә килгән сәгать.

Ни сөйләргә дип тордым да,
Шуны алдым сәбәпкә:
— Башлагыз яңа тормышны
Сез хәерле сәгатьтә!

Кавышу минутларын сез,
Беләм, аз көтмәгәнсез,
Тату парлардан көнләшеп,
Бер генә үтмәгәнсез.

Сукты көткән сәгатегез,—
Кызыгырлык пар сез дә.
Минут — тулмас, сәгать — булмас,
Бераз сүзем бар сезгә...

Акыл өйрәтергә ансы
Минем полный хакым бар,
Тәҗрибәм зур: биш балам һәм
Бер булса да хатын бар.

Белмәгәннәр генә белми,
Файдалы эш — өйләнү,
Бу бит берьюлы икәүнең
Тормышлары көйләнү!

Әйтик, һәркем, үзенә дип,
Юрганын алган итә,
Өйләнгәч, экономия —
Икеңә берәү җитә.

Егет чакның шунсы кыен —
Урамда күп торасың.
Өйләнгәч, экономия —
Гел өйдә утырасың...

Ялгыз чакта көн дә иртән
Сакал кырмый ярамый.
Өйләнгәч, экономия —
Барыбер кеше карамый...

Бүләккә килгән сәгать тә
Тормышта ярап куяр.
Өч минутка соң кайттың дип,
Хатының карап куяр...

Сез шүрләп калмагыз тагын
Гел болай сөйләнгәнгә,
Мин, мәсәлән, һич кенә дә
Үкенмим өйләнгәнгә.

Көн туган саен хатынга
Мәхәббәт артып тора,
Магнит шикелле суырып,
Үзенә тартып тора.

Менә дигән кыз-улларның
Анасы, атасы без,
Гомергә бетәрлек түгел
Мәхәббәт запасыбыз!

Тату яшибез, һичкайчан
Каты итеп дәшмибез,
Кайчак йомшак та дәшмибез —
Бөтенләй эндәшмибез...

Кыскасы, мин әйтә алам,
Әйбәт хатын таптым, дип,
Син дә үкенмәскә тырыш,
Бетте башлар, каптым, дип...

Кияү тертәксез булмый,
Килен бүләксез булмый,
Кунак йөрәксез булмый,
Табын теләксез булмый.

Яшәгез, кайгы-шатлыкның
Кадерен белеп кенә,
Хәтта чикләвек төшен дә
Урталай бүлеп кенә...

Мәхәббәттән күңелләргә
Канат чыгарлык булсын,
Теләсә нинди сагышны
Сугып егарлык булсын!

...Күп сайрадым, вакыт бугай
Бокаллар чыңлатырга,
Бокалларны корытырга,
Тамакны чылатырга.

Җыелышка күп йөргәнгә
Кереп калган бу гадәт —
Хатын чабудан тартмаса,
Сөйләп ташлыйм өч сәгать...

*Август, 1960*

## Яңа өйгә яңа көй

Өй туенда уйнап-көлеп
Утырып алыйк әле,
Йорт салганнар хөрмәтенә
Тутырып салыйк әле!
    Армасыннар,
    Талмасыннар,
    Җиңел булсын ташлары,
    Җиңел булсын ташлары,
    Әйләнмәсен башлары!
Өй кыегы сырлы-сырлы,
Кәрнизгә дә сыр кирәк.
Кәрнизләргә сыр кирәкми,
Табыннарга җыр кирәк.
    Яңа өйгә
    Яңа көй дә
    Алып килдек бүләккә,
    Алып килдек бүләккә
    Сезгә изге теләк тә!
Өй туенда көй, уен да,
Гармуны да тынмас бит,
Сыныйк әле идәннәрен,
Сынаганда сынмас бит!
    Китереп бас,
    Сикереп бас,
    Бер югары, бер түбән,
    Бер югары, бер түбән,
    Түшәмгә тисен түбәң!
Рәхәт көн итсен хуҗалар,
Бәхетле нигез булсын,
Имин яшәсен күршеләр,
Шатлыклар тигез булсын!
    Өйләнгәннәр,
    Көйләнгәннәр,
    Шатланышып торсыннар,
    Шатланышып торсыннар,
    Матур тормыш корсыннар!

*1960*

## Үзгәреш

Билләрдән генә тотып,
Күз карашларын йотып,
Елмаюлар балкытып,
Бар дөньяны онытып,
Егет белән кыз килә,
Егет көлә, кыз көлә!

Кара, ничек баралар,
Җил дә үтмәс арадан,
Әйтерсең ябышканнар...
Һай, ничек табышканнар!
Сыланмышлары матур,
Кыланмышлары матур!

...Очрады тагын алар,
Аллы-артлы баралар,
Дүрт-биш адым аралар...
Егет чыраен сыткан,
Әйтерсең керпе йоткан.
Кыз бәрәңге күтәргән,
Күзен җиргә текәгән...

Уйлап куям мин эчтән:
«Болар да өйләнешкән!..»

*Февраль, 1968*

## Сүзендә тора...

«Өрмичә урындыкка да
Утыртмам» дигән иде,
Һау да һау гел өреп тора,
Сүзе рас килгән инде!

*Гыйнвар, 1966*

## Урамда һәм өйдә

Ридикюлен күтәрер ул хатынының,
Чеметеп алыр җеп кисәген макинтоштан.
«Тарт итекне!» — диеп кайткач аяк сузар...
Кеше дип бит ялгышырга мөмкин тыштан!

*1957*

## Экономия булмагач...

Кыз чагында язган хатларыңны укып
Тоям синең ташып торган иркәң, назың;
Ник чамалап тотмадың син хисләреңне —
Ник хәзергә калдырмадың соң беразын?

*1957*

## Бу көннәрдә

Аппетитым да шәбәйде, яхшы йоклыйм,
Юк җәнҗал да хәзер өйдә, юк һәм шау-шу.
Тынычлыкның сере шунда:
Суык тиеп
Бетеп тора әле хатынымның тавышы.

*1957*

## Будильниклар

Өйләнгәчтен, йоклап калмыйм дип,
будильник
Алган идем, баш очына куя торган,
Хәзер будильник кирәкми. Өч балам бар,
Иртә таңнан ук елашып уятырга...

*1957*

## *Алмашыну*

Егет сөйгәнен култыклый —
Ятлар алмасын, диеп.
Өйләнгәч, хатын култыклый —
Китеп бармасын, диеп...

*1977*

## *Никах җепләре*

Верхолазлар гомерләрен
Бил бавына ышана —
Алар тыныч, биеклекләр
Нинди хәтәр булса да.

Безнең хәләл җефетләр дә
Нәкъ шундый, диләр ирләр:
Егылырга да бирмиләр,
Ерак та җибәрмиләр!..

*1969*

## *Тыйнакландым*

Яшь чакта тыйнаксыз идем —
Күп кызга «яратам!» дидем,
Шактый яздым хатымда да.
Өйләнгәчтен тыйнакландым,
Инде хәзер «яратам!» дип
Әйткәнем юк хатынга да!

*Октябрь, 1967*

## Морадына ирешкән Морат

**1**

Морат кайта
Шәһәрдән,
Бер атналык
Сәфәрдән.

Тияр-тимәс
Юл ташына,
Оча гына,
Әй машина!

Карый уңга,
Бер авылга:
Бер кыз чыгып
Баскан юлга.

Тормозына
Баса Морат,
Ишекне киң
Ача Морат.

Әйтеп куя
Чая гына:
— Сөял чыгар
Аягыңа,

Утыр, әйдә,
Юл уңае!
Юл уңае,
Сүз уңае...

Очраштырган
Безне язмыш,
Ә язмыштан
Юктыр узмыш.

Кыз кызарып
Аска карый,
Мәгънәсе шул:
«Күнәм, ярый...»

...Ә ун көннән
Эш хараптыр,
Туры килми,
Дип, характер,

Куа Морат:
— Сыпырт кына!
Тыңлый хатын
Шыпырт кына,

Төенчеген
Кулга ала,
Морат авыз
Ерып кала...

**2**

Морат тагын
Шәһәрдән,
Кайтып бара
Сәфәрдән.

Тияр-тимәс
Юл ташына,
Оча гына,
Әй машина!

Карый сулга,
Бер авылга:
Бер кыз чыгып
Килә юлга.

Тормозына
Баса Морат,
Ишекне киң
Ача Морат.

Әйтеп куя
Чая гына:
— Сөял чыгар
Аягыңа,

Утыр, әйдә,
Юл уңае!
Юл уңае,
Сүз уңае...

Очраштырган
Безне язмыш,
Ә язмыштан
Юктыр узмыш.

Кыз, кызарып,
Аска карый,
Мәгънәсе шул:
«Күнәм, ярый...»

...Ә ун көннән
Эш хараптыр,
Туры килми,
Дип, характер,

Куа Морат:
— Сыпырт кына!
Тыңлый хатын
Шыпырт кына

Һәм кулына
Кисәү ала,
Морат телен
Тешләп кала...

Бусагага
Баса хатын,
Ишекне киң
Ача хатын,

Әйтеп куя
Чая гына:
— Кит, теләсәң
Кая гына!

Морат дәшми,
Аска карый,
Мәгънәсе шул:
«Күнәм, ярый...»

**3**

Морат тагын
Шәһәрдән,
Кайтып килә
Сәфәрдән.

Үтә авыл
Арасын,
Ник читкә бер
Карасын!

*Ноябрь, 1959*

## *Куллары да куллары...*

Көтмәгәндә килеп берәү
Томалап алды күзне.
Йоп-йомшак инде куллары...
— Фәния, җаным, сезме?

— Синме, сөеклем Сәлимә?
— Роза, синме, алтыным?
Кулларын ачып җибәрсәм...
Басып тора хатыным!

Әйе, әйе, хатын шул,
Кулы бигрәк каты шул...

*1958*

## Яр эзләдем, яр таптым*

(Җыр)

Яр эзләдем, яр таптым,
Киңәшкә өйгә кайттым.
Бик ошата әти дә,
Бик ошата әни дә,
Тик сеңлемә ошамый,
Тик энемә ошамый...
Кыз күзләүдән, кыз күзләүдән,
Кыз эзләүдән бушамыйм...

Яр эзләдем, яр таптым,
Шатланып өйгә кайттым.
Бик ошата сеңлем дә,
Бик ошата энем дә,
Тик әтигә ошамый,
Тик әнигә ошамый.
Кыз күзләүдән, кыз күзләүдән,
Кыз эзләүдән бушамыйм...

Яр эзләдем, яр таптым,
Очынып өйгә кайттым.
Сеңелемә дә ошый,
Әтиемә дә ошый,
Тик әнигә ошамый,
Тик әбигә ошамый...
Кыз күзләүдән, кыз күзләүдән,
Кыз эзләүдән бушамыйм...

Күрше карчык яр тапты,
Җитәкләп өйгә кайттым.
Бик ошата әти дә,
Бик ошата әни дә,
Сеңелкәшкә дә ошый,
Энекәшкә дә ошый.
Тик үземә, тик үземә,
Тик үземә ошамый —
Ызгышудан бушамыйм!

*Март, 1958*

* Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы.

## *Җәһәннәм...*

Җәннәт исемле хатынга
Кызыгып йөргән,
Дүрт баласын ташлаган да
Йортка кергән,—
Җәһәннәмнең ниндилеген
Шунда белгән...

*Июль, 1958*

## *Шүрлекләр мәсьәләсе*

Хатын бәләкәй, уңайсыз
Кешегә күренергә...
Туры килә шүрлеккә дә
Үземә үрелергә.

Өйләндем озын буйлыга,
Көткәнне күрдем менә —
Җитеп кенә тора буе
Нәкъ ипи шүрлегемә...

*1968*

## *Фикер уртаклыгы*

Фәләх барда искә алсаң:
«Каенана» дип,
Ишетә ул:
«Кандала» дип.

Каенанасы телдән әйтә:
«Киявем» дип,
Эчтән уйлый:
«Кигәвен» дип...

*1964*

## Тимер һәм игәү

Хатын һәм ир
Яши икәү:
Берсе — тимер,
Берсе — игәү.

*Март, 1966*

## Гармунчы язмышы

Туйга чаклы — кыз биеде,—
Тынмады гармун чыңы.
Инде өйләнешкәч — хатын
«Биетә» гармунчыны!..

*1960*

## Нәфес

Үзе инде күптән мичкә бил,
Эзләп йөри һаман нечкә бил...

*1961*

## Вокзал...

Вокзал кебек синең йөрәк —
Кереп чыкмаганнар сирәк...

*1961*

## Шундыйлар

Бер күрәсең — киләләр пычакка-пычак,
Бер күрәсең —
киләләр кочакка-кочак...

*1961*

## *Киңәш*

«Тиле!» дисәләр сиңа
күреп юньсез эшеңне,
Акланма син, күрсәтеп акыл тешеңне...

*1961*

## *Китә микән?*

Пыр тузынып, дулап, хатын
Аерылып китеп бара:
— Мин юкта тилгән алмасын,
Чебешләрне яхшы кара!..

*Сентябрь, 1959*

## *Ике ут арасында*

Каенана һәм килен талаша;
Карап торсаң, хәйран-тамаша,
Сүзләреннән колак камаша...

Каенананың улы да — мин,
Килененең ире дә — мин,—
Нишли алам бирерә мин?!

*Июль, 1958*

## *Буш бармаклар*

Бармак саен алтын балдак,
Гел балкып-балкып бара.
Кысан балдак, кысыр бармак —
Җитәкләсәче бала...

*1988*

## «Өйгә кайткач»

Кибет янында өч кеше
Бер яртыны салып тора.
Милиционер килеп шунда
Усал гына тамак кыра:
— Һей, ярамый!
Өйгә кайткач.
Өйгә кайткач...

Бер сәрхуше, бугаз ертып,
Үзенчә җыр сузган итә.
Кай әмәлдер, каш җыерып,
Милиционер килеп җитә:
— Һей, ярамый!
Өйгә кайткач.
Өйгә кайткач...

Артта калган бер аңсызы
Кул күтәргән хатынына.
Килеп чыга милиционер,
Әйтеп куя каты гына:
— Һей, ярамый!
Өйгә кайткач.
Өйгә кайткач...

*Август, 1960*

## *Өйдә бөтен шартлар туган*

— Өс-башың кара йөрисең,
Кайнар аш күрми йөдисең...
Адәм рәтле торыйм, дисәң,
Юньле тормыш корыйм, дисәң,
Йөрмә син, өйләнеп җибәр! —
Дусларым гел шулай диләр.

Тыңладым алар киңәшен —
Бар өйдә япь-яшь кәләшем.
Чәем кайнар, тәмле ашым,
Яшәмим мин ялгыз башым.
Күлмәкләрем чиста — юган,
Өйдә бөтен шартлар туган.

Хатын тәртип сөя, нишлим —
Бөтенесен үзем эшлим...

*Ноябрь, 1961*

## *Характер шундый минем...*

Күрсәм эштә хаксызлык,
Йә берәр җавапсызлык,
Беркемгә тынгы бирмим —
Характер шундый минем!

Кайткан чакта урамда
Бер-бер хәл булганда да
Читләтеп үтә белмим —
Характер шундый минем!

Өйдә кысам койрыкны,
Хатын бирә боерыкны,
Беркайчан каршы килмим —
Характер шундый минем...

*1968*

## Хатынга булышам

Яңа мәсьәлә түгел бу,
Ирләргә күптән таныш:
Өйдә, булышмыйсың, диеп,
Куптарды хатын тавыш.

Беләм анысы, йорт эше дип,
Сүздә җиңел әйтергә,
Нинди конкрет ярдәм белән,
Ничек җиңеләйтергә?

Игътибарсыз булганмын шул,
Үзем дә кире беткән.
Уйладым да, менә ниләр
Алып кайттым кибеттән:

Кишер турагыч машина,
Суган турагыч машина,
Кер юу машинасы,
Идән шомарткыч машина,
Оек ямагыч машина,
Ит тарту машинасы,
Күкәй язу машинасы,
Пилмән бөгү машинасы,
Борыч ваклагыч машина,
Инә саплагыч машина
Һәм тегү машинасы,
Бәрәңге әрчү машинасы,
Җиләк сыгу машинасы,
Тузан суырткыч машина,
Һава дымлаткыч машина
Һәм дә чәч машинасы!

Борынгы әбиләр кебек,
Нигә җәфа чигәргә,
Бүгенгесе көндә кирәк
Техниканы җигәргә.

Моннан соң инде хатыным
Иркенләп сулыш алыр,

Үз өстендә эшләргә дә
Шактый вакыты калыр.
Хатын әйтә: — Рәхмәт, эшләр
Җиңеләя бара,— ди,—
Әмма бераз булышсаңчы,
Кулларым бик тала,— ди.

— Дөрес! — дидем, ничек бу уй
Килмәгән соң башыма?
Алып кайттым кулга массаж
Ясый торган машина!

*Февраль, 1966*

## «Оча торган тәлинкәләр»

Төрле сүзләр
Йөргән иде
Шушы хакта.
Хәтта бәхәс
Купкан иде
Матбугатта.

Ул вакытта
Әкият дип
Көлдем генә.
Инде үзем
Ничә тапкыр
Күрдем менә...

Күрше абзый
Эчеп кайта;
Шул чагында —
Тәрәзәдән
Тәлинкәләр
Оча гына!

*Гыйнвар, 1970*

## Ачы тәҗрибә

Хатын:
— Өйләнгәнче син һәрвакыт,
Гүзәлем, җаным, дидең.
Тәмле сүзләр күп сөйләдең,
Шикәрем, балым, дидең.
Әллә инде үзгәрдең —
Бетте андый сүзләрең...

Ир:
— Әле хәзер дә җаным син,
Шикәрем син, балым син,
Тик гаепкә алмачы:
Күпкә китсә — бал да ачы!..

*1962*

## Ул-бу булмагае...

Көн дә эшкә бара икән,
Икеләнеп кала икән:
Алай итсәм? Болай итсәм?..
Хәл кылыныр әле иртән —
Ул-бу булмагае...

Кызлар көлеп караса да,
Киметмәгән уяулыкны —
Ришвәт диеп әйтерләр дип,
Кире биргән кулъяулыкны —
Ул-бу булмагае...

Гомергә бер тәвәккәлләп,
Гомергә бер ялгышмаган,
Карышмаган, ярышмаган,
Танышмаган, кавышмаган —
Ул-бу булмагае...

*1967*

## *Бәхетле билет*

Яңа елларның
Иң кызыклысы
Кайсы — кем белсен?
Әмма гомергә
Онытмам берсен....

Шулай бер дуска
Мин автобуста
Мәҗлескә барам.
Гадәттәгечә
Билет та алам
Һәм күз дә салам.
Раслаган кебек
Минем теләкне —
Бәхетлесе бит
Килеп эләкте!
Бара торгачтын
Хыялга чумып,
Китә язганмын
Хәтта ки узып!
Торсам ашыгып,
Төшсәм сикереп,
Бер чибәр тора
Билет тикшереп...
Әллә нигә мин
Каушабрак калдым,
Билет та бар бит,
Алдым бит, алдым,
Кайда соң, кайсы
Кесәмә салдым?

Усал елмаеп,
Контролер көтте,
Көтте-көтте дә
Баш чайкап китте...
Ә мин актардым,
Эзләдем, таптым!
Һәм... Автобусның
Артыннан чаптым.

Күрде кешеләр,
Көлде кешеләр:
— Очраса чибәр
Тикшерүчеләр,
Булгалый мондый
Йөгерүчеләр!..

Әйе, мин чабам
Күпме бар чама,
Әмма автобус
Иплерәк бара!
Куып карадым
Троллейбус белән,
Трамвайлар белән,
Такси белән дә,—
Кузгала китә,
Җиттек дигәндә!

Тик үзем бер дә
Өметне өзмим,
Мәҗлес онтылды —
Контролер эзлим.
Шактый йөргәчтен
Күрәм һәм таныйм,
Туктагызчы, дип,
Эндәшеп карыйм.
Әйләнеп тә бер,
Ичмасам, бакмый,
Чак-чак иярәм,
Бик җилле атлый!..
(Чү әле, хатын,
Аякка басма,
Күптәнге хәлне
Сөйлим ләбаса!)
Әйе, туктагыз,
Чапмагыз, дидем,
Карагыз, дидем,
Билетны бирдем...
Һәм син туктадың,
Һәм без аңлаштык,

Яңа ел белән
Әле котлаштык!

Икәүләп уттек
Еллар арасын...
Юк, ансын әйтмим,
Төртмә, анасы!
Әйтмәкче булам
Инде дә килеп —
Тәки бәхетле
Булды ул билет!
Киңәшем шушы,
Колак салыгыз;
Һәрвакытта да
Билет алыгыз!

*1969*

## Күршең белән тату торасыңмы?

— Күршеләрең ничек? — дисәң,
Ул әйтер сиңа көлеп:
— Күршеләрме? Күршеләрем
Нәкъ туганнарым кебек!

— Туганнарың ниндирәк соң?
— Ә, туганнарым, димсез,
Нәкъ күршеләрем шикелле —
Туганнар минем юньсез!

*Декабрь, 1968*

## Бер балл

Сөмсере коелып кайтты кыз:
Шешенгән күзе,
Башын түбән иеп тора,
Әйталмый сүзен...

Институтка этисе
Шунда ук чапты,
Барды, сорашты, тиешле
Кешесен тапты:

— Авыл кызы дипме, аны
Нигә алмадың?
— Андыйлар бар, бер ул гына
Читтә калмады.

Күп киләләр монда миңа,
Имеш: ал да ал.
Синең кыз да үтәр иде —
Җитмәде бер балл.

— Һай, рәхмәт төшкере, нигә
Әйтмәдең алдан,
Эш шуңар терәлгән икән,
Тормабыз балдан! —

Нургали институттан
Чыкты да чапты,
Бер тәпән бал алып килде,
Тегене тапты...

— Ишеткән идем лә,— ди ул,—
Була дип җайлап,
Тик белми идем, бал белән
Була дип майлап...

*Август, 1956*

## Үзебезнең...

Кыз тугач сөенде агай:
— Сөбханалла — йөзләрендә
Иман нуры,
Үзебезнең иман нуры!

Кыз — кияүдә, оныкк туды:
— Боже ты мой — йөзләрендә
Иван нуры,
Үзебезнең Иван нуры!

*1986*

## Үз байлыгы

Мактап ире
Хәләленә
Болай диде:
— Яшьлектәге
Карап туймас
Куанычым!
Картлыктагы
Колач җитмәс
Ю а н ычым!

*Октябрь, 2000*

## Гыйбрәт

Яшьлек белән
Мактанма —
Яшьлек калган
Карттан да!

*Декабрь, 2000*

## Бер яшьлектә, бер картлыкта

Яшь чагымда
Тезләремә
Кыз утырды —
Рәхәт иде!
Картайгачтын
Тезләремә
Тоз утырды —
Зәхмәт инде!

Яшь чагында
Кызлар янда
Күз уйнаттым.
Хәзер инде
Читләп үтәм
Сүз уйнатып.

Без көләбез:
Бер — яшьлектән,
Бер — картлыктан.
Ярый әле
Шуклык атлы
Шул шатлык бар!

*Февраль, 1997*

## Яшем...

Яшем миннән алда йөгерә —
Куып җитә алмыйм гел генә.
Елатырга, картлык, ашыкма,
Балачагым әле көлдерә!

*Октябрь, 1997*

## «Яшь» диеп сана

Карт түгел әле,
Без — өлкән генә,
Гомеремдә бу
Бер өлкәм генә.

Абый, дип кенә
Мөлаем эндәш —
Нечкәрә күңел,
Күзләремдә яшь.

— Ничә яшь? — дисең,
Яшь диеп сана —
Бер дә карт түгел,
Күздән яшь тама!

*Декабрь, 1999*

## Бакчада йөри бер бабай

Бакчада йөри бер бабай
Ияртеп чибәр кызын.
Барып сүз дә кушар хәл юк,
Калдырмый бит ялгызын!

Утка килгән күбәләктәй
Әйләнәм кыз катында.
Карт шунда таяк күтәрә:
— Тимә минем катынга!..

*Октябрь, 1959*

## Төрле караш

Яшь кыз:
— Алтын тешләр булсачы,
Балкып кына торсачы!

Әби:
— Алтыннары корсачы,
Үз тешләрең булсачы!

*1964*

## Камашу

Язгы көндә кайтып керә
Әби урамнан —
Карлар якты, чагылдыра,
Күз тышта калган.

Бабай елмая, күзлеген
Кулына алган —
Чибәркәйләр камаштырган,
Күз кызда калган!

*1989*

## Ярату нишләтми...

— Үз ишеңне тапмадыңмы,
Бик карт ирең!
— Яраттым шул, бик ошаттым...
Квартирын.

*1958*

## *Озак яшәүнең сере**

Җавабын фән табасы
Сорауларның шул бере:
Нәрсәдәрәк икән соң
Озак яшәүнең сере?

Күрше бабайга кердем,
Көйләп бер сәлам бирдем,
Ике куллап күрештем,
Хәл-әхвәлен белештем.
Соравымны тыңлагач,
Болай диде бабакай:
— Озак яшәүнең сере
Татулыкта, балакай.
Әбиең белән бергә
Яшибез җиде дистә,
Сүзгә килгән юк һич тә.
Тиргәшкән дә юк, шөкер,
Әрләшкән дә юк, шөкер,
Ачу килгән чакларда
Эндәшкән дә юк, шөкер!
Сүз куештык өйләнгәч,
Без бик ныгытып кына:
Беребез тузынганда,
Беребез чыгып тора.
Менә әле бүген дә
Ул тузына тегендә...
Үтте ярты гомерем
Шушы капка төбендә.
Ә бит монда нинди тын,
Каймак кебек саф һава.
Ә саф һава, беләсең,
Организмга дәва!

...Бу сүзләрдән сез шуны
Төшенергә тиешле:
Озак яшәүнең сере
Шаянлыкта, кәнишне!

*Гыйнвар, 1968*

* Сайдә Вәлиди музыкасы.

## Бәрәңге турында

*Күренекле селекционер*
*Александр Георгиевич Лорхка*

Бер карасаң — сугыш чоры
Сагынырлык елларсмы,
Бигрәк тә мәзәккә урын
Табылырлык елларсмы?

Хәвеф-хәтәрне ул көннәр,
Әйе, аз китермәде,
Әмма иңне иңдерсә дә,
Башларны идермәде!

Кайгылар кара булсалар,
Өметләр якты иде,
Үткәннәр юк та, киләчәк
Гел безнең яклы иде!

Ипи эләкмәгән икән,
Бәрәңге тиде әзрәк.
Бәрәңге беткән чакта да,
Бетмәде бездә мәзәк!

«Бу дөньяны авыр, диләр,
Кем күтәреп караган!..»
Шулай дидек, ә бәрәңге,
Имеш, болай юраган:
«Иртә дә мин,
Кич тә мин,
Учакта мин,
Мичтә мин,
Чыдый алмыйм
Һич тә мин,
Асылынам
Кичтә мин...»

Мәзәк иде бу, ә чыны
Башкача килеп чыкты —
Дошманнар элмәккә керде,
Бәрәңге җиңеп чыкты!

...Яз иде, көннәр җылынган,
Юрганны илтеп саттык...
Һәм ниндидер бер «лорх» дигән
Бәрәңге алып кайттык.

(Юрганга карап аякны
Сузасылар калмады!
Аякларны суза идек —
Шул бәрәңге ялгады...)

Җир тулып уңды яңа сорт,
Бик тиз таралды даны.
Соңрак белдем, мәгълүм галим
Лорх тапканын аны.

Лорх бабай иҗатына
Бик күбебез бурычлы.
Шул җимешкә тоташкан бит
Шигъремнең дә бер очы.

Гадилектә ул да шуның
Кебегрәк булсын иде,
Халыкка бәрәңге кебек
Гел кирәк булсын иде!

*Август, 1970*

## Тормыш тозы

Гадәти күк тоелса да
Болай карап торышка —
Ансыз яшәп булмый торган
Нәрсәләр бар тормышта.

— Икмәк! — диярләр хатыннар,
— Су! — диярләр яшь кызлар.
— Икмәк белән су...— диярләр
Дуадаклар — ярсызлар.

Өйләнгәннәр: «Хатын»,— дияр,
Бездәйләр: «Кыз!» — диярләр.
Башкалар ни диярләрдер,
Бабайлар: «Тоз...» — диярләр.

Тормыш әйбәт, имин була
Һәрвакыт ул барында.
Күрдек аның юк чагын да,
Без сугыш елларында.

Тормыш тозы нидәлеген
Белдек шул вакытларда,
Тоздан агарды аркалар
Тылда һәм окопларда.

Сез күрмәдегез, димим мин,
Бик җиткән без күргән дә,
Тик ачысын онытмагыз,
Тәмнәр татып йөргәндә.

Аңла син ул заманны да,
Тозсыз сүздән арала,
Кайчагында тозсыз сүз дә
Тоз сала бит ярага...

Һәр кешенең тозы була,
Була, ягъни мәгънәсе,
Сер түгел, тозсыз да була
Кайбер хода бәндәсе...

Ә тормыш — тозлы тир түккән
Җир уллары кулында.
Җирдә иң кирәк тә шулар —
Сүземнең тозы шунда!

*Сентябрь, 1971*

## *Бабай сүзе*

Склероз ул бик файдалы,
Әллә шуны белмисең —
Карт икәнеңне онытып,
Гел яшьләрчә йөрисең!

*1988*

## *Бабай зары*

Нишләтим бу яшьлегемне,
Сикерә дә чыга бит,
Алга узып, аяк чалып,
Картлыгымны ега бит!

*Май, 1998*

# Бала тәрбияләү тәҗрибәсе

## *Куаныч*

Мотыйк килә урамнан,
Марля белән уралган.
Үзе шундый кәефле,
Үзе шундый куанган!

Бер елмаеп җибәрсә —
Авызын җыеп алалмый,
Бер сөйләргә керешсә —
Сүзен тыеп калалмый:

— Ай-һай, гайрәт, ай-һай, дәрт,
Малаемнан чыгар рәт!
Сыек дип белгән идем,
Сыныйк дип көлгән идем,

Әй алды да бөтереп,
Әй салды бер китереп,
Торалмаслык иттереп,
Тын алмаслык иттереп!

Мотыйк йөри шатлыгын
Кеше саен өләшеп.
«Шундый улың булса!..» — дип,
Без карыйбыз көнләшеп.

*Гыйнвар, 1971*

## Кибеттә

— Бәләкәй ич бу ботинка! —
Дип әйтәләр агайга.
Ачыклап бирә агай да:
— Үземә түгел, малайга!

Биш ел узгач:
— Ник бу зурны
Алдың? — диләр агайга.
Елмаеп куя агай да:
— Үземә түгел, малайга!

*1965*

## Әнкәй белән бәхәс

Һәркемнең дә бит үзенә
Бик кадерле баласы,—
Җай чыкканда, иплэп кенә
Килә бер мактанасы.

Минем әнкәй дә бу эштән
Азат түгел, әлбәттә,—
Мин акыллы, мин тәүфыйклы,
Мин уңган да, әйбәт тә...

Мин мактыйм үз малаемны:
— Ипләбрәк карачы, дим,—
Яхшы яклары күбрәк бит,
Замана баласы, дим.

Әнкәй тагын үзенекен!..
Мин дә тормыйм аптырап:
— Ни әйтсәң дә, минем малай
Синекеннән яхшырак!

*Ноябрь, 1968*

## Юылган сөт...

Тузга язмаганны сорап,
Бер малай аптырата:
— Мондый сөт эчәсем килми,
Сөтне юып бир, апа!

— Кайда күрдең сөт юганны,
Әйтәсең каян алып?!
— Фермага баргач, үзең бит
Юдың сөтне су салып!

*1974*

## Әни кушканча...

Озатканда кызын ана
Үгет-киңәш бирә аңа:
— Инсаф белән генә йөр,
Тәүфыйк белән генә йөр!

Хатларга да язып сала,
Кайткачтын да әйтеп кала:
— Инсаф белән генә йөр,
Тәүфыйк белән генә йөр!

...Ана сүзен тота кызы,
Йөрми кичен һич ялгызы:
Беркөнне ул —
Инсаф белән,
Иртәгесен —
Тәүфыйк белән!

*Октябрь, 1967*

## *Юатылар*

Улы армиягә киткәч,
Кереп күрше апалар,
«Кайтыр, кайтыр,
кайгырма!» — дип,
Әнисен юаталар.

Кызы кияүгә киткәч тә,
Керә шул ук апалар:
«Кайтыр, кайтыр,
кайгырма!» — дип,
Әнисен юаталар...

*Март, 1967*

## *Урманчы Былтыр...*

Яши аулакта
Ул тыныч кына.
Авылда бер кыз
Былтыр кочканга
Быел кычкыра:
Җылый баласы,
Кая барасы?!

*Июль, 2000*

## *Буыннар*

Өлкәнәя кеше —
Сызлый карт буыннар.
Ни кызганыч, бүген
Яшь буын өчен дә
Сызланыр урын бар.

*Декабрь, 2000*

## Качышлы уйный Касыйм

### 1

Качышлы уйныйлар
Атасы, баласы,
Бер читтән, сөенеп,
Күзәтә анасы.
Һай, эттәгенәсе,
Кача бәбкә генәсе,
Эзли эттә генәсе.
Ары да чаба ул,
Бире дә чаба ул,
Кире дә чаба ул,
Эзли дә таба ул.

### 2

Һай, эттәгенәсе,
Кача эттә генәсе,
Эзли бәбкә генәсе.
Анда юк, монда юк,
Ничек соң табасы?
Тапмагач баласы,
Кушыла анасы.
Һай, эттәгенәсе,
Эзли милициясе,
Кайда эттә генәсе?..

*Август, 1963*

## Һашим

...Һашим әле кечкенә,
Тешләре дә өч кенә.
Өсте-башы килбәтле,
Иреннәре ширбәтле.
Уйныйм дисә, уен бар,
Атланырга муен бар...
Үчти-үчти иттер, ди,
Абажурга җиткер, ди;
Кичен дә, иртәсен дә —
Әтисе җилкәсендә!
— Бераз иркәрәк бугай...
Әмма сүз әйтеп торырга,
Юкка кәефен кырырга,
Әле иртәрәк бугай.

...Һашим инде мыеклы,
Бүрекләре кыеклы.
Эчкәннәре шәрабтыр,
Кыланышы хараптыр:
Аза-туза, типтерә,
Типтерә дә сиптерә.
Ал иттең, гөл иттер, ди,
Укыттың — ял иттер, ди;
Кичен дә, иртәсен дә —
Әтисе җилкәсендә...
— Бозылуы чын бугай...
Әмма сүз әйтеп торырга,
Колакларыннан борырга
Хәзер инде соң бугай...

*Март, 1961*

## Тәмәкенең файдасы

Мин тәмәке тартмадым,
Шуңа күрә артмадым.
Тәмәке тарта башладым,
Әзрәк арта башладым.
*(Халык мәзәгеннән)*

Белеп җиткерәсез микән
Тәмәкенең файдасын.
Тәмәке тарткан кешенең
Тормышлары җай да соң!

Андыйларны эт таламый —
Ул яктан юк куркыныч;
Өенә керми караклар —
Бу яктан да гел тыныч!

(Эт таламый, чөнки алар
Таяк таянып йөри;
Төнлә йөткереп яткачтын,
Өйгә карак та керми...)

Тагын шунсы бигрәк мөһим —
Картаймыйлар андыйлар.
(Картаймыйлар, чөнки алар
Озак яши алмыйлар...)

Менә инде күрдегезме
Тәмәкенең файдасын.
Тәмәке тарткан кешенең
Тормышлары җай да соң!

*1964*

## *Кыскарта*

«Тәмәке юл кыскарта» дип,
Син аңа юлдаш булдың.
Кыскартуы дөрес инде —
Кыскарта гомер юлын!

*Гыйнвар, 1988*

## *Уздырган...*

Хәйран калдым бер абзыйның
Зип-зифа буен күреп:
Үз корсагыннан качалган
Ул җәй буе йөгереп!

*Февраль, 1977*

## *Сөлек кебек...*

Бигрәк инде
Чибәр егет,
Сокланмыйсың
Ничек күреп.
Чибәр егет —
Сөлек кебек!
Сөлек кебек!

— Кайда эшли
Егетегез? —
Дип сорадым.
Ник сорадым?
Яши икән
Сөлек кебек,
Сөлек кебек...

*Июль, 1968*

## Яхшы мөгаләмә

Мин үзем дә нәзакәтле,
Малайны да өйрәтәм:
— Мөгамәләң һәр вакытта
Әйбәт булсын, минәйтәм.

Әдәп белән эндәшергә
Кирәк һәрбер очракта —
Мондый чакта болай диген,
Болай диген бу чакта.

...Эшне куеп, төзүчеләр
Утыра «кәҗә» сугып.
Минем тәүфыйклы малаем
Китми тик кенә узып:

— Исәнмесез, абыйлар,— ди,—
Армый эшләгез! — дия.
Көлүдән туктыйлар бар да —
Авырткан төшкә тия.

Егет белән кыз үбешә...
Күрмәстер дисәм бусын,
Кул болгап кычкыра улым:
— Ашыгыз тәмле булсын!

Әнә җәнҗалчы егетне
Дружинник алып бара.
Улым аңарга елмаеп:
— Рәхим ит! — диеп кала.

— Тыныч йокы! — диеп үтте
Каравылчы агайга.
Көпә-көндез уятырсың,
Шаулама, дим, абайла.

Болай булгач, була инде,
Ярыйсы маташтыра.
Әмма кайчан, ни диясен
Әз генә саташтыра.

*Гыйнвар, 1969*

## Бала тәрбияләү тәҗрибәсеннән

— Нәрсәдән башларга икән?
Туктагыз, болай итик —
Иң элек егет чакларга
Бераз тукталып үтик.

Туй узган, тун тузып бара,
Сөйләп бирим дөресен —
Кузгатылган мәсьәләгә
Кагылган кадәресен...

*

Бәлкем, әти мактангандыр:
«Минем балам — ут!» — диеп,
Башкалар кул селти иде:
«Беләм — баламут!» — диеп.

Яшерен-батырын түгел,
Әйләндем дә тулгандым,
Кем «сала» да усаллана —
Шул тирәдә болгандым.

Әйтәләр иде, теленә
Шайтан төкергән, диеп,
Кәләш таба алмас, диеп,
Юньле көн күрмәс, диеп.

Ә мин үзем, эчтән генә,
Башкача теләп йөрдем —
Илебездәге иң әйбәт
Бер кызны эләктердем!

Тормышның бик кирәк ягын
Куйды хатын тигезләп:
Тугыз ай тулыр-тулмаста
Алды-кайтты игезәк!

Билгеләп үттек шатлыкны,
Ду килеп, тиешенчә;
«Юмаган» җире калмады,
Бар да булды кешечә!

Исем куштыру дигәндә,
Беркем уздыра алмас —
Таптым иң-иң әйбәтләрен:
Кыз — Энҗе, малай — Алмаз!

Тагын игезәк булса да
Аптырап-нитеп калмам —
Запаска Мәрҗән, Зөбәрҗәт
Әзерләп куйдым алдан.

Ул да булгач, кыз да булгач,
Ышанмаучылар тагын:
Ерып чыгалмас, диделәр,
Тәрбия бирү ягын.

*

Әйе, үсәләр балалар.
Мин йөрим караштырып,
Ниндирәк тәэсир ясарга
Заманга яраштырып?

Көннәрдән бер көнне шулай,
Күземне ачсам иртән —
Исерек булып, малаем
Килә бит алпан-тилпән!

Кесәсенә шешә тыккан,
Папиросын да тапкан,
Тәмәкеле ягы белән
Берсен алып та капкан.

Сүзләрнең дә ычкындыра
Китап кушмый торганын.
(Истә шул сүз өчен эти
Колагымны борганы...)

Ятам гырылдаган булып,
Йоклаганга салышып,
Ятам керфек арасыннан
Хәлләр белән танышып.

Шул көннән соң Алмазымны
Тәрбияли башладым:
Беренчедән, ун ел имгән
Тәмәкене ташладым;

Икенчедән, аракыны
Чамадан тыш капмадым.
(Акча алган көннәрдә дә
Дүрт аяклап кайтмадым.)

Өченчедән, сөйлим хәзер
Тәртипле сүзләр генә.
Әнә шулай мәҗбүр иттем
Малайны үзгәрергә!..

*

Ярый, хуш, инде керештем
Энҗене күзәтергә.
Күрәм, кайбер сыйфатларын
Кирәк бит төзәтергә.

Хуҗалыкта берүзенә
Эш бик күп әнисенә,
Ә булышу дигәнне кыз
Кертми бер дә исенә!

Керсен дип моннан соң кызый
Иплəп кул арасына,
Ике җиңемне сызганып
Керештем чарасына:

Беренчедән, ашап-эчкәч,
Савыт-сабалар юам;
Икенчедән, оек ямыйм;
Өченчедән, кер уам.

Кызым да хәзер булыша,
Йөзепме йөзә генә,
Мәҗбүр иттем бит монсын да
Шәп якка үзгәрергә!

Нәтиҗәдә тәмам бетте
Андый-мондый гадәтләр.
Хәзер кыз да, малаем да
Үзем кебек әйбәтләр!

Әгәр дә мәгәр тәртипсез
Булса сезнең балагыз,
Минем тәҗрибәдән чыгып
Тәрбияләп карагыз!

*Декабрь, 1963*

# Каз ашады башымны

## *Халык әйтсә — хак әйтә*

Җәйнең тын кичләрендә
Бүрәнә өсләрендә
Җыелышып утырулар,
Сөйләшеп утырулар...
Кем янса нәрсә өчен,
Нәрсә пошырса эчен,
Сүз иярә сүз китеп,
Сөйли шуны үз итеп...

Башлап китте Гаптери:
— Председательгә аптырыйм;
Сайлап куйган чагында
Карадык ул ягын да —
Эчмәгән дә шикелле иде,
Эшләгән дә шикелле иде.
Врачлар да кушмый, дип,
Юк белән булышмыйм, дип,
Эчмәде туенда да,
Кертмәде уена да.
Әйләнеп тә карамый —
Йөрәккә, ди, ярамый.

Башта ул шулай иде,
Хуҗа иң кулай иде.
Ә аннары бозылды —
Гел шешәгә сузылды.
Ярамаулар кайда ул,
Йөрәккә, ди, файда ул.

Эчә ул базарда да,
Кибеттә-мазарда да,
Стаканга салып та,
Муеныннан алып та.
Эчә суган тешләп тә,
Эчә бүрек иснәп тә.
Йөгерә ул кунакка,
Пышылдауга колакка.
Чакыра аны Хәбир дә,
Күпер төбе Кәбир дә,
Арт урамнан Сафи да,
Түбән очтан Гафи да.
Йөреп чыга барсын ул,
Юк тартыну-тарсыну...

— Эх, җәмәгать,— ди Гата,—
Эче пошып сүз ката,—
Мондый хуҗа хуҗамы,
Хуҗа түгел, нужа ул!
Эчә дигәч тә әллә,
Үз малын эчә мәллә?
Күптән түгел, мәсәлән,
Йорт сипләтте Мөсәләм,
Күз алдында, күр әнә —
Колхозныкы бүрәнә.
Йөзәр граммлап тотты —
Хәй бүрәнәне йотты!
Йота ул үгезен дә,
Күрмисең мөгезен дә!
Пичәт барында, ди ул,
Эшлим барын да, ди ул.

...Җыелыш булды.
Кыскасы —
Очты эчү остасы!

*Июль, 1955*

## *Җитешмәгән шөрепләр хакында*

Кулга шактый акча бирделәр,
Зинһар, запчасть тапчы, диделәр.
— Булыр,— дидем, тыйнак йөткереп.—
Без өйрәнгән инде күп йөреп.
Кайтырбыз,— дим,— эшне пешереп —
Шөреп-мазар кулга төшереп!

Базадагы дусны күрдем мин,
Ресторанга алып кердем мин,
Майламыйча запчасть купмый ла!
Төшерергә рәис кушты дип,
Сыйлыйм әле яхшы дусны дип,
Кунак итә торгач шатлыктан,
Бераз гына киткән артыкка.
Калганнарын белдем актыктан,
Калганнарын белдем акттан...

...Дустым шәбен табар, дигәнмен,
Бүрегемне җиргә бәргәнмен.
Урамда баш белән йөргәнмен...
Цирк гөмбәсеннән шуганмын!
Машиналар күрсәм, куганмын —
Көпчәкләрен алмак булганмын...
Кием кибетенә кергәнмен,
Калган акчаларны биргәнмен:
— Бир хатынга запчасть! — дигәнмен.
Аңа бүрек, пальто алганмын,
Алганмын да үзем кигәнмен...
Зоопаркка җитеп үрмәләп,
Маймыл читлегенә чүгәләп,
Без мәңгегә бергә, дигәнмен,
Аркасыннан аның сөйгәнмен.
Көнгерәнең кулын кысканмын.
Аюга честь биреп үткәнмен,
Бегемотны барып үпкәнмен,
Тәмам онтылмаслык иткәнмен —
Жираф муенын төйнәп киткәнмен...

Боларны мин белдем актыктан,
Рәис кулындагы акттан.
Һәммәсен дә искә төшереп,
Чыгарды ул мине пешереп:
— Йөри торгач шактый төшереп,
Төшеп калган синең бер шөреп!..

Монысын инде каян табасы —
Димәк, тагын эзләп чабасы...

*Октябрь, 1970*

## *Бергәләп тотыйк*

Акчаны урлый,
Вакытны урлый,
Саулыкны урлый,
Шатлыкны урлый!
Тотуын да мин
Тотам да бурны,
Әмма тоткачтын
Җибәрми булмый...

Әллә бергәләп
Тотып карыйкмы
Бурны-каракны?
Тануы ансат,
Табуы ансат,
Һәркемгә мәгълүм,
Ул бит атаклы;
Ул бит — аракы!..

*1967*

## *Каз ашады башымны...*

Бер ата каз бар иде,
Усал эткә пар иде.
Акбайдан ким таламый —
Бот тирәсен чамалый!
Чатыр-чотыр чаптыра,
Чапмас идең, каптыра...
Тарак кебек тешләре,
Бик күп юньсез эшләре.
Ишегеңне тукый ул.
Тәрәзәңне чукый ул.
Шундый азгын, шундый шук,
Җитешмәгән җире юк.
Нишлим, тыя алмагач,
Түзәр әмәл калмагач,
Җитәр, дидем, азарга! —
Алып чыктым базарга.
Хак сорадым аз гына,
Китсен мәлгунь каз гына!
Саттым, дидем, котылдым,
Тагын килеп тотылдым...
Качты яңа хуҗадан!
Аптырагач, нужадан,
Эт чылбыры алдым мин,—
Аягына салдым мин.
Дәрт-дәрманын чикләдем,
Кар базына бикләдем.
Каз кычкыра: — Га-га-га!
Ә мин көләм: —Ха-ха-ха!
Өздең мәче койрыгын,
Шушы булыр боерыгым!
Бераз тузан йот әле,
Күсе-тычкан тот әле!
Чи бәрәңге кимергәч,
Әйбәтләнгәч, симергәч,
Суеп бәлеш ясармын,
Башыңны, дим, ашармын!

Кичкә табан карасам,
Йоклап ята хөрәсән!
Кыланырга белгән бу!

Хатын әйтә: — Үлгән бу...
Кем каз яба базга соң,
Каз башына азгансың!..

— Холкы булды алама,
Инде син дә талама.
Китер, атыйм чокырга!

— Кирәк башта йолкырга.
Хатын вакыт уздырып,
Утырды йон туздырып.

Бер карасаң, кызганыч,
Мескен, аяк сузган ич...
Муеннары тырпайган,
Канатлары кылтайган,
Ачкан, мәрхүм, авызын,
Явыз иде явызын...
Казны ярга тондырдым,
Шөкер, җанны тындырдым!

Каз кебек канатланып,
Кайттым өйгә шатланып.
Әйтәм керә-керешкә:
— Хатын, чыгар көмешкә!

Хатын әйтә: — Кем эчкән?
Беткән монда көмешкәң!

Карыйм базга төшәм дә,
Каз йоннары шешәмдә!
Бер дә тузан йотмаган,
Тычкан-мазар тотмаган,—
Көмешкәне чөмергән...
Булмаган хәл гомергә!

Хатын әйтә: — Җүләр,— ди,—
Әйтсәң кеше көләр,— ди.—
Сылтамый тор казга,— ди,—
Үзең йөрдең базда,— ди.—
— Хафаланма, анасы,
Кайнатырбыз яңасын!

Иртән китә кем эшкә,
Мин кайнатам көмешкә.
Базга төшеп посуым,
Тустаганлап сосуым!
Кинәт тышта: — Ха-ха-ха!
Каз тавышы: — Га-га-га...
Шардай булды күзләрем,
Онытылды сүзләрем,
Дөнья китте айкалып,
Казым кайта чайкалып!..
Шыр ялангач бар төше,
Ятып көлә бар кеше.
Менә сиңа кыяфәт,
Менә сиңа кыямәт!
Үлгән казым айныган,
Бар урамны җыйнаган.
Бөтенесе көләләр,
Каз артыннан киләләр.
Юньсез, кайткан көйгә үк
Килеп керде өйгә үк!
Әллә базга төшмәкче,
Әллә тагын эчмәкче?!
Каз артыннан керделәр,
Аппаратны күрделәр...
Яшермичә фактны,
Яздылар бит актны...

Бик күп булды мазасы,
Шул мөртәтнең казасы.
Аш итмәде ашымны,
Каз ашады башымны!..

*Октябрь, 1960*

## Министрлыклар һәм без...

Әсәт агай җыелышта
Кызып чыгыш ясады.
Вакланмады, сүзләрен ул
Масштаблы башлады:

— Махсус министрлык безнең
Сәламәтлекне саклый.
Нигездә, әйтергә кирәк,
Ул ышанычны аклый.

Тамчылап-тамчылап безгә
Дарулар эчерә ул,
«Аракы — агу!» дигәнне
Исеңә төшерә ул.

Ә сәүдә министрлыгы
Үзенчә тәэмин итә —
Тамчылап түгел, яртышар
Литрлап тәкъдим итә.

Уйлап карасаң, чыннан да,
Мәзәгрәк килеп чыга:
Берсе — аякка бастыра,
Берсе — аяктан ега!

Теләсәң нишлә, нәтиҗә
Үзе соралып тора:
Берсе эшен икенчесе
Юкка чыгарып тора...

Кирәк моңа чик куярга,
Күрергә кирәк чара,—
Сүз бит сезнең һәм дә безнең
Саулык турында бара!..

Сөйләвенә кул чаптылар,
Директор да хуплады.

...Кайтырга чыккач,
Әсәтләр
Бер кибеткә тукталды.

Гадәти эш — бу уңышлы
Җыелышны «юдылар».
Нәтиҗәсе дә табигый —
Айныткычта кундылар...

Ошатмады Әсәт абзый
Штрафның зурлыгын;
Бу юлы ул гаепләде
Финанс министрлыгын!

*Гыйнвар, 1970*

## Тиле белән миле

Берсе — тиле,
Берсе — миле,
Ялгыз-ялгыз
Йөри иде.

Бер шешәдә
Кушылдылар, —
Иш булдылар,
Куш булдылар.

Икесе дә
Тигез инде:
Хәзер берсе
Тиле-миле,
Икенчесе
«Ми»ле тиле!

*Март, 1976*

## *Минем кебек беткәнче...*

Кодабызның туган көне,
Күңленә наз тулган көне.
Чокырларга өсти-өсти,
Мине кыстый:
— Килсә дә көч,
Бер генә кич
Беткәнче эч!

Дустым кайткан башкаладан,
Коньягы бар башламаган.
Рюмкаларга өсти-өсти,
Һаман кыстый:
— Якын итсәң,
Карышма һич,
Беткәнче эч!

Баҗай ял йортына китә,
Безне тагын мәҗлес көтә.
Стаканга өсти-өсти,
Ул да кыстый:
— Бер генә кич
Без бергә ич,
Беткәнче эч!

Кияү алган хезмәт хакы,
Өстәлендә ак аракы.
Кружкага өсти-өсти,
Өзеп кыстый:
— Килсә дә көч,
Бер генә кич
Беткәнче эч!

Каениш кайта чалбар алып,
Кесәсенә шешә салып.
Тустаганга өсти-өсти.
Гел-гел кыстый:
— Минем хакка,
Бер генә кич
Беткәнче эч!

Энем лоторейга откан.
Бер сум откан, «ярты» тоткан.
Бер-бер артлы өсти-өсти,
Буып кыстый:
— Килсә дә көч,
Туган итсәң,
Беткәнче эч!

*

Эштән чыкты ашказаным
Һәм таралды башка даным...
Суга сода өсти-өсти,
Сезне кыстыйм:
— Карышма һич,
Җүләр булсаң,
Минем кебек беткәнче эч!

*Сентябрь, 1961*

## *Җир әйләнә...*

Юл өстендә
Ята-ята,
Бер лаякыл
Акыл сата:
— Күрәм, әнә
Җир әйләнә,
Җир әйләнә...

Дружинниклар
Ике якта —
Бастыралар
Ике аякка.
Әйтә янә:
— Ә шулай да
Җир әйләнә!..

*1961*

## Шешәдән чыккан гыйфрит

(Әкият кенә булып калсачы...)

Борын-борын заман түгел,
Борын төбендә генә,
Булган, диләр, мондый хәлне
Ә-әнә тегендә генә.

...Берәүнең күзе төшкән, ди,
Шүрлектәге шешәгә,
Күзе төшүгә шешәгә,
Кулы кергән кесәгә.

Эләктереп алган да ул
Савыт төбенә суккан,
Бөке атылган.
Артыннан...
Гыйфрит тә килеп чыккан!

«Хафалыйсың, җәфалыйсың,
Калмады чыдам, дигән,
Башыңны бетерәм хәзер,
Сугам да егам!» — дигән.

Коты чыккан, ди, тегенең,
Ачылып калган авыз,
Ачык авызга шунда ук
Кергән, ди, гыйфрит, явыз.

Пычрак юлга ауган кеше
Һәм... гыйфриткә әйләнгән.
«Башыңны бетерәм!» — диеп,
Инде үзе бәйләнгән...

Баганалар санап йөргән
Маңгае белән төртеп.
Бозаулар, этләр, дуңгызлар
Качканнар аннан өркеп.

Акырган, ди, бакырган, ди,
Дуамалы арткан, ди,
Рәшәткәләрне кырган, ди,
Тәрәзәләр ваткан, ди.

Алпан-тилпән, апын-төпен
Урамнардан узган, ди,
Әтәчләрне көнләштереп,
Шундый җыру сузган, ди:

«Яңа Бистәнең күпере
Бишбалтага аусайде,
Кабан күле спирт булып,
Күктән пилмән яусайде...»

*

Айнык башлар, уйлый торгач,
Шундый әмәл тапканнар —
Гыйфритне тотып алганнар,
Унбиш көнгә япканнар.

Нык япканнар, ишеге дә,
Биклесен бикле икән,
Тик кешегә әйләнүе
Шикле, бик шикле икән...

...Борын-борын заман түгел,
Борын төбендә генә,
Булган, диләр, мондый хәлне
Ә-әнә тегендә генә...

*1959*

## Хәрам хәрәмләшә...

Елга бер ул сабантуй.
Кемгә көн дә «салган туй»...

Күпме генә көрәшсәң дә,
Аракы өскә чыга,
Күтәреп салуың була —
Аяк чала да ега!

Хәмерле гомер хәрам,
Хәрәмле гомер әрәм...

*Сентябрь, 2000*

## Тигезләштек

Элек «шәһәр» — «кала» иде,
«Авыл» — «сала» иделәр.
Хәзер икесе дә сала —
Тигезләште инделәр...

Берәү куанып кайткан ди,
Шәһәр эчкәнне күреп:
— Аерма беткән, җәмәгать,
Без дә нәкъ алар кебек!

*Июль, 2000*

## Шешәдәш дуслар

Эчкән чакта мәңгелеккә дуслар алар:
«Арабыздан безнең, диләр, җил дә үтми!»
Айнык фикерләрен инде белә калсаң:
«Яшен дә бит сукмый шуны, җир дә йотмый!»

*1956*

## *Замана табышмагы*

«Үзе ура, үзе суга...» —
Ул буладыр комбайн.
Менә бусы нәрсә булыр,
Моның белә кем җаен:
«Урман кисә, китерә,
Печән чаба, киптерә,
Җитмәгәнне җиткерә,
Бәрәңге дә утырта,
Өеңне дә яктырта,
Эшең бармый ул юкта».

Пенсионер картларның
Бик тиз исенә төшәр:
Ул булыр, әйе —шешә!

Менә шундый комбайн,
Аның белән кем баер?!

*Июль, 2000*

## *Тизәйткеч*

(Кызмачалар өчен)

Каба калса,
Кырык градусны,
Таба кырыкмаса
Кырык дусны!

*1967*

## Аерылмас тостлар

Менә, ышан «чын дусларга»,
Мактау тулы тостларга,
Эчелгән тосттай буш бар да —
Дус булганнар постларга...

*1970*

## «Өч борын»чыларга

Аерым-аерым әле —
Мәгънә сез.
Бергә килдегезме —
Мәгънәсез...

*1967*

## Мәрт

Ярты гомер йоклап үтә, диеп,
Әрәм, диеп, берәү үртәлә.
Калган яртысы да ярты белән
Аяк өсте йоклап үтә лә...

*Октябрь, 1988*

## Алкашларга алмашка

Хәмер «ветераны» әйтә:
— Яшьлек таза, яшьлек шәп —
Без каба идек шешәләп,
Болар коя ящекләп!

*Июль, 2000*

## *Гадәт буенча*

Председательнең яңасын яратмый ул:
«Рәт чыкмас, ди, аралашмый халык белән...»
Ә аныңча аралашу була икән —
Салсаң әгәр бер яртыны балык белән...

*1957*

## *Аракы хакында*

«Күз яшедәй тонык» диеп
Соклануың, бел, хата —
Шушы тонык нәрсә синең
Бар дөньяңны болгата!

*1959*

## *Ярты юлда*

Әгәр булса «ярты» кулда,
Эшең калыр ярты юлда.

*1961*

## *Чор чиреме?*

Аек яшәү — лаек яшәү,
Киткән соң кая акыл:
Нужа даруы — аракы,
Чирле чор бу — лаякыл...

*Июль, 2000*

# Шалт Мөхәммәтҗан!

## «*Мөхәммәтҗан уңган кеше...*»

**Элек: «Шалт Мөхәммәтҗан!»***

(Җыр)

Мөхәммәтҗан уңган кеше,
Гөрләп кенә бара эше.
Кай ара акча җыйган бит,
Дача салдырып куйган бит,
Шалт Мөхәммәтҗан!

Туган-тумачаны алып,
Түбәтәен кыңгыр салып,
Ял иткән чакта коньякта,
Уч төбе белән коньякка —
Шалт Мөхәммәтҗан!

Мөхәммәтҗан уңган кеше,
Җырлап кына бара эше,
Министрдан әллә кимме?
Әнә ишеген яба «ЗИЛ»ның,
Шалт Мөхәммәтҗан!

Кешедә аның эше юк,
Чөнки эшләгән төше юк.
Шактый шулай җаен тапты,
Берзаманны килеп капты —
Шалт Мөхәммәтҗан!

*1968*

* Ефрат Хисамов музыкасы.

**Һәм хәзер: «Шат Мөхәммәтҗан!»**

Мөхәммәтҗан уңган кеше,
Гөрләп кенә бара эше.
Кай ара акча җыйган бит,
Коттедж салдырып куйган бит —
Шат Мөхәммәтҗан!

Туган-тумачаны алып,
Түбәтәйне кыңгыр салып,
Ял иткән чакта еракта
Исе дә китми коньякка —
Шат Мөхәммәтҗан!

Мөхәммәтҗан уңган кеше,
Җырлап кына бара эше,
Министрлар аңа тиңме,
Машинасы бигрәк җилле —
Шат Мөхәммәтҗан!

Кешедә аның эше юк,
Беркемдә андый төшем юк.
Шактый йөрде, җаен тапты,
Заманасы аның яклы —
Шат Мөхәммәтҗан!

*2000*

## *Килер заман...*

Өметләндек, хыялландык,
Нинди булыр килер заман?
Кара битлек киеп килде
Гел көтмәгән
«киллер» заман!

*Гыйнвар, 1999*

## Безнең заман

Чик белмәс,
Шик белмәс
Адәм акылы:
Салават күпере аркылы
Галәмгә аша —
Айга аяк баса.
Өстән генә карый
Үткәненә —
Күтәрелә,
Күтәрелә!
Ниләр булыр алга табан —
Менә шундый безнең заман!

Чик белмәс,
Шик белмәс
Адәм актыгы:
Оят качкан,
Азган, шашкан,
Илергән, тилергән,
Шашына
Үз башына.
Җир шары чыдармы,
Сират күперен чыгармы...
Ниләр булыр алга табан?
Менә шундый безнең заман:
Бер очы — күктә,
Бер очы — чүптә...

*Март, 2000*

## Тәҗрибә уртаклашу

Әйткән ди бер
Үрмәкүч:
«Кайда хәйлә —
Шунда көч!»

*1962*

## Дәлил

Үгез сәерсенә икән:
«Ник этләр этләшәләр,
Ник яманлык эшләшәләр,
Ник һаман тешләшәләр?!»

Этләр җавапка ыржая
Күрсәтеп теш казнасын:
«Үгезләр хәленә калып
Сөзешергә язмасын!»

...Ике хуҗага бәхәсне
Акыллы чишү калды.
Дәлил итеп алар шундук
Казык суырып алды...

*Октябрь, 1989*

## Акыллы булсаң...

Хакыйкать бу
Өч сүзлек:
«Көч куллану —
Көчсезлек!»

*Сентябрь, 2000*

## Дошман елмаюы

Гел кара коелыр иде,
Гел зәһәр тоелыр иде,
Нигә яктырган дисәм,
Көлеп кул бирде дисәм,—
Грипп йоктырган икән!

*1989*

## Шәкүр язмышы

Яхшы атлар урлап та ул
Чыга икән яман ат.
Гасыр буена сөйлиләр
Кем хуплап, кем яманлап.

Атка ябышкан шүрәле
Хәлендәдер Шәкүр дә —
Атлар заманнан китсә дә,
Калган бит ул хәтердә.

Ихтыяри-мәҗбүрилек
Шәкүрдәнмени калган?!
Ул сайлап кына урласа,
Колхоз бит рәттән алган!

...Ике улы бар Шәкүрнең,
Зур-зур эшләр майтарган —
Әтисе «алып торганны»
Икеләтә кайтарган.

Шәкүрнекеләр сынатмый
Узды заманаларны.
Хәзерге «данлы» бурларның
Кем булыр балалары?

*Март, 2000*

## Сәүдә ханым

Авызын ачса, үпкәсе
Күренә торган иде.
Хәзер теше дә күренми —
Алтыннан тулган инде!

*1988*

## *Базарның файдасы...*

Борчылма, табиб, кисәтмә,
Симермәм мин, тазармам:
Ходай бирмеш һәр көнемне
Сатып алам базардан.

Бил каешым да гел кысмый,
Иркенләп, җыйнак тора.
Безнең исәнлекне саклап,
Симерү... кыйбат тора!

*Сентябрь, 2000*

## *Базар*

Төшем арты төшем кереп,
Кемнең тора теше көлеп!
Ә кайсының эше харап —
Башын ия төшенкелек.

Уйный үлчәү тәлинкәсе...
Юатып соң ни әйтәсе?
Син дә шәбрәк алдашырсың,
Урыннарны алмашырсыз!

*Октябрь, 2000*

## *Пышын-пышын...*

«Каракның бүреге яна!» —
Дип кычкырмый беркем аңа.
Пышын-пышын сөйләшәләр:
«Каракның бүреге яңа!»

*1969*

## Дөп-дөрес

— Хезмәт итим сездә,— диде,—
Исемем — Тугры,— диде.
Исеме шулай иде дә,
Җисеме Угры иде.

Кеше бит ул карбыз түгел,
Булмый ич ярып карап.
Ялкау түгел, өлгер бик тә,
Тырыша, бер дә харап.

— Шома егет, булдыра бит
Бу,— диделәр,— башкарак.
Биктә дөрес, хәзер инде —
Тәҗрибәле Баш Карак.

*Июль, 2000*

## Сан һәм сыйфат

Күп дигәндә дусларыңның санын,
Онытма син тагын сыйфат ягын!

*Август, 1963*

## Берәү

Яши янәшәңдә
Алдау белән,
Ялганны ялганга
Ялгау белән.

*Август, 1963*

## *Кире кагу*

«Сөткә су кушалар» диеп,
Яла якма, кушавыз,—
Сөткә суны кушмыйбыз без,
Суны сөткә кушабыз!

*Сентябрь, 1962*

## *Сөттән авызы пешкәчтен...*

Сөт кибетеннән кудылар,
Хәләф хәзер су сата:
— Сөттән ак мин,
          судан пакь,— ди, —
Миндә булмады хата!..

Әйе, шактый ук шомарган,
Хәзер ул белә чама:
Сөттән авызы пешкәчтен,
Суны да өреп каба!

*1970*

## *Бер кассирга*

«Ил төкерсә, күл була» дип
Калдыра гел үзенә.
Нәрсә кылыр, моның өчен
Ил төкерсә йөзенә?

*1960*

## Ишетмәсәң ишет

Самовар шикелле кайнап,
Паровоз кебек дулап,
Йөри Булат еш-еш сулап,
— Сиңа ни булды, Булат?

— Ничек соң ярсымыйсың да
Ничек соң дуламыйсың,
Шундый мөртәтләрне күргәч,
Дуламый буламы соң?

Миннән булсын бер изгелек,
Ал, әйдә, ала бир дип,
Әле генә берәүгә мин
Бирдерттем холодильник.

Юньле кеше мәллә дисәм —
Унбиш сум ришвәт төртә!
Ничек шундый оятсызны
Бу җир йотмыйча йөртә?

Андый белән буялырга
Әллә соң мин тилеме,
Сүгеп чыгардым тегене —
Бирсә бирсен иллене!

*1963*

## Берәү офтана

«Майламыйча купмый таба —
Җайлау көтә бары да...
Майламасаң, алга таба
Әйләнмәс Җир шары да!»

*Февраль, 1977*

## Сакаулану

Иң якыны, иң кирәге
Брат иде;
Иң якыны, иң кирәге
Блат инде...

*Сентябрь, 1975*

## Заграничный...

Әй, өлгер дә соң Хисми,
Вай, өлгер дә соң Хисми,
Читләтми аны һични —
Күлмәк тә заграничный,
Чүлмәк тә заграничный,
Оек та заграничный,
Берет та заграничный,
Мыек та заграничный!

Бер төчкерә, бер исни,
Әмма мактана Хисми:
— Гадәти түгел ич,— ди,—
Грипп та заграничный!

*Декабрь, 1968*

*

Үз «Волга»сы белән берәү
Выжылдап үтеп китте,
Тәрәзеннән башын сузып
Бик важный бара эте.

Кайчакта дөнья дигәнең
Әллә соң белми чама —
Этләр йөри машинада,
Кешеләр җәяү чаба...

*1968*

## Череп баеган

Өен күрсәң, исең китәр,
Универсаль кибет төсле:
Чемоданнар, сандыкларны
Өеп куйган аслы-өсле.
Драплары төргәк-төргәк,
Бостоннары кисәк-кисәк,
Ефәкләргә юктыр исәп.
Дөрес булыр шулай дисәк:
— Череп баеган,
Череп баеган!

Заграничный сервизлары
Буфетында әллә ничә,
Кружкадан кишер чәен
Шикәр ялап кына эчә...
Тез башлары ямау-ямау,
Терсәкләре тишек-тишек.
Хатыны да үзе кебек,
Иш-ишен табышкан ничек?

Ә беркөнне карап бакса,
Череп беткән бостон, драп.
Күя төшкән каракүлгә,
Киемнәре күптән брак...
Айлар, еллар үтеп киткән
Исни-исни черек исен.
Әрәм маллар, әрәм гомер...
Моңа тагын ничек дисең:
— Череп баеган,
Череп баеган!

*1961*

## *Май кап...*

Май заводында ревизор
Санап бакса — җитешмәү зур.
Хуҗа әйтә:
— Зинһар, җай тап,
Дәшмә, май кап!

Майлагандай бара эшләр,
Тора-бара нишләр...

Тагын килә шул ревизор,
Бу килүдә әшнәлек зур.
Хуҗа әйтә:
— Дускай, җай тап,
Дәшмә, май кап!

Майлагандай бара эшләр,
Тора-бара нишләр...

Ревизор бар ревизорга,
Боларның эш китте зурга.
Чыгардылар
Барсын айкап:
— Кайда май, тап!!!

*1961*

## *Кызганыч козгыннар*

«Яман хәбәр килер» диләр иде,
Козгын аваз салса һавада.
«Кызыл китап» саклар
көнгә калды —
Юрар көннәр килде аңа да...

*Ноябрь, 1989*

## Диңгезләр һәм дуңгызлар турында

Сәер генә кай кешедә
Чисталыкка хирыслык —
Каралты-кура тәртиптә,
Инеш буе — тиреслек.
Чишмәләрдән туган сулар
Кушыла бит елгага,
Дуңгыз пычрагы акканда,
Диңгезләр дә болгана.
Диңгез — ерак, дуңгыз — якын,
Диючеләр очраса,
Әйтерем шул: күңел — диңгез,
Үзеңне дә пычратма!

*Июнь, 1999*

## Көләсе килми-килә...

Көлү — иттән файдалы, ди,
Күнәсем килми.
Ит бәясенә карыйм да,
Көләсе килми.
Пенсия алгач кем ничектер,
Беләсем килә —
Исәпкә бар, санга юк дип,
Көләсем килә.
Көлгәннәрнең ите бар да —
Бүләсе килми.
Аларны симертер өчен
Көләсе килми.
Көлкегә ит алмашканны
Күрәсе килә.
Күз алдыма китерәм дә,
Көләсе килә!

*Март, 1997*

## *Төп башына...*

Чыбык-чабык җыеп бирәү
Култыгына кыстыра.
Урман сакчысы күрә дә:
«Стой!» — диеп кычкыра.

Ялынып та карый агай:
— Бу бит,— ди,— коры-сары...
Ә теге китә кабынып,
Әйтерсең коры дары!

Син фәлән, ди, син төгән, ди,
Бөтен урманга шаулый.
Тел төбен төшенә агай —
Бу бит «яртыны» даулый...

— Чү, кызма, бозма каныңны,
Мондый юк-барга, чүпкә,
Тыныч кына сөйләшик бер
Утырып шушы төпкә.

Ял ит азрак, йөри-йөри
Беткәнсең арып, талып,
Бер тавык та бер савыт бар,
Килим олаудан алып...

Сөйләгән агай, көйләгән
Аппетитын котыртып.
Калдырган урман сакчысын,
Төп башына утыртып!

*1959*

# Кызганычка каршы

## *Уздырыштан*

Чыкмыйбыз без
Утырыштан,
Утырабыз
Уздырыштан —
Ыштан
Туздырыштан,
Гомер
Уздырыштан!

*1967*

## *Кыюлык*

— Туры әйткән бу сүзләрем
Бетмәс тә, бәлкем, ярап:
Нинди кеше икәнеңне
Әйтәм күзеңә карап!
Начальник дип тормам бүтән,
Күп йөрдем инде түзеп! —
Һәм китте, китте абзагыз...
Мактау сүзләрен тезеп!

## *Тегермәннәр*

Бик кирәк безгә
Су тегермәне,
Бик кирәк безгә
Җил тегермәне.
Кирәкми безгә
Тел тегермәне!

*Гыйнвар, 1966*

## *Куштан*

Кушсаң, яхшыны — яман, ди,
Яхшы, ди ул яманны.
Дөресне дә ялган, дия,
Дөрес, дия ялганны.

Юк кыйбласы, юк иманы —
Теләгәнчә куй борып...
Яши заман чүплегеннән
Шулай тамак туйдырып.

*1969*

## *Ул елларда*

Шымчыдан да нидер калган,
Тарихта бит «өлеш» кергән:
Якты сүзләр артыннан ул
Күләгә дип теркәп йөргән...

*1988*

## Елдам

Электән үк
Әләкләгән —
Кемнәр генә
Эләкмәгән...

Ни кыланмас
Бала-чага...
Инде олы —
Әмма чага!

Елгыр кеше,
Елдам кеше,
Ә бит эше —
Елан эше...

*1969*

## Тормыш илләгендә

Салмак орлык
Аска тарта,
Җиңел кибәк
Өскә калка.

Өскә калка
Вакытлыча;
Орлык кала,
Кибәк оча!..

*1971*

## *Чтереп мактыйм!..*

### Юмарт

Анда да ул
Акыл бирә,
Монда да ул
Акыл бирә,
Кызганмый —
Актыгын бирә!..

*1963*

### Елгырлык

Бигрәк уяу, бигрәк сизгер
Синең борының;
Җил каян иссә, һәрвакыт
Шунда борылдың.
Биектә — флюгер янында
Синең урының!

*1963*

### Принципиаль

Йөргән булыр
«Эш» дип көеп;
Өсте-өстенә
Факт өеп,
Сүзен башлар
Өстәл төеп.
Соңын очлар:
«Әйттем исә
Кайттым» диеп.

*1963*

## Белеп тор

Берәү әйтә кимчелекне
Күзгә карап,
Берәү әйтә сылап-сыйпап —
Сиңа ярап.
Мондыена колак салсаң —
Эшең харап!

*Март, 1963*

## Көтә

Аһ, кыюлар, фидакарьләр
Төштә түгел, өндә булса,
Тайчанмыйча хакны әйтү
Нәкъ бүгенге көндә булса,
Без әйтәсе сүзләр белән
Чәчрәп чыкса кем дә булса!..

*1976*

## Шапалак һәм Чебен

Кар китте,
Яз җитте.
«Кышны исән-сау чыктык!» — дип,
Шапалак Чебенне котлады.
Мәрттән кайтуын онытмады,
Тәбрикләп шат итте:
Очып кына төшеп, өстенә
«Ша-ап!» итте...

*1988*

## Ваклаучы

— Күрче, бу бәндә гайбәтен
Тырыша нигезләргә...
Нигә тырнак астында да
Булмаганны эзләргә?!

— Тели безне дә вакларга —
Үзенә тигезләргә...

*1968*

## Яраклашкан...

Дөрес әйттем —
Хурладылар,
Ялганладым —
Зурладылар!..

*1964*

## Борчылу

Вак-төякләр күмә башлаганны
Күреп тор да, имеш, карышма —
Кабырчыклар сарган көймә сыман
Авырая алга барышлар...

*1975*

## Белгеч

Бөлдергеч белгеч булды бу,
Гел өйрәтә, белми чама —
Машиналар заманында
Дуга белән печән чаба...

*1969*

## *Юктан бар...*

Эшчән булып күренергә
Бигрәк маһир, бигрәк оста.
Бушата да тора инде
Бушны — юкка,
юкны — бушка!

*1975*

## *Актив*

Һаман сөйли, бүтәннәрне
Гаепли пассивлыкта:
Пассивлыкны сүгеп кенә
Йөри ул активлыкта.

*1962*

## *Тырышып-тырмашып*

Көнгә чыксаң, авырта кул,
Яза-яза пыртакул.
Авырта бил, авырта кул,
Эшләр һаман урта кул!..

*Ноябрь, 1966*

## *Җыелыштан соң...*

Эш белән сүз арасы —
Кул белән күз арасы —
Җир белән күк арасы...
Җиң сызганып карачы!

*1981*

## *Дөрес...*

Күп ул дөрес сөйләүчеләр,
Күп ул дөп-дөп-дөрес сүзләр!
Туктап тын алыйк беразрак:
Дөрес эшләүчеләр азрак...

*1988*

## *Сыеклау*

«Сүз куертмыйк!» — дия-дия,
Теле-телгә йокмады:
Йокыны тәмам куертты,
Фикерне сыеклады...

*1987*

## *«Үзем» дигәч...*

— Туктатмагыз мине, җәмәгать,
Мин үземнән түгел канәгать!
Юк-юк, юк-юк, түгел канәгать —
Шул ягым бик ошый, җәмәгать!

*1977*

## *Бер үк чара*

Тимер тутыкса, тимерче, утта тотып,
Кыздыра да кыйный сандалына салып.
Инде тимерче тутыкса,
җыелышта
Кыздыралар аны тәнкыйть утына алып...

*1956*

## Сере шул…

Мактанчыкларны күрсә ул,
Җен ачуы кузгала,
Алар барда чөнки үзе
Мактана алмый кала!

*Март, 1966*

## Чрмәкуч

Баш ора-баш ора,
Әкерен-әкерен
Гамәлгә ашыра
Мәкерен…

*1976*

## Үзара тәнкыйть

— Җыелышта ник кызарга,
Кеше кәефен бозарга?
Кер бүлмәмә, әйт үземә,
Тәнкыйтьләшик үзара!

*1964*

## Эш аксаса…

«Эш аксый…» диләр дә алар,
Утырышта гәп коралар;
Аксаганга күрә, ахры,
Утырышып тик торалар!

*1960*

## Дөрес әйтә...

Әйе, гомерендә күпне
Күргән аның башы —
Канга батып көрәшкән ул...
Кандалага каршы!

*1963*

## Сөйрәлүчеләр классыннан

Тел — сөяксез, сылап-сыйпап
Сөйләнә дә сөйләнә.
Хуҗасы да сырт сөяксез —
Тел артыннан сөйрәлә...

*1965*

## Югары күрсәткеч

Җыелышлар саны белән
Уртача җан башына,
Узганбыз барлык илләрне —
Мин ышанам ансына...

*1965*

## Замана шаманнары

Җыелышка йөргәч һаман,
Искә төште берзаман —
Үз сүзе башына кабып
Шапылдап ауган шаман...
Болар аумый!

*1966*

## Күнә-күнә...

Ни әйтсәләр, шуңа күнеп,
Яраклаша барасың,
Үз-үзеңнән, торган саен,
Ераклаша барасың...

*1966*

## Форма һәм эчтәлек

Әйбәтен әйбәт сөйли,
Әмма ки гайбәт сөйли!

*Сентябрь, 1965*

## «Ачыктан-ачык биш минут...»

...Бер мәҗлестә кемдер тәкъдим итте
Биш минутлык шундый бер уен:
Яшермичә бер дә, туп-турысын
Әйтеп бирсен һәркем үз уен!

Шактый кызык булып тоелса да,
Ансат күренсә дә башта бу,
Уеныбыз шул чинга ашмады —
Беребез дә серен ачмады...

Чын уеңны ничек әйтмәк кирәк?!
Ык-мык килдек, аннан — көлештек,
Ярый, уен, диеп сөенештек,
Вакытлыча гына, диештек...

Гомерлеккә булса, әй, нишләрсең,
Дөньяларда ничек яшәрсең?!
Зинһар өчен, безнең гадәттәге
Күнегелгән тормыш яшәсен...

*1967*

## *Бетсеннәр утырышлар*

(Тәкъдим)

Бетсеннәр утырышлар,
Булсын басып торышлар.
Утырдашлар арырлар
Һәм бик тиз таралырлар!

*1962*

## *Тел очында гына тора...*

Сынауда тагын сынаттым...
Өйрәнүен өйрәндем —
Тел очында гына тора,
Әйтеп кенә бирәлмим!

Бер кыз очрап каш сикертте...
«Әйдә!» диде, өйләндем —
Тел очында гына тора,
Әмма отказ бирәлмим!

Начальнигым кушып торгач,
Шикле эшкә иярдем —
Тел очында гына тора,
Әмма каршы киләлмим.

Безнең тирәдә хәлләр бар...
Күрүен дә күрәм мин —
Тел очында гына тора,
Әйтеп кенә бирәлмим!

...Мондыйларны кем диләр соң?
Белүен дә беләм мин —
Тел очында гына тора,
Әйтеп кенә бирәлмим!

*1968*

## Сөйләде Лотфи

Үпкәләп, залга
Кырынрак торып,
Сөйләде Лотфи
Күңеле тулып:

— Белү юк бездә
Кеше кадерен,
Саклау юк бер дә
Кеше хәтерен...
Фани дөньялар
Үтәр дә китәр,
Татулыкларга
Ни генә җитәр.
Туганнарча гел
Тату яшикче,
Усал әйтмикче,
Каты дәшмикче!..

Нияте аның
Изгесен изге,
Ник бүген генә
Әйтә бу сүзне?
Хикмәте моның
Гади икән бик —
Бүген үзенә
Тәнкыйть тигән бит!

*1970*

## *Тормыш көрәшсез булмый...*

Гыйният бик гадел кеше,
Хаксызлык күрде исә —
Тәнкыйть кылычы белән ул
Уңга да сулга кисә.

«Катышмавың хәерле», — дип,
Искәртүчеләр була,
«Үзеңә дә эләгер!» — дип,
Кисәтүчеләр була.

Андый киңәшчеләргә
Гыйният колак салмый,
Гыйният бик дөрес уйлый:
— Тормыш көрәшсез булмый!

Үчлеләр чәчрәп чыкмады,
Хәтта тынып калдылар,
Үзләре астыртын гына
Аңа аяк чалдылар...

Эшсез калган Гыйниятулла
Хаклыгын исбат итә.
Исбат итә-итә-итә
Әллә кайларга җитә —

Әле дә булса йөри!
(Нишлисең, ансыз булмый...)
Ә тегеләр авыз ера:
— Көрәш корбансыз булмый!

*Февраль, 1970*

## Төзәлер ул, төзәлер...

Егет эшли, әйбәт эшли
Зур гына бер әртилдә.
Атлыгып кына тора ул,
Кимчелекне әйтергә,
Тиз генә төзәтергә.
Ул шуңа ияләнгән,
Шулай тәрбияләнгән.

Директор тыңлап утыра,
Елмаеп куйган итә.
Бер тыңлый, ике тыңлый да
Тыңлаудан кызык бетә;
Директор кызып китә,
Чыгырыннан чыга ул,
Шап! — өстәлгә суга ул.

Мастеры яклый егетне:
— Ул белми,— ди,— ул бала,
Яшь бит әле, тәҗрибәсез —
Турысын әйтеп сала.
Төшендерербез аңа...
Үзгәрер ул, үзгәрер,
Төзәлер ул, төзәлер!

*Февраль, 1970*

## Икейөзле димәсеннәр

Кемне күрсә, шуңа ярый,
Юхасы ул юханың.
Икейөзле димәсеннәр —
Бер йөзе дә юк аның!

*1962*

## *Кыю Галләм*

Коридорда Галләм кыю —
Мөмкин түгел аны тыю.
Йодрык селкеп, бармак төртеп,
Муен тамырлары бүртеп,
Сөйләп тора, әй, дәртләнеп,
Кайнарланып, гайрәтләнеп.
Помнарны да кыздыра ул,
Замнарны да туздыра ул,
«Сам»нарны да телгә ала,
Тетмәләрен тетеп сала:
Ул як, бу як җитеш түгел,
Җитәкчеләр җитез түгел.
Бер тәнкыйтьләп чыгыйк, ди ул,
Яшен булып сугыйк, ди ул.

Җыелышта үзе ләм-мим,
Ни булгандыр аңа, белмим —
Тел яшергән киленнәрдәй
Кыймылдый тик иреннәре.
«Семьям бар бит... Кызмыйм әле,
Юкка ара бозмыйм әле;
Җыелышлар үтәр китәр,
Хуҗа үзенекен итәр.
Җаен табып эштән куар,
Йә акча аз төшкә куяр.
Югарыда танышы бар —
Кая миңа ярышулар!..»
Үзе карый бүтәннәргә:
«Алар тәнкыйть итәр әллә?»
Тик барсы да сөйли шома...
Бик пошына Галләм шуңа.

Кайткан чакта, әй, дәртләнеп,
Сөйли Галләм гайрәтләнеп:
— Беләсезме, сез кемнәр,— ди,—

Куркак җаннар,
                    мескеннәр! — ди.—
Кирәк иде җайлап кына,
Әче сүзләр сайлап кына,
Һәммәсен дә сөйләргә бер,
Сөйләргә бер — чөйләргә бер!
Тәнкыйть итәргә — тетәргә!
Ник һаман мине көтәргә —
Анда да мин, монда да мин,
Бер үзем ничек өлгерим?

*1961*

## *Тешегезне саклагыз!*

Аптекада бер игълан бар,
Укыгыз да ятлагыз:
«Онытмагыз, чистартыгыз —
Тешегезне саклагыз!»

Караңгы урамнан төнлә
Соңга калып кайтмагыз,
Иртәрәк өйгә атлагыз —
Тешегезне саклагыз!

Юньсезлекне күргән чакта,
Авызга су капмагыз,
Теш кысып дәшми ятмагыз —
Тешегезне саклагыз!

Алай да сез хуҗагызны
Бигүк каты чакмагыз —
Тешегез дә исән калыр...
Эшегезне саклагыз!..

*1968*

## «Чаян» ярдәм итте

Чәчү — чәчкән,
Урак — ерак,
Эшләр азайган ара.
Клуб янында биш егет
Көн дә көнбагыш яра.

Идарә ягына табан
Бармагы белән төртеп:
— Булмады да һәм булмас та
Безнең колхозда тәртип! —
ди беренчесе.

— Өч идән тактасы сынган,
Клубыбыз бикле тора.
Кичә-бүген генә түгел,
Былтырдан тикле тора! —
ди икенчесе.

— Китапханәгә су үтә,
Агып китмәсә ярый.
Ник түбәне төзәттерми,
Председатель ни карый? —
ди өченчесе.

— Яшьләр турында, гомумән,
Күптәннән кайгыртмыйлар.
Физкультура ясар идең —
Турник та куйдыртмыйлар,—
ди дүртенчесе.

— Безнең мондагы хәлләрне
Белмиләр югарыда.
Кирәк боларның барсын да
«Чаян»да чыгарырга! —
ди бишенчесе.

— Ваемсызлар һәм ялкаулар
Бездән шәфкать көтмәсен,
Кем кемлегенә карамый
Тетәрбез без тетмәсен!—
диләр бишесе бергә.

*

Ун көннән соң председатель
Егетләрне чакырта.
— Сезгә йомышым бар,— диеп,
Каршысына утырта. —

Җитешмәгән якларыңны
Күрәләр бит каян да —
Безнең клуб хакында да
Мәгълүм булган «Чаян»да.

Турнигына хәтле шунда
Язган бит бер юньсезе...
Шул эшләрне башкарырга
Дәшкән идем мин сезне.

*

Чәчү — чәчкән,
Урак — ерак,
Эшләр азайган ара.
Клуб янында биш егет
Шаулатып такта яра!

*1962*

## *Төшендә*

Һәр тумыш көн Хәйбуш иртән
Йөзен чытып күзен ачар:
«Бүген тагын кәеф начар,
Бүген тагын эшләр начар...

Бакчы инде бу һаваны,
Былчыракка манганмыни:
Үләннәр дә кара-кучкыл,
Көеп утта янганмыни!

Күңелсез һәм соры, төссез
Каршыдагы бөтен йортлар.
Әйтерсең лә яшен суккан,
Әйтерсең лә төтен йоккан...

Кара коелып йөри һәркем,
Шулай үтә һәр тумыш көн.
Рәте китте бу дөньяның,
Рәте бетте бу тормышның!»

...Ә беркөнне, күзен ачса,
Бар тирә-як юган төсле.
Хәйбушны да танып булмый,
Ул яңадан туган төсле.

Сәбәпсезгә көлә-көлә
Сабый төсле сикерә ул,
Җилтерәтеп хатынын да
Тәрәзәгә китерә ул:

— Кара әле, кара, иркәм,
Тизрәк кара бу дөньяга —
Үзе якты, үзе нурлы,
Саф бит бар да, бар да яңа!

Һава нинди зәңгәрләнгән,
Үлән нинди яшелләнгән.
Йортлар ничек чибәрләнгән,
Ә кешеләр яшәргәннәр;

Һәммәсе дә елмайганнар,
Һәммәсе дә сөенгәннәр,
Бигрәк инде матур итеп,
Нәкъ бәйрәмчә киенгәннәр!

Ничек шулай үзгәргән ул,
Нәрсә булган бу дөньяга?!
Хатын әйтә: «Нәрсә булсын,
Тәрәзләрне юдым яңа...»

*

Һәр сулышта һәр нәрсәне
Сүгәргә син оста икән —
Уйлап кара иң әүвәле:
Үз «тәрәзәң» чиста микән?

*Май, 1963*

## *Сер саклау мәсьәләсендә...*

Зарланып утыра Гани:
— Аптыраган хәл бик тә —
Бер бүлмәдә сөйләшәсең,
Ишек тә була биктә,—
Әллә ничек тарала сүз,
Әллә кайларга китә...

— Сер саклау мәсьәләсендә
Биримме әйбәт киңәш?
Ишегеңне түгел, иптәш,
Авызны ябып сөйләш!

*Февраль, 1970*

## *Яңа ысул*

Сабан туен көткән кебек,
Җыелышны көтә Зәбир,
Кызып-кызып китә Зәбир,
Тезеп-тезеп китә Зәбир,
Тетмәләрен тетә Зәбир
Һәм башлыкның,
Һәм башканың.

— Ничек телен кыскартырга?
— Кирәк штат кыскартырга!

Язды. Йөрде. Йөри торгач,
Күп җирләргә җитте Зәбир,
Үз дигәнен итте Зәбир,
Җыелышта өтте Зәбир,
Тагын ныграк төртте Зәбир
Һәм башлыкка,
Һәм башкага.

— Ничек моны туктатырга?
— Җибәрик, әйдә, укырга!

Киткән кеше бер кайта бит.
Күкрәп кайтып керде Зәбир,
Ялт-йолт карап йөрде Зәбир,
Ансын-монсын күрде Зәбир,
Кирәкләрен бирде Зәбир
Һәм башлыкның,
Һәм башканың.

— Ничек авызын томаларга?
— Кирәк бүләкләп карарга!

Менә ул көн килеп җитте,
Менә бүләк алды Зәбир,
Бүләккә күз салды Зәбир,
Юашланып калды Зәбир...
Әй, мактый башлады Зәбир
Һәм башлыкны,
Һәм башканы!..

*Ноябрь, 1967*

## Төзәлде

Һаман да бер
Көн тәртибе —
Тикшерәләр
Гел Тәкыйне.
Китерәләр
Мисал итеп
Һәм сөйлиләр
Усал итеп:
— ...эчә икән!
— ...кыйный икән!
— ...йөри икән!
Тәкый әйтә:
— Тәүбә итәм!
Төзәлермен,
Үзгәрермен,
Валлаһи!
Алдалый...

*

Тагын шул ук
Көн тәртибе —
Тикшерәләр
Гел Тәкыйне.
Күп хәлләрне
Мисал итеп,
Бар да сөйли
Усал итеп:
— ...һаман йөри,
— ...һаман эчә!
— ...һаман кыйный!
Тәкый әйтә:
— Тәүбә итәм!
Үзгәрермен,
Төзәлермен,
Валлаһи!
Алдалый...

*

Сөйли торгач,
Гомер үтте,
Тәкыйгә дә
Җитмеш җитте...
Ни булса да
Көн тәртибе,
Телгә алалар
Гел Тәкыйне:
— Кабул итте
Ул тәнкыйтьне;
Ничек ипле
Һәм тәртипле,
Һәм тәүфыйклы!..
— ...эчми!
— ...йөрми!
— ...кыйнамый!
Тәкый әйтә:
— Инде тәмам
Үзгәрдем шул,
Төзәлдем шул,
Валлаһи!..
...Алдамый.

*Октябрь, 1967*

## *Форсат*

— Була анда
Барсак та,
Була монда
Калсак та.
Була алай
Борсак та,
Була болай
Борсак та,
Ярашсын тик
Форсатка...
Принцип безнең —
Корсакта!

*Декабрь, 1968*

## Һаман да бер балык башы

Браконьерлар көн күрсәтми,
Ятьмә-ятьмә сөзеп ташый.
Ни күрсә дә күрә инде
Һаман да бер балык башы...

Бар җылымсыз браконьерлар —
Күпме завод шакшы ташлый...
Беркем күрмәгәнне күрә
Һаман да бер балык башы...

Нефтьтән дә керә өлеш,
Елгаларга ул да ташый.
Башың и дә, җилкәң кашы —
Һаман да бер балык башы...

«Штраф!» — дигәч, җитәкче абзый
Гел дәүләт кесәсен капшый,
Ничек кенә әйләндермә —
Һаман да бер балык башы!..

Су сафлыгын яклый-яклый,
Күпме кеше чыгыш ясый!
Күпме генә сөйләсәң дә,
Һаман да бер балык башы...

Идел ярын дулкын ашый,
Күңелләрдә ярсу ташый...
Кибетләрдә гел камбала —
Һаман да бер балык башы!..

*Июль, 1968*

## *Кызганычка каршы*

Җыелышлар була тора,
Кызганычка каршы;
Яшь гомерләр уза тора,
Кызганычка каршы.

Кемнәр эшли, алар дәшми,
Кызганычка каршы;
Кемдер трибунадан төшми,
Кызганычка каршы!

Селкеп куллар, эчеп сулар,
Кызганычка каршы,
Актив булып йөри шулар,
Кызганычка каршы.

Бар да акыл өйрәтәләр,
Кызганычка каршы;
Тыңла, диеп йөдәтәләр,
Кызганычка каршы.

Мин аларны күреп торам,
Кызганычка каршы,
Кул селтим дә эчтән тынам...
Кызганычка каршы.

*Февраль, 1968*

## Тәнкыйтькә ода

(Бер җыелыш протоколыннан)

— Әүвәлгеләр тәнкыйтьне бит
Аңламаган:
«Туры әйткән туганына
Ярамаган!»

Тәнкыйть белән хәзер көн дә
Эш итәбез —
Әйтәбез һәм үзебез дә
Ишетәбез.

Һава кебек кирәк бит ул,
Ул бик тә шәп.
Алга барып булмый ансыз,
Булмый яшәп!

Дөрес... кирәк чамаларга
Алны, артны —
Булмасын ул артык шырпы,
Артык каты.

Дөрес... булсын дисәң гомум
Эшкә файда,
Белү кирәк: Кемне? Ничек?
Күпме? Кайда?

Менә монда кемдер әйбәт
Тәкъдим бирә:
Булсын бездә мактый торган
Тәнкыйть кенә!

*Февраль, 1969*

## Өйдәге чүп

Җыелышны бик тансыклап
Көтеп алдык,
Управдомны әйбәт кенә
Тетеп салдык.

Искә алдык түгелмәгән
Чүп-чарны да,
Эчү фактын, халык әйткән
Күп зарны да.

Ә бер абзый ишекләрне
Ябып килде,
Ирененә бармак куеп,
Болай диде:

— Онытмагыз, дус-дошман бар
Бит дөньяда,
Ирешмәсен бу хәбәрләр
Барып аңа!

Киметергә һич ярамый
Уяулыкны —
Күрсен ятлар безнең бары
Уңай якны!

Уйлап-уйлап тордык та без:
— Дөрес! — дидек,
Управдомга бик һәйбәтләп
Бүләк бирдек.

Чыгармыйк без өйдән чүпне —
Ул чүп кенә,
Берни булмас артса хәтта
Ул чүт кенә...

...Җыела торгач, чүп-чар белән
Дөнья тулды...
Әмма ләкин безнең дошман
Кызык булды!

*Февраль, 1969*

## Озатыйк!

Елларда-залларда
Сүстәй сүз талкышлар...
Шап та шоп тавышлар:
Алкышлар, алкышлар...

Уйлары оеган,
Алкыдыр-салкыдыр,
Сөйләүче тирләгән,
Телмәре салкындыр.

Юкны бар итешләр,
Сузышлар, тартышлар,
Колакка барабан —
Дөмбер сүз кагышлар...

Кәгазьдә-вәгазьдә
Ал да гөл балкышлар,
Күзләрне йомдырган,
Изрәткән алкышлар...

Миңгерәп-түнепләр
Бер сүзне кабатлау!
...Ачудан, теш кысып,
Кулларны яңаклау...

Үткәнне сүгеп ни —
Бүген тел озайтмыйк:
Чамасыз алкышны
Алкышсыз озатыйк!

*1988*

## *Урыннан реплика*

Торып залга кырын гына,
Президиумга йөз белән —
Кулыннан эш килмәгәннәр
Алдыралар сүз белән.

Алдыйлар бит эш дигәндә
Янмыйлар да көймиләр,
Бер тиенлек эшләсәләр,
Ун тиенлек сөйлиләр.

Шулай көйләп йөри торгач,
Алар тәмам остара,
Сүзгә тел озайган саен,
Эшкә кулы кыскара...

Гел күз алдында булгачтын,
Таный башлый түрәләр —
Эшләгәннәр эштә кала,
Сөйләгәнне күрәләр —

Начальник та ярата шул
Үзенә охшаганны!
Көтәм шуны әйтер өчен
Трибуна бушаганны...

*1965*

## Операция

«Һәр эштә заманга хаслык
Үзен белдереп тора,
Күрсәтә күңел киңлеген
Хәтта архитектура.

Бетеп бара крепость кебек
Тар тәрәзле оялар —
Мул үткәрә яктылыкны
Тоташ, зур пыялалар.

Нигә кирәк чит күзләрдән
Яшерену, сагаю.
Эре панельләргә күчкәч,
Гөнаһ бит ул вагаю!..»

Яңа больницага карап,
Матурлыкка сокланып,
Эшкә барган чакта шулай
Уйлый идем тукталып.

Ә бүген редакциягә
Бик усал бер хат килгән.
Хатта: «Хирург Бакир Сафин
Ришвәт ала гел,— дигән.

Үзе дә инкарь италмас,
Раслап торганда халык.
Имзамны яшермим — Гатин.
Тантана итсен хаклык!»

«Четерекле мәсьәлә...» дип
Киттем хат биргән эздән.
Ерактан ук больницаны
Кичереп киләм күздән.

Әнә Сафин квартирасы,
Өр-яңадан барчасы.

Алмагачлар, чия, каен...
Бигрәк әйбәт бакчасы!

Чү, чыптага төреп, бирәү
Нидер күтәреп керде,
Сафин белән киңәште дә
Төргәкне җиргә күмде.

Бик шикле эш... Мин ялт моның
Кайтыр юлына чыктым.
«Эләктең!» дип, көлгән булып,
Кулыннан килеп тоттым.

«Сафингамы?»
«Сафинга!» ди.
Китте барды.
— Ашыкма!
— Эшкә соңлыйм. Әнә Җәгъфәр,
Ул барын да ачыклар.

«Сафин», «ришвәт» дигәч, Җәгъфәр
Башта: «Юк, булмас!» — диде.
Күргәнемне әйтеп биргәч,
Уйланып башын иде:

— Алай икән... Әйе, дөрес,
Минем дә катнашым бар;
Бер кузгаткач, әйдә инде,
Сөйләп бирим башыннан...

Бакир яңа килгән чакны,
Берничә ел элек мин
Бик тә авыр, мөшкел хәлдә
Больницага эләктем.

Пычактан курыккан идем,
Пычак үлемне суйды!
Ай дигәндә Сафин мине
Кеше итте дә куйды.

Моннан да зуррак изгелек
Буламыни дөньяда?
Менә шунда, чын күңелдән
Китергән идем аңа...

Ошатканын белеп, моны
Сиздердем бүтәннәргә —
Палатада бергә ятып,
Савыгып киткәннәргә.

Минем шикелле, алар да
Буш итмәде, әлбәттә.
Шул көннән башлап бу нәрсә
Кереп китте гадәткә.

Нәкъ шундыйларның берсен сез
Күргәнсез үзегез дә,
Газиз китергән үсенте
Чалынган күзегезгә;

Үзебезгә охшап микән,
Алар да тиз терелә,
Яхшылыкка рәхмәт укып,
Яктылыкка үрелә.

Шул инде безнең «ришвәтләр»:
Алмасы, чиясе бар,
Ак халатлар кигән төсле,
Утыра ак каеннар!..

— Менә хикмәт нидә икән!..
Сөйләп тегенең хатын,
Сорыйм Җәгъфәрдән:
— Ә үзе
Кайда тора ул Гатин?

— Улмы? Ул...
Тукта, кемнәрдер
Больницага киләләр,
Кемнедер алып киләләр,
Ә үзләре көләләр:

— Мөртәт Гатинның бу хәлгә
Калуы бик шәп,— диләр,—
Тәмам җанга тигән иде,
Тынып торыр, шәт,— диләр.

...Гатин кем дисезме? Гатин
Бер беткән адәм икән,
Аның хакында сөйләргә
Сүзләр дә әрәм икән.

Ул гади хулиган түгел,
Астыртын эшли икән,
Колакларың белән бергә
Башыңны тешли икән...

Кемнәргә генә бу бәндә
Нинди бәла якмаган!
Зәһәре күп булгангамы,
Сөенер нәрсә тапмаган.

Сафин белән аерым хисап,
Күптән теш кайрап йөргән,
Батырырга дип чамалап,
Форсатны сайлап йөргән;

Фәкать шул эштән кудыртты
«Кеше чагучы» диеп,
Бөтен илгә рисвай итте
«Яла ягучы» диеп...

Сафинны күрүгә, теге
Ялт итеп күзен ача:
— Үләр алдыннан үзеңә
Әйтеп калыйм, ичмаса...

Гатин хәзер синең кулда,
Нишләтсәң дә, барыбер...
Әмма тиешле урында
Минем сигнал барын бел!

Әрепләшеп тә талашып
Торырлыкмыни бу чак,
Сүз әйтмичә генә Сафин
Ала кулына пычак...

*

...Бакчасында йөри хирург —
Ак канат күк ак халат...
Әйттем аңа, Гатин яткан
Бүлмә ягына карап:

— Мондыйлар ак каенны да
Кара итеп күрәләр,
Явыз уйлар пәрәвезен
Үрмәкүчтәй үрәләр.

Тәнен сихәтләтеп чыгар
Бу гөнаһлар иясе,
Ә җанын инде дәвалар
Каләм хирургиясе!

*Сентябрь, 1965*

# Куркыныч «АЮ»лар

## *Сәер кеше*

Казан тирәсендәге
Урманнарның берсендә
Юлыкканнар туристлар
Бик шикле бер кешегә.

Болай карап торышка
Безнең кебек, ди, үзе.
Ныклабрак карасаң,
Түгел кебек, ди, үзе.

Һәркем кара күзлектән,
Тик ул кара күзлексез,
Як-ягына текәлеп
Күзәтә, ди, өзлексез.

Күпне күргән туристлар
Бер карауда сизенгән,
Белдермичә үзенә
Атлаганнар эзеннән...

Шомырт күргән — иснәгән,
Сирень күргән — кисмәгән,
Кырмыска оясына
Таяк тыгып китмәгән!

Гөмбәләргә типмәгән,
Кошларга таш атмаган,
Көне буе йөреп тә
Хәтта учак якмаган!

Сәер кеше, бик сәер...
Болай булмый тормышта —
Димәк ки, ул эзләрен
Калдырмаска тырыша?

Күзләп барган туристлар
Аның тагын нишләрен.
Менә теге берзаман
Салып куйган биштәрен.

Утырып сөт эчкән, ди,
Тәмәке дә тартмаган.
Алып киткән шешәсен —
Төпкә бәреп ватмаган!

Кыен түгел төшенү
Моның исәпләренә —
Җыеп, төреп алган ул
Кәгазь кисәкләрен дә!

Оргсинтез янына
Чыккан да ул урманнан,
Троллейбуска утырган —
Шунда эзе югалган.

Чөнки карап торырга
Безнең кебек, ди, үзе.
Ныклабрак карасаң,
Түгел кебек, ди, үзе.

Үзем аны күрмәдем,
Сөйләгәнне ишеттем.
Булды микән ул кеше —
Ышандырмый ничектер...

*Май, 1971*

## Заграница мантосы

Чит илгә баргач бер ханым,
Бик кызыгып, ошатып,
Мех манто алган сатып.

Бигрәк нәфис, бигрәк һәйбәт —
Күз явыңны алырлык,
Күреп өнсез калырлык!

Кайткач, таныш-белешләрнең
Күреп күзе кызачак,
Йөрәк мае сызачак!

Бездә мондый шәп нәрсәне
Мәңге эшли алмыйлар —
Тумаганнар андыйлар!

И затлы соң, и зиннәтле
Заграница мантосы.
Бакса... Казан маркасы!

*Май, 1962*

## Көчле ягым

Төрле чакларым булыр,
Көчсез чакларым булыр,
Берәү түгел, бишәүдер,
Бәлкем әллә ничәүдер...
Белмим димсең әллә син,
Белеп торам һәммәсен!
Нәрсә кирәк соң тагын —
Шул иң-иң көчле ягым!

*1988*

## Үзе юкта...

1

Дилә, Зиләһәм дә Виләһ
Кое янына килә.
Коедан су алганда,
Сүзләр сүзгә ялгана.
Читләп йөри дә башта,
Бер танышка тоташа...

Җыеп кына әйткәндә —
Миләбик юньсез бәндә!

2

Зилә, Миләһәм дә Вилә
Кибет янына килә.
Кайтканда һәм барганда
Сүзләр сүзгә ялгана
Һәм Диләгә туктала,
Инде Диләтукмала.

Кимчелеге күп икән,
Кеше түгел, чүп икән!

3

Вилә, Диләһәм дә Милә
Кичен яслегә килә.
Балаларын алганда,
Сүзләр сүзгә ялгана.
Әй, Зиләне сүтәләр,
Теттерепме тетәләр!

Аңа сүз әрәм, диләр,
Мәгънәсез адәм, диләр.

4

Зилә, Миләһәм дә Диләо
Кер чайкарга дип килә.
Туңганны да сизмиләр,
Бүлә-бүлә сөйлиләр.

Сөйлиләр рәхәтләнеп,
Тәм табып, ләззәтләнеп.

Гөнаһсы хәтсез икән,
Виләә бик рәтсез икән!

...Һәркайсы үзе әйбәт,
Бүтәннәр генә начар...
Кем яхшы да кем яман —
Үзең нәтиҗә яса!

*Ноябрь, 1968*

## *Куркыныч «АЮ»лар*

Мин куркам
Унбер АЮдан:
ЗурАЮдан —
Уклау кебек
ТурАЮдан,—
Фикердәшләр
АзАЮдан;
ВагАЮдан —
Уйланганда
СагАЮдан,
Ил шатланса
МоңАЮдан,
Ир кайгырса
ЕлмАЮдан;
МасАЮдан —
Карашларым
ТарАЮдан,
Гомер буе
ТурсАЮдан,
Яшь көенчә
КартАЮдан!

*Гыйнвар, 1964*

## Спекуляция турында

Гыйбадулла чыкса юлга —
Алда мотор тавышы,
Яңа «Москвич»ка утырган
Шәкүр атлы танышы.

Мактый Гыйбат:
— Һәйбәт икән,
Ялт-йолт килә, баксана!
Эчтән әйтә: алды микән
Моны хәләл акчага?

*

Ай үтәме, ике аймы,
Гыйбадулла ни күрә —
Ялтырап торган «Победа»
Бу очрауда Шәкүрдә!

— Тагын син диимме, Шәкүр,
Күзләрем алдашамы?
Күзем күнеп өлгергәнче
Машинаң алмашамы?

Елмая да китеп бара
Танышы аңа карап.
Гыйбадулла уйлап кала:
«Азгансың, Шәкүр карак!»

*

Өч ай үтәме, дүрт аймы,
Беркөнне Гыйбадулла
Шомырттай кара «Волга»да
Танышын күрә юлда.

«Җитәр,— ди ул,—
бик күп чаптың,
Мин сине каптырырмын,
«Москвич»ларны таптырырмын,
Төрмәгә яптырырмын!..»

Яза: «Механик Шәкүрнең
Койрыгына басыгыз.
Машина сатып яшиләр,
Шайкаларын ачыгыз!»

*

Алып китәләр Шәкүрне,
Шәкүрне һәм «Чайка»сын.
Шундук кире җибәрәләр
Һәм ачмыйлар шайкасын...

Гайбәт бетә, Гыйбат кала
Атланып агач атка:
— Шәкүр йөргән машиналар
Алынган... прокатка.

*

Ярамый һәрбер Шәкүрне
Карак итеп күрергә.
Спекуляция бит ул
Гайбәт сатып йөрү дә!

*1963*

## Югары урында

Кайберәүләр сорашалар
Кайда эшләвем турында.
Әйтсәм әйтим, эшлимен мин
Бик югары урында.

Минем каршыда
Барсы да:
«Сафа Вафич!» — диеп кенә,
«Ничек итик?» — диеп кенә,
Йөриләр биеп кенә.

Берәр нәрсә кирәк булса
Бик күп сөйләп тормыйм мин;
Йә кул белән ишарәлим,
Йә баш кагып ымлыйм мин.

Минем каршыда
Барсы да:
«Сафа Вафич!» — диеп кенә,
«Ничек итик?» — диеп кенә,
Йөриләр биеп кенә.

Югары урында мин дип,
Күтәрмим борынымны —
Җәһәт кенә эшләтәмен
Күтәрү кранымны!

Минем каршыда
Барсы да:
«Сафа Вафич!» — диеп кенә,
«Ничек итик?» — диеп кенә,
Йөриләр биеп кенә.

*1963*

## Үз кешеләр

Инде ничә ел буе
Чыкмый иде тавыш-тын —
Онытылып беткәчтен,
Хат язган бер танышым:

«Имин дә исән, диген,
Балалар үсә, диген,
Бергә булган вакытлар
Һаман да истә, диген.

Еллар үтә төшкәчтен,
Шулай була торгандыр —
Рәхәттә дә торган җир,
Сагындыра туган җир...

Илгә тарта күңелләр,
Кузгалмыйча булмастыр,
Бардыр үз кешеләрең,
Булыш әле, урнаштыр?»

Җавап яздым:
«Гыйльмулла!
Хафаланма, борчылма,
Синдәй иптәш хакына
Булдырырбыз барсын да.

Бик күбәүләр атлыккан,
Бик күбәүләр омтылган,
Бер урын бар шәп кенә —
Ошатырсың дип торам.

Ә абзаңның ул яктан
Хәзер бик зур мөмкинлек —
Дус-ишләр белән бергә
Яшә генә гөр килеп!

Синең дә үз кешеләр
Булыр гел әйләнәңдә,
Кунактан кунакларга
Йөрербез бәйрәмнәрдә.

Күтәрелү җае бар —
Шул ягын да чамала.
Машинаңда йөрисе
Хатының Гөлҗамал да.

Менә шундый фикерләр
Синең йомыш турында.
Тәвәккәллә дә җыен,
Перспектива зур монда!»

Ничек каршылау ягын
Бергәләп уйлаштырдык,
Гыйльмулланы әлеге
Шәп җиргә урнаштырдык.

Хатынын машинага
Утыртып кына йөртә —
Төзүчеләрне эшкә
Очыртып кына илтә.

Күтәрелү җае бар
Гыйльмулланың бераздан —
Югарырак менәр ул —
Утырыр ул «КРАЗ»га.

Инде аның үзенә,
Язалар танышлары,
Кемнәргә генә ул да
Үз итеп булышмады.

Менә шулай яшибез,
Ятсынуны белмибез,
Җир җимертеп Чаллыда
Завод төзеп йөрибез.

Монда кырык төбәктән
Кырык төрле милләт бар.
Бик үз итеп сезне дә
Каршыларга ният бар!

*Май, 1971*

## *Битараф булсаң*

Беркөн шулай, азып-тузып,
Кешеләрнең кәефен бозып,
Кирле-мырлы сүзләр көйләп,
Килде-китте җырлар сөйләп,
Үткән-сүткәнгә бәйләнеп,
Эчеп дуңгызга әйләнеп,
Урам буйлап берәү кайта.

Шундук барып җитешүем,
Айныткычка илтешүем.

Иптәш әйтә:
— Кысылма син,
Андый чакта кушылма син,
Бер син генә бу дөньяны
Рәтли алмассың аны!

— Нәрсә булыр, барыбыз да
Тәртәләрне читкә борсак,
Күрмәмешкә салынып торсак?

*

Кич клубта ике егет
Бер-берсенә янашалар.
Тартышалар, талашалар
(Онытылды тамашалар!),
Тора-бара ямашалар —
Кабыргалар санашалар.
Ничек карап тормак кирәк?
Шундук барып аеруым,
Берсен читкә каеруым.

Иптәш әйтә:
— Кысылма син,
Андый чакта кушылма син,
Бер син генә бу дөньяны
Рәтли алмассың аны!

— Нәрсә булыр, барыбыз да
Тәртәләрне читкә борсак,
Күрмәмешкә салынып торсак?

*

Тыкрыкка килеп керәм,
Керсәм шундый хәлне күрәм:
Берәү дусны туный гына,
Йодрыклары уйный гына,
Ай-һай, малай, шәп төшерә,
Битарафны шәп пешерә,
Үрле-кырлы сикертә бит!

Тизрәк барып аерыйммы,
Хулиганны каерыйммы?
Үзе әйтте, кысылма, дип,
Андый чакта кушылма, дип...

Чатка җиткәч, бармак янап
Качты иптәш, борны канап.
Дәшәр иде — теле шешкән,
Өстәвенә теше төшкән.
Җыеп әйтсәк — авыз пешкән!..

*1961*

## Дәва

Докторыбыз барын бар да,
Каравын ул карыйдыр да.
Без күбәү шул, көннәр буе
Утырабыз коридорда.

Бигрәк озак көтәбез, дип,
Булса берәр дәгъвалаучы,
Доктор әйтә:
— Вакыт бит ул
Үзе иң шәп дәвалаучы!

*1968*

## *Үз башыма*

Минем башта һаман да шул
Кыршылыплар беткән бүрек...
— Баш сау булса, бүрек табылыр! —
Диеп әйткән дустым белеп. —

Ат бәясе булмаса да,
Шактый сумнар бирдем шуңа.
Бик тә таман булды, хәер,
Теккәнмени үз башыма!

Кызыгышып караштылар
Миңа таныш-белешләр дә.
Иске бүрек, туйган бүрек
Оя булсын чебешләргә!

...Бүрек тә юк, баш та тишек
(Өчәү чыкты кич каршыма)...
Алганмын ла икән ич мин
Ул бүрекне... үз башыма!

Минем башта һаман да шул
Кыршылыплар беткән бүрек.
— Бүрек булса, баш табылыр! —
Диеп йөри дустым, көлеп.

*1969*

* * *

Дошманнарга рәхмәт әле —
Котырталар,
Ялкауланып китсәм, эшкә
Утырталар.

Бер ваемсыз йөргән чакта —
Ырылдыйлар,
Ачуымны кузгаталар,
Мырылдыйлар.

Күзләре шар булсынчы, дим,
Ишетәм дә —
Тырышлыкны арттырам мин,
Үч итәм дә.

Ир-егеткә көч бирмәсме
Яңа дау соң?
Гайрәт биргән дошманнарга
Рәхмәт яусын!

*Июль, 1961*

## Балта

Берәү яңа фатир ала.
Мәгълүм инде — бик шатлана.
Бакчасына бер күз сала —
Алмагачлар бик җәл кала,
Алмагачлар бик җәл кала...
Әллә кемгә торып кала!

Хуҗа кара янып чыга,
Өйдән балта алып чыга,
Төпләреннән чабып чыга...
Чабып чыга берәм-берәм:
— Тәки калдырмадым әрәм!..

*1968*

## «Әйдә, чыгып сөйләшик!»

Чир китә, гадәт китми, ди,
Гадәт гомергә кала —
Трамвайда ике картлач
Юктан әрләшеп бара.

Берсе бигрәк тә пырдымсыз,
Теләсәң ничек чыда:
— Әйдә, чыгып сөйләшик! — дип,
Кулын кесәгә тыга...

Бетерә бу, дигән идек,
Валидол алмак икән,
Ярсуларын басмак икән,
Һәм тынычланмак икән:

— Бигайбә, яшьлегем борчый —
Тыялмыйм мин-минлекне,
Һаман үзем дә үзем, дим —
Үзеңдә иминлекме?

— Шөкерле-бөкерле инде,
Шаярткалый шул яшьлек...
Менә минем йортка җиттек —
Әйдә, кереп сөйләшик!

Култыклашып алды болар,
Атлыйлар җайлап кына,
Бозлавыксыз, быжлавыксыз
Сүзләрне сайлап кына.

Була икән бит тырышсаң,
Гадәт дигән чир китә,
Ирләр, илләр арасында
Татулыкка ни җитә!

Йодрыкларны язып кына
Шул хакта да киңәшик,
Чыгырдан күп чыктык инде,
Әйдә, кереп сөйләшик!

*Гыйнвар, 1988*

## Агымдагы ремонт

Балакларымны сызганып
Йөрим яңа өйдә мин.
Күрми калдым, сизми калдым,
Күлдәй булган идәнем...

Барып әйттем управдомга:
— Бетте түзәр чама,— дип,—
Үзе әллә ни акмый да,
Акмаса да тама бит!

Килде оста, алды акча,
Нәрсәдер кайнаштырды,
Нәрсәнедер кыйнаштырды,
Таммаска җайлаштырды.

Иртәгесен — яңадан күл...
— Күрегезче чара,— дип,
Тагын чаптым управдомга.—
Акмаса да тама бит!

Килде оста, алды акча,
Борды да суккалады.
Чакырган саен кергәләп,
Каккалап чыккалады.

...Әйтә икән бу осталар:
— Без беләбез чама,— дип,—
Җаен белеп эшләгәндә,
Акмаса да тама бит!

*Февраль, 1964*

## *«Штраф кына ал лутчы!»*

Хәйрулла агай счетчикның
Кайсы төшендер борган,
Белдерми-сиздерми генә
Ут урлап тормак булган.

Көтмәгәндә монтер кергән —
Агаебыз әләккән!
Янаган теге:
— Мин синнән
Бик зур штраф түләтәм!

— Яхшылыгыңны онытмам,—
Дип ялынгач Хәйрулла,
— Ут урлау — ат урлау түгел,
Дәшмәм,— дигән,— бер юлга...

Шуннан соң, үткән-сүткәндә
Керә дә чыга икән,
Кергән саен яртыны эчеп,
Агайны сыга икән.

Хәйрулланың шактый гына
Кыйммәткә төшкән уты...
— Җитте,— дигән,—
яхшылыгың,
Штраф кына ал лутчы!

*1968*

## Ансыз дөнья сансыз

Әти дә аны яраткан,
Бабай да баш тартмаган,
Ак дип, пакь дип,
пакьлек хак дип,
Эчкән саен мактаган.

Сәфәр чыккан чакларда да,
Үзеннән калдырмаган.
Шешәсеннән генә имгән,
Бер дә ялындырмаган.

Минем дә өстәл өстемдә
Әлеге шул ак тора.
Өстәлемдә шул ак торса,
Күз алларым ялтыра.

Кемнән сорасаң, шул әйтер,
Яшәп булмый ансыз, дип.
Уйлап баксаң, чынлап әгәр,
Ансыз дөнья сансыз бит!

Сез дә каршы килмисездер
Шулай икәнлегенә.
Күтәрик әле бу... сөтне
Сыер исәнлегенә!

*Гыйнвар, 1964*

## Үпкәләштән түгел монда

«Бик кирәктә дуңгызны да
җизни диярсең...»
*«Аптыраган» халык сүзе*

Авыл агайлары сөйли,
Әйтә инде, әйтсә дә,
Үпкәләштән түгел монда,
Артыгракка китсә дә.

— Чарыйлатып куа идек,
Авылга дуңгыз керсә.

— Камунислар кимесә дә,
«Сазнателныс» бит үсә —
Хәзер инде чучкаларны
Каршылыйбыз шатланып —
Бәлки, нужадан чыгарбыз
Шул «айгырга» атланып?

— «Бик кирәктә дуңгызны да
Җизни диярсең» диләр!

— Җизнәң дуңгыз булгачтын соң,
Кем буласың син җүләр?!

— Сарыклардан керем юк бит,
Дуңгыз ул — кәсебеңә.

— Әүвәл керә кәсебеңә,
Аннары — нәселеңә...
Иш-ишен табар, дигәннәр,
Үзең белеп сайлыйсың,
Инде «җизни» дисең икән,
Син буласың, «каенише».

...Авыл агайлары сөйли,
Әйтә инде, әйтсә дә,
Үпкәләштән түгел монда,
Артыгракка китсә дә.

*Июль, 2000*

## *Тәти кашык базардан...*

(Бүләк янына теләк)

Тәти-тәти кашыклар
Китердек без сезләргә,
Насыйп булсын аларга
Балда-майда йөзәргә!
Мәгәр ярдәм кирәксә,
Безне дә чакырыгыз —
Кашыклар әйләнешен
Бергәләп арттырырбыз.
Тәти кашык — базардан,
Майлы ботка — Казаннан:
Кашыксызлар ябыккан,
Зур кашыклы тазарган.
Яхшы тормыш алдамы?
Заман безне алдады,
Теш кысып яши торгач,
Кысарга теш калмады.
Инде эш тә, теш тә юк,
Хәлләр шундый, фаразан:
Кашыкларга ураза —
Ел буена рамазан.
Әйе, тормыш-көнкүреш
Тәмам техникалашты,
Тик авызга кул белән
Ташысак иде ашны.

Баллар-майлар — байларга,
Безгә ничек җайларга,
Очын-очка ялгарга?
Без — хыялда йөзәрбез:
Заман — авыр,
Кашык — җиңел,
Исән булсак, түзәрбез!

*Декабрь, 1998*

## *Читләр читтән күргәнчә...*

Бик ерак бер илдән, ди,
Бер журналист килгән, ди.
Безнең якта күргәнен
Кайткач язып биргән, ди.

«...Төрле анда килешләр,
Төрле анда килбәтләр,
Дөрес әйтеп килгәнбез —
Дус яшәми милләтләр!

Мәсәлән, бер колхозга
«Дуслык» диеп кушканнар,
Бактың исә, үзләре
Менә дигән дошманнар!

Җыйнаулашып сугышлар
Гадәт икән гел генә,
Мин үзем дә юлыктым
Шундыйларның беренә.

...Башта Миклай каршына
Педер атылып чыкты,
Миклай сугуын сукты,
Педер бәреп үк екты!

Учларына төкереп,
Иван торды сикереп
Һәм тондырды Педергә
Мәтәлерлек иттереп!

Киерде дә түшләрен,
Кысты Вәли тешләрен —
Сизми калды Иван да
Җиргә барып төшкәнен!

Булды анда төрлесе,
Буталышып беттеләр,
Капчык белән дөп тә дөп
Тетмәләрен теттеләр!

Мин сизмәсен дип кенә
Елмаешкан итәләр,
Һәм дә шушы сугышны
«Сабантуй» дип әйтәләр!

Юк, киметә алмаслар
Бу фактның кыйммәтен —
Тукмашканда, һәркемнең
Сорап тордым милләтен:

Миклай — мари икән бит,
Педер — чуваш икән бит!
Вәли — татар икән бит,
Иваны — рус икән бит!

Җиңелгәчтен, әлбәттә,
Иван ачулангандыр,
Үч алмакчы булгандыр,
Шуңа күсәк алгандыр!

Арттан килеп бер татар
Тизрәк күзен бәйләде,
Иван селтәп күсәкне
Мәйдан буйлап әйләнде.

Дошманнарга бәрәм дип,
Җиргә суга шап та шап,
Үзләренә тимәгәч,
Педер, Вәли, Миклай шат.

Ярый әле, күсәге
Чүлмәккә генә тиде —

Юкса, Иван беррәттән
Барсын да кыра иде!

Ә бит шушы колхозга
«Дуслык» диеп кушканнар,
Күрдегез ич, үзара
Әнә ничек дошманнар!»

...Бик ерак бер илдән, ди,
Бер журналист килгән, ди,
Сабантуйда күргәнен
Шулай язып биргән, ди...

*Апрель, 1971*

## Хәйләң шул булыр!

Кемгә — бәйрәм,
Кемгә — вәйран.
Кемгә — каймак,
Кемгә — әйрән..

Заманыңның
Хутын өйрән —
Май төшәрлек
Булып әйлән.
Шушы булыр
Синең хәйләң!

*Сентябрь, 2000*

## Бәйрәмдә булган хәл

Сабан туе — җор бәйрәм,
Сабан туе — шук бәйрәм.
Юк аның күк тамаша,
Аның кебек юк бәйрәм.

Ни басынкы агроном,
Хәтта ул да үзгәрде —
Бүтәнчәрәк күзләре,
Бүтәнчәрәк сүзләре.

Сызгыргалап йөрде дә
Әйтте дә салды ярып:
— Мин дә,— ди,— йөгерешкә
Карыйм әле,— ди,— барып.

Ярый, китте. Көтәбез.
Бар да юлга карыйлар:
— Район сабан туе бит,
Сынатмаса ярый ла...

Колхоз исеменнән шул,
Уйлап баксаң, чынлап та.
Куәт бирә рәис тә:
— Давай! Давай! Сынатма!

— Шәп килә бит!
— Маладис!
— Борыннарына чиртте!
Егет килеп тә җитте,
Уктай узып та китте.

Котларга дип йөгердек.
Котларсың, җитеп кара!
— Ипле бара!
— Кая бара?
— Станциягә таба!..

Агроном кире кайтмады,
Кайтты шул хәбәр генә:
Поездга менгән йөгереп
Һәм качкан шәһәренә...

Рәисебез ачудан
Кәпәчен җиргә атты,
Күсәк алып, гарьлектән
Барып чүлмәкне ватты!

...Килгәч яңа агроном,
Әйттек бу хәл турында.
Искә алды рәис тә
Быел сабан туенда.

— Агроном дускай,— диеп
Әйтте, башыннан сөеп: —
Йөгерәм дисәң, йөгер,
Әмма тик капчык киеп!

*1968*

## Ышаныч

Күтәрел көлеп. —
Күтәренкелек!
Яшә — өстенлек,
Дәшмә — мескенлек!

Тик үзебезгә
Җиң сызганасы —
Күктән көткәнне
Җирдән аласы!

*Июнь, 1999*

## Сабан туе батыры

...Кайчан булды, дисәң бу хәл,
Килгән генә ел иде,
Килү белән мул уңышлар
Алам, дигән ел иде...

Һәр авылның үз холкы бар.
Болар бик кырыс кына:
Сүзгә дә аптырап тормый,
Эшкә дә тырыш кына.

Миңа да сынап карыйлар,
Мин дә сынап йөргән чак.
Бер көнне яшь агрономга,
Ягъни миңа, килгән хат.

Сабакташ дус язган икән.
Хатның шундый ахыры:
«Эштә дә сынатма, дигән,
Сабан туе батыры!»

Бу сүзләрдән ни чыгасын
Белгән булсамчы әгәр!
Парторгка да ирешкән
«Батыр ул» дигән хәбәр:

— Килүең бу форсаттан да
Вакытлы,— диде,— бигрәк,
Дружинага синең кебек
Көчле җитәкче кирәк!

Яшермим, җиңел булмастыр,
Очрар төрле егетләр...
Шуңа да сиңа тапшырдык,
Синдә безнең өметләр.

Авыз ачсам да, дәшмәдем —
Тәртип бар да, әдәп бар.

Аннары, тапшырган эшне
Үти торган гадәт бар!

Озын телле сабакташны
Алуын алдым искә...
Бигүк озак көттермичә,
Эш тә табылды кичкә —

Исерек ире тузынганда,
Күрше апа чакырды:
— Син генә тыйсаң инде,— ди, —
Сабан туе батыры!

Каршысында кем торганын
Әллә инде аңлады,
Әллә дулап арган иде,
Абзыем тиз җайланды.

Ә егетләргә килгәндә,
Алар шактый тирләтте;
Егетләрне өйрәтергә
Күп вакытлар кирәкте.

Мактанып әйтүем түгел,
Ә акылга утырттым —
Түгәрәктә игенчелек
Гыйлеменә укыттым!

Буш вакыт кына аздырган,
Егетләр ипле икән;
Чәчүдә ут уйнаттылар —
囙штә дә төпле икән.

Дөрес, караңгы тыкрыкта
Каршыга да чыктылар,
Дөрес, ипле генә итеп,
Күкрәккә дә суктылар:

— Шәп егет икәнсең,— диләр,—
Шәп булуың бик әйбәт.
Инде сабан туйларында
Җиңүләр серен өйрәт!

— Үземнең вакыт чамалы,
Фәнни эш кыса,— дидем...—
Тренерын, ансы, табарбыз,
Теләкләр булса,— дидем.

Сынатмады, сер бирмәде
Эштә чыныгучылар —
Күп булды безнең яшьләрдән
Батырга чыгучылар.

Колхозыбызның исемен
Күмделәр бит, әй, данга!
Көтмәгәндә үземне дә
Чакырдылар мәйданга...

Алкышлап каршылый халык,
Мин нишләргә дә белмим...
Ил алдында хур булганчы,
Дөресен әйтеп бирим:

— Батыр диярге син мине,
Парторг иптәш, ашыкма,
Мин бары йөгергән идем,
Күкәй куеп кашыкка...

Белмәгәннәр: «Шаярма!» — ди,
Ә парторг белеп тора,
Юк мыеклары астыннан
Хәйләкәр көлеп тора:

— Агроном дус, мәйдан сине
Бүтән эшкә чакырды,—
Карар кылдык, бүгеннән син
Безнең кырлар батыры!

Ышанабыз, булган чакта
Сезнең кебек егетләр,
Көрәшләрнең барсында да
Акланырлар өметләр!..

Мин дә күп сөйләп тормадым —
Тәртип бар да, әдәп бар.
Аннары, кушылган эшне
Үти торган гадәт бар!

Һәр авылның — үз холкы шул,
Безнеке кырыс кына.
Сүзгә дә ялкау түгелләр,
Эштә дә тырыш кына!

*Апрель, 1974*

## *Тарафлар*

Күпсенгәннәр түбәндә —
Дөмберди баш түбәңдә.
Азсынганнар тирәңдә —
Үпкәләре тирәндә.
Алда-артта — битараф,
Ачык микән кай тараф?

Аңлап тора тарафдар —
Биек дигән тараф бар.

*Сентябрь, 2000*

## Гомердә булмаганны!..

Гаҗәп хәлләр булгалый
Кичәле дә бүгенле.
Уйлап кына карагыз,
Ис китмәле түгелме?

**1**

Иртән өйдән чыктым да
Барып кердем кибеткә.
Сатучылар шулар да
Шулар түгел кебек тә.

Арты белән борылып,
Кара коелып тормый.
Мөлаем гына карап,
Елмаеп кына тыңлый.

Гомердә булмаганны! —
Бу ни эш, ни тамаша:
Танышы дип белепме,
Миңа әйбер сайлаша?!

**2**

Троллейбуста кондуктор
Кояштай көлеп тора,
Әйтер сүзе бар төсле,
Күземә кереп тора.

Матур иттереп кенә,
Билетлар өзеп тора,
«Бәхетлесен бирәм!» дип,
Шаян сүз тезеп тора.

Гомердә булмаганны! —
Әллә соң ошатамы,
Минем төбәп караулар
Күңелен йомшатамы?

3

Минем хәзер кәеф шәп!
Тикшерүче кергәч тә,
«Юк бит» диеп шаяртам,
Билет сорап килгәч тә.

Янамый да өркетми,
Каш та җыермый хәтта:
— Кайгырма, дөнья булгач,
Булыр,— ди,— булган чак та!

Гомердә булмаганны! —
Ни булган бу кешегә?
Ошаткандыр, мөгаен,
Йә берәр белешенә...

4

Хәйран калып йөрим мин,
Барсам да кая гына.
Бер абзыйның, ялгышып,
Басканмын аягына.

Сүз әйтәлми тотлыгып,
Куркудан чүгәм инде —
Хәзер халык алдында
Эт итеп сүгәр мине...

Гомердә булмаганны! —
Үз итеп башын ия:
— Гафу итегез! — дия.—
Рәхим итегез! — дия.

5

Бөтен кеше елмайгач,
Җырлап эшлим эшемне.
Ни хикмәт, ни әкәмәт,
Өнемме бу, төшемме?

Хәтта ашханәдә дә
Миңа шундый караш, әй;
Иптәшләрчә игътибар,
Ачык чырай, такта чәй!

Гомердә булмаганны! —
Кая барсаң да уңай —
Йә делегат, йә депутат
Диеп белделәр бугай...

**6**

Гаҗәп дисәң дә гаҗәп,
Сәер дисәң дә сәер!
Бу көннәрдә үзем дә
Бөтенләй үзгә, хәер.

Адым саен сукранмыйм,
Юкка-барга бәйләнмим,
Шырпы кебек кабынмыйм,
Бик иплегә әйләндем —

Гомердә булмаганны!
Бар сәбәбе шул икән:
Кеше әйбәт булсын дисәң,
Үзең әйбәт бул икән!

*1968*

# Әдәбият тирәсендә

## *Табиб бәйрәмендә елмаю*

*Фәрит Хафизовка*

Елмаю хәзер дефицит,
Чырайлар бигрәк җитди.
Авыз бәхәстән бушамый,
Көлүгә чират җитми.

Бетте кибеттә елмаю,
Безгәме сагышларга —
Бирәләр итәк астыннан
Бары тик танышларга...

Каш җыерып уйлап торам,
Саектымы маябыз —
Талонга алган шикелле
Бик сирәк елмаябыз.

Сибелеп бетте микәнни
Яшьлекнең юлларына?
Артыграк көлештек мәллә
Торгынлык елларында?

Заманага ничә яшь соң,
Ник аның йөзе чытык,
Ачуташ каптырдылармы
Туктаусыз нотык тукып?

Чү, нигә тынып калдыгыз,
Куңелле табындашлар,
Бу сүзләрнең берсе дә бит
Сезләргә кагылмаслар.

Торгынлыкмы, бүтән чормы,
Яши, эшли белдегез,
Сүзегезгә, үзегезгә
Хуҗа булып көлдегез.

Иманына тугры калды
Бирешмәс гадел җаннар,
Рухташ, уйдаш кардәшләрем —
Фәритләр, Гаделҗаннар.

Язмыш бездән көлмәк булса,
Бергә күтәрик әле,
Тән сызлыймы, җан әрниме —
Көлеп үткәрик әле.

Яшәүнең рәхәтен тоеп,
Сүзебездән дә көлик,
Тәкәбберләр димәсеннәр,
Үзебездән дә көлик.

Көлик, көлик, дип кыстыйм да,
Көләрсең, ди, пычагым! —
Хатының ачып тормаса
Елмаюлы кочагын.

Күзне чагылдырып бик тиз
Югала кыз-рәшәләр,
Гомергә сине кыздырган
Кояшың — янәшәдә.

Демократия юклыктан
Зарланырга хакың юк:
Барыбыз да шундый хәлдә —
Альтернатив хатын юк!

«Көлү» дигән бәлзәмне гел
Кирәк чакта табып тор —
Көлү дә сезнең һөнәрдәш,
Бик борынгы табибтыр.

Елмаюлар балкып торсын,
Бәйрәм мөбарәк булсын.
Түрегезгә бәхет кунсын,
Еллар көлгәләк булсын!

*Июль, 1990*

* * *

Игенчеләр
Тимер төрән белән
Җирне ерта —
Ниятләре изге.

Бакчачылар
Үткен пәке белән
Ботак кырка —
Ниятләре изге.

Докторлар да
Скальпельләр белән
Тәнне яра —
Ниятләре изге.

Әдипләр дә
Кайчак каләм белән
Чәнчеп ала —
Ниятләре изге!

*Февраль, 1964*

## Без

Барыбер бер тишеп чыга,
Без ул капчыкта ятмый.
Шуңа күрә, без — капчыкны,
Капчык — безне яратмый...

*1983*

## Көлке килә...

Гомер буе көлгән кеше,
Көлүнең тәмен белгән.
Көлеп туктагач, үзеннән
Җыерчыклары көлгән!

*Июль, 2000*

## Керпе хәле

Керпе булдым кайбер чакларда,
Кемнәргәдер сүзем кадалган;
Энәләре очлы, димәгез,
Үткенрәге эчкә караган...

*1971*

## *Оныталмыйм сине...*

Унҗидедә сиңа гашыйк булдым,
Үз-үземне онытып сөйдем мин,
Кая басканымны белми йөрдем,
Синең өчен яндым, көйдем мин.

Кайберәүләр әйтте: «Яшьлек үтәр,
Яшь чакта кем шулай шашмаган!»
Сәхнәләргә чыктым синең белән,
Һаман бергә йөри башладым...

Яшьлек узды, ләкин онытылмадың,
Синдә һаман минем күңелем,
Сизә барам, синнән башка миңа
Яшәү инде мөмкин түгелен...

Мине өзелеп сөйгән, якын иткән
Кеше булганда да куенымда,
Күңелемдә минем һаман да син,
Син гүзәлем генә уемда.

Әрсезләнеп киттең үзең дә син,
Трамвайда да яныма киләсең,
Урамда да мине табасың син,
Эш вакытында килеп керәсең...

Һәрвакытта күңелем синдә генә,—
Башым уйлар белән шыгырым,
Язмыш мине кая ташласа да,
Мин ташламам сине — шигырем!

*1955*

* * *

Барган юлдан
Туктап бик күп
Бәйрәм итмик —
Уңышларны
Канат итеп
Алга үтик!

Әле бездә
Җитешмәгән
Җирләр дә бар,
Яшермәскә
Тиеш булган
Чирләр дә бар.

...Мин язам да —
Кимчелекләр
Бетәр сыман,
Илгә йоккан
Чир-шаукымнар
Китәр сыман...

*1967*

## Бар...

Төзүчеләр көне бар,
Геологлар көне бар,
Балыкчылар көне бар,
Шахтерларга да көн бар,
Химикларга да көн бар,
Медикларга да көн бар,
Милициягә көн бар.
Ник
Сатирикларга көн юк?

*1968*

## Әз-мәз мәзәк

Мәзәк тә мәзәк,
Мәзәк-җилбәзәк,
Булсаңчы затлы,
Булсаңчы... әзрәк.

Биек очсаңчы
Көлү-көлгәләк,
Авызга кермә
Җиңел күбәләк.

Кашың җыерма,
«Бу ни гаҗәп?» дип,
Тиккә яздыммы,
«Әз-мәз мәзәк» дип.

Артык тозлы да,
Тәмам тозсыз да —
Кызганыч бит ул,
Һәм кызыксыз да.

Булмасаң иде
Тәнкыйтьтән түбән,
Кендектән түбән,
Кемлектән түбән.

Гомумән, түбән
Булмасаң иде,
Бу шаяртМАУны
Аңласаң иде!

*Июнь, 1999*

## «Иң шәп экстрасенс»

Алар бик күп үрчегән,
Мин ышанам берсенә:
Сизә бөтен серемне,
Бик тә белеп күзәтә,
Сүзсез генә төзәтә.

Төшенке булса күңел,
Аңа проблема түгел —
Хикмәтен белеп кенә
Күтәрә көлеп кенә.
Гипноз булса да ярый —
Ул мине бушлай карый.

Беркайчан зарланма, ди,
Сыкранма, тарланма, ди,
Кешегә сиздермә, ди,
Үзеңнән биздермә, ди,
Үзләренә булыш, ди,
Шулай әйбәт булмыш, ди.

Һәрчак миңа карата
Әйбәт инде, ярата.
Бик тырыша, бик түзем.
Кем дисәң, ул бит — ү з е м!

Үземне, сезне көйләп
Йөрим шаян сүз сөйләп!

*Июнь, 1999*

## ШИГЪРИ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

### *Габдрахман Әпсәләмовка*

(«Ак чәчәкләр» романын укыгач)

Бирәм, диде, роман бирде,
Әпсәләм ул алдамый;
Бусы әле — чәчәкләре,
Җимешләре алда! — ди.

*1965*

### *Аяз Гыйләҗевка*

Юкка йөрде кайберәүләр:
«Алай язма, болай яз!..»
«Өч аршын җир» өч карышка
Үстерде сине, Аяз!

*1965*

### *Илдар Юзеевка*

Кем генә язмый поэма,
Төшенәлми җаена.
Ә сиңа уңыш китерде
«Язылмаган поэма»!

*1965*

### *Хисам Камаловка*

Сирәк кенә биреп төчесен,
Күп күрсәтте тормыш ачысын.
Йомшак табигатьле кеше син,
Кырыс хакыйкатьле кеше син,
Шул сыйфатлар белән көчле син!

*1967*

## *Равил Фәйзуллинга*

Бар иде кызыл шигырьләр...
Син язасың ак шигырь.
Әгәр булмаса сак шигырь,
Әгәр булмаса вак шигырь,
Әгәр булмаса чак шигырь,
Әгәр дә булса хак шигырь —
Ник язмаска ак шигырь!

*1966*

## *Нил Юзиевка*

(«Традицияләр яңарганда» исемле китабы уңае белән)

Эзләнергә, уйланырга,
Шигырь диеп янарга,
Сау шагыйрьләр турында да
Мөмкин икән язарга!
Традицияләр яңара!!

*1967*

## *Рафаэль Мостафинга*

«Туры сүз таш яра» диләр,—
Икеләнми эшең башкар;
Без барасы юлда ята,
Син ярасы бик күп ташлар.

*1970*

## *Автоэпиграмма*

Үземә дә шәфкатьсез мин;
Кичектермичә бер дә
Каты әйтәм —
Кешеләргә
Ишеттермичә генә!..

*1970*

## ЭПИГРАММАЛАР

(Әдәбият түтәлендә)

### *Хикмәтле уңыш*

Шагыйрь алды халык җырын,
Композитор калыплашты.
Соңрак алар мактанышты:
— Безнең җыр бит халыклашты!

*1965*

### *Чамалый...*

«Халтурщик...» дип авыз ачсаң,
Бигрәк шома ычкына;
Син исемен атаганчы,
«Бетсен!» — диеп кычкыра.

*1965*

### *Тактика*

Тыйнаклык мәсьәләсендә ул
Бар кешедән арттыра —
Беркайчан үзе мактанмый,
Бүтәннән мактаттыра!

*1965*

### *Таныш сере*

Әдәбият ишегеннән
Һәркем үзенчә керә:
Берәүләр — иҗаты белән,
Берәүләр — булып түрә.

*1965*

## Парадокс

Булмады дип кемнәр әйтер,
Булды инде андыйлар:
Башта Мәскәүдә таныйлар,
Ә аннары
Казанда да аңлыйлар!

*1965*

## Аныңча

— Халык теленә керер өчен,
Әүвәл тәрәзне ватар.
Үскәч, шигырь юлын ватар —
Шушы булыр новатор!

*1965*

## Юл газабы

Үтәм шигырь юлларыңнан
Булырмы, дип, бер азагы?
Бигрәк белеп әйткән халык:
«Юл газабы — гүр газабы»!

*1964*

## Шигырьчегә

Ничә карасаң да, китабыңда
Хуплар өчен урын әз әзен,
Мактамыйча булмый әмма тышын
Һәм шытырдап торган кәгазен!

*1967*

## Бай традиция

Иҗатың бай традицияле,
Тамыры тирән киткән,
Халтура дигән нәрсә дә
Килә бит ул бик күптән!..

*1967*

## *Мәкаль хөкеме*

Шундый нәтиҗәгә киләм,
Тәрҗемәңне укый торгач:
«Татарга тылмач кирәкми»
Һәм бигрәк тә синдәй тылмач!

*1967*

## *Бер язучы юлы*

Авылда туды,
Шәһәргә шуды
(Һәм гомер буе
Җырлады шуны)!

*1965*

## *Универсал*

Авторыбыз уңган
Һәр яктан,
Әсәр бирә барлык
Тармактан,
Суырып кына тора
Бармактан!

*1963*

## *«Регламент!»*

Сүзләреңнең очы-кырые юк,
Ташкынына тәмам күмәсең.
Күп сөйләсә кеше, сагаям мин,
Әйтер сүзе юктыр, күрәсең...

*1963*

## Бер газета редакторына

Шатланырсыз дип уйлыйм
Болай мактап язганга:
Ял итәм сезнең гәҗитне
Кулларыма алганда —
Укыр нәрсә аз анда!

1967

## Икәүләп

Икәүләшеп язалар да
Икәүләп үткәрәләр,
Тәнкыйть тә җиңелгә килә —
Икәүләп күтәрәләр.

1967

## Без үзебез

Без үзебез дә үткеннәр,
Үткеннәрне яклыйбыз.
Салмагыз безне капчыкка,
Без капчыкта ятмыйбыз!

1967

## Дөнья — куласа...

«Картлар алай, картлар болай» диеп
Йөри торгач,
Яшь гомерләр үткән.
Инде менә:
«Яшьләр алай, яшьләр болай» диеп
Сукраныр чак җиткән...

1967

## *Хакыйкать*

Чыкмый сиңа
Эпиграмма —
Фикерең, юк
Ике грамм да!

*1965*

## *Ярты-йорты*

Ятканы — ярты
Һәм Матбугат йорты.
Язганнары
Ярты-йорты!

*1965*

## *Үзгәреш*

— Инде хәзер ул язганны
Беркем әйтми начар дип.
— Остардымыни?
— Остарды...
Ул бит хәзер начальник!

*1967*

## *Ник?*

Язганнарың — ташка үлчим,
Бу өлкәдә уңмадың син.
Әмма бик тә шәп укыйсың!
Ник укучы булмадың син?!

*1967*

## Тынычлан

Ерак киләчәгең уйлап
Борчылма, иптәш, бер дә —
Тынычлан,
Син язганнарны
Укымыйлар бүген дә!

*1963*

## Астыртын

Сине дә ул сөзмәк була,
Мине дә ул сөзмәк була:
Ярый әле —
Сөзгәк сыер мүкләк була!

*1967*

## Кәсепчегә

Тырышасың, тырмашасың,
Күп язасың. Ә шулай да
Язмый торсаң, укучыга
Булыр иде күбрәк файда!

*1965*

## Юлдан язган

Аннан йолкып, моннан йолкып
Юллар тезә, күз дә йоммый.
Гомер буе шулай җырлый —
Үзе урлый, үзе юллый.

*1968*

## Актив

Язар иде — булдыралмый,
Үзе тик тә торалмый;
Иҗаттагы кысырлыгын
Нотык белән томалый.

*1965*

## Сукранучы

— Берзаман, тормышлар тәмам
Әйбәтләнгәч, нишләр ул?
— Сукраныр нәрсә калмады,
Дип сукранып яшәр ул!

*1967*

## Әдәбият түтәлендә

Мәгълүм инде ни икәне
«Кат-кат тунлы, карыш буйлы».
Әдәбиятта кем икән —
«Кат-кат томлы, карыш уйлы?»

*1969*

## Турысы

— Ни әйтерсең
Шушы сәнгать
Әсәренә?
— Бу әсәрдә
Юк сәнгатьнең
Әсәре дә!

*1967*

## Әдәбият дәрьясында

Тулганабыз
Бер тирәдә...
«Кермәгез, дип,
Бик тирәнгә!» —
Җаваплылар
Күзләп тора:
Санап тора,
Эзләп тора,
Чикләп тора
Кызыл «буйлар»!
...Чыпырдаша
Сайда уйлар...

*1972*

## Үзең нинди...

Бик тә сай бит, бик беркатлы,
Бик төссез геройлары —
Ташка үлчим генә инде
Хисләре дә уйлары!

Үзеннән-үзе нәтиҗә
Чыгадыр, ахры, моннан —
Геройлар шул акыллырак
Булалмый авторыннан...

*1968*

## Надан

Укып карыйм уңнан, сулдан,
Укып карыйм яңадан;
Кайсы яктан карасаң да —
**Надан** барыбер **надан**!

*Февраль, 1967*

## «Кыскалык — талантның сеңлесе...»

Чехов сүзен кабатлыйсың...
Онытма шул ягын да:
Сеңелләр була дөньяда
Апалар булса гына;

Синең урында отадыр
Эчтән тынганнар гына:
Иҗат-ыруың бер төрле —
Гел ир туганнар гына...

*1988*

## Кыюлык турында

Әйттеләр бер шагыйрьгә:
— Син дә яшисең җирдә...
Тарихка кара, туган,
Нинди кыюлар булган!

— Әйе, беләм, мин сак шул...
Безгә кыю булу кыен,
Үлгәннәргә ансат ул!

*1967*

## Сырганак

Зур идеягә дә кайчак
Вак адәмнәр сырыша.
Мактый-мактый,
мактый-мактый
Туеныргa тырыша.

*1968*

## Кисәтү

Суккан чакта көннең
Кадагына,
Саклан, әләкмәсен...
Яңагыңа!

*1977*

## Өлгер «шагыйрь»

Әле карасы кипмәгән,
Инде тәрҗемә иткән...
Мөслимгә килеп җитмәгән,
Мәскәүгә барып җиткән!

*1984*

## Мактана торгач

Тукай диеп, без горурлар, мактанабыз:
Яхшы белгән сүзнең эшен, сүзнең көчен!
Туры Тукай безгә карап нәрсә дияр,
Кызармасмы шагыйрь бүген безнең өчен?..

*1976*

## Кызганыч хәл

Чама белә —
Ах, сак!
Яза белә —
Ах, сак!
Яши белә —
Ах, сак!
Фикер ягы...
Аксак.
Ерак китәр
Аксак!

*1967*

## *Сүз кадере*

Күзен май баскан тавыктай
Җырлап йөрисем килми;
Урынлысын-урынсызын
Зурлап йөрисем килми...

*1960*

## *Аңлашу*

Шактый нәрсәне төшенгән,
Шактый нәрсәне аңлый.
Тик...
Искечә җырлыйсы килми,
Яңача җырлый алмый...

*1964*

## *Сәхнә артында*

Пьесаның шомасын
Сәхнәгә куябыз.
Тешлесен сәхнәнең
Артына җыябыз!

*1965*

## *Тел-теш*

Тел ягыннан әсәренә
Тел тидергән кеше юк.
Теле шома. Бигрәк шома —
Бер генә дә теше юк...

*1972*

## Тормыш өйрәнүче зары

Шофер кеше машинасын
Уңга бормыш, сулга бормыш.
Аның рәхәт. Минем генә
Өйрәнәсе бар бит тормыш...

Игенчеләр иген икмеш,
Мал үрчетмеш, йортлар кормыш.
Аларның җай. Минем генә
Өйрәнәсе бар бит тормыш...

Терлекчелек фермалары
Рәт-рәт булып тезелеп тормыш.
Төш чагында шунда барып
Мин өйрәнеп кайттым тормыш.

Күрдем тавык-чебешен дә,
Сыер, сарык, үгезен дә,
Тарттым кәҗә сакалын да,
Тоттым үгез мөгезен дә.

...Кайттым. Яздым. Редакторлар
Әсәремне кире бормыш...
Инде шул да ярамагач!
Инде минме белмим тормыш?!

*1961*

## *Танышлык белән...*

Булдым мин бер танышымда
Бик күңелле табында.
Бик белгәннәр арасында
Бер белмәгән бар монда.

Мәҗлес түренә утыргач,
Бик якыны буласы —
Сорап өлгерә алмадым,
Килгән мәллә кодасы?

Үзе дә утыра абзый
Бәһасен белеп кенә,
Тыңлыйлар аның һәр сүзен
Күзенә кереп кенә...

Кич буе кадерле кунак
Игътибар үзәгендә.
Җупләргә туры килә бит
Иң тозсыз сүзләрен дә.

Сүз аралаш сала торгач
Кызып алды бу шактый,
Хуҗаларга илтифат юк,
Столичныйны мактый.

Ник мактавы аңлашылды:
Ул табып бирә икән!
(Шешәләренә ияреп,
Үзе дә килә икән...)

Тотып алды мине дә бу
Тәнәфес арасында:
— Тсс! Танышлык хакына,— ди, —
Табарбыз барысын да!

Безнең эш тә җиңел түгел,
Юк кына аңлаучылар.

Син менә союзпичәттә
Миңа да шигырь чыгар!

— Тсс! Танышлык белән аны
Эшләргә була,— дидем.
...Һәм итәк астыннан гына
Шушы шигырьне бирдем.

*1969*

## *Аптырагач...*

**1**

Шигырьләрен укыйлар да
Киңәш бирәләр аңа:
— Син, энекәш, ни инде...
Хикәя язып кара.

**2**

Хикәясен дә укыйлар,
Киңәшчеләре яңа:
— Син, иптәшкәй, ни инде...
Пьеса язып кара.

**3**

Драмасын укып карыйлар,
Юк тагын бүтән чара:
— Син, абзыкай, ни инде...
Тәнкыйть тә язып кара.

Әйтте агай, дулкынланып,
(Күзендә аның яшьләр):
— Минем хәлләр, алайса,
Ничава бит, иптәшләр!

*1968*

## *Очраклы хәл*

Икеләнеп йөрдем дә мин
Тәки баздым —
Үзем белгән директорга
Төртеп яздым:
«Аерылдың халыктан, дим,
Тәмам аздың!»
Әсәремне матбугатка
Алып бардым.

Әдәбият бүлегендә
Бер сотрудник:
— Бу,— ди,— ни,— ди,—
очраклы хәл,
Түгел типик,
Беләсеңме, әйдә, ни,— ди,—
Болай нитик —
Түбәнәйтик — урынбасар
Моны итик!

Дөрес сөйли, ничек каршы
Сүз әйтергә,
Теләп шигырь бастыруны
Тизләтергә,
Шунда ук мин каләм алдым
Төзәтергә —
Тиешенчә типик итеп
Үзгәртергә.

Мөдиренә бүлекнең без
Кертеп бирдек.
— Бу,— ди,— ни,— ди,—
мәгълүм инде —
Түгел типик,
Беләсеңме — мәгълүм инде —
Ни,— ди,— нитик,
Әйе, әйтик, бер управдом
Моны итик!

Секретарь да, редактор да
Тамга салды,
Һәр бүлектә үзгәрешләр
Була барды —
«Аерылды халыктан һәм
Тәмам азды» —
Мәгълүм абзый тик дворник
Булып калды...

...Белеп торам — мондый автор
Түгел типик,
Сизеп торам — редактор да
Түгел типик.
Беләсезме, мондыйларны,
Әйдә, нитик —
Әлеге дә баягы инде —
Дворник итик!..

*1969*

## Үз кальбына

Әйтеп куйды, диңгез шавын
Тыңлагачтын:
— Нинди су бу, бакасы да
Булмагачтын!

*1961*

## *Кемгә нәрсә...*

...Кибетләре зур икән,
Шүрлекләре тар икән.
Шүрлекләре тар булса да,
Шактый нәрсә бар икән.

Мин шүрлекләрне күзләп,
Әйләнәм китап эзләп,
Ничек кенә үрелмим,
Күренми дә күренми,
Шешә генә, гел шешә...

Йөри торгач күз төшә:
Шул шешә артларында
Тора китапларым да!
Тәртип дисәң дә тәртип...
Шул якка таба төртеп
Сорыйм мин кибетчедән:
— Ничек соң, үтәме? — дим.

— Ә син әйт, җитәме, диң! —
Елмаеп куя агай:
— Ул шундый товар, малай,
Торса да шүрлек тулып,
Тормый һич тузан кунып!

(Сата белә китапны! —
Дип куям инде эчтән,
Көтмәгән идем һич тә!)
— Соң, мәйтәм, ничек үзең...
Әйтеп бетермим сүзем,
Күз кысып куя агай:
— Үзең беләсең, малай,
Яшәп булмый ансыз һич,
Ансыз дөнья сансыз ич,
Кайгыны тараттыра,
Безгә шул ярап тора.

Хатын гына орыша,
Биздерергә тырыша,
Имеш, акча туздырам,
Көнем әрәм уздырам!

(Хатынмыни ул хатын,
Күпсенгәч китап хакын!)
— Кем күбрәк ала, агай? —
Дигәч, кибетче көлә:
— Ә монсын инде малай,
Райкомнар шәбрәк белә!
Күпләр шелтә алдылар,
Көчкә эштә калдылар...

— Китап өчен?! Шелтәме?! —
Агай кулын селтәде:
— Ниткән китап? Кем әйтә?
Кем баштан сыйпар, мәйтәм,
Сала белмичә салгач,
Ящигы белән алгач! —
...Төшендем тик шулчакны:
Күзләсәк тә бер якны,
Мин күргәнмен китапны,
Ә кибетче — гел акны...

Кибетләргә кердем мин,
Шундый хәлләр күрдем мин;
Китап — шешә артында,
Чөнки сельпо халкында —
Аракы алгы планда,
Шулай тула план да!

*1956*

## Әшрафҗан китаплары

Әшрәфҗанның бүлмәсендә
Китаплары — йөзләгән,
Ниндиләрне алмаган да,
Ниндиләрне тезмәгән!

Китап дигәндә бу кеше
Инде гел харап кына:
Сабый шикелле яратып,
Тота бик карап кына!

Күреп гыйлемнең нигезен
Гаҗәп-хәйран каласың,
Сокланасың Әшрафҗанга,
Чамалыйсың колачын.

Әйтерсең лә шәһәрнең бу
Берәр гыйльми үзәге!
Әлбикә ханым кушыла:
— Китап — өйнең бизәге.

Әйе, әйе, Әшрафҗанның
Китаплары йөзләгән.
Әмма гыйлем диңгезендә
Чуммаган ул, йөзмәгән.

Салкын пыяла аркылы
Яши ул барлап кына,
Укымый да укытмый да,
Тора тик карап кына!..

*Февраль, 1964*

## Ах...

Һәркем дә ярата аны,
Андый кеше азласа!
Бар ягы да килгән инде,
Ах, шигырь дә язмаса!..

*1972*

## Чират күреп сөендем

Кибеткә барып кердем,
Чират күреп сөендем.
Чираты да чираты —
Борма-борма, бормалы!
Бу кадәрле чиратның
Булмагандыр булганы.

Ашык-пошык сорашып,
Мин дә бастым очына.
Киштәләргә карашып,
Күршеләрем борчыла:
— Икешәрне бирмәгез!
— Әй, чиратсыз кермәгез!
— Шулхәтле көтеп-көтеп,
Нишләрсең, куйса бетеп!..

Кибеткә тагын кердем,
Чират күреп сөендем.
Бетмәсәче бу чират,
Килсәләрче гел сорап
Рухи азыкны шулай.
Мондый чират бик кулай;
Басыгыз, бас чиратка,
Без торабыз китапка!

*1963*

## *Бабай җыена җомгага...*

Бабай җыена җомгага:
Сакалын тарап ала,
Стенадагы күкеле
Сәгатькә карап ала.

— Биш туларга унбиш минут!
Соңга калам бит инде...
Түбәтәемне табалмыйм,
Карчык, ярдәм ит инде!

Түбәтәе дә табыла,
Сөртелә хушбуе да:
— Насыйп булса, җомгаларны
Калдырмам кыш буе да.

Бармый калсам, эчем поша —
Күнегелгән күптәннән.
Ни әйтсәң дә, гомеребез
Шул тирәдә үткән лә...

Танышларың очрап куя,
Кордашларны күрәсең.
Өеңә күңел хушланып,
Җиңел кайтып керәсең.

Бабай ашыга җомгага:
Мыегын тарап ала,
Кулында — Чистай сәгате,
Күзлексез карап ала...

Мин дә кердем аның белән
Авыр ишекләр ачып.
Урын җитми калганнары
Тыңлап тордылар басып.

Ошата, димәк, кешеләр,
Җанга азык табалар.

Кызыкларыннан көләләр,
Шаулатып кул чабалар.

...Нинди җомга икәнлеген
Калдырып тордым соңга:
Тукай клубында булды
Бик шәп әдәби җомга!

*1960*

## *Барабан йоткан мәллә?*

Мәзәкче күрдем циркта,
Аптырап эчен тоткан:
Авызына капкач, имеш,
Ялгыш сыбызгы йоткан...

Йөри-йөри дә тулганып,
Үзенчә җыр сыздыра.
Тик тавышы ишетелми —
Гел сыбызгы сызгыра...

Аны күргәч искә төште
Шигырьче бер танышым,
Ни гомердән бирле һаман
Ишетмим үз тавышын.

Кайбер гадәтләрен ул да
Циркта откан мәллә,
Җырлаган бер җыры дөмбер,
Барабан йоткан мәллә?!

*1961*

# Аннан-моннан

## *Әмин белән Дәмин*

«Дага» артелендә
Әмин бар,
«Дуга» артелендә
Дәмин бар.

Дагалары сына
Әминнең,
Дугалары шартлый
Дәминнең.

Эшең пешми, диләр
Әмингә,
Рәт чыкмады, диләр
Дәмингә.

Рәислектән оча
Әмин дә,
Рәислектән оча
Дәмин дә!

Кая киткән, димсең,
Әминне?
Кая күчергәннәр
Дәминне?

«Дага» артелендә
Дәмин бар,
«Дуга» артелендә
Әмин бар...

*Октябрь, 1959*

## Ул да шундый...

Уенчыкның була шундыйлары,
Ачкыч алып кына борасың —
Тыз-быз килеп чабып йөри башлый,
Кызыксынып карап торасың.

Ә борганы беткәч, туктап кала.
Нәкъ шундый ук минем күршем дә:
Чакыргалап колагын бормасалар,
Шып туктала ул да эшендә.

*1957*

## Хикмәтле икмәк

Алдым икмәк, тоттым иплэп,
Бәлагә калдым юлда;
Өч адым да атламадым,
Икмәк таралды кулда.

Киттем-бардым пекарняга,
Сорадым: «Нинди хикмәт,
Үзегез тирләп-пешкәнсез,
Нигә пешмәгән икмәк?»

Пекарня мөдире әйтә:
«Чиен чи, ну көймәгән...»
Әйе, дидем, күренеп тора,
Тәнкыйть уты тимәгән!

*Август, 1952*

## «Кеше хәлен кеше белми...»

Ничә барып, ничә әйттем,—
Бик беткән бит түшәм, дип,
Зинһар, төзәтә күрегез,
Тора төшәм-төшәм, дип...

Колак салучы булмады,
Түшәм төште ишелеп.
Түшәм төште, мин больниска
Киттем башым тишелеп...

Яныпп-пешеп чапсаң да ул
Пешми бит эш пешмәсә.
Кеше хәлен кеше белми,
Үз башына төшмәсә...

*1959*

## Бракчы ник шурлаган?

Болытларны ашып, күктә очабыз.
Төшкән, ахры, коты ботына —
Самолет чак селкендеме, берәү
Утыргычка ныграк тотына:

— Минем деталь шушы машинага
Эләкмәсә ярый... Җир ерак...
Исән төшсәм, иренмәс лә идем,
Җибәрмәс лә идем һич брак...

*1957*

## Оста

Гаҗиз булдым мин ай буе йөри-йөри:
«Ник бу оста ботинкамны рәтли алмый?»
Хикмәт шунда икән: көн дә баш төзәткәч,
Ботинкамны төзәтергә вакыты калмый...

*1958*

## Фокусник килгән авылга

Фокусник килгән авылга,
Клуб шыгырым тулы.
Күз иярми, уйнап кына
Тора каһәрнең кулы!

Һавадан күкәй чүпли ул,
Минутта чиләк тула...
(Ферма мөдире Заһитның
Күзе шакмактай була.)

Кукуруз орлыкларын да
Чәчкән иде идәнгә,
Куе урман кебек булып
Үстеләр «ә!» дигәндә.

Урынында утыралмый,
Рәискә күз сал әле,
Кычкыра сәхнәгә карап:
— Энем, бездә кал әле!

*Октябрь, 1959*

## *Аннан-моннан* *

Фабрикада эшли Маннан,
Ботинкалар тегә Маннан.
Ничек эшли дисәң Маннан:
Аннан-моннан,
Аннан-моннан...

«Үзем өчен түгел» диеп,
Кулын гына селти Маннан.
Ботинканы сатып алган
Магазинга чыгып Ханнан.

Азмы-күпме вакыт үткән,
Ботинканың рәте киткән.
«Әйберләре начар!» диеп,
Фабриканы Ханнан сүккән.

...Заводында эшли Ханнан,
Телевизор ясый Ханнан.
Үзе ничек эшли Ханнан?
Аннан-моннан,
Аннан-моннан...

«Үзем өчен түгел» диеп,
Авыз гына ера Ханнан.
Телевизор сатып алган
Магазинга чыгып Маннан.

Ничә генә көннәр үткән,
Төзәтергә алып киткән:
«Әйберләре начар!» диеп,
Заводларын Маннан сүккән.

*

Кайберләрнең исемнәре
Булмаса да Ханнан, Маннан,
Бер нәтиҗә ясар моннан,
Укымаса аннан-моннан!

*Июнь, 1966*

* Резеда Әхиярова музыкасы.

## «Ай, дүдәк, дүдәк...»

«Кыйгак-кыйгак,
бак-бак-бак-бак» дигән
Тавыш килә клуб ягыннан.
Шул тарафка киттек иптәш белән,
Ул да шушы җырны сагынган.

— Күр, үзешчән сәнгать тырыша бит,
Бигрәк әйбәт чыга бу «Дүдәк»!
Клуб ишеген барып ачкан идек,
Каршы алды безне... каз-үрдәк.

*1957*

## Чагыштыру

Кышын безнең
Көтепханә —
Менә дигән
Котыпханә!

*1964*

## Кырда

— Ник таптыйсың бәрәңгене,
Хәзер колагыңны борам!
— Белмәдем бит, абзыкаем,
Колхозныкы диеп торам...

*1959*

## Ярдәм

Колхоз тормышында вәкил
Борылыш ясап китте:
Алты күкәй әзерләште,
Алтмышны ашап китте!

*1964*

## *Килде-китте*

Командировкага килеп,
Колхозда ул өч көн булды,
Әрле-бирле йөренде дә:
— Китәм,— диде,— срок тулды.
«Килде», «китте» дип кәгазьгә
Язып бирсәгез, шул җитте...
— Алдыңнан артың хәерле,
Эшең дә шул «килде-китте»!..

*1959*

## *Тырыш*

Ятмый вакытын
Бушка үткәреп,
Ялт та йолт кына
Тора түнтәреп —
Мускул үстерә
Кашык күтәреп!

*Сентябрь, 1963*

## *Лотерея*

Бергәләшеп билет алдык,
Ә отуын ул отты:
Ялкауның бәхет йокламый —
Йокы капчыгы чыкты!

*1969*

## *Чир*

Мактанучан
Ирләр була.
Ирләр нәрсә —
Илләр була...

*1970*

## Агай үе

Уч-уч орден-медаль өләшәләр,
Кемгә генә инде бирмиләр,
Әллә шунда чама белмиләр?

Әмма никтер мине күрмиләр...
Җәлмени соң шунда бер медаль?..

*1967*

## Гыйбрәт

*Бер дуска*

«Аягым юк» диеп гел кимсенмә,
Әрнүләрең сызма тирәнгә,
Ташла зарлануың,
Башсызлар да
Йөриләр бит әле тирәндә!

*1959*

## Кечке серенада

«Гомер үтә, тик торам, ай,
Тик торам, вай,
Һаман көтәм, килмисең ләй
Ник, трамвай?..»

*1958*

## Төшенгәннәр

Сөйләштеләр, серләштеләр
Мичкәдәге балыклар:
«Гомер буе троллейбуста
Ничек йөри халыклар?!»

*1962*

## *Читтән торып*

Сезнең нәрсә — диплом кулда,
Тик йөрисез авыз ерып.
Тырышып та тырмашып мин
Укып йөрим
Читтән торып.

Әле ярый, дуслар яхшы,
Ярдәм кулын сузалар гел —
Мәсьәләләр чишәләр гел,
Сызымнарны сызалар гел.

Инглизчәсе терәлсә дә,
Төкерәм дә китәм торып.
Дустым сүзлек актарганда,
Куәт бирәм
Читтән торып.

Контроль эшләр өелсә дә,
Рәхмәт инде — чыга ерып;
Дустым мышнап утырганда,
Мин дәрт бирәм
Читтән торып.

Экзаменнар килеп җиткәч,
Шәп планнар эчтән корып,
Башкаларның укыганын
Тыңлаштырам
Читтән торып.

Булмый башны ташка орып,
Чыгардылар тагын борып.
Курсташлар күчкән чакта,
Башны кашыйм
Читтән торып...

...Сезнең нәрсә — диплом кулда,
Тик йөрисез авыз ерып.
Тырышып та тырмашып мин
Укыйм һаман
Читтән торып...

*Август, 1964*

## Кысалар...

Автобуска ерып керде
Шактый юан танышым.
Ишеттем калын тавышын:
— Нихәл, эшкә барышмы?

Автобустан чыккан иде,
Чак таныдым танышны —
Үзе дә нәп-нәзек калган,
Һәм неп-нечкә тавышы...

*Февраль, 1977*

## Озын чираттагы кыска уйлар

Әгәр дә мәгәр әҗәлгә
Чират торыш булса иде,
Гомерләр тиз үтмәс иде.
Һәм андый дефицит әле
Безгә һич тә җитмәс иде!
Хәер, ул бит танышларга
Арт ишектән китмәс иде,
Димәк ки, ягъни мәсәлән,
Андый товар бетмәс иде...

*1989*

## Кибеттә

— Алга! — диеп сөрән салдык,
Ник әле тынып калдык?

— Чират әкрен барды ла —
Чиратта торып калдык...

*1989*

## «Ансы безнең эш түгел»

(А.Мелузниковтан)

Искелекнең калдыклары
Югала бара, бетә.
Тик күбесе әле безнең
Очлы каләмне көтә.

Сөйләмәкче булам бүген
Сезгә шушы җырымда:
«Ансы безнең эш түгел!» — дип
Яшәүчеләр турында.

*

Ялкаулыкның чигенә чыккан,
Ай-һай бозык бала ул;
Аннан жалу, моннан жалу —
Бала түгел, бәла ул.

Борчылмый әти-әнисе,
Тыныч аларның күңел:
— Тәрбия, ул — мәктәп эше,
«Ансы безнең эш түгел!»

*

Хуҗага тел тидерде ул,
Кемлегенә карамый.
Туры әйткән, шулай инде,
Туганына ярамый —

Тәнкыйтьләүче хисабына
Штат кыскара бүген.
Местком исә читтә тора:
«Ансы безнең эш түгел!»

*

Дүрт хатында — дүрт баласы,
Бар да көтә алимент.

Галләметдин алименттан
Кача торган элемент.

Күргән-белгәннәр кул селти:
— Шома ычкына бу гел.
Судья чамаласын, диләр,
«Ансы безнең эш түгел!»

*

Узган-барганга бәйләнеп,
Исерек кайта җикереп,
Җиде бабаңа җитә ул,
Йә тамыза китереп.

Читләтеп үтә кешеләр:
— Узындырып йөртү гел
Килешми дә килешүен,
«Ансы безнең эш түгел!»

*

Архитектор складның
Проектын эшләде.
Бу әкәмәтне күргәннәр
Телен генә тешләде.

Ә өлкәне раслый шуны:
— Бизәсен шәһәр күген.
Артык акча чыкса чыгар,
«Ансы безнең эш түгел!»

Төн буе йокы симертә,
Көн буе ята хырлап.
Кеше җиң сызганып эшли,
Ул йөри һаман җырлап.

— Торма,— диләр,— сызгырып гел,
Ал көрәк, бераз бөгел...
Исни ул иренеп кенә:
«Ансы безнең, эш түгел!»

*

Кимчелек беткәнен, иптәш,
Кул кушырып көтмә син,
«Ансы безнең эш түгел!» дип,
Читтән генә үтмә син.

*1957*

## Киләчәк, сиңа әйтәм, бүген, син тыңла

### Председатель кайда?

Кызу урак өстендә ул
Космоста очып йөри,
Айга менеп, аяк тибеп,
Иж суы эчеп йөри.

### Ферма отчеты

Бер дә түшәмгә карамый,
Бу мөдир күккә карый;
«Үгез бозау» йолдызларын
Отчетка кертеп саный...

*1962*

### Газета хәбәреннән

Толыпларның һәм туннарның
Кирәге тәмам бетте:
Әлмәт ягында янган газ
Котыпларны эретте.

*1962*

## Сәер табылдык

Борынгы бер баш табылды
Боз диңгезе төбеннән.
Яла ягучы икәнен
Таныдылар теленнән.

*1962*

## Яңа диссертация

Бик өлгергән мәсьәләсе,
Актуаль темасы да:
«Озынборынның тәэсире
Кояш системасына».

*1962*

## Суны нефтьләндерү проблемасы

Чиста агымда балыклар
Яши алмый ничек тә —
Харап булалар нефтьсез,
Күнеккәннәр нефтькә!

*1962*

## Ай космодромында

Кәлимулла риза түгел
Аэропортта фәрманга:
— Өч минутка соңга кала
Ракеталар Сарманга!

*1962*

# Лично үзе

## *Яңабаштан*

...Мөхәммәтша
Килде дә:
— Без — яңача! —
Диде дә
Эшчәнлеген
Күрсәтте,
Кабинетны
Үзгәртте:

— Бүтән төскә
Буярга,
Моннан ишек
Уярга,
Зуррак өстәл
Куярга!

Үтте көннәр
Шул рәвеш,
Тик эштә юк
Үзгәреш.

Түргә түрә
Беткәнме;
Җибәрделәр
Рөстәмне.
Бусы да эш
Күрсәтте,
Кабинетны
Үзгәртте:

— Бүтән төскә
Буярга,
Моннан ишек
Уярга,
Өстәп өстәл
Куярга!

Үтте көннәр
Шул рәвеш,
Тик эштә юк
Үзгәреш.

— Уңмадык! — дип
Кудылар,
Мөхәрләмне
Куйдылар.
Бу да үзен
Күрсәтте,
Кабинетны
Үзгәртте...

Шуннан килде
Габделхак...
Яңабаштан
Укып бак!

*1966*

## Һайтка тайт...

Шап-шоп басар үкчәсен ул,
Һәм киерер бүксәсен ул.
Кирәк икән — күз дә буяр,
Кирәк икән — күз дә буар,
Кирәк икән — сүз дә буар...

*1964*

## *Бер директорның яраткан җырлары*

*

Әй, дусларым да гынай, Закир абый,
Сезнең белән, Җамалый кода,
Шат минем күңелләрем,
Сәйфетдин җизни, Якуп агай-эне.
Сезнең белән бергә, бер конторда,
Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,
Үтсә иде лә гомерләрем.

*

Ай яктылары ла, Мәрьям кодача,
Бигрәк якты, Зәйнәп балдыз,
Утырып кынай мәрҗән тезәргә,
Гайшә кодагый, Галия кайнигәч.
Үз дускайларыңлай бигрәк яхшы,
Зәйнәп балдыз, Мәрьям кодача,
Гайшә кодагый,
Утырып ла киңәш итәргә.

*

Агай да гына эне, Зиннур туган,
Ак та мыек, Әкрам баҗай,
Бер-беребезне какмыек.
Каюм күрше, Насыйх каениш,
Кага да гына суга башласалар,
Зиннур туган, Әкрам баҗай,
Насыйх каениш,
Зәйнәп балдыз, Мәрьям кодача,
Гайшә кодагый,
Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,
Җаен гынай табып яклыек!

*Август, 1963*

## Мөстәкыйль Мөстәкыйм

Гел районга шалтырата
Юкка-барга Мөстәкыйм,
Киңәш сорый, рөхсәт сорый:
— Ничек итим? Нишләтим?

Багланышта тора икән,
Тыңлаучан кеше, димсез?
Үз өстенә җаваплылык
Аласы килми, юньсез!

Мине генә көтмә син, дим,
Үзең хәл ит мөстәкыйль.
Юкса нигә кирәгең бар
Синең анда, Мөстәкыйм!

Куарга булдым куркакны,
Мондыйлардан ни файда?
Тукта, башта Казан белән
Киңәш итим шулай да...

*Июнь, 1966*

## Акылсыз бүрек

Җитәкчелек итә бездә
Бер абзый бүлек белән.
Берәр эш чыкса, тукта, ди,
Киңәшим бүрек белән.

Еллар үтә, әмма һич тә
Эшкә файдасы тими —
Юньсез бүрек бер генә дә
Акыллы киңәш бирми!..

*1966*

## *Доклад яздык начальникка...*

Һәр тармактан ничә кеше,
Һәр бүлектән ничә кеше,
Читкә куеп бүтән эшне —
Доклад яздык начальникка.

Доклад яздык көн утырып,
Доклад яздык төн утырып,
Саннар, мисаллар тутырып —
Чын күңелдән тырыштык, әй!

Без язганны бергә туплап,
Бик һәйбәт дип, бик тә хуплап,
Һәммәсен бер төпкә төпләп,
Мөдирләр дә тир түктеләр.

Менә җыелыш көне килде,
Тыңларга күп кеше килде,
Трибунага менеп инде
Сөйли хуҗа важный гына.

Тыңлый-тыңлый оеп беттек,
Исни-исни туеп беттек,
Беткәнне бик озак көттек —
Тәмам тиде теңкәләргә!

Сөйли һаман сөйләнгәнне,
Чәйни һаман чәйнәлгәнне,
Чәйнәп чүпкә әйләнгәнне —
Бер дә рәте юк ич монык!

...Һәр тармактан ничә кеше,
Һәр бүлектән ничә кеше,
Читкә куеп бүтән эшне,
Без тетәбез начальникны;

Уңмадык бит моннан да, вай,
Мәгълүматы бигрәк тә сай,
Килсен безгә бүтән, давай —
Эшләр бармас моның белән!..

*1970*

8 Б-644

## Яхшы характеристика

Теләмәгән кешесеннән
Котылыр көннәр җиткәч,
Характеристика язды
Әллә Кемевич иптәш:

«Фәлән Фәләнев — тәнкыйтьтә
Армый һәм талмый торган!
Кемнең кемлегенә карап
Тукталып калмый торган!

Җитешсезлек булган чакта
Турыдан яра торган!
Утлы табага бастырып,
Җаннарын ала торган!..»

«Принципиаль!» дигән сүзләргә
Саранланып тормады.
Авызларын кыегайтып,
Имзасын да сырлады.

Аннары зәһәр елмайды:
«Әй, җаный, күзең кара,
Инде шушы кәгазь белән
Син эшкә кереп кара!..»

*Август, 1964*

## Лично үзе...

...Начальникка килә кешеләр,
Кешеләрнең чөнки эше бар.

— Эшкә баралмыйча йөдибез,
Трамвайга ябышып йөрибез,
Троллейбус та шулай ул якта.
Сиңа килдек менә шул хакта,
Ярдәм итсәң иде, начальник!

— Шулай дисезмени? Ярар, мин
Лично үзем барып карармын.

Иртән сәгать унда ул торып
Чыгып китә «ЗИЛ»га утырып.
Тәрәзәдән карый бу түрә
Һәм нормальный гына хәл күрә:
Троллейбуслар әнә ашыга,
Трамвайлар килә каршыга.

Көтәселәр инде көткәннәр,
Китәселәр инде киткәннәр...

Җавап яза кайткач начальник:
«Юкка зарланасыз начар, дип,—
Ул якларда күпме йөрмәдем,
Ярамаган нәрсә күрмәдем».

...Начальникка килә кешеләр,
Кешеләрнең тагын эше бар.

— Ашханәгә керсәң әбәткә,
Ике сәгать үтә, әлбәттә;
Ашларның юк рәте-чираты
Һәм теңкәгә тия чираты.
Чара күрче шуңа, начальник.

— Шулай дисезмени? Ярар, мин
Лично үзем барып карармын.

Хуҗа кеше соңрак ашый шул —
Сәгать өчтә әбәт ясый ул.
Мөдир аның килерен ишеткән,
Каршы чыгып ала ишектән;
Өргән җиргә генә утырта,
Ашка итнең шәбен тутырта.
Ашханәдә кеше бик сирәк.
Тәртип яхшы. Тагын ни кирәк?
Рестрандагыдай, әйбәтләп,
Начальнигым куя әбәтләп
Һәм, кәефле генә кикереп,
Җавап яза шартын китереп:

«Ашханәгә ничә кермәдем,
Зарланырлык нәрсә күрмәдем».

...Начальникта — тагын кешеләр,
Кешеләрнең тагын эше бар.

— Клубтан халык бизә башлады,
Тәртипсезлек сизелә башлады.
Кассада юк билет, кулда бар,
Хулиганлык дисәң, ул да бар.
Чик куярга иде, начальник!

— Шулай дисезмени? Ярар, мин
Лично үзем барып карармын.

Баруында шундый секрет бар:
Билет алып куя секретарь;
Килә икән — каршы алалар,
Китә икән — озатып калалар.
Мәшәкатьнең белми барын да
Һәм аңламый халык зарын да.
Иртәгесен әйтә начальник:
— Юкка зарланалар начар, дип,
Ничә генә тапкыр кермәдем,
Ошамаган нәрсә күрмәдем.

*

Яздым моны, бәлки, ярар, дип,
«Лично үзе» укып карар, дип...

*Декабрь, 1956*

## *Эчтән зур...*

Лилипут ул, дип ялгышма,
Зур эчке мөмкинлеге:
Сыйган аңа Гулливердай
Мин-минлек, мин — кемлеге!

*Октябрь, 1989*

## *Тәртип яратучы*

Беркөнне ул
Каберлеккә
Барып керә,
Һәр тарафта
Менә дигән
Тәртип күрә:
— Юк монда һич
Эзли-эзли
Аһ итәсе —
Баш очында
Һәр кешенең
Анкетасы!

*1967*

## Мыегына чорнады

Каты чыкты Гайфи,
Ай-һай, каты.
Борһановның тетте тетмәсен.
Шундый тетте,
Хәтта шүрләп йөрде
Сизеп юньле язмыш көтмәсен...
Ә Борһанов,
Гайфи юраганча,
Җай китереп муенын бормады:
— Шәп, шәп,—
диеп, бары җыелыш саен,
Мыегына гына чорнады.

Көннәрдән бер көнне
Исполкомда
Ул шушындый тәкъдим ясады:
— Белеп торам,
Гайфи Сәйфиевнең
Чыгышлары сезгә ошады.

Һәм әйтергә кирәк,
«Утильсырье»
Масштабы аңа хәзер тар,
Ә культура бүлеген җитәкләргә
Мөмкинлекләр анда полный бар.
— Вот работник! —
диләр иртәгесен,—
Гел тәнкыйтьли диеп тормады.

Ә Борһанов моны ишетте һәм
Мыегына тагын чорнады...
Ничек кирәк алай,
Безнең Гайфи
Культурада бер ай утыра.
Һәм Борһанов әйтә:
— Сиңа, туган,
Вакыт түгел микән укырга?

— Шунсы жалкы,—
                    диде озатканда, —
Җибәрмәсләр безгә яңадан...
Ну ничего,
Яңа районда бит
Яңа урын көтә, яңа дан. —

Гайфи китте икеләнеп кенә.
Уңар микән аның юллары?
Ә Борһанов калды
Җиңел сулап,
«Котылдым» дип уып кулларын.

...Тагын җыелыш.
Тагын берәү чыкты,
Каты чыкты — кемнән куркырга?
Ә Борһанов уйлый:
«Бусына да
Вакыт җиткән икән... укырга».

*1956*

## *Көтек*

Күпне көткән идек аңардан,
Тик өметләр чынга ашмады:
Авызында ботка пешереп,
Корсак белән уйлый башлады...

*1972*

## «Кеше турында кайгырту»

Башлады сүзен директор
Җитди уйчанлык белән:
— Чолгап алыйк кешеләрне
Кайгыртучанлык белән!..

Коры сүзләр белән генә
Калмады ул чикләнеп —
Йомыш белән дә кертмичә,
Нык эшләде бикләнеп.

Озак көтеп, озак юрап
Булмады күп түзәсе,
Озакламый һәммәбезгә
Күренде нәтиҗәсе:

Ялы дисәң — рәтләнгән!
Ашы дисәң — тәмләнгән!
Йокы дисәң — шәпләнгән!
Күңел дисәң — дәртләнгән!

— Әйе,— дибез Сибаевка,—
Сүз иттең лә сүзеңне,
Ләкин һаман кайгыртасың
Син бит бары... үзеңне?

Гаҗәпләнүдән директор
Урыныннан торып баса:
— Кеше турында дидек бит,
Мин дә кеше ләбаса!

*1964*

## *Хәтергә сал*

Ишет тә син моны,
Хәтергә сал гына:
Күңеле сукырның
Йөрәге саңгырау...

*1988*

## *Чын сәбәбе*

Кабинетта йөри тыз-быз,
Минһаҗевның эше тыгыз:
Шылтыратыр һәм орышыр,
Карлыкканчы ул тырышыр.
Күпләрне эштән аерыр,
Бүлмәсенә җыеп алыр.
Йодрык төйнәр, өстәл төяр,
Һаман да бер көйне көйләр:
— Давай! Давай! Давай! — дияр, —
Эшләр аксый нигә? — дияр,—
Чын сәбәбе нидә? — дияр...

Тормышта бит шулай була —
Минһаҗев та бер егыла...
Эшләр бара ансыз гына,
Кычкырусыз, шаусыз гына,
Ызгышларсыз, даусыз гына,
Җыелышсыз-нисез генә,
«Давай!» дигән имсез генә.
Шунсы гаҗәп — гөрләп бара,
Әүвәлгедән шәбрәк бара!
Эш аксаган нигә? дисәң,
Чын сәбәбе нидә? дисәң,
Бөтен эшкә мишәйт иткән —
Минһаҗев ул үзе икән!..

*1968*

## Графин белән су

Бу фәнни факт,
Уйлап карасаң,
Исең китәрлек —
Кеше миендә
Сиксән процент
Су бар икән бит!

Күз алдыбызга
Бер чагыштыру
Килә дә баса —
Баш дигәнебез
Графин белән су
Икән ләбаса!

Хуҗабыз хәлен
Шунда аңладым,
Шунда төшендем —
Әйтәм, аңа бик
Кыенга килә
Әртил эшендә...

Әйтәм, һәрвакыт
«Су» дигән нәрсә
Бик күп сүзендә!
(Узмыймы икән
Проценты хәтта
Туксан, йөзне дә?)

Нәрсәгә безгә
Андый директор?
Мин тәкъдим итәм:
— Президиумга
Графин белән су
Куйсак — шул җиткән!

*Ноябрь, 1968*

## *Башлык сурәте*

Яшь түрә иде,
Еш күрә идем,
Һавалы иде —
Үзеннән алда
**Борыны** йөрде.

Җил җаен сизде,
Көчсезне сөзде,
Үрләде өскә:
Үскәннән-үсә
Бүлтәеп **Буксә**.

**Куллар** нык инде —
Бер селтәнүдә
Егарлык инде!

Ә менә **Башы**...
Шомлыкка каршы,
Ансы юк иде...

*1988*

## *Җитми икән...*

— Фигура булгач, булсын ул,
Эредән, дәүдән булсын —
Президиумга сайларлык
Мәһабәт гәүдән булсын!

— Мин дә нәкъ синең шикелле
Уйлаган идем башта...
Гәүдә генә җитми икән,
Кирәк икән шул баш та!

*1983*

## Кирәк...

Аңарга бүтән
Берни кирәкми,
Аңа кирәк
Ми!

*1981*

## Ни Низамы, ни замы...

Йомыш белән
Барган идем,
Көтә-көтә
Арган идем,
Кабул итмәде берсе дә —
Ни Низамы,
Ни замы...

Гамьсезлектә —
Туган икән,
Бер чыбыктан
Куган икән,
Миһербан юк берсендә дә —
Ни Низамда,
Ни замда...

Атна йөрдем,
Айлар йөрдем,
Ниһаять, бер
Барып кердем!
Җилләр искән, юк берсе дә —
Ни Низамы,
Ни замы!..

*1969*

## *Профоргыбыз уңмаган*

Рәт чыкмасын күрәбез,
Эш пешмәсен беләбез,
Әмма кул күтәрәбез,
Месткомга үткәрәбез...
Сайлау гына үтә, без
Профоргны тетәбез,
Профоргны сүтәбез:
— Булмас икән булмаса,
Йоклар икән йокласа,
Бигрәк фикерсез ласа!..
Ә дәрәҗә ярата!
Булдыклылык чамалы,
Аумакайлык чамасыз,
Сайлап куйгач, нишлисең,
Баш иясең чарасыз.

Күп була теш кайраулар:
— Җитсен генә сайлаулар...
Тора бит урын билэп,
Күптән белгәнне сөйләп!
Азмы төпле егетләр,
Азмы ипле егетләр!
Сайлауны җиткерәбез,
Бердәм кул күтәрәбез.
Бергәләп мактый-мактый,
Бергәләп кыстый-кыстый,
Шуны ук үткәрәбез...

Юньсезлеген кем белми?
Эш бармасын кем белми?
Тик берәүнең дә бушка
Үзе чабасы килми...

*Гыйнвар, 1968*

## Сәбәпле мөнәсәбәт

Ханов һаман бер үк, әмма
Караш аңа өр-яңа —
Илтифат та итүче юк,
Бармы-юкмы дөньяда...

Урыннан алынгач, шулай
Үзгәрде мөнәсәбәт.
Кайберәүләр дәрәҗәгә
Карыйлар — менә сәбәп!

Тешен кысып йөри Ханов:
«Ах, мөртәтләр, юньсезләр,
Берәр җиргә керим генә,
Күрсәтермен мин сезгә!»

Элек якын киләлмәгән
Хәйдаров күреп исә,
Хәлен-әхвәлен белеште,
Кунакка дәште кичә.

— Шәп кеше сез, шәп җитәкче,
Ихтирамым зур минем.
Эшләгәндә әйтәлмәдем —
Ялгыш аңларсыз,— дидем.

Җан рәхәте сезнең белән
Утыру бер табында!..
Күңеле нечкәреп Ханов
Уйлады шул чагында:

«Кемнең кем булуы, әйе,
Кыен чакта беленә!»
Хәйдаров та бик канәгать,
Чын исәбен бел менә:

«Бүре печән ашамый ул,
Моңа урын табылыр.
Шул чагында абзаңның да
Эшләре хутта булыр!»

*1970*

## *Булмады...*

Җыелышта Галләм бер дә
Урыннан купмый иде,
Йә эчтән генә карыша,
Яисә хуплый иде.

Ниһаять, түзмәде бугай,
Торды егет сикереп,
Сөйләде гамьсез күңел дә
Кузгалырлык иттереп.

Эш өчен борчыла икән,
Эш өчен яна кеше,
Кемгә кагылам дип тормый,
Турыдан бара кеше!

«Дөрес!» — дип, теләктәш күзләр
Елмаеп карадылар,
Кайсы, әлбәттә, сагайды,
Кайсылар янадылар...

Ә директор, директор бит
Башлап үзе кул чапты.
Галләм ул көнне бик озак
Йоклый алмыйча ятты.

«Сиздерми генәдер әле,
Чын уйларын кем белгән...
Араны бозып бетерсәм,
Яшәрмен кемнәр белән?
Булмады...»

Иртәгесен директор да
Шуннан башлады эшне:
— Күптәннән эшлиме ул,— дип,
Белем ягын белеште.

Кемдер ишетеп калган да
Җиткергән бит дустына:
— Синең белән, Галләм, анда
Үзе бик кызыксына...

Тикмәгә түгелдер инде,
Әгәр эштән кусалар?
Гәҗиткә язасы мәллә:
«Тәнкыйть өчен кысалар!»

Язмады ул, директордан
Барып гафу үтенде:
— Артык дуамалланып мин
Киткәнмен лә ул көнне...

— Принципиаль кеше бу дип
Уйлаган идем, энем,
Һәм дә исәп мастер итеп
Куярга иде минем.
Булмады!..

*1970*

## Аңлашыла

«Работникларың белемсез нигә?» дисәң,
«Практиклар шәбрәк» дип аклана ул.
Хикмәт шунда: үзеннән дә наданны алса,
Креслосында озаграк саклана ул.

*1956*

## Тау авыруы

Биек күтәрелә барган кеше
Төшәр яктан куркып менәдер;
Таудан төшкәннәрдән битәр моны
Түрдән төшкән түрә беләдер...

*1988*

## Дөресе шул

Пенсиягә китә Ханов —
Озата бөтен әртил.
Дулкынланып нотык сөйли
Районнан килгән вәкил.

— Мин әйтер идем, шәп барды
Эшләре оешманың.
Барыгыздан да зур булды
Бу эштә өлеш анның.
Акмал Ханов иптәш уңган,
Зирәк җитәкче иде,
Район аңа зуррак урын
Тәкъдим итмәкче иде.

Үзегезгә яхшы мәгълүм,
Андый эшкә ул оста.
Ышанычны аклар иде
Теләсә нинди постта.

Ләкин табигать рәхимсез,
Сирәкләтә сафларны...
Әртил мәңгегә онытмас
Ул эшләгән чакларны!

...Һәммәсе котлый Хановны,
Кулын кыса, мәш килә.
Китүченең, моны күреп,
Күзләренә яшь килә.

Үзе чыккач, әйтеп куя
Районнан килгән вәкил:
— Ул бардагы безобразие
Бүтән булмасын ләкин!

*1962*

## Күчә-күчә...

Күтәрделәр Шакировны
Мактый-мактый:
«Аны куйсак, район алга
Китәр шактый...»

Кәгазьләргә борын төртеп
Йоклады ла,
Он суы да, тоз суы да
Чыкмады ла!

Дөнья булгач була ул дип
Кичерделәр,
Райсобеска мөдир итеп
Күчерделәр.

Райпланы, райфосы да
Калмады шул,
Берсендә дә рәт чыгара
Алмады шул.

Күчә-күчә «рай»ларның ул
Үтте барын,
«Кая, диләр, куярга соң
Моны тагын?»

Эзли торгач урын чыкты
Чибәр генә —
Шакировны рай... архивка
Җибәрделәр!

*

Кая күчәр
бу юлы да чыкмаса рәт?
Ә кем белә,
урны шулдыр,
күчмәс тә шәт...

*1956*

## *Күтәрелгән*

Эшләми ул дөресне дә,
Ясамый ул ялгыш та —
Кул буш түгел,
            ычкынмыйм дип,
Креслосына ябышкан.

Баш әйләнерлек биектә —
Ябышмыйча нишләсен,
Белә, күтәрелгән саен
Биектәнрәк төшәсен!..

*1977*

## *Диләр...*

Бу дөньяда
Җиңел, диләр
Вакланулы.
Кыен, диләр
Эреләнүдән
Саклануы!

*1964*

## *Авырткан урын*

— Трамвайда урын бирмиләр,
Яшьләр тәртип белми һич!
— Эштә картлар үзләре дә
«Урыннарын» бирми ич!

*1989*

## *Югалтсаң...*

Табышлар өстәле һәрбер
Шәһәрдә барын бар да,
Авторитетың югалтсаң,
Эзләп син анда барма...

*1968*

## *! һәм ?*

Гамьсез булган һәрвакытта
Өндәү Билгесе,
Ул бит мәшәкать-шөгыльне
Белмәү билгесе!

Заман үзгәргәч, буыны
Йомшаган, диләр,
Хәзер Сорау Билгесенә
Охшаган, диләр?

«Кайтыр микән теге еллар —
Безнең чор?» — диеп,
Йөри ди үзе һаман да
Астыртын көеп.

Инде сорау бөкресе дә
Чыксачы юкка —
Калсын ул теге дәвергә
Булып тик нокта.

*1988*

## Баш Бармакның башсыз чагы

Баш Бармак дип аталса да,
Үзе үк тәртип бозган:
Ике бармак арасыннан,
Мыскыллап, башын сузган.

Имән Бармак, Урта Бармак
Авыз ачып торганнар —
Затсыз бармак аркасында
Кыен хәлдә калганнар.

Баш Бармакның андый чагы
Булган диләр элек тә,
Хәзер инде әйбәт егет —
Урта Бармак кебек лә!

*Март, 1985*

## Дөрес кушамат

Йомыш белән барсаң, җанга тия Мәгазь:
«Ә соң бармы синең кулда берәр кәгазь?»
Халык та усал: үч алуның җаен тапты —
«Кәгазь Мәгазь» дип, үзенә исем такты.

*1958*

## Могҗиза түгел

Сыер тиресеннән теккән портфельгә ул
Шыплап-шыплап, кәгазьләрне гел тутырды.
Юанаеп җиткәч, портфель бозаулады
Һәм мөгезсез бер бюрократны тудырды...

*1958*

## Эшләпә

Башыңдагы эшләпәңнең
Исемнәре фетр бит;
Эшләпәң яңа мода да,
Аста — иске фикер бит!

*1960*

## Хаста

Шаулый, күрми ак-караны,
Күзләренә кан йөгергән;
Коткарырга инде соңдыр —
Баш миенә... дан йөгергән.

*1988*

## Юату

«Яхшы кеше озак яшәми»,— дип,
Син төшермә бер дә күңелне,
Ул куркыныч сиңа һич янамый,
Син булырсың озын гомерле...

*1988*

## Багана

Төбе черек багананы, аумасын дип,
Бәйләгәннәр, җиргә имән казык кагып.
Ә багана шуннан бирле лаф ора ди:
— Куйдылар бит әле җирне миңа тагып!

*1959*

## *Чамала*

Әйтсә халык:
«Нишләп йөри, дип, бу надан?»
Акыл өйрәтмә син трибунадан.

*1961*

## *Дөнья куласа...*

— Өлкәннәр — төшкән түрәдәй,
Мөмкин исәпләшмәскә,
Күрмәмешкә салышырга,
Һәм дә исәнләшмәскә.

Кайчандыр булыштым, дидер,
Нәрсәдер сорап тора,
Картлар үпкәләүчән була —
Имеш, ул сынап тора.

Сынамагае, сынасын,
Инде базары беткән:
Моңардан нәрсә аласың,
Кирәге чыкмас бүтән...

Яшь нәчәлник нык утыра,
Холык дигәнең — текә!
...Кабул итү бүлмәсендә
Картлыгы чират көтә.

*Октябрь, 2000*

# Сөзгәк үгез мажаралары

Юмористик поэма

Көлке көлә килә,
Артыңнан куа килә.
*Мәкаль*

## Мөгез оч

Килде көне, тотмыйк инде
Үгезне мөгезеннән,
Әйләнсен әле доньяны
Әйдә бер үзе генә!

Нинди үгез? Каян килгән?
Үзебезнең якныкы.
Чыкты мөгез, үсте үгез,
Җитте сөзәр вакыты!

Чынмы? Тәнкыйть үгеземе?
Баш ватма җавап эзләп,
Кайсы булса да бик усал,
Кайсы булса да сөзгәк!

Сизәм, мондый үгезләрне
Кайберәүләр яратмый.
Мөгез булып, сөзмәгәч тә,
Нәрсәгә ул, ярабби!

Әйтмәсләр: дуласа, аңа
Күренми дип ак-кара —
Аклык-хаклыкка таянып,
Караларны актара.

Кемгә файда, тотсаң аны
Әгәр дә мәгәр бәйдә?
Мөгез-сәнәкләрен сузып
Гизсен бер, сөзсен әйдә!

Үгез ачуының купләр
Тәмен татыр шикелле,
Минем бурыч футболдагы
Комментатор шикелле...

### Беренче әкәмәт

Тап-такыр безнең урамнар —
Көн-төн машина таптый.
Машиналар арасында
Тояк эзе дә шактый...

Түбән очтан үгез килә
Йөгереп җан-фәрманга.
Бераз алдан Хөҗҗәт абзый
Элдертә бар дәрманга.

Әле ярый, шунсы уңай —
Буй яклары тәбәнәк,
Аяклары да күренми,
Килә туптай тәгәрәп.

Авылдашлар төрттереп тә,
Көлешеп тә калалар,
Болай да кызган канына
Мәзәк тозы салалар:

— Моның аяклары махсус
Чабарга көйләнгәндер!
— Алименттан кача-кача
Шулай шәп өйрәнгәндер!

Йөргән Хөҗҗәт мут мәчедәй
Кәефле мырлап кына,
Кая барса да, һаман шул
Бер җырын җырлап кына:

— Үкчәләрең
Кадак сыман,
Күкрәкләрең
Кабак сыман,

Син йөзәсең
Кораб сыман,
Мин йөримен
Карак сыман...

Синсез тормыш
Харап сыман,
Үтик бергә
Пар ат сыман!..

Җырлар иде әле дә ул,
Әгәр сулу капмаса,
Мөгез-сәнәкләрен сузып,
Арттан үгез чапмаса...

Хатын саен йөри торгач,
Сукмаклары юл булган;
Эш хакында уйлау кая —
Бар шөгыле шул булган.

Йөргән ятимнәр арттырып,
Булса да башы такыр.
Уллары белән беррәттән
Туй ясый ул да, бахыр.

Үгез соң, шулчаклы ярсып,
Тикмәгә димсең куа —
Бу эштә син минем белән
«Ярышма!» димәк була.

«Болельщиклар бармы?» — дисәк,
Китереп футбол шартын,—
«Кайсы капкага керер?..» дип,
Күзәтә тугыз хатын.

Хәрәм җефетләре икән
Ул карап калучылар;
Алучысы алыр инде,
Ни уйлый баручылар?

Үгез аларга, үтешли,
Карый күзен акайтып,

Мөгаен, вәгъдә итәдер
Сөзәргә кире кайтып.

Хөҗҗәт ул, никах яңартып,
Гомер буе йөрмәкче,
Әле чапкан уңайга да
Тагын йортка кермәкче!

Яңа болдыр бикле булгач,
Искесенә тотынды,
Үз хатыны капкасына
Кереп кенә котылды...

Котылды? Котылмый торсын,
Хатын әллә җансызмы?
Уклау белән яра-яра,
Кире бора сансызны.

Илле яшьлек яшь кияүгә
Килде бигрәк тыгызга!..
Судья да сызгыртыр инде,
Исәп җитте тугызга!

Болай булгач, имин генә
Котылмас Хөҗҗәт җаный —
Аунаты-аунаты үгез
Кабыргаларын саный.

Күреп туйдан соң биюен
Шулай мөгез көенә,
Тугыз хатын — тугыз көндәш
Тугыз яктан сөенә!..

**Икенче әкәмәт**

Габделәкбәр хәзрәт көн дә
Кунычлы галош кия.
Шул галош әнә шап та шоп
Чалбар төбенә тия...

Мотоциклларны узып,
Дуңгызларны өркетеп,
Оча бикле клубларның
Йозакларын селкетеп.

Үзе чаба янып-пешеп,
Үзе укый әгузе.
Тәһарәтеңне боза бит
Бу замана үгезе!

Кычкырмак та була хәзрәт:
«Куарга бар ни хакың?
Укыдым ич мин Хөҗҗәтнең
Нибары биш никахын...

Мине бар да кыерсыта...
Тилермә, йөзең кара,
Хәлеңнән килсә, син әнә
Парторгны сөзеп кара!

Ул да бит күргән чакларда
Күрмәмешкә салышты...»
Чү, кинәт хәзрәт ниндидер
Бер баскычка ябышты;

Ә баскыч турыдан-туры
Күккә үк менә алып!
«Шунда ашуым микән?» дип,
Тора мулла таң калып...

Ни булса да, бу форсатны
Ычкындыру ярамый —
Үрмәләде һаман өскә
Алны-артны карамый.

Аннан-моннан, тәһарәтсез
Теләсә дә теләкне,
Әллә инде, чынлап торып,
Оҗмахка ук эләкте?..

Әйе, әнә җимешләре,
Пешкән ничек кызарып!

Кәс-кәс басып бакчасында
Йөриләр хур кызлары!

Җитмешләп кенә дә түгел,
Сиксәнләп булыр мәгәр,
Хөҗҗәт керсә, өлеш чыкмас,
Сайлап калмасаң әгәр...

Чү, күзләрем алдашамы —
Монда да машиналар!
Әллә җәннәт сельпосыннан
Продукты ташый алар?!

Әллә кызмача шайтаннар
Күрсәтә буташтырып —
Җәннәтне дә корганнармы
Механикалаштырып?

Тфү, тфү, ни күрәм мин,
Тәүбә, әстәгыфирулла —
Ничек оҗмахка эләккән
Коммунист Гарифулла?!

Шунда барлык күренешләр
Гүя әйләнеп баса —
Биектән шулай күренгән
Бу безнең авыл ласа!..

Үгез янгын каланчасын
Әнә ничек селкетә...
Һай бу газиз башкайларны
Нинди афәтләр көтә?

Инде хәзер нишләргә?! — дип
Тора хәзрәт баш кашып —
Җиргә дә төшәр әмәл юк,
Күккә дә булмый ашып...

Үгез әллә төбеннән үк
Кузгатты каланчаны —
Даң-даң!.. «Янгын!» дигән кебек
Яңгырап китә чаңы...

Даң-доң! Даң-доң! Бер мизгелдә,
Әйтерсең давыл куба —
«Янгын! Янгын!» дип шаулашып,
Ду килеп авыл куба.

Кем яланбаш, кем ялангач,
Кем чалбар киеп чыккан,
Кайсы күрәк, кайсы күлмәк,
Кайсысы башын тоткан!..

Этләр чиный, тавык-үрдәк
Оча юлдан пырылдап,
Күрше авыл машинасы
Килеп җитә тырылдап.

Ни жары, ни пожары юк,
Ник шулчаклы кагалар?!
«Янгынчылар янмыймы?» дип,
Бар да шунда чабалар.

Кабаланып килгән шәпкә,
Аңлашмый торгач әзрәк,
Танып алалар:
— Бәй, хәзрәт,
Ни кылана бу хәсрәт?

— Манараны юксынганмы?
— Ә бит заманасында
Үзе кисешкән иде ич
Мәчет манарасын да!

— Менгәндер ул эче пошып
Дин тотучылар азга!
— Пожар, диеп чаң какмаса,
Кем йөрсен соң намазга!

Күккә түгел, җиргә карап
Ялвара Габделәкбәр:
— Унбиш тәүлеккә дә риза,
Язмыштыр, аллаһәкбәр;

Тик моннан гына төшим дә,
Тик үгезгә бирмәгез!..
«Акылың алтын икән!» дип
Көлешәбез җирдә без.

Сизә мулла, котылу юк
Үгезнең хөкеменнән,
Төшкәч, тик бер нәрсә сорый
Җыелган төркеменнән:

— Җәмәгать... чалбарны гына
Чыгыймчы алыштырып,
Тәһарәтне бозып, ләгыйнь,
Куйган бит ялгыштырып...

Үгез үгезлеген итте,
Өркетеп аңын алды,
Элеп алды, селкеп салды,
Хәзрәтнең җанын алды;

Сикертте дә үрле-кырлы,
Йөгертте әрле-бирле,
«Үгезебилләһи...» диеп
Укый ул шуннан бирле!..

...Уяна да иң соңыннан
Янгынчыбыз Мурашов:
— Нигә шаулаштыгыз? — диеп
Йөри шунда сорашып...

### Өченче экәмәт

Бик зарыгып торган идек,
Килче, диеп, кил дә кил —
Ярдәмгә килде колхозга
Иптәш Бәйрәмов Вәкил.

Килү-килүенчә шәпләп
Акыл бирә башлады,—
Җыен җыеп, кайнар-кайнар
Речьләр сөйләп ташлады.

Җил тегермәне шикелле
Кулларын селкә-селкә,
Мәчеле сәгатьтәй ялт-йолт
Күзләрен йөртә-йөртә,

Ай-һай, малай, чая сөйли,
Авызына карата —
Без тыңларга яратмыйбыз
Ул сөйләргә ярата:

— «Киңәйтик тә җәелдерик!
Давай, давай, күтәрик!
Оештырыйк та көрәшик!
Давай, давай, үткәрик!»

Күр, ничек асат икән ич,—
Шуңа да баш җитмәгән!
Чакырулар аз булганга,
Эш тә алга китмәгән...

Әйдәгез, Вәкил иптәштән
Сорыйк әле баш орып:
Күрсәтсен шәп киңәшләрен
Үзе эшкә ашырып!

Баш итеп сайлыйкчы үзен
Колхозның штабына,—
Без дә бер яңгырап карыйк
Өлкә масштабында!

Вәкил иптәш, калды никтер
Ярты сүздә тотлыгып,
Тып-тын калып көтә идек,
Ник йөгерде ул торып?

Без тыңларга әзер идек,
Күнеккәннәр инде без.
Әллә каян килде чыкты,
Эшне бозды бит үгез!

Килде чыкты, куды китте
Бөтен шартын китереп —

Фамилиясен дә сорамый,
Дөбер-шатыр иттереп!

Аякларың да телең күк
Шома икән, оратор,
Без бүтәнгә борыйк гәпне,
Чатыр-чотыр чаба тор!

Очратканың бар идеме
Болай үгез куганын?
Җете кызылны күрдеме —
Җене чыга шул аның...

Әүвәл андый мөгезлеләр
Түзә торган иде дә,
Дәрәҗәгә карап кына
Сөзә торган иде дә.

Заманалар үзгәрде шул,
Хәзергеләр бик кыю,
Кабынып киттеме, бетте —
Һич мөмкин түгел тыю!

Сөзсә инде, белеп сөзә,
Сөзә абайлап кына,
Нәкъ менә синең ишене
Арадан сайлап кына...

Портфелең — бозау тиресе,
Ахры, шуңа ярсуы —
Мәрхүм малкайларны уйлап
Кабаргандыр ачуы.

Өстәвенә, башыңда да
Сары салам фуражка,
Бир безнең өлешне, диме,
Калдыр, диме, фуражга?

Әллә «Давай» диюеңнән
Туеп кына куамы,
Гаебе барга качадыр,
Диеп кенә куамы?

Ә без ул сүзне ошаттык,
Шуңа хуплап тик тордык —
Үгез сине сөзгән чакта:
«Давай, давай!» дип тордык!

### Дүртенче әкәмәт

Вәкил китте, ак юл аңа,
Шакир аннан ким түгел,
Хәтта Вәкил бик күп яктан
Үзе аңа тиң түгел.

...Ул чакта бу күркәм сыйфат
Туры килгән бик таман —
Булган ич сөйләшеп кенә
Яши торган шәп заман!..

Дөнья күргән авылдашлар
Бик зур киләчәк юрап,
Мондый әвәслеге белән
Китәр, дигәннәр, ерак!

Йоклаган чакта да теле
Кыймылдап тора, диләр,
Сүз әвәләп иреннәре
Мимылдап тора, диләр.

Шуңа аны күтәргәннәр,
Ә ул тырышып эшләгән:
Су эчкән дә сүзләр чәчкән —
Трибунадан төшмәгән.

Ә беркөнне авылыбызны
Шакирсыз калдырганнар.
Безгә бик кулай кадр, дип,
Районга алдырганнар.

Анда да озак тормаган,
Анда да тиз танылган,
Казан хәтле Казанга ук
Чакыртучы табылган.

Кәнсәләр тормышы бит ул
Туктаусыз кайнап тора,
Шундый телгә осталарны
Өскәрәк сайлап тора...

Ә Казанда нотыгын да
Язып кына биргәннәр,
Цитаталар эзләп вакыт
Әрәм итмә, дигәннәр.

Махсус җирдә дәваланган,
Махсус җирдә яшәгән,
Махсус урында ял иткән,
Махсус төштә ашаган.

Торганнар аны һәрвакыт
Уңайга гына сыйпап,
Гомер иткән ул халыкны
Нотыклар белән сыйлап.

Дөнья — куласа, ул һаман
Әйләнә алга табан.
Җитте, сөйләүдән тыелып,
Эшләп күрсәтер заман!

Ә моңа ул өйрәнмәгән,
Трибуна — бар белгәне;
Техникасы да искергән,
Гел бер тел тегермәне...

Бүтән эшкә күчерделәр,
Булдыралмый — һөнәрсез.
(Тигәнәк сыман ябышып
Яшәгән бит ул әрсез!)

Күчергәләп рәт чыкмагач,
Калмагач бернинди ранг,
Үзебезгә кайтып төште,
Әйтерсең лә бумеранг.

Өлкә дә шат, район да шат,
Хәзер алар котылды,

Ә Шапырҗан, иркенәеп,
Инде безгә тотынды.

Әмма дөнья күләмендә
Сайрап күнгән юртак тел,
Кайтып төшкәч, авылда да
Табалмады уртак тел.

Халык та бит хәзер шундый,
Дәшми тормыйлар, каһәр,
Берсеннән-берсе чаялар,
Берсеннән-берсе зәһәр.

Ә Шакир, кая куйсаң да,
Үз туксанын туксанлый,
Регламентыңны да белми,
Сөйли бирә, туктамый.

Тап булсаң хәтта урамда,
Төймәңне бора-бора,
Актыгын өзеп алганчы
Сөйләпме сөйләп тора!

Качыйм дисәң, арттан бара,
Калдырып азрак ара...
Бертуктаусыз ярма яра,
Тавышы колак яра.

Ул ярманы тавыклар да
Бетерә алмас чүпләп!
Өлгерсә тик болар гына
Өлгерер инде җүпләп, —

Шапырҗанны үрдәкләргә
Мөдир итеп куйдылар;
Бакылдауга ни мәшһүрләр,
Такылдаудан туйдылар!..

Шул рәвешле тагын күпме
Йөрер иде Шапырҗан,
Яңа эшкә күчерергә
Идарәбез чакырган.

Артта калган бер тармакка
Ярдәм дигән формада,
«Сүз бозау имезер», диеп,
Җибәргәннәр фермага.

Эшләп акласын әле бер
Сөйләп алган билетын —
Гомер буе тик ятарга
Түгел бит ул бюллетень!

Нишләсен, киткән Шапырҗан,
Фермага барып кергән,
Мондыйларны күп күрдек, дип,
Үгез сөзеп үтергән...

Күзе йомык, тәне суык,
Йөрәк күптән туктаган.
Сәгать теле кебек йөри —
Чү, телдән җан чыкмаган!

«Бик вакытлы ычкынды», дип,
Макталгач макталасын,
Чүт кенә өзелми калды
Озату тантанасы.

Тикмәгә генә селкенеп
Ятмаган икән теле —
«Җыелыш башландымыни?» дип,
Сикереп торды теге!..

Ярсып-ярсып сөйләп китте,
Тәмам үтте үзәккә.
(Бөкерене, ахры, чынлап та,
Кабер генә төзәтә.)

**Бишенче әкәмәт**

Быел электр керттеләр —
Бөтен авыл тиенде:
— Ходай уттан аермасын! —
Дип картлар да сөенде.

Лично үзем мыекны да
Электр белән кырам.
Ә кайчак, сакал сыпырып,
Караңгыда утырам...

Эш бүленде, дип сукранып
Иртә ятсак без шулай,
Беләсеңме, берәүләргә
Караңгылык та уңай.

Туксан литр сөтне эчкән
Ферманың учетчигы.
Ничек эчкән? Сатып эчкән,
Вәт кычыткан чыпчыгы!

Күрше авыл буйдаклары
Кара айгыр җиккәннәр,
Айсылу дип, ялкау Хәйне
Ялгыш урлап киткәннәр...

Күрше врач теш дип телен
Суырган Сафураның,
Буранынан котылдым, дип,
Шатлана ире аның.

Төннәр уза, монтер Мөнип
Исереп аунап ята,
Җилтерәтәбез җыйнаулап,
Кабыз, дип, яхшы чакта!

Нәрсәдер җитми, ди мөртәт —
Пробка диме, бөкеме;
Бөке генә өмет итми,
Төшенәбез төлкене...

Мөнип шундый, гадәтенчә
Мең вәгъдәләп мең алдый,
Лаякылда кая акыл —
Баганага меналмый!

Билгеле инде, әйтерсез,
Көн дә эчмәсен, диеп,

Без бит аны эчерәбез
Тизрәк эшләсен, диеп!

...Беркөн кибет урамыннан
Тәгәрәп чыкты мичкә.
Мичкә икәнен дә аның
Абайлап алдык көчкә.

Мәгълүм түгел бу мичкәнең
Эчләрендә ни бары —
Бәлкем судыр, бәлкем сыра,
Ә бәлкем әле дары!..

Үзе йөри торган мичкә
Уйлап чыгарганнармы?!
Иһи, салмыш агайларның
Эш җайлана аннары!

Чү, чыннан да, бер ягыннан
Ике аяк күренә,
Кем икәнлеге күренми,
Башын төрткән түренә!

Шул мизгелдә баганага
Бәрелде дә таралды —
Кыршаулары тәгәрәде,
Мөнибе генә калды...

Шешәдән имеп туймагач,
Мичкәгә күчкән икән,
Ятып-ятып эчкән килеш
Эченә төшкән икән.

Килеп җитте, үгез икән
Мичкәгә җан кертүче,
Мөнипле мичкәне шулай
Тәгәрәтеп йөртүче.

Мөгезен генә күрсәтте
Ул Мөнип багалмага —
Сизми дә калды монтерың
Менгәнен баганага!

Менгәч инде ни хәл итсен —
Бүтән чара калмады,
Мөгезләргә карый-карый
Чыбыкларны ялгады.

Безнең генә, әйтә-әйтә,
Сүздән тәмам тәм китте,
Тиз кабул итте бу юлы
Ул түбәннән тәнкыйтьне!

Рәхмәт укыйбыз үгезгә,
Утка караган саен,—
Хөрти иде безнең эшләр,
Ул да тапмаса җаен.

...Бу мисалдан тагын бер кат
Күрдегез үзегез сез —
Техника заманында да
Булмый икән үгезсез!

**Алтынчы әкәмәт**

Халык: «Туа мөгез чыкмый,
Тора мөгез чыга»,— дип,
Дөрес әйткән, әнә Хамис
Йөри мөгез чыгарып.

Сугышырга йомарланган
Зур йодрык кебек башы;
Һаваны да сөзеп йөри,
Пәке кебек карашы.

Әйтәләр дә: «Сүзенең, дип,
Юк атасы-анасы»,
«Атасы» юк, ә «анасын»
Гел кабатлый баласы...

Тореодорлык булса булыр
Сөрхәнтәйдә өлешчә:
Дүрт аякланып баскан да
Үгез белән сөзешә...

Беркавым шулай алышкач,
Чамалар аңлашылды:
Хамис тыкырыкка шылды,
Күренеш алмашынды...

Йөри торгач, очрый Хамис
Бер ташландык коега.
Ахры, кое, качар өчен,
Җайлы булып тоела;

Атылып килә дә мүкле
Чылбырына тотына...
Сүз дә юк ансы, үгездән
Котылуын котыла,

Ә менә кое төбенә
Бик әйбәт кенә — гөмберт!
Шунда йолдыз санасын дип,
Рәхәтләнеп бер көлдек!

Ул санасын, без кыйссаның,
Җепләрен төйни торыйк;
Ни кылмышын, ни кырмышын,
Тормышын сөйли торыйк...

Үсте безнең күз алдында,
Мәгълүм һәрбер адымы;
Шундый иде әтисенең
Тәрбияләү алымы:

«Малай булса — үткен булсын,
Башкисәр булып үссен,
Үз дигәнен йолкып алсын,
Капкан җиреннән өзсен!

Шунсыз бит ул яшәп булмый,
Юаш булсаң, басалар.
Усал булсаң, асалармы?
Асалмыйлар — качалар!

Җебегәннәр җебеп торсын,
Көчленеке замана!..»

Хамис шушы кодексны
Истә тотты һаман да.

Юаш малай-шалайларны
Ул акыртып кыйнады.
Үсә төшкәч, кыланышы
Мәктәпкә дә сыймады;

Сабыр сабакташларының
Йөрде ул башларыннан.
Алдан йөреп артта калды
«Дөнья юашларыннан»...

Гомерләр бит уза торган,
Ә теге «пешмәгәннәр»
Кай арада ВУЗ бетереп,
Кай ара эшләгәннәр?!

Шуңа Хамисның эчендә
Үт кабара башлаган,
Юньле кеше күргән саен
Үч кайтара башлаган.

Эш кырмаган, тәрәз кырган,
Сугышмыйча тормаган;
Ничә тәүлек утырса да,
Акылга утырмаган.

Әнә тозлы сүзләр килә
Коедан тонык кына...
Авылдашлар сөйләшәләр
Ерактан торып кына.

Галәветдин бабай әйтә:
— Яшьләр бик бозылдылар...
Лотфи абзый:
— Тормыш яхшы —
Менә ник узындылар!

Габделәкбәр:
— Сәбәп бүтән —
Өркер нәрсә калмаган;

Курыкмыйлар райкомнан да,
Курыкмыйлар алладан!

Тимербулат:
— Абзыкаем,
Куркытып яки алдап
Тоткан заман — тю-тю,
Кеше
Яшәргә тиеш аңлап!

Шиһап:
— Җитеп бетми бездә
Политагарту эше.
Җәгъфәр:
— Мең ел каралган шул,
Бик тиз агармый кеше!

Хаҗи:
— Алайса коеда
Бусы агарсын әле,
Чыккач колак тынып торыр,
Кычкырып арсын әле!

Садыйк:
— Авыз ермагыз сез,
Ул да адәм баласы,
Харап булганчы, җәһәтрәк
Тартасы да аласы!

Тартуын тартып алды да,
Әмма әзрәк ялгышты:
«Ник элегрәк алмадың?» — дип,
Якасына ябышты...

Карап-карап тордык та без
Алдык үзен боргычлап,
Син күр, мин күр, шуннан бирле
Тора әле тынычлап.

Ни килешкәндер, тәгаен
Әйтер идек, белмибез —
Әллә кое, әллә үгез,
Әллә инде үзебез?..

## Җиденче әкәмәт

Һәр кеше сата базарда
Товарын мактый-мактый.
Берсе бигрәк килештереп,
Бигрәк чая такмаклый:

— Алмасы да алмасы —
Яшь кызлар бит алмасы!
Тышы — шикәр, эче — бал,
Исме — алма, төсе — ал,
Алып җибәр, тизрәк ал!
Күпме үлчик? Рәхим ит!
Алма аша, йөзгә җит!

Бигрәк оста сатучы бу:
Кырыкка бөгеләдер;
Ничек сөйләп, ничек көйләп
Һәм «чөйләп» өлгерәдер?

Үлчәвенең үрдәкләре
Чүгәләп биеп тора,
Алар да баш иеп тора,
«Рәхим ит!» диеп тора.

Тәмле телгә тартылганны
Сизмичә дә каласың,
Бармас җирдән барасың да
Алмас җирдән аласың.

...Иртәгесен әллә инде
Сул ягы белән торган,
Әллә, әбиләр әйтмешли,
Төнлә җен алмаштырган?!

Акаеп кына карый ул
Уңга да сулга гына,
Гердәй авыр сүзләр белән
Ора да суга гына.

Сикереп кенә кунмый да
Ырылдап кына капмый —

Гүя сиңа гомер бакый
Җан ачулары саклый.

— Абый, алмагыз кыйммәтме?
— Язган! Күрмисеңмени?!
Күзең чыкмагандыр! Кара!
Укый белмисеңмени?!

Нәкъ кыршылган кибетче кук —
Алдың ни, алмадың ни...
Бу үзгәрешнең хикмәтен
Соңыннан аңладым мин.

Кичә саткан үзенекен,
Бүгенгесе колхоздан.
Кичә эш эшләнгән, бүген
Көн узганмы — көн узган...

Гыймран бу. Ләкин аңарга
Дәшмиләр «Гыймран» диеп,
Кушаматсыз заманда да
Йөртәләр «Йомран» диеп.

Үзе ул һәрчак муенын
Алгарак сузып йөри,
Мылтык төзәгән аучыдай
Бер күзен кысып йөри.

Копилка ярыгы төсле
Сыңар күзе караңгы,
Дөньяга ул гомер буе
Йотам диеп каранды.

Нинди байлык ята икән,
Ярыктан карыйк әле,
Күңленә күз салыйк әле,
Күзәтеп барыйк әле...

«...Эшләгән, ди ул, эшләсен
Лом белән, кәйлә белән,
Без яшик әмәлен белеп,
Җай белән, хәйлә белән!

Сүзләрне дә зирәк кенә,
Сирәк кенә кыстырыйк,
Җитәкчеләр сөйләгәндә,
«Дөрес!» диеп кычкырыйк.

Активка да кертмәсеннәр,
Пассив дип сукмәсеннәр,
Бик күреп тә тормасыннар,
Күрми дә үтмәсеннәр.

Тормыш ул кире кәҗә кук,
Бармый, белмәсәң җаен,
Кемнәр йоклый, кемнәр йолкый,
Дөнья бу, абзыкаем!

Белештерми чапкан аттай
Яна бирсен тиләләр,
Андыйларга ядрәләр дә
Иң әувәле тиделәр.

Беркатлылар кайтса кайтты
Имгәнеп, канын коеп,
Без кайттык медальсез генә,
Әмма ләкин мал җыеп.

Инде колхоз диеп алар
Көне-төне чабалар,
Гыймран ул хөрәсән түгел,
Гыймран үзен чамалар.

Булмаса, кеше бирелми,
Булса, сине күрәлми.
Күмәк эшнең шунсы яхшы —
Син тартмый дип терәлми.

Бөкре чыгарган без түгел,
Беләбез тормыш хутын,
Миңа: «үгезе үлсә — ит,
Арба ватылса — утын...»

...Артта калды базар шавы,
Алда — авыл тынлыгы.

Каян гына килеп чыкты,
Аһ, бу гөнаһ шомлыгы!

Нишли дә алмыйсың, үгез
Биетә үз көенә,
Кереп качмак булып Гыймран
Йөгерә үз өенә.

Өе дә өе! ДОТ кебек,
Тәрәзә — амбразура,
Имән капка, нарат койма,
Мәңгелек амбар-кура.

Тоз белән корган мылтыкны
Ничек төбәү хакында
Һәм кая төбәү хакында
Әйтеп киткән хатынга.

Үгезең түгел, чуртың да
Ни ватып, ни ачтырып
Керә алмас — бик өстенә
Салган чуен бастырык!

Гыймран алты-җиде тапкыр
Әйләнә йорт тирәли,
Үгез кермәве шәп шәбен,
Ләкин үзе керәлми.

Уй тиз диләр, чаба Гыймран
Узып хәтта уйларын...
Шактый ураттыргач үгез
Биек койма буйларын,

Мөгезенә элеп кенә
Чөйде дә атты тыштан!
Шытырт итеп кенә китте
Трофейный мурт ыштан.

«Шытырт»тан соң яңгырады
Колак яргыч «шарт!»ы да,
Аяз көнне яшен суккан
Кебек булды артына.

Тимер чыбыкка эләккәч,
Төшмәк булып тартыла,
Әңгер-меңгердә хатыны
Пух! иттереп аттыра!

Форточкадан карап көлә:
— Шәп булдымы? Йөрмәссез!
Үзе юк дип, алмаларын
Ботарларга кермәссез!

Уйлый хатын: «Карткаемның
Өйрәтүе ярады...»
Өйдә насыйп икән Гыймран
Алу сиңа яраны!

«Ай-вай...» диеп, тыз-быз килеп
Йөри Гыймран котырып,
Әчетүгә чыдый алмый,
Кычкыра торып-торып.

Утыра торган төштәрәк —
Шунсы бигрәк уңайсыз.
Кемдер әйтә, мондый нәрсә
Төзәлми, ди, ун айсыз.

Авылдашлар юаталар:
— Алай ук газап чикмә —
Тозың үзеңә булды ич,
Әрәм китмәде читкә!

## Сигезенче әкәмәт

Хәбәр булды Мәүлиягә
Күргәзмәгә барырга.
Җыелды ферма кызлары
Озатышып калырга.

Үгезне күргәч, нигәдер
Куя кинәт кычкырып —
Сыза кызый дусларының
Кочагыннан ычкынып...

Мөдир алдында үгезнең
Абруе төшә язды,
Җенләнеп китеп Карибҗан
Мөгезен кисә язды:

«Мәүлияне сөзмәк була!
Ә бит ул безнең маяк!
Димәк, бу очракта мөгез —
Безнең көпчәккә таяк!

Дөрес әйтәмме? Бик дөрес!
Мәүлия аркасында
Фермабыз һәм колхозыбыз
Гәҗитнең уртасында.

Шунсы да бар: маяк күргәч,
Күзләре чагыла да,
Карый алмыйлар эшеңнең
Күләгә ягына да...»

Чыннан да, ник карый үгез
Күзенең агы белән,
Ошамый башлаган аңа
Кыз кайсы ягы белән?

...Хәтеремдә Мәүлиянең
Фермабызга төшкәне,
Кыяр-кыймас эндәшкәне,
Кызарып күрешкәне.

Бигрәк тә оялчан инде —
Авызыннан сүз чыкмый.
Эш дигәндә, ут уйната —
Куллары кулга, йокмый!

Бер сүз белән әйтсәк, кызкай
Эш өчен яратылган!
Вакыт тапмый диләр хәтта
Егетләр яратырга...

Тыныч кына эшлим дисәң,
Шулай бит ул кайчакта —

Әйләндерделәр куйдылар
Мәүлияне маякка!

Китте шуннан, китте кәмит,
Теләсәң ничек чыда...
Сыер белән бергә төшкән
Портретлары да чыга;

Районында, өлкәсендә
Мактыйлар да зурлыйлар,
Шагыйрьләре җырга сала,
Җырчылары җырлыйлар.

Журналистлар бигрәк җитез—
Көн аралаш киләләр,
Әйтергә тиешле сүзен
Сырлап кына бирәләр.

Шуннан бирле Мәүлиябез
Алдынгыдан санала,
Сайлау-мазар җитте исә,
Гел өскәрәк сайлана.

Мөнәвир бабай әйтмешли,
Уйламыйча языкны,
Мәүлия улакларына
Салалар бар азыкны;

Шуңа күрә сыерлары
Су эчә дә тоз ялый.
Бүтәннәрнекенә ярый —
Салам чәйнәп боз ялый...

Гап-гади кызга да, ахры,
Ошап куйды дәрәҗә,
Күзләрне томалый бугай
Мактау — матур пәрәнҗә...

Әйләнә шулай карусель —
Күзләрне бәйләндерә,
Алга барган күк булса да,
Бер төштә әйләндерә...

Мәскәүләргә җиткәч кенә
Үзе һәм яхшы аты,
Мәүлиябезнең беркөнне
Килде шушындый хаты:

«Ялганлап яшәргә бүтән
Түзәр хәл калмагачтын,
Чирәм җирдән кайтучыга
Кияүгә чыгып качтым.

Мактау арта, сөт артмый, дип,
Йөргән чакта ми түнеп,
Кариб абый сыерларны
Күрсәтте ким иттереп.

Имеш, бүтәннәрне әйдәр
Минем уңай үрнәгем.
Гаеп миндә, хәйлә корып
Йөрүләрен күрмәдем...»

Бу хәл ачылгач, бар кеше
Аһ итте, исе китте.
Ә мөдир Карибҗан исә
Мыегын да селкетми:

— Кызмагыз әле, һәр эшкә
Сәбәп була бит аңа —
Кирәк иде чыгарырга
Колхозны орбитага.

Агымга каршы кем йөзсен —
Тормыш ул шулай бара,
Шома гына үтәләме
Берәр җаваплы чара?

Шулчак үгез, дәррәү кубып,
Екты да Карибҗанны,
Мөгез белән укол ясап
Дәвалый гарип җанны.

Ә халык, карый да көлә:
— Тормыш ул шулай бара,
Шома гына үтәләме
Берәр җаваплы чара?

## Тугызынчы әкәмәт

Йөри торгач урамнарны
Урап буйдан-буена,
Җитеп килә үгезебез
Район сабан туена...

Бер-бер артлы алмашынып
Тора монда күренеш,
Халык куйган комедиядә
Рольләр болай бүленмеш:

Кем нинди һөнәргә маһир,
Шул тирәгә сырыша,
Шул тармакта, осталыгын
Күрсәтергә тырыша.

...Әнә кассир Сәфәргали
Башын чүлмәккә тыккан,
Җитешмәгән акчаларын
Тапмакчыдыр катыктан.

...Колхоз һәм авыл рәисе
Усал караш атыша:
— Минемчә!
— Юк, минемчә! — дип,
Икәү аркан тартыша.

...Вил белән Хәй йөгерәләр
Кабып күкәйле кашык —
Күнеккән алар күкәйне
Фермадан өйгә ташып.

...Урынбасар Мөстәкыймов
Капчык тотып сугыша,
Директоры Яхъяевны
Түнтәрергә тырыша.

...Селкор Сабит гомер буе
Көрәшкән яклап чынны,
Бүген ул егып салмакчы
Әхмәтҗан ялганчыны;

Икесенең ике төрле
Даны илгә таралган,
Халык күз алдында хәзер
Көрәшә Чын вә Ялган.

Көчле көченә ышанса,
Көчсезе аяк чала,
Алдап Чынны егып сала
Һәм Ялган батыр кала!

«Дөрес түгел!» дигәнгә дә
Һич кенә китми исе,
Ялганны «чын» диеп раслый
Комиссия рәисе.

...Күзен бәйләгән тәнкыйтьче
Гайрәт чәчеп йөрмәктә,
Кизәнеп имән күсәкне
Юнәлә буш чүлмәккә.

Тик шәһәрдән кайткан кунак
Эш чыгара алмады,
Әдәбият түгел шул ул
Сабан туе мәйданы!..

Күтәреп алды күсәкне
Парторг Гарифулла,
Снайпер була торып та,
Тидермәс микән ул да?

«Уңга, уңга!» дип карадык,
Колак салмады агай,
Җәһәт кенә атлый торгач,
Китте чүлмәк ягалай.

Өстәл янына җитәрәк
Күтәрде ул күсәген...
...Тидерүен-тидермәвен
Соңрак әйтү исәбем.

Шау-шу булгач сизелмәгән,
Мәйданга кергән үгез,

Җәядән атылган уктай
Выжылдап килә мөгез.

Ялганны чын диюченең
Тавышы калтырады,
Тавышы калтыраса да,
Күзлеге ялтырады:

— Нишләттерергә белермен —
Фәлән Фәләнев бит мин,
Танымасаң, танытырмын —
Җаваплы работник мин!

Бүгенгесе көндә миндә
Гаять мөһим миссия —
Сабан туен, үткәрттерү
Буенча комиссия!

Ник бәйрәмнең шундый җитди
Программасын өзәсең
Һәм дә нигә безнең белән
Киңәшмичә сөзәсең?

Әйтү шушы, сез, үгезләр,
Гомумиләштермәгез,
Ә гомумиләштерсәгез,
Гомумән, дәштермәбез!

Кирәк инде, күптән кирәк
Сөзүләрдән туктарга,
Мөмкин елмаерлык итеп,
Чак кына кытыкларга...

Үгез: «Сайрап кал»,— дигәндәй,
Сүзе беткәнне көтте.
Көтте, иплән килеп төртте,
Өстәл аша сикертте;

Ялгышыпмы, чынлапмыдыр,
Ни булса булды, шунда
Фәлән Фәләнев башына
Тамызды Гарифулла!

Әйтерсең лә, буш чүлмәккә
«Гөрс!» иттереп кундырды —
Бик еракларга кайтаваз
Озак яңгырап торды.

### Унынчы әкәмәт

Төшләрендә мөгез күреп,
Кемнәрдер уяналар,
Бер туңып, бер эсселәнеп,
Төн буе уйланалар.

Очрашкач та киңәшәләр:
— Бу үгезне нишләргә? —
Күрә торып тормышны бит
Әйләндерә мәхшәргә...

— Гафил булырга ярамас,
Кирәк тозак корырга,
Үгезлеген сылтау итеп,
Иткә озаттырырга!

Калды алар җиңел сулап:
— Әҗәл җитте каһәргә!..
Көтү белән җибәрделәр
Үзен ерак сәфәргә.

Тузан йотып кичәмә көн
Бара колхоз терлеге,
Тояк астына коелып
Кала малның көрлеге.

Көч-хәл белән комбинатка
Җиткәч тә өстерәлеп,
Ун көн торалар капкага
Мөгез белән терәлеп.

Ашатмыйлар, шәп саклыйлар,
(Кәгазьдә мал саны бар!)
Сөякләре төртеп тора —
Саны бар да җаны бар...

Комбинатның директоры
Бигрәк калын тиреле.
Капшап карамакчы үгез
Үзе барып тегене.

Килсә, күрә — начальникка
Көтүдәй чират тора,
«Кайчан кабул итәр?» диеп,
Һәрберсе сорап тора.

Карлыгып беткән секретарь
Игълан итә һәркемгә:
— Өченчекөн язылганнар
Килсеннәр берсекөнгә.

Ансы дөрес, көтәр өчен
Шартлары тудырылган:
Газет-журнал, шашка-шахмат,
Домино куйдырылган:

Әрәм итмәсен вакытын,
Файда алып утырсын!
Башыңа төшкәч, нишләрсең,
Баш мәкалә укырсың...

Тик газета-журналларның
Сорама яңаларын —
Син чират көткән арада
«Хуҗа» укый аларын!

Башын айкый башлый үгез
Түземе тәмам бетеп.
Катлы-катлы ишекләрне
Мөгезе белән төртеп,

Кабинетка барып керә.
Күрә, утыра түрдә
Өстәлгә ябышып каткан
Такыр башлы бер түрә.

Шундый такыр, шундый якты —
Күренә күк үтәли...

Үтәли күренгән башын
Кәгазьләрдән күтәрми.

Булмый моны урыныннан
Һич кенә дә аерып,
Өстәлләре-ние белән
Ташлый үгез каерып!

Мәтәлдергәч бу түмгәкне,
Юнәлә ул капкага.
Караса, бер юан корсак
Бик сәер атлап бара.

Бу нинди гуҗ тагын диеп,
Бара да бәреп ега —
Йөрәге, үпкә-бавыры
Эләгеп килеп чыга...

«Бетте!..» димсез? Ашыкмагыз,
Торып йөгерде әнә;
Менә хикмәт, әллә инде
Ике йөрәкле бәндә?!

Җиңеләеп калгачтын ул
Йөгерә бар көченә —
Көн дә урлап ташый икән
Бәйләп шулай эченә...

...Капкадан чыккачтын үгез
Беравык карап торды,
Карашларын күз күрмәгән
Бүтән якларга борды.

Алда яңа маҗаралар,
Яңа сәфәрләр көтә.
Бәлкем әле очратырсыз —
Сезнең якларга китә!

*Сентябрь, 1964 – март, 1965*

# Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы

## *Белмимнең белеме артмый*

(Котбетдиннең бик белеп әйткән сүзе)

### Үз бизмәне

— Үземнең әллә ни вакыт калмый, әмма күршем китапны су кебек эчә! — ди Сәйфетдин мактанып.

— Минем күршегә җиткерәлми икән,— ди Котбетдин.— Минем күрше аракы кебек эчә...

### Хәстәрле

Берәү һәрвакыт чемодан белән китап күтәреп йөри икән.

— Нәрсәгә алар?

— Хәзер әйтәм,— ди теге, үзе шунда ук калын бер китап алып укый:

«Китап — белем чишмәсе!»

### Акыллы

— Кичә акыллы дигән сүзләреңнең бүген беркатлы икәненә төшенәсең,— дип көрсенгән Сәйфетдин.

— Анысы ярый! Былтыргы беркатлы сүзләрен быел да акыллы дип йөрүчеләр бар әле! — дип юаткан аны дусты.

### Йөзү

Сәйфетдин бер галим турында сөйли:

— Бик мәгълүматлы кеше, фәндә ул йөзә генә!

— Беләм мин аны, бер аягы белән җирдән тырнап бара! — ди Котбетдин.— Әллә ни тирәнгә керә алмый...

*Акылың алтын булса, аны алтын тешләр куйдырырга гына сарыф итмә!*

(Котбетдиннең акыл тешләре арасыннан чыккан сүзе)

### Такыр

Кара бөдрәләре белән масайган берәү Котбетдиннең сирәк чәчләренә ишарәләп:

— Тап-такыр калгансың ич, агай! — дип көлә.

— Нишләмәк кирәк, кайсы баш тыштан такыр инде, кайсы баш — эчтән...

### Чикләвек

Әстерхан чикләвеге баш өчен файдалы дигәнне ишеткәч, Сәйфетдин аны чамасыз күп ашаган да, эче авыртып ята:

— Кайчан акыл керер миңа, ах, тиле баш, тиле баш!

— Кара әле, кара, файдасы тия түгелме соң? — дип сөенә Котбетдин.— Үзеңә дөрес бәя бирә башладың!

### Ачыш

Берәү ачыш ясагандай әйтә:

— Беләсеңме, тормыштагы каршылыклар, бәхетсезлекләр кешене тәҗрибәле, акыллы итә!

— Синең көнкүреш артыгы белән шәп булган икән алайса,— ди Котбетдин.

### Яхшы эт

Нәселле этен кич йөртергә алып чыккан берәүгә юлыга Котбетдин. Тегенең бөтен сөйләгәне шул эте: ул акыллы да, ул тәртипле дә, ул тыңлаучан да, ул тагын әллә нәрсәләр икән!

— Үзе алдында сөйләмә, бозарсың! — ди Котбетдин.

— Әй, ул аңгыра нәрсә аңлый соң?!

### Кемнәр кала

— Төрле фикерләр килә башка. Кайсы шунда ук онытыла,— ди Сәйфетдин.— Фикерләр киләләр дә китәләр — без калабыз, Котбетдин...

— Без киләбез дә китәбез — фикерләр кала! — диген.— Хәер, кайсы кешенең фикерләре үзеннән алда китә...

### Бүтән оешмадан

Бик дәрәҗәле банкетта мәгълүм генә бер ханым биергә чакыргач, Котбетдин:

— Бии белмим шул, гафу итегез,— ди.

— Ничек инде? Шундый җирдә эшләүче шундый кеше бии белмиме?

— Без бит аяк белән эшләмибез, гафу итегез! — ди Котбетдин.— Без бүтән оешмадан!

### Танышлар

Кем турында сөйләсәләр дә, юньсезгә чыгарып тора бу кеше. Әле дә бергә эшләүче бер агайны мактагач:

— Би-ик яхшы беләм мин аны, ахмаклыкның аргы ягына чыккан нәрсә ул! — ди.

— Сез ул аргы якта еш күрешәсезме әллә? — дигән Котбетдин.

### Эчке культура

Каракүл бүрек, кыйммәтле пальто кигән бер адәм кукраеп кына йөри, сөйләшкәндә «эчке культура» дигән сүзләр дә кыстыргалый...

— Эчке культурасы тышкы кием булып күренә калса, бу кеше... шыр ялангач булыр иде...— дигән Котбетдин.

## *Күп сөйләүченең уйларга вакыты калмый*

(Сәйфетдиннең үз тәҗрибәсеннән)

### Бугаз

Сөйли дә сөйли берәү, тыңлый да тыңлый Котбетдин: «Кушбугаздыр бу!»

Сөйли дә сөйли теге, тыңлый да тыңлый Котбетдин: «Бишбугаздыр бу!»

Сөйли дә сөйли теге, тыңламый Котбетдин: «Бушбугаздыр бу!»

### Моны туктатып булмый

— Әгәр дә мәгәр бу иптәшнең җыелышта сөйләүгә киткән җегәрен эшкә җигеп булсамы,— дип хыяллана Котбетдин,— аның башы өстендә көне-төне зу-ур прожектор янып торыр иде!

— Көндез электр сарыф итү эшмени?

— Анысын аның теләгәндә сүндереп тә була, Сәйфетдин!

### Осталык

Берәү сөйли, Котбетдин тыңлый, тыңлаган саен гаҗәпләнүе арта:

— Ай-һай-һай!

Тора-тора да шуны кабатлый:

— Ай-һай-һай!

— Бик ошаттыгыз, ахры,— дигән сөйләүче соңыннан.

— Осталыгыңа хәйраннар-вәйраннар калып утырдым — шул хәтле сөйләп тә, мәгънәле сүз ычкындырмадың!

### Лекциядән кайткач

— Йә, Котбетдин абзый, ничегрәк булды лекция?

— Ул лектор сөйләгәндә чебен очкан тавыш та ишетелми... Алар да йоклап бетте...

### Озак яшәүнең сере

Тәнәфессез-нисез тоташтан бик озак барган җыелышларның берсендә:

— Попугай озак яши икән, менә укып кара,— дип, Сәйфетдин гәҗит суза.— 180 гә җитә дигән...

— Кеше әйткәнне кабатлаучылар озак яши шул,— ди Котбетдин.

— Әле трибунадагы иптәшне тагын 150 ел тыңлыйсы бар микәнни?

— Тыныч бул, ул чакта инде аны син түгел, оныкларың тыңлар...

### Озакка киткәч

Шактый сыек көн тәртибе тирәсендә сүз куерып киткәч, Сәйфетдин:

— Үгезнең мөгезеннән алырга кирәк иде! — дип ачынып утыра.

— Мәсьәләсе мүкләк бит, кай җиреннән эләктермәк буласың? — ди Котбетдин.

### Кем күпме сөйләшә

Котбетдин тагын хатын-кызның күп сөйләшүе турында шаярта башлагач, Хөббениса түзми:

— Сөйләшмибез, сөйләшмибез дип, сез, ирләр, күбрәк тә сөйләшәсез әле! — ди.

— Булыр да... Сез бит кыска гына әйтәсез: «Кайда йөрдең?» Ә безгә озын итеп аңлатырга кирәк...

### Мәгълүмат

Фәнни-популяр журнал укыштырып, шуның эчтәлеген сөйләп аптыраткан берәү:

— Дөньяда иң аз сөйләшә торган халык — финнар, иң күп сөйләшүчеләр — итальяннар, бразилиялеләр, мексикалылар икән! — ди.

Котбетдин абзый сөйләүчегә хөрмәт белән карый:

— О-о, болай булса, син итало-бразило-мексиканец түгелме икән?

### Сүзнең файдасы

Фермада җыелыш бара икән. Озакка сузылгач, Котбетдин кузгала башлый:

— Җәмәгать, сүз бозау имезә, диләр, бозауларыгыз туктыр да, әйдәгез, сыерларны ашатырга чыгыйк!

### Юаныч

Кулы-кулга йокмаса ни әйттең иде дә, теле-телгә йокмый шул, бертуктаусыз сөйләнә сатучы:

— Кулларым икәү генә, күрмисезме! Дүрт түгел бит!

Котбетдин исе китеп тора:

— Ә теле дүртәү бугай!..

### Учетка ябылган

Бер кеше турында сүз кузгалгач, һәркем үз мөнәсәбәтен белдерә:

— Тешләре камашканчы гайбәт сөйли ул! — ди Хөббениса.

— Гайбәт аңа һава белән су кебек кирәк,— ди Сәйфетдин.

— Ул гәҗитне дә дөнья гайбәтен эзләп укый! — дигән була Сәйфетдин хатыны да.

— Чү, җәмәгать, кызмагыз,— ди Котбетдин.— Авызы «учетка ябылган» — җавапка тартканнар. Үзегез аның урынына калмагыз...

### Җыелыш

Урамнан берәү үзалдына сөйләнеп кайта. Гаҗәпләнеп карыйлар бу кешегә.

— Нәрсәсе гаҗәп? — ди Котбетдин.— Гадәти күренеш — бер кешелек җыелыш бу!

### Хикмәте бар

Берәү Сәйфетдин турында сөйли:

— Тыйнак та кеше инде, үзе «алдан килгән — урын өчен!» дияр, үзе бер җыелышта да алга узмас, иң артта утырыр...

— Шул арттагы урын өчен алдан килә дә инде ул,— таярга уңайрак,— ди Котбетдин.

### Йокы качкан

Җыелыштан кайткач, Котбетдин йоклый алмый ята:

— Вәт, әкәмәт! Җыелышта үлепләр йокы килә, ә өйгә кайткач — ап-аяз... Сөйлә әле, хатын, берәр нәрсә... Юк, син йокы кача торган итеп сөйлисең шул! Гомумирәк сөйлә, безнең җыелыштагы кебегрәк итеп...

## *Мактаганда арттырып җибәрсәң дә бер сүз әйтмиләр, тәнкыйтьләгәндә киметеп әйтсәң дә үпкәлиләр*

(Котбетдиннең җыелыштан соң ясаган нәтиҗәсе)

### «Күз тимәсен!»

Трибунага чибәр генә ханым чыккач, Сәйфетдин:

— Тфү, тфү, күз тимәсен! — ди.

— Тфү, тфү, сүзе тимәсен, диген, шактый усал хатын ул...— дип төзәтә аны Котбетдин...

### «Җанкыйть»

Бер җыелышта утырганда Сәйфетдин:

— «Тәнкыйть» дип дөрес әйтмибездер, «җанкыйть» кирәктер... Җанны кыя бит, тәнне түгел!— ди. Котбетдин үзенчә аныклый:

— Икесе дә үз урынында дөрес: бүтәннәргә тисә — тәнкыйть, үзеңә эләксә — җанкыйть...

### Бирде кирәген

Сәйфетдин йокыдан соң гына уяна да кичәге җыелыш турында уйлап кәефләнеп ята:

— Әйттем әле! Бирдем кирәген! Шул кирәк ул юньсезгә! Авызын ачты да калды! Шулай йөзенә бәреп әйткәнне гомер күрмәгәндер!.. Ярый, бәхете инде — төшемдә булды бу хәлләр!

### Ялгышкан

Котбетдин, бик борчылып, мәҗлестәш ханымнан гафу үтенә:

— Зинһар, кичерә күрегез, кичә кызмача хәлдә: «Сез чибәр ханым!» — дип мактап, теңкәгезгә тиеп беткәнмен...

### Дөрес сүзгә җавап

— Әйбәт кеше син, Котбетдин!

— Мактама, Сәйфетдин, син уйлаганча ук әйбәт түгел мин!

— Үзеңә шундый таләпчән булгач, мин әйткәннән дә әйбәтрәк икәнсең!

— Менә монысына бер сүзем дә юк,— дигән Котбетдин, түбән карап.

## *Эш пешмәсә, эч поша*

(Котбетдиннең түшәмгә карап ятканда уйлаган уе)

### Муллык

— Булса да булыр икән муллык! — дип тел шартлата Котбетдин.— Ташыса да ташыр икән байлык: Камадан тоткан балыклардан нефть тәме килә! Камада үскән казлардан нефть тәме килә!! Камада йөзгән кызлардан нефть тәме килә!!!

## Бер хәреф

Котбетдин ферма сарыклары кайтып барганны карап тора:

— Начар көткәннәр көтүчеләр, бер хәрефен югалтканнар сарыкларның...

— Ул нинди хәреф тагын? — дигән председатель.

— Сарыкның «с»сын югалтканнар, «арык» кына калган...

## Симертә торгач

Калган ашлар әрәм түгелә дип, бер ашханәдә дуңгыз симертмәк булганнар. Ә ул, ни хикмәттер, ябыга бара икән... Мал докторына күрсәтәләр.

— Бар җире сау-сәламәт, юньләп ашатырга гына кирәк! —дигән тәҗрибәле врач.

— Кеше ашаганны ашый инде! — дигән директор.

— Кеше бәлкем ябыгыр өчен ашыйдыр, моңа бит симерергә кирәк! — дигән ашханәдән чыгып баручы Котбетдин.

## Күзне ачып

Гөмбә җыеп йөргәндә күз кабагына чыбык төртелгәч, Сәйфетдин:

— Ярый әле, күземне ачып барган чак булмаган! — дип сөенә.

— Әкәмәт, күзеңне ачыбрак карасаң, бусы да кагылмас иде! — дип төрттергән Котбетдин...

*Берәүләр — эш карый,*
*берәүләр — теш казый...*

(Котбетдиннең шулар арасында торып әйткән сүзе...)

## Хәер

Вокзалда чегән хатыны хәер сорашып йөри:

— Балаларымны ашатырга берничә тиен бирегезче...

Сузылган кулына акча салганда күрә Котбетдин — бармак саен алтын балдак!

— Вак акчасы юктыр мескеннең,— дип жәлләп кала Котбетдин.

## Дөреслек

Гыйльметдин бүлмәдә әрле-бирле йөри, үзе сәгатькә карый:

— Бер урында торсаң да, сине «йөри» диләр. Мине, йөрсәм дә, «тик тора» диләр. Кайда монда дөреслек?

— Кил әле, миңа булыш, дөреслекне бергәләп табарбыз! — дип кычкыра ишегалдында кое казып ятучы әтисе.

## Борынгыдан

Сәйфетдин тел галимнәре кызыгырлык ачыш ясаган:

— Иң борынгы фразеологик әйләнмәне беләсеңме? — «Койрыкны сыртка салып!» Моны кеше койрыклы чагында ук әйткән.

— Мин икенче нәрсә турында уйладым,— дигән Котбетдин.— Койрыкны сыртка салып йөрүче җилкуарлар бик борынгыдан килә икән!

## Хөрәсәннәр

Ял көнне Сәйфетдинне сәгать уннарда гына уяталар. Караватына торып утыра да ул, өйдәгеләрне битәрли башлый:

— Шушы көнгә хәтле йоклатмасагыз! И хөрәсәннәр дә инде — иртәрәк уятырга ярамаган! Хәзер менә торасы да килми...

## Ике авыру

Сәйфетдин эшкә чыкмый калган Котбетдиннең хәлен белергә килгән:

— Ни булды әле сиңа?

— Урында ятам менә, кузгалдым исә, акырам — радикулит...

— Гыйльметдин дә авырыймы әллә?

— Аның радиокулит — көне буе урында ятып радио акырта!

## Куучы бар

— Кая чаба бу Сәйфетдин, артыннан куып килүче юктыр ич? — дигән кибет каршында тәмәке төтәтеп утыручы берәү.

— Бар шул, дөнья үзе куа! —дигән Котбетдин.

## Яңа сынамыш

Котбетдиннән сорадылар:
— Кояш ни өчен кызарып чыга?
Котбетдин әйтте:
— Йоклап ятучылар өчен оялып...
Котбетдиннән сорадылар:
— Ә ни өчен кызарып байый?
Котбетдин әйтте:
— Уянмаганнар өчен оялып...

## Өлгерлек

Торып, юынып, эшләрен караштырып өлгергән Сәйфетдин малаен орыша:

— Ялкау малай! Төш җитеп килә, урын да җыймагансың!

— Кичкегә җәеп өлгергән диген, әти!

## Чисталык

Хөббениса тирләп-пешеп кер юа.

— Халык чистарды хәзер, керне химикатлар белән генә агарта,— ди ул эш ансатлашуга сөенеп.

— Халык чистарды, табигать пычранды! — ди Котбетдин төтәп торган торбаларга карап.

## Ырым-шырым

— Ит ашап йоклама, битеңне юып ят, пәри кызы үбәр, дип куркыталар иде безне бәләкәй чакта. Өлкәнәйгәч пәри кызы да үпми хәзер...— дип көрсенә икән Сәйфетдин.

— Өметсез — шайтан, диләр. Ит ашап йоклап кара әле,— ди Котбетдин, кордашының хәленә кереп.

## Командирны кызгана

Хөббениса түтәй армиягә китәсе оныгын иртән уята алмый гаҗизләнә:

— Мондый малайларны ничек уятыр командир бахыр... Берсен уятып күпме иза чигәсең!

### Сынатмыш

Оеп-оеп, йөгенеп утыра да:

— Йокы килә, яңгыр явар, ахрысы...— ди Хөббениса.

— Синең йокы килгән саен яңгыр ява торган булса, җирне күптән су басар иде! — ди Котбетдин.

### Тел-теш...

Конфет сатып алгач, Котбетдин:

— Комбинат директоры бик дөрес сүзле кеше икән! — дигән.

— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнгәннәр.

— Шулай!— дигән Котбетдин.— «Безнең конфетлар тел-теш тидерерлек түгел!» дигән иде, чыннан да, ни телгә, ни тешкә тидерерлек түгел — чытырдап ябыша!

## *Абруең югалса, табылдыклар өстәленнән эзләмә*

(Котбетдиннең начальнигына әйтәсе килгән тәкъдиме)

### Охшашлык

Ишегалдында йөргән әтәч бөртек таба да, дөнья куптарып, тавыкларны җыя һәм... үзе кабып йота!

— Безнең местком председателе сыман икән бу — бер путевка бар, дип җыеп киңәште дә, үзе үк Кырымга китеп барды,— ди Котбетдин.

### Төшә-төшә...

— Кибет мөдирен эшеннән алганнар иде, идарәгә зам итеп куйдылар,— ди Сәйфетдин.— Аннан да төшерделәр. Тагын да югарырак куялар...

— Төшә торгач, тәмам күтәрелеп беткән икән! — дигән Котбетдин.

### Алтын сәгать

Кабул итү бүлмәсендә көтеп утыра-утыра да сыкранып куя Котбетдин:

— Алтын сәгатемне югалттым бит...

Секретарь кыз гаҗәпләнә:

— Алтын дисезме?

— Алтын шул — иртәнге эш сәгатем!

### Эреле-ваклы...

Үзен бик зурга куеп йөргән берәүнең кабинетыннан чыга Котбетдин. Чират көткән Сәйфетдин сорый:

— Йә, ниндирәк адәм соң?

— Ерактан гына эре күренә икән, якын килеп карасаң, шактый вак кеше...

### Утырткан

— Рәхим итегез! — дип, бүлмәгә кергән начальнигына урын тәкъдим итә Котбетдин.

— Начальник башым белән шушы өтек урындыкка утырыйммы?

— Ә сез башыгыз белән утырмагыз! — дигән Котбетдин.

### Турысы

— Син нәрсә, тәртә йоткан кебек йөрисең! — ди берәү, имеш, Котбетдиннең горурлыгыннан көлә.

— Дугасын син йоткансың ич,— дигән Котбетдин, тегенең начальниклар алдында кырыкка бөгелүенә төрттереп.

### Авыру-сырхау

Бер иптәш, төчкерүен дә зур сырхауга санап, врачтан врачка йөри, җае чыккан саен шуның белән мактанып куя...

Котбетдин аны кызгана:

— Терелеп китсә нишләр бу, мескенем... Бөтен абруен югалта бит!..

## *Намустагы тапны химчистка бетерә алмый*

(Котбетдиннең саф күңеленә килгән уйлардан)

### Алдау

Котбетдин сыр сатып алганда ничектер кибетченең артыграк салуын сизенеп кала. Уйланып кайта — кире бирергәме, юкмы? Ярар, кибетче дә алдансын бер!

Кайткач карасa — арзанлы сыр... Бик сөенә Котбетдин:

— Ярый әле, мине алдаганнар! Үзем алдадым дип эчем пошкан иде!

## Ышанычны акламады

— Теге агай беркөн алган акчаны бирдеме әле?
— Юк, бирми инде ул аны!
Күп тә үтмәде, теге агай керде, Котбетдингә акчасын кайтарды... Котбетдин оялып калды:
— Ышанычны акламады... Кайтармаса ояты аңа була иде... Инде миңа калды.

## Югалту

Сәйфетдин оялып кына сөйли:
— ...Акча таптым. Кемнеке икәнне дә белеп торам, шайтан котыртты бит, кызыгып үземдә калдырдым... Уянып киткәч, төштәге табышым өчен тынычлыгымны югалттым...
— Юкка кыйналма — бир акчаңны, бүген төшемдә үзем хуҗасына кайтарырмын! — ди Котбетдин, дустына булышырга теләп...

## Биографиягә бер сүз

Бер егет судта биографиясен сөйли:
— Туганмын. Укыганмын. Эчкәнмен. Сугышканмын...
— «Утырганмын» дип тә кушарсың инде моннан соң —биографияңә бер юл, үзеңә өч ел өстәлер,— дигән Котбетдин залдан чыкканда.

## Ышаныч

Болынга чыккан кешеләр ярыша-ярыша чәчәк җыялар. Берсе кызыгып сары чәчәк өзә дә икеләнеп кала:
— Хыянәт төсе диләр...
— Ә син аны үзеңә калдыр,— ди Котбетдин.— Үзеңә хыянәт итмәссең бит!

## Борчылу

Сәйфетдин зарлана:
— Үрнәк итеп куеп, мактап кына харап иттеләр газиз башларымны! Эчми, тартмый, диләр... Ничек тарта-

сың, ничек эчәсең — әйбәт, дигәч, әйбәт булырга туры килә... Шулай, рәхәтләнеп бер кешечә яши алмыйча, гомерләрең заяга узып китсә нишләрсең...

Котбетдин дустына авырлык килгәндә күтәрешергә әзер:

— Кайгырма, булышырбыз, ул якларын безгә калдыр!

## Юатты...

Берәү гаеп эш эшләгән дә көрсенеп утыра икән.

Сәйфетдин моның хәленә керә:

— Беренче тапкырмыни... Кемнән ояласың, беркем дә белми, дисең ич!..

— Үзем беләм. Үземнән оят...

— Тапкансың оялыр кеше! Юньле кешедән оялсаң бер хәл иде! — дигән Котбетдин, тегене тәмам тынычландырып...

# *Дуслык — күңелгә кирәк, йөрәккә — терәк*

(Котбетдиннең Сәйфетдиннән ишетәсе килеп йөргән сүзләре)

## Яхшылыкның чиге юк...

Җыелышта Сәйфетдиннең персональ эше карала. Кызганып кына, каты бәрелмичә генә сөйлиләр. Стена газетасы редакторы чәчрәп чыга:

— Әй, сез, дуслары, яхшылык эшлибез дип, батырасыз бит кешене! Якларга түгел, аңларлык итеп әйтергә кирәк бүген!

— Шелтә бирергә кирәк, алайса,— ди Галәветдин уңайсызланып кына.

— Тагын да якынрак күрүче юкмыни? — ди местком председателе.

— Эшеннән алырга кирәк! Сабак булсын! Төзәлсен! — диде Галләметдин.

— Мин иң якын дус буларак: «Җавапка тартырга!» — дип кычкырырга тиеш икән алайса...— ди Котбетдин.

### Игътибар

Эре панельле йортта яшәүчеләр бер-берсенә аеруча игътибарлы. Үз фатирында Котбетдин төчкерсә, Сәйфетдин:

— Исән бул! — дип кенә тора. Димәс иде дә, ачулана теге:

— Ишетмәмешкә салышма, чукрак стеналар юк монда! — ди.

### Бүләк

Берәү кызыксына:

— Сәйфетдиннең туган көненә ни алдыгыз?

— Пианино.

— Шундый зур бүләкме?!

— Безгә нәрсә — җыйнаулашып илле сум җыйдык, калганын үзе өстәгән итте шунда...

### Аерма

— Колга буе үскәнсең инде!

— Ә син — кәрлә!

— Ник мине кимсетәсең?

— Үзең «колга» дидең...

— Мин синең артык ягыңны әйтәм, син бит минем ким ягымнан көләсең! — дигән Сәйфетдин үпкәләп.

### Уздырган

Таныш-белешләр Сәйфетдиннең исәнләшми-нитми генә узып баруын күреп хәйран калганнар:

— Кара әле, кара моны, яңа тун алдым дигәч тә, сәлам дә бирми башлады!

— Безне генә түгел, үз өен дә танымый узып киткән әле! — ди Котбетдин.

*Ул таныш-белешләр аркылы эш йөртә. Ә син?*

(Хөббенисаның Котбетдингә танышлык белән әйткәне)

### Замана баласы

Бишектә Гыйльметдин елый. Тирәсендә эти-энисе үрсәләнеп йөри.

— Кайлардан гына табасы шул имезлек дигәнне! — ди Хөббениса.

— Танышларыгыз юкмыни? — дип, тагын да катырак елый башлый бала.— Ничек яшәрсең мондый этиәни белән?..

### Файда

Сәйфетдин хезмәттәшенең кулын кыса:

— Рәхмәт инде, җыелышта минем эш тикшерелгәндә синең зур файдаң тиде!

— Нишләп? Мин бит бөтенләй сүзгә катнашмадым!

— Катнашмавың белән файда эшләдең дә...— дигән Сәйфетдин.

### Бай кеше

— Акча ваклап бир әле! — ди Сәйфетдин бер танышына.

— Хәзер, хәзер! — ди теге. Портмонетын ала, бүлемнәрен кат-кат актарып карый — эресе дә, вагы да юк...

— Вәт бай кеше! Акчасы югын да белми! — ди Сәйфетдин кызыгып.

### Үз итеп

Ательедан нәүмизләнеп кайткан Сәйфетдин Котбетдингә эчен бушата:

— Таныш тегүчегә костюм тегәргә биргән идем. Икенче ай йөртә инде! Килгән саен шатланып каршылый, юмалап озата... Танышлык белән тектерәм шул, юкса әллә кайчан якасыннан алып эшләткән булыр идем!

### Төшкә керегез

Бер танышы Котбетдиннең өенә килә дә:

— Син минем төшемә кердең,— ди.

Тәрбияле кеше буларак, Котбетдин:

— Вакытлы-вакытсыз кереп борчыганым өчен гафу итегез. Вакытыгыз булганда, минем төшкә дә кергәләгез! — ди.

### Модага ияреп

Мода турында сүз чыккач, Сәйфетдин:

— Хәзер итәкләр минидан максига таба китте,— ди.

— Кайсыбер кибетләрдә итәк астыннан әйбер озатулар да нәкъ шул юнәлештә үсә,— дигән Котбетдин.

### Ничек бетерергә?

Фельетон укыгач, Сәйфетдин:
— Әшнәлек тә әшнәлек дибез, ничек бетерергә соң үзен?! — ди.
— Танышлыксыз булмастыр, мөгаен! — ди Котбетдин.

### Җиде баҗай

— Җиде баҗайны бер бүре ашаган,— дип сөйләгәнне ишетә дә каршы төшә Котбетдин:
— Бер-берсен ашаганнар да, бүрегә сылтаганнардыр әле! Беләм мин хәзерге баҗайларны...

### Яхшы түгел

— Шатланам да, кайгырам да, Сәйфетдин, теге иптәш мин уйлаганнан шактый әйбәт кеше булып чыкты бит...
— Алайса ник кайгырасың?
— Инде мин үзем ул уйлаганнан начаррак булып калдым ич!

### Уен түгел

— Хәтерлисеңдер, Сәйфетдин, без яшь чакта «йөзек салыш» уены бар иде...
— Хәзер шуны кайберәүләр «йөзлек салыш» итеп уйныйлар икән. Кемнең кемгә салганын белмичә аптырый тикшерүчеләр...

### Ышанмый

Идел буеннан дача җире алгач, Сәйфетдин яңа күршесен мактый:
— Әйбәт булырга охшаган, «күрше хакы — алла хакы!» дип кенә тора.
Котбетдин икеләнә:
— Белмим шул — аллага ышанмый бугай ул...

## *Кеше кунагы тиз китүчән була...*

(Котбетдиннең сәгатькә карап уйлануларыннан)

### Яңарыш

Капкадан килеп керүгә, кунак ишегалдындагы үзгәрешне күреп ала:

— Былтыр ак тавыклар иде, быел һәммәсе дә кызылдан икән!

— Былтыр сез киткәннән соң нәсел яңартырга туры килде...— ди хуҗа.

— Алайса,— ди Котбетдин,— киләсе елга ниндиләр булыр икән?

### «Әтәч булып»

— Бер тавыгыбыз әтәч булып кычкыра башлады, хәерлегә түгелдер! — ди хуҗа, пычагын кайрап. Кунак моңа бик канәгать, кунак моны елмаеп тыңлый...

Иртән каралтыга чыкса, хуҗа кеше ни күрсен — кунак тавыкларны әтәч булып кычкырырга өйрәтеп ята.

### Кайчы

Кунак кайчы сорагач, Котбетдин:

— Дус кешедә тырнак кисмиләр! — ди.

— Ай буе торсаң, нишләргә?!

— Ай буе торгач, дус буламыни инде ул!..

### Хәленә керә

Килгән көнне үк кунак китәр юлга самолет белешмәкче.

— Килмәс борын киту турында уйлыйлармы? — ди хуҗа.

— Уйламыйм уйлавын,— ди Котбетдин.— Хуҗаның күңеле булсын дип соравым — үземә дә килгәннәре бар...

### Сагынган

Бер мәҗлестә моңарчы дәшми утырган бер абзый тора да моңлы-сагышлы итеп җырлап җибәрә:

Безнең дә бар мачыбыз,
Сезнең дә бар мачыгыз;

Безнең мачы сезгә барса,
Зинһар, ишек ачыгыз!

Җырлап бетерүе, елап җибәрүе була.

— Сагынган бу мәчесен, бик сагынган! — ди Котбетдин.— Тизрәк озатырга кирәк!

## Озата торгач

Хуҗа кеше кунакларына кызык итеп бер кыйсса сөйли:

— Китәбез, китәбез,— дип тәмам аптыраткач, төн уртасында кунакларны озатырга чыктык. Автобус килеп туктады. Соңгы автобус! Без өлгерик дип ашыгабыз, кунаклар әкрен генә атлый. Хатын белән икәү борылып карыйбыз да, әйдәп, кул изи-изи йөгерәбез. Кузгалды! Китә бит автобус! Сикереп менеп утырдык! Өлгердек! Ә кунаклар? Ашыгып озата торгач, үзебез киткәнбез, кунаклар кул болгап тора...

— Без соңгы автобуска калмабыз, иртәгә беренчесе белән үк китәрбез,— ди Котбетдин, хуҗаны тынычландырып.

## Әтәч тавышы

Котбетдин белән Хөббениса, элекке чакларын сагынып, кунакка кайткач, урынны печәнлектән сайлыйлар. Көн дә яшь әтәчләр кычкырып уята:

— Торырга вакыт! — ди Котбетдин, кәефләнеп.

Тора-бара әтәч тавышлары сирәгәя, ялгыз әтәчнең гайрәтле тавышы гына кала.

— Китәргә вакыт! — ди Котбетдин моңсу гына...

## «Үзем дә...»

Котбетдинне озату мәҗлесенә җыелганнар. Озатучыларның берсе тәмам кәефләнеп җиткән:

— Монда гына саубуллашыйм, вокзалга төшеп йөри алмамдыр,— ди. Кәефле Котбетдин үзе дә кулын гына селти:

— Йөрмә! Мөгаен, мин үзем дә китмәм әле...

## Кунак ашы — кара-каршы...

Төньяктан кайткан танышлары Котбетдиннәрдә кунак булып, үзләре яшәгән яклар турында сөйләгәннәр:

— Бездә төннәр алты айга сузыла...

— Алай икән,— дигән Котбетдин.— Чакыруыгызны кабул итеп без дә берәр кич кунып кайтырбыз әле!

## Культура җитми

Төнлә ресторанга чакыргач, бик шатланып бара кунак абзый. Шулпасын да эчә, башкасын да, һаман туктамый... Ул тукталмагач, хуҗа мул итеп тагын заказ бирә. Кунак, ашый-ашый тәмам авырайгач, ачуланып сөйләшә:

— Юк та инде культура безнең халыкта: төнге унбердә дык иткәнче ашаталар димени?

— Җитми инде культура дигәнең, җитми! — ди Котбетдин, аның сүзләрен җөпләп.

## Ашыгу

Кунаклар китәсе көн. Котбетдин өтәләнеп йөри: әйберләре җыелмаган, тутырылмаган, ә болар сузылып гәҗит укып ята!

— Соңга каласыз бит инде! — ди Хөббениса да түземсезләнеп.

Вокзалда билетка озын чират күргәч тә кунаклар:

— Булма-ас,— диләр, өметсезләнеп читкә борылалар. Котбетдин касса янына өелешкән кешеләрне этеп-төртеп ерып керә... Берзаман авызы колагына җиткән, билет әләктереп чыгып та килә!

Тәмам поезд кузгала башлагач кына тынычланып:

— Бигрәк ашыктыгыз!! Тагын бер-икене кунар идегез! — ди.

## Батырайган

Соң гына, ялгыз гына өенә китеп баручы Котбетдинне озата чыгалар. Хуҗа кайгыртып:

— Озатып куйыйк мәллә? — ди.

— Кирәкмәс. Нигә?

— Усал-унтагай очраса?

— Курыкмагыз, мин аларга тимәм!

Хуҗа канәгать — Котбетдин курыкмаслык хәлгә килгән ич!

### Чакыру

Котбетдин кунаклар озата. Күршесе киң күңеллеләнеп:

— Тагын килегез, озак тормагыз! — дип кала.

Озакламый күршегә дә ике-өч гаилә килеп төшә. Котбетдин сөенче ала:

— Кунак ашы — кара-каршы, бик сагыналар сезне дип, мин чакырдым аларны!

### Ял

Көн буе ашап-эчеп, кәеф-сафа корып йөргән кунаклар хуҗага рәхмәтләрен белдерә:

— Рәхәтләнеп ял иттек, ичмасам!

Котбетдин эчтән генә кунакларын саный да:

«Ун кешелек һәм бер атналык ардым...» — дип кала.

### Кунакчыллык

Җәй көне бер гаилә кунакка кайткан. Балаларның берсе Котбетдиннең муенына асылына, икенчесе җилкәсенә атлана, өченчесе бил каешыннан тарта, дүртенчесе артыннан этә...

— Атнадан артык тора алмыйбыз. Бик ашыгабыз! — диләр эти-әниләре.

Котбетдин авыз да ачтырмый:

— Юк, юк, уйламагыз да, сөйләмәгез дә, җибәрәбезме соң, җибәрмибез — өч-дүрт көнсез беркая да кузгалмыйсыз!

## *Техника заманында да юллардан җәяүле буран йөгерә!*

(Котбетдиннең автобус көткәндәге күзәтүләреннән)

### Коры калды

Коеп яуган яңгыр астында Котбетдин машина көтә. Килде машина, әмма туктамады. Яңгыр астында торган Котбетдин янына тагын бер юлчы килде:

— Юешләнеп торабызмы?
— Юк, коры калдык... машинадан!

### Кыйбатсына

Котбетдин машинага утырып кайта. Ярты юлга җиткәч:
— Күпме сорарсың? — ди.
— Биш сум.
— Туктат! Биш сумга мин аны җәяү дә кайтам, ник элегрәк әйтмәдең?! — ди Котбетдин.

### Әдәп

ГАИ посты каршыннан машиналар бик әдәпле генә, әкрен генә үтәләр. Котбетдин елмая:
— Мин, соңга калып кайткач, Хөббениса караваты яныннан аяк очларына басып үткән сыман болар!

### Юл рәхәте

Шәһәргә күчеп килгән Хөббенисаны трамвайда авылдаш ахирәте очрата:
— Шушылай рәхәтләнеп трамвайда гына йөрисең инде, ә? — ди ул, кызыгуын яшермичә.
— Котбетдин әле, авылны сагынып, җәяү дә йөри!
— Шәһәр кешесе шәһәр кешесе инде,— ди ахирәте болар тормышыннан көнләшеп.— Без шул җәяү йөрүнең дә кадерен белмибез...

### Ошамый

Хөббениса кайтып керә дә сукрана:
— Трамвайга кердең исә, сикереп торалар да урын бирәләр! Картая башлагансың диюләре юньсезләрнең! И-и, хәзерге яшьләр!
— Барысы да андый түгел, яшьләрне юкка чыгарып ташлама әле,— ди Котбетдин.— Миңа, мәсәлән, беркайчан да урын биргәннәре юк!

### Шофер ни атлы!

Исеме — Мөхәммәт аның. Руслар Миша диләр. Юлда очрап бик утырып кайтасы килгән бер әби:

— Миңлемөхәммәтмишә балам, әле дә син туры килдең! — ди.

## Каза

Мотоциклга атланып чапкан Гыйльметдин автобуска бәрелгән...

— Малаеңның хәле ничек? — дип кайгыртып сораганнар Котбетдиннән.

— Хәле әйбәт түгел автобусның — түләтмәгәйләре,— дигән абзый.— Безнең ташбаш башы белән яньчеп бетергән!

## Арзанайту

Берәү троллейбуста сөйләнеп бара:

— Менә, әйтегез әле, кеше кыйммәтрәкме, чемоданмы?

Берәү дә эндәшмәгәч, үзе үк җавап бирә:

— Чемодан, әлбәттә! Әнә кешегә билет 5 тиен, ә чемоданга — 10!

Шулай бара торгач, контролер керде. Тегенең билеты юк, имеш — штраф түләттеләр.

— Бер сум тора икән бу агай! — дип, тел шартлата Котбетдин.— Ә бит юкка гына үзен арзанайтып маташа!

## Киресенчә

Кунак йортында зур бүлмә. Төн уртасы узган. Ә ике кеше тәмәке тартып, кызмача баштан һаман гәпләшә. Менә Котбетдин торып утыра.

— Шаулашып уяттык мәллә? — дип сорыйлар аңардан.

— Юк, киресенчә, бөтенләй йоклатмадыгыз!

## Борчыла

Сәфәр чыккан Котбетдин ике-өч көн буе, бик сагынган сыман:

— Хатынга шалтыратасы иде, хатынга! — дип борчылып йөрде. Ниһаять, төн уртасында сөйләшергә җай чыкты:

— Нихәл анда, килгәннән бирле эчем пошып тора, мәчене дачада онытып калдырмадыгызмы?

### Юллар

Ике авыл арасында бер егетне туктатып, Котбетдин юл сорый.

— Әнә,— ди егет,— күрәсеңме каберлекне? Шуннан уңда...

— Аңлап җитмәдем, улым...

— Һемм... Әнә, ике кыз велосипедта килә! Шулар артыннан барырсың...

— Һай, рәхмәт төшкере, әйбәт тә төшендереп бирдең инде!

### Тәкъдим

Бер ханым самолетта очуны авыр кичерә. Машинадагы гадәт белән, иркәләнебрәк, йөрәген тотып ыңгыраша:

— Туктатыгыз! Хәлем начар!

— Туктатсак, барыбызның да хәле мөшкелләнер, әллә үзең генә чыгып керәсеңме? — ди Котбетдин.

### Җылыну аппараты

Авылда машина көтеп торганда салкын үтә башлагач, Котбетдин:

— Әйдә, җылыну аппараты күрсәтәм,— дип, Сәйфетдинне үзләренең капка төбенә алып килгән.— Ике элементтан тора ул — менә түмәр, әнә балтасы! Машина килгәнче җылына тор! Миннән булсын яхшылык!

### Ерак сәфәр

Котбетдин белән Хөббениса сәфәр чыгалар. Купеда икәүдән-икәү үзләре генә. Юл озын, вакыт күп! Дәшмитынмый, кызыксыз гына барганнан соң Котбетдин көрсенеп куя:

— Әй, син кыз чакта шулай бергә туры килгән булсак, рәхәтләнеп бер сөйләшкән булыр идек, иеме?

### Үзара бәйләнеш

— Производствода үзара бәйләнеш турында мисал китер, Котбетдин абзый! — ди бер дәрестә пропагандист.

— Була ул. Мәсәлән, трампарк белән төймә фабрикасы...

— Мин монда бернинди бәйләнеш күрмим!
— Трампарк яхшы эшләсә, фабриканың продукциясе складларда ятар иде...

## Җәяү йөрү

Трамвай ватылып туктап калгач, Сәйфетдин белән Котбетдин тәпи-тәпи киткәннәр. Сәйфетдин юлда очраган плакатларны укый кайта.
— Әһә, менә тагын берәү: «Җәяү йөрү файдалы, гомерне озайта!» дигән.
— Бик дөрес! Безнең саулыкны кайгыртып трампарк куйдыргандыр аны!

## Әйбәт урын

Шофер сөйли:
«Юлда өч карчык очрады. Икесен кабинага утырттым, өченчесен кузовка менгерештем. Карап торды да бусы:
— Ник мине дә кабинага кертмисең? — ди.
— Урын юк бит! — дим.
— Ә син чыгып тор! Япь-яшь башың белән! — ди бу.
Руль артыннан торып, җиргә төштем. Әби бераз утырды да, миңа карап:
— Ә-ә, юк, булмый икән...» — диде.
— Анда утырырга права кирәк шул! — дигән Котбетдин.

## Сюрприз

Кырымнан кайтыр алдыннан, көтелмәгәнрәк, гаҗәбрәк күчтәнәч эзләп йөриләр:
— Әнә теге ялтыравыклы кәгазьгә төргәнне бирегез әле! — ди Сәйфетдин. Карасалар — кипкән бәрәңге...
— Ал, ал,— ди Котбетдин,— ни әйтсәң дә, чит ил әйбере!
— Ничек чит илнеке булсын — бәрәңге ич!
— Америкадан килгән лә ул... Өч йөз ел элек!

## Аулак

— Синең өчен иң аулак җир кайда? — дип сораганнар Котбетдиннән.

— Танышлар булмаган җирдә! — дигән абзый.— Юкбар сораулар биреп йөдәтүче юк.

## *Тормыш тукталмасын өчен без йөгерәбез*

(Котбетдиннең ашыгып үтеп барышлый
әйтеп өлгермәгән сүзе)

### Саклый

Сәйфетдин үзе юкта дачадан мендәрләрен алып чыкканнар. Каравылчыга бәйләнә бу:

— Юньләп сакламыйсың! Аракы чөмерәсең дә йокы симертәсең! Атналар буе күренгәнең юк.

Каравылчы шул кичне үк мылтык асып чыга. Болар турысына җиткәч — гөрс! Төнге тынлыкта туп аткандай, сискәнеп уяналар... Күзне йомдым дигәндә генә, тагын — гөрс!

Хәзер инде каравылчы гына түгел, Сәйфетдин дә йокламый.

### Арифметика

Сәйфетдингә бер танышы зарлана:

— Бүтән эшкә күчерделәр бит әле.

— Кайгырма, урын алмаштырудан сумма үзгәрми,— дип юата Сәйфетдин.

— Үзгәрә икән шул — элекке урында илле сумга артыграк ала идем...

### Бер төчкерү белән

— Исәнлеккә-саулыкка! — ди Котбетдин, дусты төчкергәч.

— ... байлык белән муллыкка! — дип тә өстә инде.

— Бер төчкерү белән барына да ирешмәк буласың, Сәйфетдин! Бераз үзең дә тырыш әле!

### Тормыш сәнгате

— Һәркем үз тормышының сценарием үзе яза. Режиссеры да үзе, артисты да...

— Төрлечә була, Сәйфетдин дус. Кайберәүләрнең

сценарие — эти-әнисенеке, режиссеры — хатыны, үзе артист кына да була.

### Хәйлә

Җиткерүче булган, ахрысы, бер кибеткә халык контроле килеп, тикшеренә башлый:

— Итәк астыннан сатып ятасыз икән!

— Бик дөрес!

— Үзегез үк раслап торасызмы?

— Мин дә раслый алам! — ди Котбетдин.— Күз алдында күпме ятты — товарга әйләнеп караучы булмады. Танышлык белән дигәч, теттереп алалар! Өйрәнгән халык! Сезгә дә төреп бирикме — танышлык белән?

## *Мәңгелек двигатель юк диләр...*
## *Бар, ул — мәхәббәт!*

(Бу эшнең инженеры Котбетдиннең мәхәббәт двигателен көйләгәч ясаган ачышы)

### Конфет кебек

Котбетдингә Хөббенисаны мактап:

— Конфет кебек кыз! Бер кашык су белән йотарлык! — диләр.

— Конфет кебек дисезме? Тешкә тимәс микән? — дигән Котбетдин.

### Сирәк җимеш

Егет белән кыз, иркәләнешеп, бер-берсенә банан ашаталар.

— Банан күргән саен искә төшерермен! — ди Котбетдин.

Хөббениса курка кала:

— Ой! Алай ук онытып җибәрмә инде!

— Алайса, бәрәңге күргән саен! — дип тынычландыра Котбетдин.

### Миләүшәсе...

— «Маргариткам минем!» — дип эндәшкәч, яшь кыз Хөббенисаның күңелләре йомшап киткән. Котбетдин шаярта икән:

— Татарчасы «ишәк миләүшәсе» дигән чәчәк була бит.
— Синең миләүшәң булырга мин каршы түгел! — дип җавап биргән кыз елмаеп.

### Телсез мәхәббәт

Егет белән кызның ишарәләп кенә, елмаеп сөйләшүләрен күргән Хөббениса:
— Болар яратуларын ничек аңлаша икән? — ди.
— Мәхәббәткә сүз кирәкми. Ул кими башлаганда гына сүз арта,— ди Котбетдин.

### Хәйләкәр сорау

Хәйләкәр сорау биреп, кызык итмәкче булганнар Котбетдинне:
— Үткәннең кызы кирәкме сиңа, киләчәкнең әбиеме? Әйт әле тиз генә!
— Әлбәттә, киләчәкнең әбие! Үткәннең бер кызы өйдә утыра...

### Белергә кирәк

Хөббенисаны култыклаган Котбетдин сукранып бара:
— Хәзерге яшьләрнең кайсы егет, кайсы кыз икәнен дә аерып булмый!
— Сиңа барыбер түгелмени?
— Түгел шул — ялгыш егетләргә елмаеп куюың бар!

### Яратмый...

Хөббениса хезмәттәшләре турында сөйләгәч, Котбетдин:
— Сине яратмаган кешеләрне мин дә яратмыйм! — дигән.
— Ә яратканнарын? — дип наянланган кыз.
— У-у, яратканнарын бөтенләй яратмыйм!

### Әйтелмәгән сүз

— Гомер узды, «яратам» дип авыз тутырып әйткәнең дә юк! — дип турсайган Хөббениса.
— Нишлим соң? — дигән Котбетдин.— Башта иртәрәк иде, әллә үземә буласың, әллә юк...

— Ә хәзер?
— Хәзер — соңрак, инде тәмам үземнеке!

### Җыена

— Әни, мин теге егеткә кияүгә чыгам! — ди беркөнне Хөббенисаның кызы.
— Бик аз беләсең ич әле син аны?!
— Кеше — укылмаган китап кебек,— белеп бетергәч кызык түгел,— белер өчен чыгам!
— Кайткач, эчтәлеген безгә дә сөйләрсең! — ди Котбетдин.

## *Хатын-кыз урамга чыгып бер әйләнү өчен өч көн бизәнә*

(Котбетдин белән Сәйфетдиннең эчтән тынган сүзләре)

### Үлчәү

Кибеттән кибеткә йөреп эзләп тә Хөббенисага яраклы пальто таба алмагач, Котбетдин булып Котбетдин түзми:
— Синең үлчәүле кием табуга караганда, кечкенә үлчәүле хатын табуым ансатрак! — дип ычкындыра.

### Тун алу

Кибеттән кибеткә йөреп, тун сайлыйлар. Хөббениса киеп карый:
— Ничегрәк?
— «Кешеләрнең туны кыйммәткә төшә, үз тиреӊ булуга җитми инде», дип әйтә ди аю...
— Бар, күп сөйләнмә, түләп кил!
Түләп килде дә өстәде Котбетдин:
— Тун алу — туналу!

### Харап иткән

Машина таптап киткәч Хөббениса сикереп тора да шоферның якасына барып ябыша:
— Харап иттеӊ юбкамның плиссе-гофресын, ничек кеше күзенә күреним хәзер!

### Өлгермәгән

Урам буйлап ярым ялангач киенгән кыз узып бара. Борылып карый да, аптырап тора Сәйфетдин:

— Киенеп бетмәгән димме?..

— Чишенеп бетмәгән диген...— ди Котбетдин.

### Мәми һәм мини

— Хәзерге балалар белеп туа! — ди Хөббениса, оныгының кыланышларына исе китеп.

— Шулай, шулай,— ди Котбетдин.— «Мәми» дип телләре ачылуга «мини» дия башлыйлар!

### Алтын йөгерткән

Күрше хатыны Хөббенисага яңа алкасын күрсәтеп мактана икән:

— Алтын йөгерткән бу, алтын йөгерткән!

Котбетдин дә күз сала:

— Дөресрәге — алтын яныннан йөгерткән! — ди.

## *Хатыны бала тартып бара, ире тәмәке тартып бара*

(Котбетдин турында кеше сүзе)

### Хобби

«Минем Хөббием» дигәнне ишеткән дә, үпкәләгән Хөббениса:

— Егерме биш ел яшәгәч, хоббиең булып кына калдыммыни?!

Булдыра алганча юата Котбетдин:

— Хобби белән Хөббине бутама син. Шуны да аермаска — берсен ташлап була аның, икенчесен — юк!

### «Мәңгедән соң...»

Күңеле нечкәреп киткән минутларда Котбетдин карчыгына назлау сүзләре әйтмәкче була:

— Мәңге ташламам! Мәңгедән соң да бер-ике көн торырбыз!

— Ә ул ике көннән соң кем янына китмәкче буласың? — дип бәйләнә, имеш, Хөббениса.

## Үкенечле мәхәббәт

Ял концерты тыңлаганда, Котбетдин хискә бирелеп киткән, үкенечле мәхәббәт турындагы җырлар бигрәк тә күңелен кузгаткан:

— Нинди матур җыр... Синең белән кавыша алмасак, безнең мәхәббәттән дә матур җыр туасы икән... Иеме, Хөббениса?

## Телефоннан гына

Котбетдингә әйттеләр:

— Әле генә сине сорап хатының шалтыратты. Бигрәк матур икән тавышы!

— Һай, аның белән гомер буе телефоннан гына сөйләшеп торсам иде кана! — диде Котбетдин.

## Кактуслар

Бер буйдак дустының өй тулы кактусларын күреп, Котбетдин мондый киңәш биргән:

— Шулар урынына бер хатын гына алып кайтып утыртсаң, чәнечкеләре болардан ким булмас иде!

## Дөрес икән...

— «Кәгазь белән өстәл сөртсәң, тавыш чыга»,— диләр иде, дөрес икән...

— Син дә юк-барга ышана башладыңмы әллә, Котбетдин?

— Юк түгел, барны әйтәм — язылышу турындагы загс кәгазе белән өстәл сөрткәнмен дә, Хөббениса апагыз тавыш куптарды!

## Балдак һәм кыршау

Егет нечкә билле сөйгәне белән мактана:

— Сәгать каешы алып биргән идем, біленә буып куйган.

— Бигрәк юан икән,— ди икенчесе.— Минеке біленә балдак киеп йөри!

Мичкәгә кыршау көйләп тирләгән Котбетдин мыек астыннан елмая: «Мичкә көйләр чагыгыз алда әле!»

### Мөлаем тавышлы

Карты бер хатын турында сораша башлагач, Хөббениса:

— Аның белән ник кызыксынасың тагын? — дигән.

— Бигрәк мөлаем тавышлы... Ире белән ничек сөйләшкәнен күз алдына китерә алмыйм...

### «Ике хатын кирәк...»

— Бер хатын гына җитми шул,— дигән Котбетдин, хатыны белән култыклашып барганда...

— Картаеп беткәч, сөйлән инде!

— Картайгачрак кирәк тә инде ул, ике яктан култыкларга — аумас өчен...

### Мәхәббәт авазы

Заманында Котбетдин абзаң да озын-озын мәхәббәт хатлары яза торган булган:

«Әй минем сандугачым-сайрар кошым, синнән башка юк тормышым, аш түгел ашым...»

Чирек гасыр бергә яши һәм ашый торгач, озын җөмләләр ымлыклар белән алмашынган. Хәзер ул теге сүзләрнең дә соңгысын гына әйтергә ярата, ди:

«Әй, кайчан өлгерә ашың!..»

### Курыкмый

Хөббениса дачада, идән себеркесе тузган дип, урманга кереп чыкмакчы.

— Хатыныңны ялгыз җибәрәсең... Авызын томаларлар да алып китәрләр! — ди күршеләре.

— Булмас! — ди Котбетдин.— Алып китсәләр дә авызын томалый алмаслар...

### Чынбарлык

Бергәләшеп телевизордан, балалар әйтмешли, «мульти-пульти» карыйлар.

— Әкият дисәң дә әкият инде — убырлы карчык чепчибәр кызга әйләнде дә куйды бит әй! — ди Сәйфетдин кызыгып.

— Тормышта киресенчәрәк була шул — чеп-чибәр кызга өйләнәсең, тора-бара убырлы карчыкка әйләнә дә китә,— ди Котбетдин.

## Кайта торгач

— Кичә мәҗлестән ничек кайтып җиттең? — дип сорый Сәйфетдин Котбетдиннән.

— Җиту генә түгел, узып та киткәнмен! Кеше хатыннары кайтып җитмәгән өчен орыша, минеке узып киткән өчен ачуланды!

## Шик

Котбетдин өйгә төн уртасында гына кайтып керә.

— Эчеп кайттыңмы? — ди Хөббениса.

— Юк...

— Дуслар белән булдым, диярсең?

— Юк.

— Нишләп кенә йөрдең алайса?!

— Соңарганга сәбәп эзләдем дә, табалмый йөреп соңардым...

## Уртак сөенеч

Беркөнне Котбетдин бик борчылып кайта. Күрә, Хөббениса да кәефсез.

— Ни булды, карчыккаем?

— Сигез сум акча югалттым...

— Шулаймыни? Бик яхшы булган! Мин дә биш сум югалттым, әйтергә шүрләп тора идем әле!

## Төзәтү

Котбетдинне бер гаилә белән таныштыралар:

— Ире — Хәнҗәр, хатыны — Һаҗәр булыр...

Дәшми Котбетдин, аз утыра, күп сыный да әйтә:

— Боларның бит Хәнҗәре хәнҗәр түгел, Һаҗәре — хәнҗәр, ә Хәнҗәре — Һаҗәр!..

## *Ата-ананың эгоизмы да – үзен онытып, баласын кайгыртуда...*

(Котбетдиннең Хөббенисага, Хөббенисаның Котбетдингә аударган сүзләре)

### Бозалар...

Кунак малайның күңелен табарга теләп, ни сораса шуны кулына тоттыралар. Хәтта өстәлдәге кыңгыраулы сәгать тә Гыйльметдин кулына күчә. Хуҗа эчтән генә борчыла борчылуын:

«Бозалар инде сәгатьне!»

Котбетдин дә борчыла:

«Иркәләп бозалар инде малайны!»

### Кайгырту

Малаен ияртеп күрше хатыны кергән. Шук бала тәрәзә төбендәге үтүккә үрелә. Әнисе борчылып:

— Башыңа төшә күрмәсен! — ди.

— Әйе, әйе, үтүк табуы кыен хәзер! — дип, Хөббениса үтүкне эчкәрәк этәреп куя...

### Зур кеше

Кунак килер алдыннан Хөббениса Гыйльметдинне кисәтеп куя:

— Безгә зур кеше килә, юкны-барны такылдама!

Гыйльметдин кызыксынып көтә. Ишектә кыска буйлы кунакны күргәчтен:

— Зур кеше, дидегез, бәләкәй ич! — дип әйтеп җибәргәнен сизми дә кала.

### Үзгәреш

Шактыйдан күрешмәгән танышы очрый да сораша Котбетдиннән:

— Ничә балагыз бар?

— Дүртәү...

— Үзгәреш юкмыни?

— Бар. Хәзер сан артыннан кумыйбыз, сыйфат ягын карыйбыз — дүртесе дә укып йөри!

### Йөгерә генә...

Котбетдиннең шул хакта сөйләшергә ратканын белеп:

— Оныгыгыз ничек, үсәме? — дип сорыйлар.

— Йөгерә генә! Җир шарыннан ике адым алга китте инде! — ди Котбетдин, шатлыгын яшерә алмыйча.

### Пенсия

Балалар тәрбияләү турында сүз чыккач:

— Бик мәшәкатьле инде бала үстерүләре,— ди Сәйфетдин.

— Күпме генә инде аның мәшәкате,— дип куя Котбетдин.— Оныгыңны пенсиягә озатканчы кайгыртасы да, эше бетте!

### Бурыч

Котбетдиннең олы малае өйләнә. Бурычка батып булса да, гөрләтеп туй итәләр. Иркен сулап куя агай:

— Шөкер, өстән бурыч төште. Кесәдән түлиселәр генә калды...

### Киңәш

Гыйльметдин, гаҗәпләнеп, колачын җәеп күрсәтә-күрсәтә сөйләп тора:

— Ул абый менә мо-оның буе итеп сүгенде!

Котбетдин чәнти бармагын күрсәтә:

— Ә син андыйларны менә моның хәтле дә тыңлама!

### Синең кебек чакта...

Өлкәннәрнең «Синең кебек чакта...» дип сөйләүләреннән яшьләрнең күңеле кайтып беткән. Гыйльметдинне туган көне белән котлаганда, Котбетдин дә:

— Мин синең кебек чакта...— дип ычкындыра да, улының мораль укуны яратмаганлыгын исенә төшереп: — уналты яшьтә идем! — дип очлый.

### Екты...

Бакча балалары көрәшеп уйный. Баласын алырга килгән бер абзый чүгәли дә Гыйльметдинне шаярта:

— Ә мине ега алмыйсың!

Малай йөгереп килеп, көтмәгәндә, агайны артына утырта...

— Мин синең малаеңны да ега алам әле! — дип борынын чөеп куя.

### Кыек атып

Грипп таралган чорда кибетчеләр авызларын марля белән томалап эшлиләр. Нәни Гыйльметдин моны күреп:

— Апаларның авызларын ызгышкан өчен бәйләп куйганнармы? — дип сорый.

### Тәүге адымнар

Дружинниклар исерек егетне култыклап машинага алып бара.

Гыйльметдин моны күзәтеп тора икән:

— Әти! Теге абый йөрергә өйрәнәме ул?

— Утырырга өйрәнә, улым...

### Хәйлә

Гомер буе шома ияк белән йөргән картлач сакал җибәрергә булган. Кордашлары гаҗәпсенеп сорыйлар, дәшми. Котбетдин ачыклый:

— Сакал үстереп, хәзерге малайлар кебек яшь булып йөрмәкче ул!

### Кыска сүз

Картаеп беткәч яшь кенә хатын алган танышыннан сорый Котбетдин:

— Ничек, агай, яңа никах?

— Никак...

### Сан һәм сын

Өлкәнрәк хатын әйтә:

— Яшьне аны, җаным, кырык тулганчы утыз дип йөрисең, илле тулганчы — кырык дисең...

— Анысы шулай, санны яшереп тә була, сынны нишләтерсең? — дип кайгыртыша Котбетдин.

### Үзгәргән зәвык

Капка төбендәге эскәмиядә карчыклар гәпләшеп утыра:

— Тәмам җанга тия шушы яшьләрнең музыка кычкыртулары! — ди берсе.

— Мин зарланмыйм хәзер. Берни ишетелми,— ди Хөббениса.

### Шәһәрчә

Авылда бодайны агарттырып кына ашыйлар — табындагы ризык һәммәсе дә ак оннан. Арыш икмәге тансык! Хөббениса кучтәнәчкә арыш икмәге алып кайткан.

— Менә яши Хөббениса,— дип кызыгып сөйли ахирәте,— теләгән саен арыш икмәге ашый!

## *Ак чәчеңне гомереңнең ак флагы итеп күтәрмә!*

(Котбетдингә бик кыйммәткә төшкән фикер)

### Яшь

Туксан яшьлек юбилярны котлыйлар, берсеннән-берсе арттырып мактыйлар:

— Яшь әле син, җитмешне дә бирмәссең! — диләр.

Котбетдиннең тыңлаган саен күңеле күтәрелә:

— Безнең дә яшь булып күренәселәр алда икән әле! — ди.

### Бушлай...

Сәйфетдин, кибеттән кайткач, ачуыннан нишләргә белми:

— Сатучы кызга хәтерем калды — мин акча сузып торам, әйләнеп тә карамый, бер егет кәмәше белән бушлай ләчтит сата!

Котбетдин дустына кызганып караган:

— Синең акчалар алмашты шул инде...

### Киңәйдекме?

Яңа йортка күчкәч өнәп бетермәгән Сәйфетдин:

— Хәзер коридорларны таррак калдыра башладылар, элек ике кеше очрашканда ансат үтеп китеп була иде!

— Тар күңелләнмә — үзебез киңәйдек бугай! — дигән Котбетдин.

### Сроксыз паспорт

Яңа паспорт алгач, Сәйфетдин моңсулана:
— Бүтән алыштырасы да юк... Соңгы паспорт...
Котбетдин сөенә генә:
— Сроксыз паспорт бирделәр — теләгән хәтле яшәргә була!

### Тигезле

— Син миңа караганда тизрәк картаясың, карткаем, чәчең агара бит...
— Сана әле, Хөббениса, ничәүләп икән?
— Күзем күрми шул...

### Яшь чактагы кебек

— Бер дә үзгәрмәгәнсең әле, һаман шул яшь чагыңдагы кебек! — диләр Котбетдингә. Абзый көзгегә карый да офтана:
— Яшь чакта да шундый карт булдым микәнни? Ничек Хөббениса миңа караган диген?!

### Тигезсезлек

— Бу нинди тигезсезлек! — дигән Котбетдин.— Без яшь чакта гел картларга хөрмәт иде, без өлкәнәйгәч — гел яшьләргә игътибар!..

## *Күңел аракы салган саен бушый бара*

(Котбетдиннең ачы тәҗрибәсеннән)

### Җитеп килә

Зират юлында бер исерек ята. Дүрт аякланып калкына да тырышып-тырмашып кузгалмак була.
— Озакламый барып җитәр бу, болай булса! — ди Котбетдин, читләтебрәк атлап.

### Эчә

Урамнан алпан-тилпән килгәнен күреп:
— Ул кеше аракы эчмәскә сүз биргән иде,— ди Сәйфетдин.
— Сүз бирү генә түгел — антлар эчкән иде!
— Соң?
— Антлар эчүче эчкечегә әйләнде! — дигән Котбетдин.

### Аяк чалу

Урамнан кызмача кеше кайтып килә, атлаулары чалыш-чолыш.
— Кара инде бу адәм көлкесен,— ди бер хатын.— Үз аякларында үзе бутала бит!
— Үзенә үзе аяк чала ул,— ди Котбетдин.

### Үлчәүдә...

Мунчада бер кызмача абзый үлчәүгә менеп баскан:
— Күпме булдым икән? Дөрес күрсәтәме бу?
Котбетдин карый да әйтә:
— Дөп-дөрес күрсәтә: 83 кило да ярты литр.

### Җыелышта

Колхозда отчет-сайлау җыелышы. Район вәкиле яңа председатель тәкъдим итә:
— Фәләнов лаеклы булырмы?
Күрше колхозда моның niләр кылганын белгән халык дәшми тора.
— Лаякыл булыр, лаякыл...— ди Котбетдин.

## *Йом күзеңне, ачкүз!*

(Котбетдиннең күзгә карап әйтәсе килгән сүзе)

### Бурыч

— Мин үзем, кешегә бурычым булса, йоклый алмыйм,— ди берәү мактанып. Котбетдин моны ишетеп торган икән:
— Алты ай буе йокысыз интеккәнсең... Тынычларсың — түлә миңа бурычыңны,— ди ул.

## Үпкә

Бер иптәшнең гадәте шундый: җыелыш булдымы, атылып трибунага чыга да үзенең кемгәдер, кайчандыр, нәрсәгәдер булган вак-төяк үпкәләрен саный башлый. Беркөнне Котбетдин аның зарын тыңлап тора да:

— Авызын ачса, үпкәсе күренә моның,— ди.

## Әдәпле сөйләштем

Көтмәгәндә башланды сүз. Кибетче хатын бер егеткә:

— Кычкырма, тупас! — диде.

— Син үзең ахмак! — дип җавап бирде тегесе.

— Ник алай сөйләшәсез, паразитлар! — дип кычкырды чираттан бер хатын. Ире дә бу тәртипсезлеккә чыдый алмады:

— Һай, әшәке халык, туктыйсызмы, дуңгызлар! — дип өстәде.

Минем дә тел кычытты, ләкин дәшмәдем, сүземне эчтән генә әйтеп чыгып киттем: «Этләр белән эт булганчы... Дәшмә, Котбетдин!»

## Мәгънәсе

— Бу егет бездән бер башка зуррак икән,— ди Сәйфетдин, ырып-ерып чиратсыз үткән үсмергә күрсәтеп.

— Бер башка түгел, бер буынга,— дип кордашы сүзен төзәтеп куя Котбетдин.

## Урлаганмы?

Янына чибәр генә яшь хатынын утыртып, машинада бер өлкән абзый узып китә.

— Яшьлеген урлаган бу моның,— дип кала Сәйфетдин.

— Ник урласын, сатып алган! — ди Котбетдин.

## Былтыр...

Киңәш-табышка дип, бер кыз килгән:

— Вәгъдәләшкән егетем ташлап китте...

— Кайчан?

— Былтыр...

— Былтыр кочканга быел кычкыралармы?! — дип, сүзне мәзәккә бормакчы Котбетдин.

— Үзем түгел, баласы кычкыра шул,— дигән яшь хатын, моңаеп...

## *Бүре баласын бүреккә салсаң да урларга карый...*

(Котбетдиннең мәкальдән чәлдереп әйткән сүзе)

### «Миләүшә нурлар»

Бер колхозда сөтнең куелыгы югары икән. Галимнәр тикшерәнә, нәрсәдә хикмәт: нәселдәме? Төбәкнең үзенчәлегендәме? Үлән составындамы? Миләүшә нурларның күбрәк төшүендәме?

Серне Котбетдин абзый ача:

— Андагы Миләүшәләр сөткә су кушмыйлар...

### Чагыштыру

Сәйфетдин сәфәрдә йөреп кайткан:

— Авылда сөт эчәсең — каймак кебек! Шәһәргә кайткач, каймак ашыйсың — сөт кебек...

— Гел тәнкыйтьләргә генә торма әле, Сәйфетдин! — ди Котбетдин.— Ә син шәһәргә кайтып май аша да, каймак дип макта!

### Физзарядка

Урман сакчысы агач кисүчене тота, акт төзи.

— Физзарядка өчен акча түләтәләрме инде?! — ди теге.

— Нинди зарядка тагын?

— Утын кисүне минем эти физзарядка гына ди...

— Этиеңә әйт — җәяү йөрү дә бик файдалы диген,— тәпиләп кенә лесхозга барып, шушы штрафны түләп кайтсын! — ди Котбетдин.

### Юмарт

Урман сакчысы зарлана:

— Бер кубометр агачтан туксан литр спирт чыга. Шуның ярты литрын алып, калганын төятеп җибәрәм икән — начармы?

— Имәнне эчеп, юкә белән баш төзәтәбез, дисең алайса,— дигән Котбетдин.— Берзаман кәкре каенга терәлеп калмабызмы?

## *Аның характерлы ягы – характерсызлык*

(Котбетдиннең әйтимме-юкмы дип икеләнеп торган сүзе)

### Төеннәр

Кемдер берәү: «Онытмас өчен яулык читеңне төйнәп куй, Котбетдин абзый»,— дип өйрәткән иде. Беркөнне, йөри торгач, яулыгымның дүрт читен дә төенләп чыкканмын. Кайткач күрдем, чишкәләп тә карадым, ник төенләгәнемне генә хәтерли алмадым... Кем биргән иде соң әле бу киңәшне?..

### Газета ярдәм итте

Берәү, яңгыр яуды исә, түшәмнән агып квартираны су баса дип зарланып газетага яза. Озакламый хаты басылып та чыга. Авторны, газетадагы адресы белән, ташлаган хатыны барып таба. Алименттан качып йөргән икән.

— Судан чыгам дип, утка барып керде бу абзый,— ди Котбетдин.

### Диагноз

Котбетдин врачка бара: вестибюляр аппаратка зыян килде, ахрысы, ди, дөнья бер якка авышкан кебек, ди. Төрле врачлар карый, төрле анализлар алып бетерәләр... Утырып, ятып торса — әйбәт, йөри башлады исә, тагын шул ук хәл — дөнья бер якка авыш...

Аксап-туксап кайтып барганда, бер карау белән әйтә моңа итекче:

— Сул ботинкаңның үкчәсе төшкән ич, кил, кагып җибәрик!

### Һавалар ничек...

Өйгә кайтып кергән картыннан сорый Хөббениса:

— Һавалар ничек анда? Кибеткә чыгыйм дигән идем.

— Белмим,— ди үз уйларына чумган Котбетдин, аптырабрак.

— Берәрсеннән сорыйсың калган!
— Кемнән сорыйсың — барысы да зонтик астында! — дигән Котбетдин, яңгыр тамып торган плащын элеп...

## *Шәхеснең бизмәне – кылган гамәле*

(Котбетдиннең бер колагыннан кереп, икенчесеннән... чыкмый калган сүзләр)

### Холык

Бер танышы төш күргән дә Котбетдингә сөйли икән:
— Төшемә бөтенләй үз холкың-гадәтең белән кердең инде, һаман шулай шырпылы...
— Кай кешенең өнендә дә үз холкы булмый әле! — дигән Котбетдин.

### Үз өстеңдә эшләү

— Үз өстеңдә ничек эшлисең? — дип сорагач, Котбетдин:
— Күпме мөмкин?! — дигән.— Болай да... гомер буе тырышып, чи материалдан нинди кеше иттем үземне! Минем кулга эләккәндә кем идем мин?! Шуннан ары яхшырту мөмкин түгел, бозып куюым гына бар...

### Читенлек

— Теге җыелыштан соң Галләметдин исәнләшми башлады,— дигән Сәйфетдин. Турысын әйткәнгә үпкәләде, ахры...
— Галләметдин нәрсә, атна буе Котбетдин сәлам бирми әле! — дигән Котбетдин.

### Ирек

Котбетдин белән Сәйфетдин ял йортына килгәннәр.
— Иреккә чыктык, ичмасам! — дип шатлана Сәйфетдин.
Котбетдин эчке тәртип кагыйдәләрен укый:
— Ашыкма әле, ирекнең шартлары шундый күп — борылырга да урын юк монда!

# *Көннең кадагына да гасырларда калырлык итеп сугып була*

(Котбетдиннең чүкечне ялгыш бармагына эләктергәч әйткән сүзе)

## Кайчан эшли?

Котбетдин бер язучы янына сөйләшеп утырырга дип кергән. Тегесе шыпырт кына кәгазьләрен читкә шудырып куя, эштән бүленеп кәефе кырылганны сиздермәскә тырыша.

Ә Котбетдин утыра-утыра да як-ягына карана:

— Бу язучылар кайчан гына эшли соң? Ничә керсәм дә тик утырасың,— ди.

## Дөрес уйлау

— Бу әсәрне укый башлагач та, яңалык юк дип уйлыйсың...

— Ә укып чыккач?

— Укып чыккачмы? Укып чыккач, үзеңнең дөрес уйлавың турында уйлыйсың...

## Мавыгу файдасы

— Бу абзый, бөтен дөньясын онытып, балык белән мавыккан әле! — ди Сәйфетдин, яр буендагы бер язучыга ишарәләп.

— Тс-с, шаулама! — ди Котбетдин.— Аның балык тотуыннан, ягъни язмый торуыннан әдәбиятка файда гына бит.

## Чиксез мөмкинлекләр

— Фәлән шагыйрь турында ни әйтер идең? — дип сораганнар Котбетдиннән.

— Укыган саен шаккатам — чиксез аның мөмкинлекләре...

Бераз тынып тора да дәвам итә:

— ...инде шуннан да начаррак язып булмыйдыр дисәң, яңадан-яңа үрнәкләрен биреп тора!

### Танышлык белән

Үзенә игътибар җитенкерәми дип уйлаган бер язучы зарлана:

— Ул Шекспир, Толстойларның юбилейлары була да тора, әсәрләре чыга да тора! Минем күз алдымда гына ничәмә тапкыр йөз еллыкларын үткәрделәр!

— Танышлык белән инде, танышлык белән! — дигән Котбетдин.— Аларның танышлары дөнья тулы бит!

### Күтәрә торгач

Сыйфаттан бигрәк, сан артыннан куучы бер язучы турында тәнкыйтьче тагын зур гына мәкалә язган.

— Күтәрә, бик күтәрә бу моны! — диләр каләмдәшләре.

— Аны күтәрә торгач, үзе төшеп бетте инде! — дигән Котбетдин.

### Үз фикере

Яңа әсәрен укыгач, авторга үз фикереңне әйтү, турысын әйтү бер дә ансат эш түгел... Котбетдин дә тотлыгыбрак:

— Теле юк бит...— ди.

— Тел нәрсәгә — тәрҗемә иттерәм мин аны!

— Алайса берочтан фикерен дә тәрҗемә иттер инде.

### Фаҗига

Сәйфетдин, укыган әсәре турында сүз башлап:

— Сиңа да кызганыч тоелгандыр, иң ахырдан герое үлә...— ди.

Котбетдин авыр сулап:

— Яңа кульязмасын укыдым, бусы тагын да кызганычрак — бусында автор үзе үлә...— дигән.

### Яңа мәзәк

Берәү яңа мәзәк язып, Котбетдингә килгән. Укып чыга да Котбетдин, кабат-кабат әйләндереп карый...

— Йә, ничек?

— Әйбәт — каян аласың шундый кәгазьне, ә?

## Юллар, юллар...

Сәйфетдин килеп кергәндә, Котбетдин, эчен тотып, ыңгырашып утыра...

— Ни булды?

— Берәүнең шигырьләрен укыган идем, сикәлтәле юлларыннан дыңгырдап бара торгач, эчемә кату чыкты.

## Яхшы китап

Яңа гына басылып чыккан бер китап турында сүз чыккач, Котбетдин дә кушыла:

— Тозы да нәкъ чамасында, борычы да кирәгенчә — тәнкыйтьче сүз әйтерлек түгел. Өстәлеңдә генә тотарлык!

Тәмле ашлар китабы турында сөйли икән...

## Тәрҗемә мәсьәләсе

Котбетдин белән Сәйфетдин кичке тынлыкта сандугач сайравын тыңлыйлар:

— Моны тәрҗемә итсәң, нәрсә килеп чыгар иде икән? — ди Сәйфетдин хыялланып.

— Чү, шаулама, тәки тәрҗемә итәрләр, тыңларсың аннары карга каркылдавын!

## Тәрҗемәнең файдасы

Бер шагыйрьнең тәрҗемә китабын укый да гаҗәпләнә Сәйфетдин:

— Әйбәтләнгән ич бу!

Котбетдин дә укып карый:

— Берәр талантлы шагыйрь яңадан язса тәмам рәтләнәчәк!

# Хикмәтле сүзләр

## Беренче төркем

### *Мактану да гаеп түгел — туган җир белән мактансаң!*

о Күл — туган ягыннан аерылырга теләмичә бөгәрләнеп яткан инештер! Саекмасын гына.

о Күңелдәге сагыну бөресе туган җирдән киткәч ачыла...

о Чыпчыкка да бер Ватан,
Лачынга да бер Ватан.

о Бөек кешеләрне һәркем үзе сыйдыра алган чаклы күрә...

о Байрак җилфердәгәндә матур, хәрәкәттә тере!

о Туган җир йөзенә кызыллык китермә!

### *Галәм гизгән батыр да көч җыярга табигатькә кайтыр*

о Язның беренче карлыгачлары — кара каргалар килде!

о Кара каргалар килгәч, күңелләр яктырып китте...

о Язгы ташу яз ташый!

о Кыш бетеп яз башланган мизгелләр янәшә генә!

о Килер язны үткәнен сагынганга көтәсең.

о Язын бар йөрәкләр дә бер яшьтә!

о Кәккүк — җәйнең кайтавазы...

о Кайсы кош үзе матур, кайсысының сайравы матур.

о Гомере бер көн булган күбәләкләр дә мәңге яши!

о «Өй артында — шымытыр...» — ягъни чәчәк аткач та ботарлап бетергәннәр шомыртны.

о «Кирәк тирәкне ега» — ләкин «кирәк»кә дә чик кирәк!

о Җәй сәламәтлеге — кызуда, кыш тазалыгы — салкында...

o Завод моржасында кош сайрамый.
o Аксак карга сак.
o Кала кары кара...
o Салкын чишмәләрдән җылы истәлекләр генә торып калмасын...

## *Сугышны секундлар башлый, еллар гына бетерә...*

o Җину көненең дә иң соңгысы булсын — сугышлар кабатланмасын!
o Сагыш — сугыш сулышы...
o Балаларны аналар тудыра, батырларны көрәш тудыра!
o Кояшта яфрак матурлыгы күренә, давылда тамыр ныклыгы беленә!
o Батыр — батмас,
Куркак — калыкмас!
o Юклыкта сынатмаган туклыкта сынган...

## *Калай сәгать тә алтын вакытны күрсәтә*

o Сәгать — егерме ташлы вакыт тегермәне.
o Сәгать әкрен йөри, вакыт тиз уза.
o Сәгать теле — барлык милләтләргә дә аңлашыла торган тел.
o Вакыт кадерен белмәүчегә сәгать телен күрсәтә.
o Сәгатең алга китсә, үзең артка калырсың.
o Һәркемдә сәгать, карап кына торабыз, алай да вакыт җитми!
o Мәңгелек утны да мизгел кабыза!
o Борын заман да заманында хәзерге заман булган.
o Берзаман безнең заман да булыр борын заман...
o Җинаятьле елларның бармак эзе гасырга төшеп кала...
o Пәрәвез паровозны туктата алмый.
o Үткән гомер әрәм түгел, әрәм үткән гомер әрәм!
o Исәннәр үлгәннәр акылы белән яши...
o Үткәннәрне үпкәләтмә, киләчәкне үртәмә!

## Аш тәме – эш тәмендә!

о Эшләп ару — тәнгә дару.
о Яратмаган кеше белән яраткан эшне дә эшләп булмый...
о Иң тиз туйдыра торган эш — ял...
о Комсыз булсаң да ярый — эшкә комсыз булсаң!
о Җир эшен авырсынмасаң,
Авыр җимешләрен җыярсың.
о Кашык белән көй чыгарып та тамак туйдырып була...
о Мич башындагы эш башында була алмый.
о Базмаган — базда утырган.
о Йокы мичкәсе кыяр тозларга да ярамый.
о Яшәүне кушәүгә алыштырган.
о Авыл хуҗалыгын авыз хуҗалыгы дип аңлый...
о Ашауда ялкаулар юк.
о Эш — эшкә, урын — ашка...
о Әрәмтамакка
Әрәм табак та!
о «Алма пеш, авызыма төш!» — дип ятканда, алма төшеп тешен сындырган.
о Бер тиле бозганны ун акыллы төзәтә.
о Уңмаса ашлык,
Урнаша ачлык...
о Кара көндә кара икмәк күз алларын яктырта.
о Пычракны яратмасаң — җиңеңне сызган!

## Кызыкны тормыштан гына көтмә, үзең дә тормышны кызыклы ит!

о Менгән биеклектә тору ансат түгел. Төшкән түбәнлектән чыгуы тагын да читенрәк.
о Бүген шатлык киләсен белсәм, кичә кайгырмаган булыр идем.
о Бүтәннәр белән тарткалашып, үзең белән көрәшергә вакыт та калмый...
о Зарланганны яратмыйбыз, зарланырга яратабыз!
о Яхшырак яшәүчеләр ешрак зарланучан.
о Кем — шатлыгын кайгырып уздыра,
Кем — кайгысын да көлеп үткәрә!
о Тар күңеллене киң күңелле дә сыйдырмас.

о Кеше ошатмаса бер хәл, үзеңне үзең ошатмый башласаң нишләрсең?
о Без беркатлылардан көлгәндә, бездән кем көлә микән?
о Борчылуыңның сәбәбен белсәң, тынычланып та була.

## *Сынатмаганны тормыш күбрәк сыный*

о Мәңгелек дөньяны мизгел гомерем белән үзгәртәм дип яшә!
о Барын да гафу итү киң күңеллелек булмагандай, таләпчәнлек тә тар күңеллелек түгел.
о Дөньяны төзәтә торгач, бөтен дөньясы белән бозылышып беттек!
о Үзсүзлелек үзең хаклы булганда гына яхшы.
о Кайчакта көчсезлегеңне күрсәтмәскә дә көч кирәк!
о Көчсез көчленең көчсез көнен күреп көчәя.
о Шапалакка кунган чебен исән кала...
о Шәхесне ихтирам итсәң, хатасын да аңларсың.
о Юл авыр булса да, юлчылар бетми.
о Һәр сәфәр —
Фәлсәфә!
о Тәгәрмәч эчендә йөгергән тиен ташбаканы да уза алмый.
о Борчалар гомер буе көрәшәбез дип инандылар...
о Һәр таштан да ут чыкмый.

## *Ятып калганчы, язып кал!*

о Сәнгатьтә тирәнлеккә төшү өчен биек күтәрелергә кирәк!
о Халыкның шатлыгына — үз җырчысы, кайгысына — үз җырчысы...
о Чорың нинди — җырың шундый!
о Мәңгелек каләм белән гомерлек фикер язсаң да ярар иде...
о Әдәбият тормышта фокус күрсәтү түгел, тормышны бер фокуска җыеп күрсәтү.
о Тормыш чынлыгын ялангач күрсәтергә ярамый — берәр нәрсә кидерергә кирәк...
о Өйрәнчек остазын уздырса, бу — остазның җиңүе!
о Беренче булырга күнекте исә, кеше икенче урынга кала.

о Дан үзе турында уйлаганнардан ерагая.
о Суын алмаган кое тизрәк корый...
о Тәнкыйтьче язучыны үз дәрәҗәсенә күтәрәм дип шактый төшергән.
о Кем лирикка илһамчы, кем — сатирикка...
о Көлке көлә килә, елатып китә.
о Мәзәк аңламаган кешегә юморист тәртип бозучы булып күренә.
о Сатира уты ут кебек — тормыш организмына бик кирәк!
о Тормышта үз принцибы булмаган язучының әсәрендә нинди принципиальлек булсын?
о Бер халтурщикка яхшылык эшләсәң, мең укучыга начарлык кылырсың!
о «Кыскалык — талантның сеңлесе» булгач, озынлык — халтураның апасыдыр?
о Тормышны артык шомартма — шома юл тайгак була...
о Искергән мэтр дөрес үлчәми...
о Үзенең яхшы атын оештыра-оештыра яман аты чыккан...
о Кайсы анекДОТ дошманның ут ноктасына әйләнә...
о Әдәби хәрәкәткә хәкарәт иткән...
о «Яшә!» дип язылган такта төшеп башын тишкән...
о Мемориаль такта — кадер тактасы: кабер тактасыннан соң йөри...

## *Сүз эчендә хикмәт бар*

о Кем сүзгә тапкыр, кем сүзгә такыр...
о Тапкыр сүз мәгънәне тапкырлый!
о Тапкыр сүз ничә тапкыр кабатланса да тапкыр!
о Күңел күзең булмаса, күңел сүзең юк инде!
о Остаз барда телең тыйма — үзең дә остар!
о Чын оста — гомер буе өйрәнчек.
о Кайчакта сүзсез җыр әйбәт, ә кайчакта — җырсыз сүз...
о Нокта — сүзләр таралмасын өчен җөмлә соңында кагылган кадак.
о «Сүз йөри...» — диләр. Жәяүлеләре йөридер, канатлылары оча!
о Юбилей китабына язылган кереш сүз — хуҗа исеменә әйтелгән озын тост!

о Ялгыш телен тешләгән... туган телен...
о Туган телгә тел тидергән — тилергән!
о Ана телен оныткан — анасын да оныткан.
о Серне, бергәләп саклауга караганда, ялгыз саклау ышанычлы.
о Ачыктан-ачык сөйләшү ябык ишекләр артында була.
о Беркатлыны савалар — телеңне җиленгә әйләндермә.

## Чын ялган була, ялган чын булмый

о Эчтән янсаң да, төтенең туры чыксын!
о Ялган сөйләп хаклыкны якламыйлар.
о Мәгънәсезлекне белү дә мәгънәле эш.
о Табу өчен нәрсә эзләгәнеңне белергә кирәк!
о Акбур белән кара фикер дә язып була...
о Дуга гомер буе тураерга омтылды — күбрәк файда китерермен дип уйлый торгандыр инде...
о Сукырга ишарәләп, чукракка кычкырып ни мәгънә?

## Наданлыгыңны тану өчен шактый гыйлемлек кирәк!

о Тизрәк алга бару өчен туктап бер уйлану да кирәк...
о Акыллы киңәш — яртылаш кимегән эш.
о Фикер — чая кош, әмма браконьерлар аңа да тидерә...
о Табигатьтә уйлы уйсызны ашый да, тормышта төрлечә була...
о Миеңне дә миең ирешкән дәрәҗәдә генә өйрәнә аласың...
о Аллалар да кеше ирешкән акыл дәрәҗәсендә зирәк...
о Акылга утыру әле ул тик утыру дигән сүз түгел...
о Бик акыллы булып йөри-йөри дә, юләргә калуың бар...
о Кем куенында таш йөртә,
Кем уенда таш йөртә...
о Акыллы фикер әйтәм дип, ул шундый катлаулы фикер әйтте ки, хәтта үзе дә төшенә алмады...
о Сәхнәдә аңгыра ролен уйнарга да акыл кирәк.
о Техника заманында да энә белән кое казыйлар...
о Югары белемне күпләр ала, тирән белемне кемнәр ала?

о Коры галим — чи надан!
о Ул әзерләгән рухи азык эчкә тия...
о Буйга җиткән, уйга җитмәгән...
о Башыңны ташка орма — таш авыртыр!
о Бер нәни генә кимчелеге бар — мие юк...
о Башы буш булуга карамастан, фикер туарга урын юк...
о Башы тулы цифр: гел нольләр дә нольләр...
о Алфавит буенча карасаң, Ахмак та Акыллы белән бер тирәдә.
о Акыл теше ахмакка да чыга.
о Фәкыйрь фикерле факыр...
о Надан сүзлек карамый, галим аны гомер буе укый!
о Күләгә — яктылык юлдашы...
о Ахмак акылдан язмый.
о Акыл тешен дә сугып сындыралар.
о Мин сезгә шундый акыл бирәм: беркайчан да акыл бирергә ашыкмагыз!

## *Яшьлек — иреннәргә кунып сайраган сандугач ул...*

о Күләгәң күләгәмә орынса да күңелем тетрәнә...
о Гашыйклар ай яктысында кызына...
о Йөрәккә ачкыч яратып булмый, яратып кына ачып була!
о Иреннәр яратуны сүзсез дә аңлаша...
о Дәртле тәндә чүпрәк тә рәтле!
о Тойгыларның ымсынып кына калганнары тулырак...
о Эзләребез янәшә, юлларыбыз — төрле...
о Кызлар матурлыгы — пропуск, ачылмас ишекләрне ачтыра!
о Әкияттәге сихерче карчык тикмәгә генә чибәр кыз сурәтенә кереп алдамый...
о Җете кызлар тиз уңа...
о «Йөрим синең белән мөлдерәмә тулып»,— диде йөкле ханым иренә...
о Язмышына җиңел караган кыз авырга кала...
о Кызлар арасында яхшылыгы белән яманаты чыккан егет...

## *Бер балалы – күп бәлале*

о Баласыз гаиләдә ир белән хатын бар, ата белән ана юк...

о Баласызлар бакчага чәчәк утырта, балалы бәрәңге тутыра.

о Балалар туу азая — проблема туа...

о Бала чагың — баллы чагың.

о «Малай актыгы!» — дип беренче балага да әйтәләр...

о Кайсыбер ата-анага охшау баланы бәхетсез итә...

о Бүтәннәрдән яхшырак итәргә теләсәң, үз балаңа кырысрак бул.

о Балалар — тормыш чәчәкләре. Җимешләре нинди булыр?

о Әти-әнине дә аңлый башладык, үзләре генә юк...

о Кыргый алма яшел була,
Үги бала яшьле була...

о Онык — бабасының киләчәктәге вәкаләтле илчесе.

о Оныклар бабайларны яшәртә.

о Хәзерге балалар күпне белә. Хәзерге бабайлар да аз белми!

о Гормоннар да, гармуннар сыман, үз көенә биетә...

## *Кайчак парлылар да ялгыз була...*

о Ярatканыңа ярашканыңны сизми дә каласың...

о Иң бәхетле чагың — бәхет турында уйламаган чак...

о Бәхетле багучыга бармас.

о Бәхетлеләр бәхетсез мәхәббәтен сагынучан...

о Кайгыны адаштырып, шатлыкны иярләштереп булсачы!

о Ир белән хатын бер-берсенең характер скульпторлары...

о Ир белән хатынның характерлары йә яраклаша, йә якалаша...

о Мәхәббәтләре булмаган ир белән хатын бала ягыннан туган тиешле генә...

о Мода — хатын-кызның кимчелеген уңыш итеп күрсәтә торган могҗизадыр.

о Мода — хатын-кыз дигән кибетнең витринасы.

о Әби үз яшьлегендәге мода белән киенә...

о Җанкисәгенең җан күсәгенә һәм җен кисәгенә әйләнгәнен абайламый калган...
о Башына уклау төшкәч кенә хатыны искә төшкән...
о Тиз танышкан — озак тынышмаган...
о Кошелегыңны югалтсаң да, кешелегеңне югалтма!
о Нәзакәтле тупас.
о «Туа мөгез чыкмый, тора мөгез чыга»,— дип башын кашыды бер ир...
о Шик — шикәр түгел, тиз эреми...
о Мәхәббәтсез үткән гомер — яшәмичә үлгән көннәр.

## Иске дусларның үткән гомере уртак

о Һәр кешегә дуска түзгәндәй түзсәк, бер дошманыбыз да булмас иде...
о Бер дустым гына китте дә, тылым, фронтым ачык калды...
о Яшең арта, гомерең кими, дошманнарың арта, дусларың кими...
о Нигә миңа йөз ел гомер — якыннарым янымда булмаса!
о Бер-берсен яхшы белгән дуслар, күз иямәшеп, берберсен белми башлый...
о Кайсы кешене якыннан белгән саен ерагаясың...
о Арада — дуслык иде,
Арада — бушлык инде...
о Дус белән дус дусны бүлешә алмый дошманлашкан.
о Кайсы дус үзенең киресенә әйләнә — суд...
о Үзен генә яраткан кешенең дусты булмый — мәхәббәте үзенә китеп бетә...
о Дустына хыянәт иткән — үзен югалткан.
Үзенә хыянәт иткән — намусын югалткан.

## Коелган чәчеңне уйлап чәч агартма!

о Акыллы кеше картайгач та матур кала.
Һәр матур да акыллы микән?..
о Кайсы картлар белән сөйләшү яшәртеп җибәрә.
о Аксакал бул, аксак акыл булма!
о Үткән көннәрнең төннәре дә якты...

- Яшьлекнең ни икәнен аңласаң — картайдың дигән сүз...
- Яшен яшәгән —
  Яшене яшьнәгән...
- Яшьләргә — романтизм,
  Картларга — ревматизм...
- Саулыкны сатып алып булмый, сырхауны бушлай да биреп булмый.
- Карт йөрәккә шатлык та авыр.
- Яшьлекнең грамматик хаталары картлыкта драматикка әйләнә...
- «Сыер гомер буе диетада әле!» — дип әйтте ди бер булдыксыз.
- Кысан киеп кыйналгач,
  Иркененнән интеккән...
- Авыру башта йога,
  Аннары — ега...
- Сәламәтлек — шөкер, калганына — төкер!
- Йортым озак яшәсен дисәң — таштан сал,
  Үзем озак яшим дисәң — агачтан сал.
- Сукыр кояшка туры карый дип көнләшмә.

## *Тел озайткан — штаттан кыскарган...*

- Кыеклап әйтсәң дә, турысын әйт.
- Кешегә үткәреп һәм үтереп әйтәсе килә, үзеңә киная дә җитә...
- Мактауны халык алдында әйтсеннәр, тәнкыйтьне — колагыма...
- Берәүнең тәнкыйтенә колак салырга борыны комачаулаган.
- Телләр озая,
  Штат кыскара...
  Йә, әйтеп кара!!!
- Тәнкыйтьләргә маһир кешене президиумга утырт.
- Бүкәнне үсмәүдә һәм алга бармауда гаепләделәр.
- Шома багана агачның кытыршы якларын тәнкыйтьләде.
- Бал кортының, чагуы файдалы икәнне дә беләләр, шулай да ул килеп кунса, сугып төшерәләр...
- Мөгез кисү эшендә мөгез чыгаручылар да булгалый...

## Тел тегермәне графиндагы су белән әйләнә

о Берәүләр өчен җыелыш — чабып арган аякларга ял биреп, кул чабып ала торган урын.

о Кайбер җыелышта утырмасак та, гомер үтәр иде, әмма әрәм үтмәс иде...

о Җыелышларда эчелгән суны тегермәнгә койсаң, он суы да, тоз суы да чыгар иде!

о Графиндагы суны доклад укыган кеше эчеп бетерде, язган кешесе сусап утырды.

о Кат-кат җыелыш казаныш түгел, казна эшен калдырган каза эш...

о Доклад — кемлегеңне күрсәтә торган лакмус кәгазе.

о Куерта торгач, көн тәртибендәге мәсьәлә шактый сыеклана...

о Көннең кадагы эшләпәле дә, ялан башлы да, башсыз да була...

о Җыелышта күргән төш рас килә.

о Ярты гомере җыелышта, яртысы өендә йоклап үтте. Калганын ул бик тырышып эшләде!

о Берәүнең йөзендә борын хаким, икенченең йөзендә авыз баш!

о Гәптәшләр арткан саен сүзнең мәгънәсе кими.

о Информация ташкыны күмү бәла түгел, информациясез юшкын күмү бәла!

о Су басудан котылган дөньяны сүз генә басмаса ярар иде!

о Телдән алда йөрергә өйрәнгән аяк кайчакта телне куып җитә алмый!

о Берәүдән сүзне штопор белән дә алыр хәл юк, берәүне бөке белән дә томалап булмый...

о Әйтер сүзең юклыкны сиздермәс өчен озак сөйләргә туры килә...

о Тыңласыннар дисәң, аз сөйлә,
Ишетсеннәр дисәң, кычкырма...

о Сакау карга каты каркылдый.

о Сүзләр микрофонның бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

о Җыелыштан кайтканда теленә машина баскан...

о Залдагы кешеләр төрле-төрле була, трибунага чыккач кына бертөрлегә әйләнә...

о Бүтәннәрнең күп сөйләвен үзең туктагач кына күрәсең...

## *Дәрәҗә — лифт сыман: бер күтәрелә, бер төшә...*

о Дәрәҗәле эштәге яшьтәшең дә олырак.

о Яңа башлыклар яңабаштан яңа эш башлатып башны бутады.

о Фикерле хезмәткәр фикерсез түрәгә бәла...

о Бәләкәй буйлы казый — озыннарга да өстән карый!

о Кешене түбәнсеткән — үзен кимсеткән!

о Тупаслык — мин-минлек күләгәсе.

о Казна эшендә казына-казына азынма!

о Ашауны урынбасарга тапшырмыйлар.

о Дуга белән Даганың аермасын белсә, ул әле дә җитәкчелек итәр иде.

о Түрәнең төшкәнен генә сүгәләр.

о Күтәрелүнең чиге бар, түбән тәгәрәүнең чиге юк...

о Дүрт аяклы өстәл дә абына дип, юанды.

## *Кычкырып торган тыйнаклык*

о Сабын куыгы: «Миңа салават күпере сыя!» — дип кабарынды...

о Үзен мактап кычкырды да, кайтавазын рәхәтләнеп тыңлады.

о Юньсез мактаса хур итәр.

о Бер генә уңай фикере бар — ул да булса үзе турында...

о Үз тормышың җайлангач, бөтен дөнья көйләнгән кебек!

о Җир үз күчәре тирәсендә, абзый үз күчәне тирәсендә әйләнә.

о Үз чебененнән фил ясый, синең филне чебен итәргә күп сорамый...

о Беркатлылыгы турында кат-кат әйткәненә ышанып беркатлы булма.

о «Миңа яңа пальто тактылар!» — дип мактанды Иске Төймә.

о «Мин Арысланны тешләдем!» — дип күкрәк какты Борча.

о «Филләр бездән ясала!» — дип куйды Чебен.

o «Сөяксез тел ни сөйләмәс!» — диде скелет эре генә.
o Мактау — менә дигән йокы даруы...
o Әй яратабыз да инде үзебезне яратканны!
o Үземне генә яраткан чагым — үземне иң яратмаган чагым!

## Аракы башка китә, аннары башка җитә...

o Шешәдәге авызыңа керсә, шешә авызына кергәнеңне сизми дә калырсың.
o Эчкән кеше башы белән йөри, аяклары белән уйлый...
o Аракы тутырган саен күңел бушый...
o Ни эчсәң — шуны авырырсың!
o Җиде кат үлчә, бер кат та... эчмә!
o «Өч кешелек»тән эчкечелеккә өч адым...
o Кыя кебек егетне дә кыяр кебек итә аракы...
o Син аракыны эчәсең, аракы сине ашый...
o Исерек аунаган җирдә акча калмый.
o Кырык градуслыны капкан кешенең холкы йөз сиксән градуска борыла...
o Бөке чыгара-чыгара бөкресе чыккан.
o Аракыга батучы бөкегә ябышыр.
o Кеше акчасына эчкәндә дә үз сәламәтлегеңне эчәсең...
o Кемнең «эш» дип кулы кычыта, кемнең «эч!» дип тамагы кычыта.
o Өстәлде кунак,
Өстәлгә кун, ак!
o Мәҗлес башында җырлаучы булмый.
Мәҗлес соңында тыңлаучы булмый...
o Буш вакыттан буш, ватык шешәләр генә калган...
o «Азмыштан узмыш юк!» — дип әйтте ди бер мут егет.
o Башта ава шешәләр, аннан ава кешеләр...
o Шешәләр шешенгәннәргә ишарәлиләр (эчүчегә тел һәм аяк көрмәкләндергеч).
o «Саулыгым-байлыгым!» — диде дә, шул байлыгын аракыга туздырып бетерде...
o Берәүгә өч метрлы һәйкәл тиеш, берәүгә — өч литрлы...
o Эчеп үзен бетергән — үзен эчеп бетергән...
o Аракы бик яхшы нәрсә ул... үзенә дошман кешегә!

## Әләк — башка бәләк!

о Ялган сөйләве дөрес, дөрес сөйлим дигәне — ялган!
о Ялгыш та дөрес сүз ычкындырмый...
о Төлке койрыгын ябынып йоклый, гайбәтче — телен...
о Интриганнар — бик оста сюжет коручылар.
о Телчән кеше — билчән кеше!
о Ат кешнәшеп, адәм сөйләшеп талаша...
о Гайрәт чәчә-чәчә гайбәт чәчә!
о Этне кем кайда асрый — кем өй эчендә, кем үз эчендә.
о Зур кешеләр гайбәтен сатудан бәләкәй кешеләр тәм таба...
о Бүре тиресе ябынган сарык...
о Имеш-мимеш ялган җимеш бирмеш.
о Кеше ишетсен дисәң — пышылдап әйт!
о Үтәли җилдәй сүз йөргән җирдә гайбәт — грипп тиз йога...
о Гайбәт сөйлим, дими, информация әйтәм, ди — заманча!
о «Этең миңа тел күрсәтте!» — дип хуҗасын эт итеп сүккән...
о Еланның теленнән курыкма, тешеннән курык.
Гайбәтченең тешеннән курыкма, теленнән курык!
о Ерткыч тырнагын кайрый, гайбәтче — телен...
о Гайбәтне бушлай бирәләр, әмма кыйммәткә төшә...

## Ялап ашаганнең тамагы тук була...

о Начальникның күләгәсендәге мамыкны да чеметеп ала!
о Боегучылар барда
Боеручылар була!
о Икеле-микеле йөргән Өндәү билгесе, бөкрәеп, сорауга әверелгән.
о Ялгышмас өчен кешегә ияреп йөрде һәм... ялгышты.
о Койрык та алдан бара... артка чигенгәндә...
о Кеше сагая-сагая саегая...
о Ун мең кешелек стадионда кул биреп күрешеп чыккан...
о Усал эткә юаш кеше койрык болгый...

o Кайбер мәгънәсезнең җирдә яшәвен күреп: «Регламент!» — дип кычкырасы килә.

## *Тәнәфес белми нәфес*

o Бал корты — кешеләргә җыя, мал корты — үзенә ташый...

o Тормыш балына бер кашык дегет — шундый ул егет...

o «Коега төкермә, үзең эчәрсең!» — диде бер кибетче, аракыга кушарга су алганда.

o Тәүбә итә-итә
Сәүдә итә.

o Акча беткәндә кесә тарта — вак акчалар арта...

o Комсыз елан койрыгыннан кабып үзен-үзе йоткан!

o Бер генә яхшылык эшлә, икенчесен йолкып алыр!

o Кем үлгәннәрдән тартына, кем исәннәрдән дә оялмый...

o Бүре баласын бүреккә салсаң да урларга карый...

o Юлдан язганнар да бүтәннәр белән бер юлдан йөри.

o Йом күзеңне, ачкүз!

o Угры тугрыны сөймәс, тугры угрыны сөймәс тә сөймәс!

o Бүре сарык мәсьәләсен кабыргасы белән куйды...

o Хәйләләп намусын яшереп куйган да, соңыннан табалмаган...

o Бердәнбер яхшы ягы шул — начарлыгын яшерми.

o Йөз суыңны түкмә, йөз сумыңны түлә!

o Кешелек дәрәҗәңне саклый белү — иң югары дәрәҗә.

o Тозсыз кешене бергәләп бер пот тоз ашамыйча да белеп була.

o Этеннән болай йортыннан бизәсең.

o Дуңгызның мөгезе борынында!

o Дуңгызның этлегенә эт дуңгызлык белән җавап бирде...

o Кара төндә дә беленеп тора йөзе кара!

o «Кулым җиңел булсын!» — диде дружинник, хулиганны култыклап.

o Законга бармак аша карау — тимер рәшәткә аша карау белән бер.

o Явызлыкка — авызлык!

## Икенче төркем

### «Тисә-тиенгә, тимәсә-талга — барыбер табигатькә зыян

о Каурый йолкып язды: «Кошларны саклыйк!»

о Җил очыртып киткән каурый: «Яңадан очам!» — дип сөенде...

о Саңгырау сандугачны сагынмас.

о Тере чәчәк кәгазь чәчәк кебек салкын чибәр булмый.

о Валериан үскән җирдә төнәтмәсен эчмиләр — табигать кочагында йөрәк болай да тыныч.

о Имәнне мең ел үсәрдәй җиргә утырт!

о Табигатьтән талап алган бер җанлы тиен өчен мең сум түләрлек булырсың.

о Йомырка — табигать уйлап тапкан консерва!

о Кояш мул якта — суга кытлык.

о Күңелләр саеккан саен күлләр саега.

о «Көймә килә — эзе юк»... Бу җыр искерде инде, хәзер майлы эз кала!

о Савыттан чыккан химия җене кешелекнең үзенә яный...

### Боз да кояштан туган...

о Кар астына су төшә, агачларга сут төшә, тел очына сүз төшә — күңелләргә моң төшә!

о Тургай — сайрый торган йолдыз.

о Язын кызарган бөредә — туасы җимеш төсе.

о Язын яфраклар бөре биләвен чишеп чыга...

о Бөре бишегендә «туп» итеп сикереп төшәсе алмалар үсә.

о Яз — бергә шатлануга, көз — ялгыз уйлануга тарта.

о Җилнең тарту көчендә җирнең тарту көче бар.

о «Без атлап вакланмыйбыз, сикереп кенә йөрибез!» — диде Чыпчык Филгә.

о Эт йортны саклый, чылбыр — этне...

о Яхшы эт — усал эт. Яхшы хуҗа — юаш кеше...

о Сарык асраучы бүре бүрек кияр.

о Тычкан уты дөньяны яктыртам дип белә...

## Безнең туган якларда таллар бии тальянга!

о Сандугачны да, шагыйрьне дә туган җир сайрата.
о Туган җиргә тамыр тирәнрәк үткән саен башыбыз өскә күтәрелә!
о Үзең читтә чакта да күңел туган якта яши.
о Чит җирнең бердәнбер яхшылыгы — туган җир кадерен ныграк сиздерә...

## Бәхетең халкың белән уртак булсын!

о Ирек белән бәхет — игезәк...
о Шатлыкның зурлыгы — шатлана белүдә.
о Бәхетсезлек булмый калу үзе бәхет.
о Кемгә бәхет елмая, кемнән көлеп уза...
о Бер үк йөрәкне талыйбыз — михнәт белән дә, рәхәт белән дә!
о Үткәндә калган бәхетен киләчәктән көтә...
о Бер күзе җылап бетерми, икенчесе көлә башлый!
о Бәхет теләп ишеккә каккан дагага бәреп башын тишкән...

## Батырның үлгән көне — үлемсезлеге туган көн

о Җиңүчедә көч булса, җиңелгәндә үч була?
о Җиңелүне күтәрә белү дә кирәк — җиңүгә әзерләнү өчен!
о Батырлар даны — Байракта?
о Һәйкәлләр очраша алмый — һәркайсының үз урыны...
о Горурлык хисе йоклаган халыкның рухы төш күрә...
о Көрәш җиле өрмәсә, күңел җилкәннәре сүнә...
о Мәңгелек йолдызларга да исемне кешеләр куша!

## Кыюлык — биеклек белән, куркаклык түбәнлек белән үлчәнә

о Үзен җиңә алмаган кеше — иң көчсез кеше.
о Рух сынган — хур булган.
о Качкын куркактан ярала.
о Куркак булудан курку — батырлыкка бер адым.

## Сыйфатны санга сукмасаң, сан сыйфатка суга

o Ике ялдан соң өч көн эшләп хәл аласың...
o Рәхәтләнеп ял иттем — арыганчы эшләдем!
o Тик торып борчылганчы, эшләп тынычлан.
o Өзлексез эшләгән — өзлекле яшәгән.
o Эшләп арыган саен көч арта!
o Шахтерның җиргә ихтирамы тирән...
o Теләп эшләгән эш — бүләк, мәҗбүрие — җәза!
o Башлыгы уңмаганның ашлыгы уңмас!
o Кешенең зурлыгын яше белән түгел, эше белән үлчиләр.
o Алтын күкәй көтмим дә, гап-гадие күп булсын!
o Кеше үлсә — эше кала. Эше үлсә, ние кала?
o Эшләгән эшеңне мактаганда эшләнәселәре борчый.
o Эшләмәгән остармый, остармыйча эш бармый.
o Осталыкка остазлык кирәк.
o Хәл белән генә түгел, әмәл белән бара эш.
o Йөзәргә өйрәнгәч, йөздертүчесез дә яшәп була...
o Рәсем эшендә буяучы булганчы, буяу эшендә рәссам булсаңчы!

## Ялкауның мускулы корсакка үсә

o Ялкау йокы симертә, йокы — ялкауны!
o Йокы мичкәсенә сыра тутырганнар...
o Ялны ялга ялкау ялгый.
o Ялкаулыкның тарту көчен җиңәлмәүче үтә ялкау кеше булыр.
o Ялкаулык тутыгы көч тимерен ашый.
o Эшсезлекне эшем дип уйлый...
o Ялкаулыкның ни икәнен белми — эшләп карамаган!
o И юньсез — мич башыннан төшми июньсез!
o Кашык зарядкасы бүксәне генә үстерә.
o Бер алдынгы яктысында өч хөрәсән күләгә...
o Бер эшне теләмәгән бер эшне дә өнәмәс.
o Эшләүчегә эш күп, эшләмәүчегә генә юк...
o Бәйрәм гомер — вәйран гомер.
o Эштә эленке-салынкы, ялда — ялкын!
o Ул гомер буе үз корсагының грузчигы булып яшәде...

## *Иген кыры – ил табыны...*

о Игеннәргә рәхәт — явым, игенчегә рәхмәт яусын!
о Комбайнчы җәен ябыга, кышын тазара.
о Эше пыскыганның көшеле яна.
о Шәһәрнең мул табыны — авылның мул хезмәте.
о Икмәккә СЕЗ дип эндәшү тиеш!

## *Шәхес – үз язмышының капитаны*

о Берәү утыз елда йөз еллык эшли, берәү йөз елда да утыз еллык эшли алмый.

о Артка киткән дә алга бара — яхшылыкка кире кайтса!

о «Сабыр төбе — сары алтын» — бәясе күтәрелә тора...

о Берәү үзен онытып дөнья өчен чаба. Берәү дөньяны онытып — үзе өчен...

о Җимерергә дә дәрман кирәк — кайчак төзәтү дәрте тулаем шуңа китә...

о «Кем булмаска» дип тыелу «кем булырга» дип омтылу кебек үк ныклык сорый.

о Үзеңне җиңү — иң зур җиңү — монда җиңелүче юк!

о Холык начар булу начар, холыксызлык тагын да начар.

о Бүтәннәр уңышына сөенә алуыңа сөен!

о Сыныйм дигән кешегә уртак сынык биреп бак.

о Һәркемгә дә яхшы булырга тырышучы яхшы кеше микән?

о Үги гасырда ятим шәхесләр туган...

## *Кошның канаты иңендә, кешенең – күңелендә*

о Күңел тау күтәрә, чүп-чар күтәрү генә авыр...
о Кояш томаланганда да күңелеңә күләгә төшмәсен.
о Тыштагы яра да эчтән сызлый.
о Күңел күзенә күзлек яратып булмый.
о Ачу дуласа сызлауны баса!
о Күтәрелмәгән күңел күтәрәмгә кала.

о Исәннәрнең күңел чисталыгы өчен мәрхүмнәрне юып күмәләр...

## Ел танытмаганны юл таныта

о Көткән юллар — серле, озатканнар — моңсу...
о Туктаган флюгерда — тынган җил юнәлеше...
о Уңга китеп уңмаган, сулга китеп соңлаган...
о Гомер юлын кабат үтеп булса, ул гаҗәеп юл булыр иде.
о Атом гасыры атына яшәү җиңел түгел.

## Табиб — тәнне, әдип җанны дәвалый

о Шагыйрь — йөрәк тылмачы.
о Шахтер күмер тирәнлегеннән, шагыйрь күңел тирәнлегеннән нур ала.
о Җыр — шагыйрьнең пароле.
о Җырны шагыйрь тудыра, халык яшәтә.
о Чын җыр өзә зынҗырны!
о Шагыйрь — халык күңеленең барометры!
о Илһамның да фамилиясе була — әгәр дә ул атаклы җырчы булса!
о Тансыклап караган иске урында да яңалык күрә.
о Яхшыны якты күзләр күрә.
о Иҗат кешесе кыска гомердә дә үзен раслап яки инкарь итеп өлгерә...
о Фикерең үзеңнән озын гомерлерәк булсын!
о Күңел дәфтәре яхшы хәтерле кешегә кирәк: начар хәтерле язарга оныта.
о Эчтәлек кыюлыгы булмаганда, форма кыюлыгы бик юаш.
о Сай темада тирән йөзеп булмый.
о Аксиомалардан теш камашкан — гипотезалар тансык!
о Яхшы язу турында сөйләшә торгач, начар язарга да вакыт калмый...
о Әсәрне ничек бәяләве белән тәнкыйтьче үзенә дә бәя бирә.
о Бию — тәннең җырлавы, җыр — күңелнең биюе!
о Балерина аяклары белән «сөйли» — кайбер акыллы башлардан үтемлерәк.
о Укучысы акыл биргәндә укытучы сөенсен — бу аның үзен-үзе җиңеп үсүе...

o Кил, яңа шагыйрь, мин әйтә алмаганны әйтеп бир, син әйтә алмаганны бүтәннәр әйтер!

o «Минемме үз тавышым юк?!» — дип тавышлана ди бер шагыйрь.

o Киштә-куначада гомер кичергән китаплар да бар...

o Популяр шагыйрь: үзен таныйлар, әсәрләрен генә белмиләр...

## Тәпи йөрергә өйрәтәләр, фикер йөртергә үзең өйрәнәсең

o Беренче хәрефләрне укый-яза белмәүче уйлап чыгарган.

o Иртәгәге көн кешеләрен кичәгеләр бүген укыта.

o Институт бусагасы ашалган — белем бинасын аяклар да кимерә...

o Фикерле кеше йөз елдан соң да замандаш!

o Үзеңне-үзең аңларга да белем кирәк!

o Җирнең уңдырышлы катламы юка. Уңган кешеләр катламы да калын түгел.

o Үзе машинада бара, культурасы җәяү титаклый...

## Чын хыялның яшьлек икәнен киләчәктә генә беләбез...

o Яшьлек — чәчәк чак. Җимеш чәчәге дә, кысыр чәчәк тә бердәй матур.

o Яшьлек чылләсендә сусаганнар мәхәббәт чишмәсе эзли.

o Кызлар сайлый димәгез, яшьлек бит ул разведка!

o Гашыйк булган мизгелгә күпме гомер сыя!

o Гашыйкларның сүзсез чагы да җыр.

o «Яратам»ны йөз дә беренче ишетүе дә рәхәт. «Яратмыйм»ны бер мәртәбә ишетәсе дә килми...

o Яратканның ярасы яхшырак ямала.

o Беренче мәхәббәтне сагындырып соңгысы килде...

o Үкенечле мәхәббәт булмаса, чын мәхәббәтнең көче беленмәс иде.

o Күңелгә яз булып киләсең, күздән яшь булып китәсең...

o Мәхәббәт кояшы үткән гомердә дә баемый!

о Күңел кошлары яшьлек дигән җылы якка оча...
о Мәхәббәт арифметикасы: «Берсе белән язылам, икенчесе күңелдә...»
о Бер кеше яратуына лаек түгел, ә бөтен халык мәхәббәтен даулый.

## *Ирәйгән ирне дә хатын-кыз тудырган*

о Хатыннар ирләрдән иртәрәк картая һәм озаграк яши.
о Кыргый кызлар да йорт хатыннарына әйләнә...
о «Без өйләнгәч төн... озын» — дип әйтә икән яшь хатын алган абзый.
о Гаилә химиясе: Әминә — кислота...

## *Тәрбиясе кырысның — баласы тырыш*

о Чыпчык буйлы ана бөркет җанлы балалар үстергән!
о Ата-ана — тормыш көрәшенә әзерләүче тренерлар.
о Ана мәрхәмәте белән ата кырыслыгы — балаларга булган мәхәббәтнең ике канаты...
о Вакыты узгач бишек тә кысан, биләү дә тышау...
о Әби белән онык елмаешып килә: икесенең дә авызында берәр теш...

## *Хисләр нечкәргән саен дуслык ныгый*

о Каурыйны җил очыра, канат — кошларны очыра!
о Дус яктырганда дошман кара яна.
о Берәү дуссыз яши алмый — күңел җылысын кемгә бирсен!
Берәү дошмансыз яши алмый — зәһәрен кая куйсын!
о Эчкерсезлек битлеге кигән мәкер дә була...
о Күңел сыну — сөяк сыну гына түгел...

## *Гомер фасыллары кабатланмый*

о Тормыш — бер очы янып көлгә әйләнеп, икенче очы чәчәк атып җимеш бирүче мәңгелек агач.
о Кеше дөнья куа-куа дөнья куя...
о Үкенү — үткәннәр җимеше.

o Чәчәк коелу — җимешкә, чәч коелу ни эшкә?
o Тансыклап өлгергәнче бәйрәм җитә, татып өлгергәнче гомер үтә...
o Карт күздән дә яшь килә.
o Туңган күңелләр истәлек учагында җылына...
o Мөмкинлеге кимегән саен күбрәк алмакчы!
o Кеше картая, көчсезләнә, ә кимчелекләре яшәрә, көчәя...
o Өлкәннәрнең данына гына кызыгалар, яшеннән көнләшмиләр...
o Хыялына ирешсә дә, картлык — югалтулар чоры...
o Бер генә кеше үлә дә, ничә кеше кемнәрен югалта: ананы, әбине, хатынны...
o Үлгәннәр күңелгә күмелә...
o Картлык булырдайны «Булмастыр...» ди, яшьлек булмастайны да булдыра!
o Яшьлек картлыкны киләчәгем дип уйламый.
o Яшь чакта төш тә истә, картайгач өн дә онытыла...
o Яшьләр дөньясында картлар чит ил кешеләре...
o Хәтер яхшы чаклар хәтер начарлангач та онытылмый...
o Яшьлек гадәтләре искелек калдыгы булып кала...
o Яшьлек килә дә китә, картлык килә дә кала...
o Яшьләр күрешә килә, картлар хушлаша китә...
o Картлыктан көлү — киләчәгеңне мыскыллау.
o Кешенең киләчәге — картлык, кешелекнең киләчәге — яшьлек!
o Балачак тәэсирләрен гомер буе конфеттай суырып йөрибез...
o Ерак бабайларның кайтавазы сез, оныклар!
o Онык — киләчәктә чәчәк атар орлык.
o Бала тапмаган хатын оныкларын да югалткан...
o Онычым яхшы — үзем кебек, малаем яман — бабасы күк...

## Озак яшәүнең серен гомер кыскарткан сәбәпләрдән эзлә

o Йөрәк — гомер сәгате...
o Төш күрү — борынгы кино.
o Заманында ябыклык — авыру иде, хәзер симезләр ябыгып тазармакчы.

о Саулык — байлык икәнне саулыгыңны туздырып бетергәч кенә беләсең.
о Үзенең кайчан үләсен белсә, кеше алданрак үләр иде...
о Саңгыраулык күзгә чыга, сукырлык тавышка...
о Авыруның дөньясы — авырткан урыны...
о Хәле авыр «хәлем авыр» дип тә әйтә алмый.
о Гомеренең соңгы сабан туенда кеше әҗәл белән аркан тартыша...
о Җәяү йөргән озак яшәр диләр дә, озатучылар машинада...
о Чебеннәр плакаты: «Чисталыктан саклан!»

## *Дөньяны үзгәртәм дисәң, үзеңнән башла*

о Җыелышта кала җыен эш.
о Үз эшен ул җыелышлар арасында эшләштергәләштергәләп ала иде...
о Кай кеше трибунада үзен ДОТтагы кебек хис итә...
о Культура җитмәү турында йодрык төя-төя сөйли...
о Бозылган компас теледәй трибунада чайкала — кыйбласы кайда моның?
о Җыелышта үткән вакытны эшкә бирсәк, җыелып торуның кирәге калмас иде.
о Юри мактасаң да кабул итә, чынлап тәнкыйтьләсәң дә кире кага.
о Хак сүз әйтергә хакың булсын.
о Пычракны чисталык белән генә җиңеп була!
о Табигать безне яратканда ук канга тоз салган...
о «Бик кыю фикер әйттең!» — дигәч, куркып калган...
о Бер җылы сүз — ике канат!
о Сүз кылчыгы озак борчый.
о Тешле тел!
о Кайчакта — дәшмәү җинаять, кайчакта — дәшү хыянәт.
о Иш ишен таба, сүзлектә дә янәшә: наган, нагайка, нахак...
о Сүзлек — миниатюралар китабы, кайсы битеннән укысаң да кызык!
о Язучы өчен СҮЗ — Архимед әйткән таяну ноктасы.
о Эшлексез сөйләр өзлексез.
о Бәйдән ычкынган тел.

o Тел чыбыркысы шартлатма!
o Кайчакта җырның да сүзсезе тансык...
o Кайсы кешегә гомер кичәр өчен берничә сүз җитә.
o Бик озак дәшми торганнан соң ул бер сүз дә әйтмәде.

## Аракы эчесенә иләшкән тормыш тәмен югалткан

o Исерек агай аек чагына аяк чала.
o Салган агай — салулы юлдан баргандай...
o Акча туздыра-туздыра үзен туздыра.
o «Ефәк бездә мунчала!» — ди торгач, «йөрәк... мунчалага»га калган.
o Аракы дигән эт йөрәкне талый.
o Шешә дигән снаряд дусларны ега...
o Шешә авызы бәләкәй дә, әзмәвердәй ирләрне йота!
o Алкоголик алфавиты аракыдан ачыла.
o Битенә чиртсәң — аракы чәчрәп чыгарга тора!
o Күзе кызарган, борын зәңгәрләнгән, йөз саргайган — тәмам өлгерүе җиткән!

## Юньсезнең остазы күләгәдә кала...

o Алтын тешле агач кеше.
o Кыйммәтле хушбуйга сыланган буш буй.
o Синтетик сарык тиресе ябынган бүре.
o Тозлы итеп сүгенгәнне тозсыз диләр.
o Аның турында сөйләсәң, авыз пычраныр сыман...
o Оятсызның оятсызлыгыннан ояласың, ә ул оялуыңнан оялмый!
o Начарлыгын яшерер иде дә, яхшының ниндилеген белми...
o Явыз ният белән эшләнгән яхшылык...
o Икеләнсәң — өчләтерләр!
o Цифр б л а т — танышлык белән алынган сәгать.
o «Әйтмә!» дигән сүз тизрәк җитә...
o Елан үз агуыннан үлми.
o Күзләре ике төпле чемодан...
o Көнченең көннәре төн.
o Үзләрен зурга куйганнарны сөйләп вакланмыйк!
o Койрык болгау да алга илтә, мәсәлән, балыкларны.

o Чәч алдырырга чират көтеп чәче агарган да, буятып чыгарга мәҗбүр булган.
o Саранның бар нәрсәсе булыр, шатлыгы гына булмас!
o Хәленнән килсә, маяга су киптереп куяр иде...
o Чебен бозаулаган!
o «Роза чәчәге миңа охшаган,— дип әйтте ди Кәбестә.— Яшел дә булса!»
o «Филгә атланып йөрим!» — дип мактанды Борча.
o Югары шүрлеккә куюдан китапның эчтәлеге үзгәрми.
o Тычкан уты үзен Җир йолдызы дип уйлады.

## Гасырны мизгелләр тудыра һәм мизгелләр тутыра

o Гаскәр ала алмаган ныгытмаларны вакыт ала...
o Фәкыйрь еллардан бай истәлекләр кала. Бай елларның хатирәсе ярлы.
o Киләчәккә хатлар барсын, хаталар бармасын.
o Ялгышлар үткәннәрдә генә була дип ялгышма!
o Техника заманында да җәяү бииләр...

Өченче төркем

## Туган җиргә яткан кар да җылырак

o Елгалар туган җирне имеп-имезеп үсә.
o Балыкларның туган җире — су.
o Таллар талымсыз була, тамыры әрсез була.
o Канат — таянырга һава әзли, тамыр — ябышырга җир әзли.
o Тамырсыз җир таралыр.
o Карга да җиде җилдәге җылы оясын сагына.
o Дала җиле хушисле — ирекле үләннәрнең дәртле төнәтмәсе.
o Кая барсак та, кайтаваз күңелләр туган якка китә.
o Үзәкләр өзелгәндә туган җиргә тарткан җепләр ныгый.
o Кыска җырлар да халык белән озын юл үткән.
o Халкың — бабаң да, балаң да.
o Халкың — иманың, син ансыз — имансыз.
o Авызың тулы алтын теш булса да үткәнеңә төкермә.
o Шәҗәрә — нәсел агачың, халкың — урманың.
o Бер юньсезгә карап халыктан бизмиләр.
o Су тирән булган саен тал биек!
o Тукран — урман йөрәге: тук-тук тибеп тора.
o Кәккүк тавышы балачактан килә күк.
o Каен балкыр аклыгы белән, имән матур ныклыгы белән.
o Табигатьне талыйбыз, үч алмасмы?
o Бу илләрдә чүлләр үсә, күлләр — үчә.
o «Кызыл китап» — яраланган табигать каны.
o Тамчылар — язның шатлык яше.
o Яз тамчылый — кышны камчылый.
o Бөре-биләүне яз җылысы чишә.
o Яз сүле йөгергән агач сайрый башлый — сыбызгы ясa!
o Язлар килде тагын яшьлек булып...
o Гармун сорый яшь кызлар, яз җиткәч...
o Язым — якты тәрәзәм!
o Язда — уңыш язмышы.
o Кояш нурында язын уянып тузаннар оча...
o Язгы хисләр чәчәгендә көзге мәгънә җимеше.
o Язның соңаруына көенәсең, кышның — иртәләвенә.

## *Дәверне еллар яңарта, заманны — кеше*

о Йомшак якларыңны белми торып, ныклыкка ирешә алмыйсың.
о Көчсезлегеңне танырга көч кирәк.
о Ялгышын кичермәсәң, кеше ничек яхшырсын?
о Атаклы кеше дә башта билгесез була.
о Икеләнүен җиңгән — максатка ирешә.
о Горурлар күп, горур яши алучылар аз.
о Биеклек яулаганда йөрәк тауны адымлап күтәрә.
о Рухың күтәрелгән саен офыклар киңрәк ачыла.
о Үзе янган кеше генә бүтәннәрне җылыта.
о Кай кешегә үзен аңлатырга, танытырга гомере җитми кала.
о Сынмаган сынатмасмы, сынатмаган сынмасмы...
о Туры сүзле дип сагынмасыннар, үзләре кыю булсыннар.

## *Күңеле сукырның йөрәге саңгырау*

о Урам тулы бәйрәм дә күңел тулы бәйрәм түгел.
о Күнелең үсмәсә, үзең дә үсмисең.
о Салкын сүз — җәен яуган боз.
о Кара кайгы чәчне агарта.
о Кайгы изгәндә дә, шатлыкта йөзгәндә дә сабырлык кирәк.
о Үпкәләргә хакың булу — син хаклы дигән сүз түгел.
о Җилкәнсез елга саега.
о Көзге яфраклар белән язгы өметләр коела.

## *Гомерне озайтыйм дисәң, кыскартмаска кирәк*

о Саулык-байлыкны туздырганда саран булсаң да ярый.
о Тешең сызлаганда йомшаграк сүзләр сайлыйсың.
о Авырту булмаса, сызланмаган чакның рәхәтен белмәс идең.
о Дару — сырхауга файда, сәламәткә — зыян.
о Узып киткәчтен сукырлар әйләнеп карамый.
о «Баш сау булса — чәч табылыр»,— диде Парик.
о Бүтән шатлыгың булмаса, сәламәтмен дип сөен!
о Кешелек үзен үтерергә корал ясый: ашау — яшәү өчен кирәк, ди.

## Тормыш яме — эш тәмендә, эш төбендә

o Эше үсә — кеше үсә.
o Эшләгән — озак яшәгән.
o Иң рәхәт ял — яраткан эш!
o Мәгънәле эшең булмаса, яшәвеңнән ни мәгънә?
o «Мин алдан барам!» — диде Баржа, үзен катер этеп йөртә.
o Сөйли торган эшләр була. Эшли торган сүзләр була!
o Бер тиенлек җилем йөз сумлык эшне ябыштыра.
o Кешене эш арытмый, кабалану алҗыта.
o Кеше эшен үзгәртә, эше — кешене.
o Акчаны туздыруы җиңел, табасы кыен.
o Җаны тыныч кеше дөньяга сокланып карый.
o Чүкеч кулга суга-суга үзен ипле тотарга өйрәтә.
o Кырга җәелгән иген җәймәгә җыела.
o Кара ипи үстергәннең йөзе ак.
o Кыйнап коймак ашатмыйлар.
o Җим-еш. Эш җиме шул җимеш!

## Үткәннәргә хаким булу ансат, бүгенгә шаһит булуы читен

o Алга бару — кояшка карап кына атлау түгел.
o Алга бара-бара да артка калырга мөмкин.
o Күңелләр киң, мөмкинлекләр генә тар.
o Соңгы сүзне көннең кадагына суккан чүкеч әйтә.
o Көннең кадагына гасыр чүкече төшә.
o Көнбагышны көнбатышка борылган өчен гаепләделәр. Ә ул кояшка ияргән иде...
o Түрәнең тавышы бөереннән чыга, ялагайның — туры эчәктән...
o Шымчы — шомчы...
o Һәйкәл буласы мәрмәр кемнәр аяк астында...
o Ирләр үлә бегә, хатыннар ирләрне тудыра да белә.
o Батырлар белән бергә тарихка атлары да керә.
o Үт дигәндә үтми вакыт, көт дисәң дә көтми вакыт.
o Озак онытылмас минутлар тиз үтә.
o Үзенең озак яшисе килә, үзе көнне ничек үткәрергә белми!
o Үткәннәр — безнең бабай, киләчәк — безнең бала да, баба да.

о Шатлык кына көтмә, кайгының да киләчәге бар.
о Яңа елга аяк басканда Яңа ел аякка басты...

## Гомерең мәңгелекнең бер өлеше

о Еллар — гомернең чакрым баганалары.
о Кояшың баш өстеңдә — күләгәң аяк астында!
о Секундлык теленә эләгеп торган кеше гасырларны әйләндерә.
о Кеше — гомер сәгате, аның аркылы еллар агыла.
о Кеше гомере — биләү белән кәфен арасы.
о Мәңгелек тынлыкка күчкәннәрне минутлык тынлык белән искә алалар.
о Бар дөнья өчен сызланып йөри дә кеше, үз сызлануыннан дөнья куя.
о Дөп-дөрес йөрдек дөньяда, ялгыш кына китеп бардык.
о Туу белән үлем — бер гомернең ике очы.
о Алга бара-бара да кеше юлының соңына җитә...
о Кеше дөньяга вакытлыча килә — сөенәбез. Мәңгелеккә китә — көенәбез.
о Дөньяга тәмам күзе ачылганда күзе йомыла кешенең.
о Онык күзе— офыкта, бабай күзе — шәфәкъта.
о Оныклар — бездән соң булачак бабайлар.
о Шәҗәрәсе — кешенең дәрәҗәсе.
о Мәрхүмне сагынабыз, исәннең кадерен белмибез.
о Киләчәк заман — көләчәк заман.

## Хакыйкатьне кабатлау да ярый — яшәвең белән!

о Көчле усал көче белән, үчле усал үче белән.
о Тарихка арт ишектән кереп булмый. Артыңа тибәрләр.
о Хакыйкать үзенең онытылмавы белән озак яшәгән кимчелекләргә дә бурычлы.
о Көн яктырыр алдыннан төн куерып ала.
о Кешеләр азрак булган саен бердәмрәк.
о Күзе йомылганда гына күзе ачыла кайсы кешенең.
о Чыпчык ач булса да дөньяны алсу итеп күрә.
о Тәҗрибә байлыгы югалтулар бәрабәренә туплана.
о Сукыр — колаклары белән «күрә», чукрак — күзләре белән «ишетә».
о Сафлыкта — шатлык.

о Алтын алып салыр идем, кесәм тишек булмаса.
о Чын алтынны таныр өчен аз микъдары да җитә.
о Салкын тимерчыбыктан кайнар ут йөгерә.
о Күпләр ирешкән биеклек җиргә якыная.
о Кеше гомер-гомергә ирек колы.
о Бәхет — тырышлык кына түгел, отыш та — һәркемгә чыкмый.
о Үзең мактану — уңайсыз, мактасалар — бик уңай!
о Тыйнаклар түзем — бүтәннәр мактаганны көтә.
о Кешенең ялгышы шунда — ялгышны гел бүтәннәрдән эзли.
о Дан аера дуслардан.
о Ал данга алданма.
о Булмаган әйбер югалмый.
о Кеше тиз үзгәрми, тиз яраклаша гына.
о Боерырга яратучыдан бигрәк, буйсынырга яратучы күбрәк.
о Ялгышын яшергән ялгыша.
о Акыллырак эт хуҗасын тыңларга мәҗбүр.
о Энә күзе сукыр була.
о Энәнең күзе күрми, үзен күрәләр.
о Энә күзенә җеп керсә генә йөри ала.
о Кандиль — лампочкалар хоры.
о Күләгә — яктылык юлдашы.
о Караңгыда күләгә булмый.

## *Кое кыен казыла*

о Кыйбласыз табыну — абыну.
о Рух хәерчелеге яманрак.
о Кем белемен куллана алмый, кем наданлыгыннан файда ала.
о Кешене укытып та надан калдырып була.
о Тар карашлы кеше — фара яктысына эләккән куяндай.
о Һәммә кеше белгәнне һәр кешегә тәкрарлап ни мәгънә?
о Томана — аязда да томанда.
о Ми сырлары кысыр.
о Берне яза, күңелендә — ноль.
о Аз белгәндә минбеләмлек күбрәк була.
о Күпне белгән ул, онытып кына бетергән.
о Ике ахмак бергә килсә бер-берсен акыллыга саный.

о Мин акыллы, дип йөрергә алай ук җүләр түгел лә!
о Кемнәр алдында без көчле, кем безнең алда көчле.
о Миннән түбән дип кимсетмә, синнән югарылар да бар.
о Бик дөрес кешеләрдән дә ял итәсе килә башлый.
о Өнем чыкмаганга җенем чыга!
о Һәммәсен дә алдан күрсәң, киләчәктә кызык та калмыйдыр.

## Җайлы тормыш та каршылыклар җиңеп бара

о Уңайлык — ун айлык, кыенлык — ун еллык.
о Тормыш — үзенчә бормыш.
о Камбала — океан үтүкләгән балыктыр.
о Шулхәтле ашыга кеше — үзен-үзе этә-төртә бара.
о Бергәләп ял итүе күңелле. Бер-береңнән ял итүе — бигрәк тә...
о Биюченең уе аягында.
о Эткә кешечә мөнәсәбәт, кешегә — киресенчә.
о Кыерсытылганны күрмиләр — яклыйсы була.
о Тәмле ризык — үзе кыстый.
о Ябык ашханә янында симез хатын сагыз сата.
о Чибәр сатучының товары тизрәк үтә.
о Универмагта уйный бармак.
о Чебен чистаны яратмый.
о Саф һаваны да танышлык белән итәк астыннан җибәрәләр, ди...
о КиБЕТкә ачу итеп, тунны утка якмыйлар.

## Башыңда уй булса, дала да буш түгел

о Күңеле бай бала далада да ялгыз түгел.
о Бәйсез кеше дә үз фикеренә бәйле.
о Кемнең уен күз иңли, кемнең күңел күзе уй җитмәс араны күрә.
о Буе биек — өстән күрә, уе биек — тирәннән.
о Фикер биреп байыйсың. Фикер алып та фәкыйрсең — кешесенә карый.
о Күп ваклыкларны бергә кушсаң да зур ваклык кына булыр.
о Һәркем берәр акыллы сүз әйтсә, дөнья зирәкләнер иде!
о Һәркемнең үз фикере булса, уртак фикер тизрәк табыла.

о Фикер уртаклашмыйча фикердәш табылмый.
о Күп укымышлылар да белмәгән әлифба бар — морзе әлифбасы!
о Галимнең наданлыгы үзенчә.
о Тозсыз сүзләр диңгезендә фикергә сусыйсың.
о Уй басмаса май баса.
о Җәяү фикерләүченең уе канатсыз.
о Канатлы уйлар, җәяүле фикерләр...
о Буйга җиткән, уйга җитмәгән.
о Уе йоклаган — уяу түгел.
о Хәтер офыгында сүнгән фикер аҗаганнары.
о Көн ыгы-зыгысында онытылган уйлар — учакка эләккән күбәләктәй.
о Очы-очка ялганмаган уйлар өзелгән чылбыр сыман.
о Уймак тулырлык та уе юк.
о Ми бураznасына эт эчәгесе үскән...
о Уйсыз кеше дә үзе хакында уйлый.
о Башсыз дигән кешенең дә башы авырта.
о Онытыр өчен ник хәтерләргә?
о Дөньяга әйтелмәгән сүз яңа кеше белән яңадан туа.

## Хыялның чыны — яшьлектә

о Чибәрлек — яшьлек юлдашы.
о Матурлык — яшьлек алтыны.
о Яшь күзгә тормыш матур — күңеле балкып карый.
о Кыз гомере иртәнге чык — балкып ала да оча...
о Керфеге белән йолдыз тузанын сөртә!
о Көзгесе дә чибәрләргә карарга ярата.
о Түбәночтан югарочка күз кысканны тоялар.
о Яшь тәндә — дәрт тогы.
о Тамагы карлыкканчы биеде!
о Канны кайнарлатып йөрәктә мәхәббәт ашкына.
о Дию пәрие диләр иде, бию пәрие дә бар икән!
о Матурлыкның көзгә кереп торганы түгел, күзеңне ачканы кадерле.
о Качкан кызга карыйсы килә, япкан ашны татыйсы килә.
о Узганда бер күз төшерү өчен дә яратканны сайлыйсың.
о Чибәрләр — үтә ялтырап атылган йолдыз сыман.
о Таң — көннең алсу йөзле кыз чагы — тиз үтә, тиз уңа.

о Яшьлекнең матур төш икәнен «уянгач» төшенәсең.
о Кояш күзне чагылдыра, яшьлек үзен сагындыра.
о Яшьлек минутлары белән еллар буе хушлашасың.
о Йөгер яшьлек киләчәккә — мин сиңа кызыгам һәм алкышлыйм.

## Адәм баласы яратыр өчен яратылган

о ЯРАТУ сүзендә ЯР да, ЯРА да бар...
о Мәхәббәт җиде ятны үз иттерә, сигез үзне оныттыра.
о Күпер — ярларның бер-берсенә сузылып тоташкан куллары.
о Иң матур кеше — сиңа яратып баккан кеше.
о Ярату — күңел җылыңны кушып карау. Салкыннарның яратканы булмый.
о Һәр яшьлекнең үз мәхәббәте, һәр мәхәббәтнең үз җыры.
о Борынгы әби-бабайлар да үбешә белде микән?
о Мәхәббәтсез үткән көннәр — атмаган таңнар.
о Сөйгән ярлы кеше — иң бай кеше.
о Мәхәббәт белән нәфрәтнең уртаклыгы шунда — сәбәпләре истән чыкмый.
о Мәхәббәт аҗаганнары күңелне балкыта.
о Без янәшә синең белән, янәшә — гасырлар күк...
о Балдыз — бал кыз!
о Ятка калган ярларда ят оныклар үсәдер...

## Бала охшый ата-анага һәм заманага

о Яңа туган бала дөньяны елап яулый.
о Бала йоклый — анага ял.
о Сабый — булачак абый!
о Йөзләгән баланы караган, үзенекенә вакыты калмаган.
о Кара кайгы чәчне агарта.
о Бала — балласт түгел, канат ул.
о Ятим бала иртә өлкәнәя.
о Үги бала яңа энисеннән өлкәнрәк тә була...
о Бармакларда балдаклар бар, җитәкләргә бала гына юк.
о Сәфәрдә озаграк йөрсәң, хатының да кыз булып күренер.
о Бала күзен эти ача. Этиләр күзен бала йомдыра...

## Ак кәгазь мәгънә вәгъдә итә

о Кәгазь битенә кызыллык китермә.
о Кайсы китапка караганда ак кәгазь мәгънәлерәк.
о Каләм кәгазьне сагынган — ничек сыланып-сырпаланып йөри!
о Язмаган күңел күгәрә.
о Каләмең тирләсә укучың тиргәмәс.
о Язучыны халык вөҗданы тудыра.
о Шигърият җаны халыкта. Халык җаны иманда.
о Язучының бәхете үзен онытып, ил-көнне кайгыртып яшәүдә.
о Үзеңнән канәгатьсезлек — яңа ачышларның башы.
о Керфек очындагы күз яшең каләм очына төшсен.
о Талантлы әсәр — канатлы биектә булыр.
о Сан да талантны күрсәткән сыйфат.
о Балачак истәлекләрен имеп яшибез...
о Беренче шигырьләр калды яшьли сөйгән яр сыман...
о Остара бара, чын тормыштан ераклаша бара шигърият...
о Кайсы шагыйрьнең гомер юлыннан бер юл шигырь дә калмый.
о Тере агачтан ясалган кәгазь, начар әсәр язгач, җансыз агачка әйләнә.
о Күп яза торгач, уйларга вакыты калмаган.
о Гонорар алса гонорлы була.
о Кул язмасыннан аякларын танышсың...
о Авторы бар әсәрнең, атасы-анасы гына юк.
о Горурлык дәрәҗәсе сәләтеннән дә югарырак.
о Сүзең эчендә үзең бул!
о Халык иҗаты — бабаларның оныкларга юллаган рухи васыяте.
о Табышмак — җавабын табасы булганга борынгыдан килеп җиткән.
о Зирәклек — сүзнең канаты, фәлсәфә — дәрманы.
о Мәзәк ул җитди мәгънәсе булганда гына кызык.
о Сүзләрнең дә ешрак очраганын күрәсең, мәгънәлесе — шыпырт.
о Тырнаклар эченә эләккән юаш сүз...
о Сүзлек — иң оста тылмач.
о Музыка теленә күңел тылмач.
о Син җыр көйлисең, җыр күңелне көйли.
о Моңда — мәгънә.

о Аларның моржасы да җырлый!
о Атказанган тамашачы. Гади артистлар күпме!

## *Юл сукмактан башлана*

о Бергә кушылган сукмаклар юлга әйләнә.
о Һәр сукмак та юлга әверелми.
о Туры юллар үтмәгәнне, борма-борма сукмак кичә.
о Юлчыга юл иярә.
о Тигездә юллар туры. Бормалы юллар хәйләкәр.
о Юраулының юлы урау.
о Япан кырда багана да юлдаш — чыбыклары кешегә тоташкан.
о Тауга менгән саен офыклар чигенә.
о Тауда курыксаң — туктау хәерле.
о Вокзалда вакыт та туктап поезд көтә — озак үтә...
о Вокзал — вак ял урыны, эресе эләкми.
о Дөнья — вокзал, кемнең поезды кайчан китә...

## *Дошманлык чыганагы — күңел сукырлыгында*

о Күзен нәфрәт томалаган адәм явызлыкны җиңел эшли.
о Нәфрәт явызлык тудыра.
о Җәнҗаллык итә — җаны ял итә...
о Өзелеп яратканнар бар. Өзеп ташлардай дошманнар да юк түгел...
о Күңелгә шырпыдай кадалган сүз кылчыклары...
о Бездән күпсенгәннәр сез азсынырлык түгел.
о Мәкерле янында хәйләсез булмый.
о Астыртыннар өскәрәк үрмәли.
о Дошманның ялагаена караганда, явызлыгы йөзенә чыкканы хәерле.
о Ерактагы белән дус, күрше белән тыныша алмый.
о Кем күңелендә дуслык чәчәге үстерә, кем — шайтан таягы...
о Шомлы заманнар тарихын шымчылар яза.
о Атаклылар тормышын шымчылар шәбрәк өйрәнгән.
о Сафлык турында сафсата сата сатлык.
о Сатлыкның шатлыгы юк.
о Дошман арткан саен дуслар кадерле.
о Дусларда әсирлектә калган чак та була.
о Чикләр кемнәрне аера, кемнәрне берләштерә.
о Озак яшәгән кешегә ялгызы күңелсездер...

## Картлык яшьлектән башлана

о Картлык — пенсиягә җиткән яшьлек ул.
о Уртак яз да яшьләргә — бер, картларга икенче төрле...
о Картлык — яшьлектә тапканнарны югалту.
о Картая-картая хәтер тая, вакыт тиз шуа.
о Карт кеше күргән төшен дә оныта — склероз анда да үтә!
о Картлык — оныта, яшьлек — ота.
о Әүвәл ромашкалар гел актан иде, хәзер сарысы зуррак...
о Яшьлектә — дөньяның чибәрлеге. Картлыкта үз чибәрлеге дә юк.
о Язда калган яктылар, кышын көткән караңгы — синеке бабай...
о Өлкәнәю өлкәсенә эләктек.
о Табигать алтын яшьлекне алып, башка көмеш йөгертеп калдыра.
о Вакыт — скульптор, адәм атлы әсәрен башта матурлый, аннары — боза...
о Пеләшләр теләктәшлеге — пеләштәшлек.
о Коелган чәч агармый.
о Бакыр башта — көмеш чәч...
о Карчыкның тавышы йомшак, карты колакка каты.
о Көчең кимегән саен эшең арта.
о Картлык ниятли, яшьлек эшли.
о Үзең картаясың, кимчелекләр яшәрә.
о Яшьлекнең көче зур эшләргә җитә, картның көче яшәүгә китә.
о Айгыр кыланышы алашага килешми.
о Картайгач чәчәк тә күршенеке, кызлар да кешенеке.
о Уртак хисләр яшь аермасын яшерә.
о Төш күрергә күзлек кирәкми.
о «Мин сине гомергә ташламам»,— диде туксан яшьлек егет.
о Өзелгән телефоннан шылтыратып ни мәгънә...
о Шыгырдый да ыңгыраша урындык — картайды бугай.
о Яшәүне кайгыртып чаба торгач, яшәргә вакыт калмый.
о Яшәү артыннан чапканда әҗәл чабудан тарта.

о Карт гомер тик торсаң да үтә.
о Картлык әкрен атлый да, вакыт узып китә.

### *Эш сыекланса сүзләр куера*

о Җыелыш бара — эш тора...
о Сүз боткасы, фикер шулпасы.
о ТрибуНАДАНЛЫК.
о Авызының биге юк, сүзләренең чиге юк.
о Сүз — бозау имезә. Сөтләтә дә бирсәче!
о Күпнең кадере аз.
о Сүзенең атасы-анасы юк — зинадан туган.
о Телеңә сөял үсмәсен.
о Чүбек чәйнәп май чыкса эшләр майлаган кебек барыр иде!
о Һәр мавыгудан бер савыгу бар!

### *Турысын әйтүче яныннан кыеклап үтәләр*

о Мактаганда дәшмисең, тәнкыйть тигәндә тыелу читен.
о Сүз чыбыркысы сүс чыбыркыдан әчерәк.
о Кимчелекләрне күреп була, төзәтүе кыенрак.
о Кешене гаепләргә ашыкма, аңларга тырыш.
о Ач карында тавыш күп була.
о Буш тамак каты кычкыручан.
о Саклана-саклана куркакка калган.
о Кычкырып пышылдаган, инде пышылдап кычкыра.
о Кабынып карамаган — януны аңламас.
о Кешенең иң аз белгән кешесе — үзедер.

### *Иренү — ялкаулыкка ашыгу*

о Эшчән кояшта эшли, ялкауга күләгәдә дә эссе.
о Ялкауның язы соңарыр, кышы иртәләр.
о Кем — үркәчкә, кем — корсакка май-мая җыяр.
о Ялкауның сәгате алда булыр — ашка ашыга.
о Бу адәмнең үзен танымыйм, бүксәсен кайдадыр күргән күк.
о Ялкауга бал кортлары да эшләми, тырышка гына җыялар.
о Рухы сәламәт эшсез яши алмас.
о Туң җанны тун да җылытмас.

о Ялкау озак яшәргә дә ирენә.
о Мәнсезгә эш тәмсез, дөнья ямьсез.
о Сөялгән сөялле булмас.

## Комсыз ком ашар

о Авызын ачса үпкәсе күренми — алтын тешләр томалый.
о Бармагы үзенә таба кәкре, кармагы — бүтәннәргә.
о Галәмдәге «кара упкын» сыман Галләм дә яктылыкны үзенә йотар иде.
о Балдан мал ясый.
о Саранлыкка ул бик юмарт.
о Саранны сынау кыйммәткә төшә.
о Бирән бирәм димәс.
о Оятсыз оялуыңа исәп тотып алдый.
о Комсыз корсагы белән абынган.
о Көя дөяне дә ашап бетерә ала.
о Саклык — саранлык түгел, җыйнаксызлык — юмартлык түгел.
о Сан артыннан куып сансызга калган.
о Саранннан күп нәрсә кала, мәгънә генә калмый.
о Мие мин-минлек белән мөлдерәмә.
о Үзең күрсәтергә тырышканның күләгәсе дә зуррак.
о Баш миенә дан йөгергән.
о Һавалар җылына, кешеләр салкыная.
о Мокытлыкка юк кытлык.

## Әхлаксыздан имансыз туа

о «Җуләр сатып йөрдек»,— диләр яхшы атларын сатканнар.
о Гәүдәгә төп кебек, үзе — төпсез...
о Чибәрлеге чикледер, оятсызлык чамасыз.
о Ярты сәгатьтә куен сәгате эшләп алган хатын.
о Акыллы кеше акыл җыяр, тилегә генә җай чыкмый.
о Буш кешегә ни тутырасың?
о Пычак — сөзгәк кеше кулына күчкән мөгездер.
о Дөньяга сыймаган ике тәкә башы бер казанга сыйган.
о Каһәрнең зәһәре.

о Культуралы үсемлек чәчелмәгән җирдә чүп үләннәре үсә.
о Файдалы үләннәрне таптап файдасыз адәмнәр йөри.
о Аңа үз тормышы яхшыру гына җитми, бүтәннәрнең кайтыш булуы да кирәк.
о Үзле балчыктай ябышкак үзсүзле.
о Пычрак чистаны өнәмәс.
о Яман сүз яман күздән туа.
о Тәмсез телдән тәмле телмәр тумас.
о Тышка чыккан явызлыктан яшерен этлек яманрак.
о Кешенең өчтән бер өлеше су. Берәүләрдә анысы да болганчык.
о Карак иректәге гомерен урлый.
о Кыңгыр эш кыңгыраулы.
о Кояш түбәнәйгән саен күләгәләр зурая.

## *Эчмәгән аракы дарудан файдалырак*

о Эчсә — чама белми, эчмәскә чара белми.
о Эчмәсә — эшли алмый, эчсә — эше бармый.
о Ана сөте белән кергән акыл ата аракысы белән чыккан.
о Авызыннан аракысы кипмәгән.
о Буш вакытта — буш шешә, буш кеше.
о Аракылы башта кайнар уйлар чаҗылдап сүнә.
о Бер йөз грамм — кешене икейөзле итә.
о Аракы — рухка наркоз, вөҗданны йоклата.
о Аракы ашказанын да, баш казанын да боза.
о Кызмача каләм аек җырламас.
о Лаякыл айнык.
о Көн дә эчкәч, эчкечеме-түгелме икәнен ничек беләсең?
о Йотып алган — ятып калган.
о Аракы — юлыңа аркылы.
о Аракылы башта — аркылы уйлар.
о Бөке суда батмый, шешәле бөке бата.
о Сыер аракы бирсә, савып җанын алырлар иде.
о Күп эчсәң — аз яшәрсең.
о Гомерлек пары — аракы пары.
о Сәүдә министрлыгы боза. Тәүбә министрлыгы кирәк.

*1987 елга хәтле.*

# Сагыну
## күренекле замандашлар турында хатирәләр һәм уйланулар

### *«Истә синең якты гомерең...»*

#### Рухи чыганак сафлыгы

«Татарның талантлы Тукае, Такташы, Туфаны...» — дип олылап әйткәнне шагыйрь үзе дә ишетте. Җор сүзле каләмдәшләренең шаяруы итеп, тыйнак кына елмаеп тыңлый иде ул аны. Өлкән шагыйребезнең, Такташ, Җәлилнең дусты-фикердәшенең исеме халык мәхәббәтен казанган әдипләр белән янәшә икәнне белә идек, иҗат гомеренә йомгак ясалгач, бу тагын да ачыграк күренде.

Классиклар дәреслектә генә була дип уйлыйсың. Безгә дә Хәсән Туфан белән бергә, уртак елларда яшәргә, иҗат итәргә насыйп булды. Шагыйрь буларак та, шәхес буларак та зур йогынтысын тойдык без аның. Халыкка-әдәбиятка хезмәт итү аның иманы, гомерлек миссиясе иде. Иҗат эше — намус эше дип карады, үтә принципиаль булды — күңеле кушканга каршы килеп беркайчан да, бер мәсьәләдә дә ярашу-яраклашу белмәс иде.

Туфан дигәч, күз алдына әзрәк сагышлы, әмма якты елмаюлы, көмеш чәчле, ак күлмәкле мөлаем шагыйрь килеп баса. Ул җаны-тәне белән ак, пакь...

Борынгылар суны бозмыйча, саф көе саклауның әмәлен белгәннәр: көмеш сала торган булганнар. Андый суны изге санаганнар. Көмеш чәчле Хәсән абыйны, аның якты шигырьләрен халыкның рухи чыганагына сафлык биреп торучы намус көмеше дияр идем. Ул чыганакка килгән кешенең дә җаны чистара, күңеле сафлана. Шагыйрьнең үзен мәңгегә озатканнан соң без моны тагын да ачыграк тойдык. Иҗатыбызны, кылган гамәлләребезне Туфан карашы белән үлчәп яшибез, Тукайлардан килгән саф намусыбыз булып күзгә карый ул, күңелгә карый...

Хәсән абыйны ярата идек. Анысы гаҗәп түгелдер — аны бар халык ярата иде. Хәсән абый да безне яратты — шуңа сөенәбез. Намусыңа төбәп караган шагыйрь өнәмәсә нишләр идең дә, ничек иҗат итәр идең. Киләчәктә дә әдәбиятыбызның яшьләре шушы намус, сафлыкка туры калыр дип ышанабыз. Әдәбият кебек изге эш бары шулай гына үсә ала, яши ала.

## Кайту

Хәсән Туфанның Казанга кайткан көне турында каршылаган кешеләр язар. Мин үз тәэсирләрем белән уртаклашам.

Телеграмма алган язучы, шагыйрьнең яшьлек чордашы Габдрахман Минский безнең «Чаян» журналының әдәби бүлек мөдире иде. Хәбәрне ул сер итеп кайбер кордашларына гына әйтте, вокзалда төркем булмаска тиеш, диде. Ул чактагы саклык, шыпыртлык, кайтучыны кыен хәлгә калдырмаска теләүдән дә. Әлбәттә, дуслары белән бергә, бүтән каршылаучылар да бар: атаклы Туфан кайта ла!

Шагыйрьнең латин хәрефләре белән басылган китапларын бик тонык кына хәтерлим. Беренче классны 1937 елны тәмамлаган идек бит без. Әмма утка якмыйча, чормаларда сакланган китаплар арасында Ибраһимов, Туфаннар барын белә идек, күзгә дә чалынганы булды. Авыл кешесенең иң яшерен, ерак урыны чорма, дип елмаерга мөмкин. Әйе, чормалар чоры иде. Иң ышанычлысы — хәтер чормасы, күңел чормасы булуын да истән чыгармаска кирәк. Бер-берсенә нык ышанган кешеләр тыелган исемнәрне, әсәрләрне үзара искә алалар иде. Катырак тыелган саен, хәтергә ныграк сыенган. Шушы хәлгә күнегеп үскән буын идек без. Туфанны тере итеп танудан бигрәк, Тукай, Такташтай, инде кайту ихтималы булмаган атаклы кеше дип белә идек.

Менә беркөнне шушы реаль булмаган исем телгә керә башлый, каяндыр пәйда булып, үзе кайтып төшә! Нәкъ менә Тукайлар яныннан, шуларның берсе кайткан шикелле!

Туфан кайтты, әдәбиятка яңа бәяләү, таләпчәнлек кайтты дип, сагаебрак калганым истә. Мондый хис бер миндә генә дә тумагандыр. Безнең иҗатны беренче адым-

нардан кайгырткан Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзиләр бәясе бар, җәмәгатьчелек күзендә үз урының бар. Ә менә Туфан хәтле Туфан кайта да, бар язганнарыңны берьюлы күздән кичерә... Тикшеру килеп төшкән шикелле. Ул ни дияр? Бетереп ташламасмы? Ул чакта әле безнең шигырьләр вакытлы матбугат битләренә сибелгән, барысын да күрә алырмы? Кем әйтмешли, «әфтияк калынлыгындагы», дөресрәге, «юкалыгындагы» икенче китап та чыгып өлгермәгән. Шушы халәтем турында шактый еллардан соң өлкән шагыйрьнең үзенә дә әйткәнем булды. «Ярый ул бераз шүрләп тору, кайчан да ярый»,— дигәндәй мәгънәле генә елмая иде. Шул ук вакытта Туфан да үзе кайткан дөньяның, үзе югында үскән буынның мөнәсәбәте хакында да уйламый калмагандыр...

«Тегеннән кайткач» дөнья күргән яшел тышлы беренче китабын кадерләп саклыйм. Автографын монда күчерсәм, тыйнаксызлык булып аңлашылмастыр. Безнең өчен атаклы шагыйрь алдында, хәзергечә әйтсәк, «аттестация узу» иде ул. Яшел кара белән язылган ул сүзләр минем дә киләчәккә очар канатларыма дәрт-дәрман биргәндер. Нәкъ менә шуның өчен язгандыр да ул аны:

«Безнең эздән безнең дәвам килә,
Яңа яшьлек килә яшәргә.[1]

Поэзиядәге, аның алгы сызыгындагы яшьлекнең талантлы вәкиле булуың шатландыра мине.

*Х.Туфан.*
*19.05.58.»*

Мондый автограф бездә дә бар, диючеләр булса, гаҗәпләнмим, әдәбиятка бергә килгән каләмдәшләргә бирелгән бәя дип тә карыйм мин ул сүзләрне. Әмма чирек гасыр буе аралашып яшәгәндә болар тынычлап калгандыр диючеләр булса, бик ялгышыр. Хәсән абый ни әйтер, Сибгат абый ничек бәяләр дигән сагаю-«шүрләүдән» беркайчан да азат булмадык без, бүтән «хөрлекне» теләмәдек тә. Әле дә вөҗданыбыз алар алдында һәр язганы белән имтихан тота. Мондый кырыс таләпне үзеңә кабул итү — әдәбиятта бик кирәк нәрсә. Оялмый башлау, мин-минлеккә бирелеп узыну беркемне дә яхшыга илтми.

[1] «Ант» поэмасыннан.

**«Тамгалы...»**

1957 елның маенда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булды. Тәмам әзерләнеп җиткәч, сугыш бүлгән бәйрәм иде ул, илнең иң биек сәхнәләренә күтәрелгән сабан туебыз, культурабыз тантанасы иде. Юлда барганда да, башкаланың Казан вокзалына төшкәч тә, газеталар язганча, «рухи күтәренкелек» иде. Кадерле кунаклар без — олылап каршыладылар.

Кунакханәләргә бүлеп, күпсанлы килүчеләрдән һәркемгә урын тәгаенләп куйганнар. Безнең, берничә яшь язучының, «Балчуг»ка эләгүен ишеткән Г.Минский шаяртып та алды:

— Сезгә «Балчык» та ярап торыр. Абзаңнар менә «Москва»ның үзендә!

Шунысы кызык, без аерым, уңай бүлмәләрдә булып чыктык. Өлкән язучыларыбыз, төркеме белән, тулай торак сыман бер бүлмәдә. Кызыксызы шунда, Туфанга урын юк, урнаштырмыйлар. «Тегеннән» кайткан паспортында ниндидер тамга бар икән — Мәскәүдә яшәү тыелган. Хәсән абыйны юатып, урын юллап йөрделәр. Булмады бугай. Ахыр чиктә барыбер әлеге уртак булмәдә йоклап йөргәне истә калган. Үзе дә хәлен сиздерми, кушылып шаярткан да итә, әмма кинәт тынып кала, йөзенә күләгә төшә.

Онытылган бу хәлне мин чирек гасырдан соң фотолар актарганда күреп алдым. Мәскәүдә яшәүче укучыларыбыз белән Колонналы залда очрашкан кичәбез. Миндәге фотоларда Бари Рәхмәтнең шигырь сөйләп торган чагы. Сәхнәдәгеләр барыбыз да рәхәтләнеп көлеп утырабыз. Арадан берәү генә уйчан, моңсу, ул — Туфан. Бер фотода гына түгел, бүтәннәрендә дә эчке борчылуы сизелеп тора. Рәхәтләнеп көлүчеләрнең күзләре йомылган, ә менә объектив күреп алган — тикмәгә генә «объектив» димиләр икән аны!

Моңа хәтле таныш фотолардан күз йөгертеп кенә узганмын, инде текәлеп карыйм. Ул чактагы Туфанны соңыннан күңелгә урнашкан ак чәчле, яктырып елмайган Туфан белән чагыштырып карыйм. Еллар үткәч килгән, аңа хас булган ышанычлы сабырлык юк әле. «Тамгалы» дип, күңеленә кагылганнар. Фотодагы Туфан иректә яшәгән, канәгать, гамьсезрәк каләмдәшләреннән аерылып тора. Шыксыз кырлар, салкын яңгырлар, әче җилләр, чатнап янган учаклардан ысланып-киселеп кайткан кы-

рыс чырай, кыяфәтендә читләштергәнне тою, ятсыну, шушы дөньяга кушарга теләмәгән өчен пошыну, әрнү...

Дошманнан күргән хаксызлыкның логикасы бар. Үзеңнекеләрдән тигән хаксызлыкка ни диярге? Шушы рәнҗүне дә җиңгән бит олы йөрәкле кешеләр. Гасырның иң шәфкатьсез шаукымына эләккән шагыйрь. Бу хакта үзегез ни уйлый идегез, дип сораганым бар. Безнең монда булуыбыз партия өчен шулай кирәктер, без төшенеп җитмәгән серләре бардыр, дип уйлый идек, дия иде...

Бергә аралашып яшәгән чирек гасыр эчендә иҗатында булсын, тормышында булсын, хаксызга чиккән газаплары өчен үпкә, усаллану сизелмәде. Торып-торып шул хакта уйлый идем: берәр җыелыштагы хаксыз, ялганнахак сүз дә җанга шырпы булып кадала, йокыңны качыра, хаклыгыңны тизрәк исбат итәсе килә, ә Туфан нинди хәлләр кичермәгән!..

Шигъри җанын керсез саклаган гаҗәеп шәхес иде ул. Нарасыйларча, изгеләрчә ихласлыгы аны рухи имгәнүләрдән аралап калгандыр. Ул беркайчан да тормышка битараф, гамьсез булмады. Йөрәге суынмаган, рухы какшамаган иде аның! Үз дигәнендә нык торыр, беркемгә дә карап ярашмас, шуның белән кемнәр өчендер «сәер» дә иде. Шигъри җанның әнә шул ныклы үзәге сыгылдырмый тоткандыр аны, иманы, безнең идеалларга, халыкның мәңгелегенә ышану яшәткәндер...

## Мәхәббәтле көннәр

1958 елның җәендә Аккош күленә — язучылар дачасына, Хәсән Туфанга баруыбызны теркәп куйганмын.

...Әйтер сүзе бар шикелле, Хәсән абый аулак юлга култыклап китте. Көр күңелле, җитез хәрәкәтле. Яшьлеге, дәрте ташып тора. Тиздән алтмышы тулыр дип һич уйламассың. Аны шулай шигърият яшь тотадыр, дип уйлап куям. Урман юлыннан атлый торгач, тартынып кына серен ача:

— Гашыйк булдым әле, малай... Яшь чагындагы шикелле... Җырлар язам, мәхәббәт җырлары!

Гашыйк хәлендә иде ул, гашыйк халәтендә. Яшь аермаларыбыз онытылды, мәхәббәт серләрен бүлешкән ике яшьтәш сыман идек. Инде тартыну беткән, сөенеч уртаклашырга ашкыну гына бар.

Бәхетле иде ул, җиңел гәүдәле, очып-атлап барган, кагынып-канатланып, үз хәленә үзе гаҗәпләнгәндәй сөйләүче яшь кеше иде. Әйтерсең лә шагыйрьнең мәхәббәт кошы озак еллар читлектә ябылып ятканнан соң Аккош күлендәге якты яшеллек бәйрәме өстендә очынып уйный! Әйтерсең лә күңелдә бикләнеп-тыелып яшәгән хисләр дәррәү күтәрелеп иреккә чыккан! Ирек тулылыгын, иркенлек хозурлыгын, илһамлы бәхетен тамырларына кайнарлыгы йөгереп мәхәббәте сиздергәндер.

...Тоташ булып, коеп-коеп яңгыр яуды. Куаклардан су коела. Аяк асты юеш. «Быел арышларны күрми калам, ахры...» — дигәч, Хәсән абый кыр ягына алып китте. Урманнан чыктык. Игеннәр җилле яңгырдан соң сөрлеккән, каерылып-каерылып ята. Ялтырап кояш чыкты, яңадан аякка басарлар әле, күтәрелерләр — табигатьнең үзе генә белгән яшерен көчләре бар аның!

Кичен дача йортында Хәсән абый, Илдар Юзеев, мин — өчәүләп идәндә тәгәрәшеп йокладык. Хәсән абый мөлаем, кайгыртучанлык белән урын-җирне рәтли, булышырга да өлгерә алмый каласың. Шундый гади, кече күңелле — аның янында тартынмыйча, үзеңне иркен тотасың. Соңыннан: «Тукта әле, саксыз сүз, йә кыланышым белән рәнҗетмәдемме?» — дип уйлап та куясың...

Бу очрашу Мәскәүдәге декада көннәреннән соң бер ел үткәч булды. Шагыйрь инде иркен күккә ияләшкән очар коштай иде...

Аккош күленә, Хәсән Туфанга баруыбызның тагын бер истәлекле ягы бар. Мондагы дачада Әхмәт Фәйзи авырып ята. Безгә дә сиздерделәр, үзе дә беләдер диделәр — хәле өметле түгел. Илдарның илһамланып гармун уйнаган чагы, башта ук сөйләшеп бардык: Әхмәт абыйга үз җырларын, ул яраткан халык җырларын тыңлатырга булды. Без ул елларда укучылар белән очрашуга авылларга чыкканда минем малайның кечкенә гармунын саквояжга салып йөри идек. Әхмәт Фәйзи тыңлаган ул гармун әле дә исән.

Әхмәт Фәйзи оптимистик рухлы, җор кеше иде. Авыру хөкемен белсә дә, сер бирмәде: «Дөньясына төкереп йөргән чаклар бар иде, инде савытка төкерергә калды...» — дип, урында яткан көе елмаерга тырыша...

Гармунга, җырга бәйләнешле сүзләре истә. «Гомереңнең чигендә иң бәхетле, мәхәббәтле көннәреңне күңелдән

кичерәсең. Иң кадерлесе шулар»,— диде шагыйрь. Шигърият-мәхәббәт-илһам аерылгысыз төшенчәдер, әдипкә көч биргән, яшәү дәрте өстәгән мәңгелек чыганактыр.

Аккош күлендә булган әлеге көн, ике шагыйрь белән очрашу шулай истә калган. Исемен серле күлләргә калдырып киткән илһамлы Аккошлар турында якты да, моңлы да бер җыр булып күңелдә калган — үзем өчен дә мәхәббәтле, сөенечле һәм үкенечле елның бер көне иде ул.

## «Давай, Галимҗан, давай!»

Дәртләндереп, дәрман биреп торган бу сүзләр, бу тавыш ул чакта Аккош күлендә яшәүчеләргә бик таныш, ерактан ишетелеп тора. Узган-барганнар елмаеп куя:

— Хәсән Туфан футбол карый!

Алтмышынчы еллар башында аның футбол белән ифрат мавыкканын күрергә туры килде. Ул чакта әле телевизор сирәк нәрсә. Утын сараен җайлаштырып, шунда уртак берне куйдылар. Хәсән абый йотылып карый, Галимҗаны артыннан йөгерми генә, тезенә йодрыгы белән суга-суга куәт биреп тора:

— Давай, Галимҗан, давай!

Футболда Галимҗан Хөсәенов дәвере, илне шаулаткан чагы. Күңелгә хуш күренеш: халыкның чая, җитез улы барыннан да уздырып илкүләм зур мәйданда көрәшә, аны дөнья белә! Хәсән абый, мөгаен, футболны шул егет өчен генә карый, хирысланып бүтәннәрне дә шул шаукымга иярлә. Горурлыгыңны, сөенүеңне белдерергә форсат бар. Җиңүе белән котлап Галимҗанга телеграммалар оештырып йөри иде.

Галимҗаннар җиңгән көнне Хәсән абыйның әлеге утын сараеннан кулларын болгый-болгый, кодрәтләнеп, балкып чыгуын күрсәгез! Бу мавыгуына төрттереп, Сибгат Хәким шаяртып берәр сүз әйтә, күз кысып куя, Гомәр Бәширов сүзсез елмаю белән кушыла. Җиңелгән көнне исә шатлык сүрелгән була, әмма, болайрак булса, тегеләйрәк итсә, дигән сүзләр белән җиңеләйтергә тырышалар. Күрсәтер әле безнең егет, сынатмас, диләр.

Ил шатлыгы белән шатланып, халык гаме белән рухланып яши иде Хәсән Туфан. Галәмгә космонавтлар очса да канатлана, диңгез кичеп дөнья шаулаткан Әсгать

Җиһаншиннар өчен дә сөенә, Татарстан игенчеләре уңышы белән дәртләнеп, илһамланып газетага шигырь язып өлгертә, безне дә бу эшкә кыстый. Кем кайда күзгә күренерлек эш башкарса да шигъри хуплау сүзе белән котлап тора — халкыбызның тырыш улларына әле дә эндәшә сыман:

— Давай, егетләр, давай!

### Сәгать төзәтүче...

Хәсән Туфанның бик оста сәгать төзәтүе турында Сибгат Хәким гаҗәпләнеп, сокланып сөйли иде:

— Бөтенләй сүтеп, таратып ташлый... Ничек белеп, җыеп бетерәдер?

Бер караганда, гел уйларына чумып йөргән, шуңа таркаурак күренгән Туфан эшеме бу төгәллек, пөхтәлек? Икенчеләй, нәкъ менә җентекләп хис -уй-сүз бөртекләреннән шигырь «җыючы» җыйнак Туфанга кулай эш...

Сәгать-күздән зур дөньяны күргән ул. «Җир әйләнә», дип язган шагыйрьнең вакыт күрсәткече булган сәгатьтә өмете зур булган: хаклык җиңәр якка барасын белгән. Ирекә чыгар, илгә кайтыр көннәрне якынайтасы килгәндер, артка кала күрмәсен, туктап кала күрмәсен, дигәндер...

Туфан сәгать төзәтә. Вакытка, заманга күз-колак булып торган оста ул. Сәгате, вөҗдан сәгате, шигърият сәгате секунд-минутларны гына түгел, гасырны дөрес күрсәтә.

Дөнья базарында күп кешеләр шаулаша, рифмалы, көйле шаулаучылар да аз түгел, бер-берсен бүлә-бүлә нидер такмаклый алар. Сәхнәләрдә, трибуналарда муен тамырларын бүрттерә-бүрттерә тәти егетләр ярыша. Ә гасыр исеменнән, шушы ыгы-зыгыны күздән кичергән, шатлыгын-кайгысын йөрәгеннән кичергән Туфан кебек халык улының авазы кала.

Тукайның 1912 елда язылган, бүген дә искиткеч актуаль булган «Ваксынмыйм» исемле шигыре бар, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны турында ул:

«Бу заман шундый заман, дип, бу вакыт мондый вакыт,

Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот»,— диючеләргә Тукай:

«Вакытны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп,
Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып», — дип җавап бирә. Туфан да, Тукайлардан килгән уяулык һәм кайгырту белән шигъриятебез сәгатенең төгәллеген, күңелләр белән тәңгәллеген барлап торган сизгер йөрәкле оста-остаз иде.

## Рухи аеклык

Укучылар белән очрашу вакытында бик кызыклы сораулар була. Берсендә болай дип сораганнар иде: «Язучылар эчмичә эшли алмый, диләр. Шул дөресме?»

Иҗат кешеләре турындагы бу сәер легенданың уйдырма икәнен исбатларга тырыштым. Спортчы һәрвакыт формада — көрәшкә әзер булырга, үзен сәламәт тоярга тиеш. Әдип тә җаны-тәне камил булганда гына иҗат итә ала, дидем. Тәңресенә табынып сәҗдәгә киткән диндар шикелле, күңеле хушланган, саф булырга тиеш. Язучы да халкына яхшылык теләп шигъри гыйдабәт кыла, аның уйлары бары тик изгелеккә көйләнгән...

Ышандырып җиткерә алдыммы икән дип, соңгы дәлилемне китердем. Хәсән Туфан хәмер белән мавыгучыларны өнәми иде. Катгый төстә рухи аеклык ягында иде, иҗатны пакь җанлы кешеләрнең изге миссиясе итеп карый иде. Бер тапкыр гаҗәпләнеп, гыйбрәт итеп сөйләгәне истә:

— Ничектер, бер банкеттан кайткач, шигырь язып караган идем. Иртәгесен укыйм — хәмер исе килә... Төзәтеп тә карадым, әллә ничә омтылдым, барыбер «айнытып» җиткерә алмадым шигырьне... Әйтәм аны «тегеләр» шигыреннән аракы пары аңкый...

Ул моны ниндидер пычраклыкка кагылган шикелле, чирканыбрак әйтте. Эчкәннәрдән йөз чөерүе, ул кешеләрдән өметне өзүе суфиланып бәйләнү түгел, яшь күңелләрне сакларга тырышуы иде. Андый чакта ул кырыс, күңеле бер суынса, кичерер димә, шәфкать көтмә.

Әле шушы арада гына бер җыелышта янәшә утырганда Гомәр ага Бәширов сөйләде:

— Беркөнне дачада иртүк Хәсән килеп керде.

«Табеев янына барырга кирәк!» — ди.

«Бик ашыгыч, кичектермәс эшмени?» — дим.

«Бүген үк барыйк!» — дип кыстый. Хәсәннең мәсьәләсе нинди дисәң:

«Талантлы ике егетебез эчә бит...» — ди.

Әнә шулай, талант — халык байлыгы дип, аның язмышы дәүләт эшлекләләре дәрәҗәсендә кайгыртылырга тиеш дип карый иде өлкән шагыйребез. Хәмер белән шул дәрәҗәдә көрәшергә кирәген ул чакта ук күргән, нинди куркыныч янаганын сизгән...

Иҗат кешесенә күңел «градусларын» шикле-шөбһәле, гарип юллар белән күтәрү кирәкми, иҗади хезмәтнең юлдашы булган илаһи көч-илһам бар дөньяда, шул кодрәтле канатлар күтәрә аны!

## *Бер Туфан — күпчелек...*

Язучылар союзы идарәсендә Хәсән абый белән бергә күп тапкырлар утырдаш булырга туры килде. Принципиаль мәсьәләләр хәл ителгәндә, яшерен-батырын түгел, үз күңеленә хилафлык кылып булса да, «шулай кирәк», дип кул күтәргән чаклар булгалады. Әйтик, инде пенсия яше җиткән, күпсанлы китаплар авторы язучылар союзына алуны сорый. Икенчесенең радиодан еш яңгыраган җырлары бар...Мондый чакта:

— Ярар инде, керсен,— дип кызганучылар табыла.

— Артык таләпчән була башласаң, берзаман союзда кеше дә калмас! — ди икенчесе.

— Генийлар союзы түгел ләбаса — алырга кирәк! — ди өченчесе дә ярашып.

Күпчелеккә кушылып, үсәр әле дип ташлама ясап, син дә яклап тавыш бирәсең. «Каршылар юкмы?» дигәндә Хәсән Туфан ягына карыйбыз — бер ул күтәргән. Ябык кулын терсәктән тотып тора — төшебрәк китеп, күренми калмасын... Бу хәл кабатлана торгач, шаяртыбрак, бер сәерлек итеп караучылар да табыла. Әмма утырыштан чыкканда күз күтәреп карарга ояласың, сүз кушарга җөрьәт итмисең — шагыйрь алдында гаепле син.

Үпкәләгәндер, хәтере калып, әйләнеп тә карамас дисәң, хикмәти хода, икенче очрашуда ул моны сиздерми, тыенкырак елмаеп булса да, сөйләшә.

Инде үзеннән соң да, хәлиткеч чакларда Туфан карашын тоясың, ул сиңа ныклык бирә, хак иманыңнан, үз

дигәнеңнән тайпылмаска куша. Ә теге елларда безнең йомшаклыкны ник кичерүен хәзер төшенгәндәй булам: без ул олылыкка тиңләшә алмаганбыз, кулны буебыз җиткән кадәренчә күтәргәнбез. Инде күрәбез: Бер Туфан хаклы булган, Бер Туфан күпчелек булган! Тормыш шуны күрсәтте, теге иптәшләр Туфан хупларлык дәрәҗәгә ирешә алмадылар.

Шәфкатьле, миһербанлы Туфан вакыты белән әнә шулай каты, кискен була иде. Әмма ул олы әдәбиятыбызның сәламәтлеген, сафлыгын кайгыртуы белән мәрхәмәтле иде.

## Өч кыйсса

Шагыйрьнең серле пәрдә артында калган еллары — мәгълүм булмаган тормышы аерата кызыксындыра иде. Бу хакта ул сирәк ачылды. Менә Горький өлкәсендә әдәбият атналыгында йөргәндә 1968 елда теркәлгән кайберләре...

### I

Хәсән абый ак нейлон күлмәктән генә, төнлә кунак йортында тәмәке тартырга чыккан.

— Хәсән абый, шушы тәмәкене ташлатасы иде сезнең! — Елмаеп карап тора да:

— Моңа хәтле әллә ни булмады әле,— ди.

— Бер дә ташлап карамадыгызмы?

— Тегендә сигез ай ташлап торган идем...

— Анда тәмәке булмагандыр шул...

— Паекка алмашып ала идек. Ярты паекка, ике йөз грамм икмәккә — бер шырпы кабы тәмәке. Шуны саклап, озаккарак җиткерергә тырышасың. Йә берне төрәсең дә, чиратлашып суырасың. Кемгә — сорок, кемгә — двадцать. Берзаман карыйбыз — йомшарта башлады бу ашауны чикләү. Шуңа күрә ташларга сүз куештык. Тартмый башладык. Үзебезне сакларга кирәк, диештек.

Безне, үлемгә хөкем ителгәннәрне, бер камерага бишалты кешене күчерделәр. Алар, атарга хөкем ителеп тә, эшләре яңадан каралуга кайтканнар. Миңа гаепләү актын укырга бирделәр. Болар күрделәр дә, расстрел булачагын белделәр. Мине алырга килгәч, озатканда кайсы тәмәке, кайсы нәрсә тыгып җибәрделәр. Мине бер каме-

рага керттеләр. «Шушында аталар икән»,— дип уйлыйм. Идәндә кара нәрсә ята. «Берәрсен аттылар микән?» — дип иелебрәк карыйм. Теге кузгалып:

«Тебя тоже на луну?» — дип сорады. Әйе, дидем. Теге:

«Нет ли закурить?» — ди. Бар, дидем. Зур итеп төреп, рәхәтләнеп көйрәтеп җибәрде.

Расстрел мәгълүм булгач, бергәләп тәмәке ташлаган кешене очраттым.

«Тартабызмы?» — ди.

«Мин тартмыйм»,— дим.

«Әллә, теге, ташлаганнан бирлеме?»

«Әйе. Сигез ай.»

«Соң безгә үзебезне саклауның ни кирәге бар?» — ди гаҗәпсенеп. Мин уйга калдым: чыннан да, саклану нигә хәзер? Шуннан бирле тарта башладым.

Ә тәмәкене Хәсән абый соңыннан барыбер ташлады: үзен алдарга тырышып көнбагыш чиртеп йөрде. Инде сәламәтлекне сакларга кирәк иде. Шигърияtебез өчен, халкыбыз өчен кирәк иде.

## II

Телепатия, төшләрнең рас килүе турында сүз чыккач, Хәсән абый искә ала:

— Тегендә чакта төш күргән идем... Ах, малаем үлгән икән, дип шомланып куйдым. Шуннан соң өч ел үтте. Балдыз мин торган якка якын иде, сөргенгә свиданиегә килде. Өй хәлләрен сөйли. Кызның: «Папа кайчан кайта?» — дип сорауларына хәтле әйтә. Ә малайны дәшми...

«Ә Идегәй, Идегәй ни хәлдә, ник аны әйтмисең?» — дим. Балдыз гаҗәпләнә:

«Белмисеңмени?! Ул бит өч ел элек үлде. 7 ноябрь көнне».

Кылт итеп теге төшем искә төште. Нәкъ шул көн иде ул. Бәйрәм көне. Онытыла торган көн түгел.

## III

Сугыш вакытында сугышка җибәрүләрен сорап Мәскәүгә язуы турында сөйли. Илгә тугрылыкны үлемем белән расларга мөмкинлек бирегез, дигән. Бер генә дә язмаган. Исән кайту ихтималы булмаган заданиегә, «смертник» итеп җибәрегез дип тә караган. Юк, рөхсәт

булмаган. Тоткында яшәү белән җәзалау үлемгә озатудан катырак булырына исәп тотканнар, күрәсең...

Корабль бату дигәч, шул ук елларда шундый ук язмышка дучар булганнардан Фатих Кәрим искә төшә. Тоткыннарны төяп барган баржа «очраклы рәвештә» баткач, бары өч кеше бозлы судан йөзеп чыга ала. Бу хакта кызы Ләйлә шагыйрьнең туган авылына барганда сөйләгән иде. Ф.Кәрим дә фронтка атлыккан: гаепсезлеген исбат итүнең бердәнбер юлы — шул изге көрәштә кан кою, корбан булу... Шагыйрьнең: «Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен сугыш кырларында үлүе», дигән юлларының мәгънәсен тирәнрәк төшенәсең.

Уттан алып суга салып сынаган кырыс еллар безнең шигъриятне. Җәлил, Туфан, Кәрим... Ил алдында килер буыннарның йөзе ак булып, горурланып яшәрлек исем калдырган өчен рәхмәт батыр йөрәкләргә. Халкыбызның тыенкы горурлыгы, рухи батырлыгы, башбирмәс ныклыгы чагылды аларда.

## Бер очрашу

Кич Хәсән абый Туфан килеп керде. Аккош күлендәге дачасыннан кайткан икән. Төн уртасына чаклы сүз өзелмәде. Аның белән сөйләшүе кызык, мавыгып, кабынып-кабынып, тәэсирләнеп, төрле аһәңнәр белән җиткерә ул уен-хисен. Куллары, бөтен торышы «сүзгә катнаша».

— Ат шикелле эшләп утырдым! — ди. Шатланып әйтә. Төнге уникедә йоклап алган да, тагын эшләгән.

— Кайткач та язып бетерәсе шигырем бар. Начар чыкса, үзең җавап бирерсең! — дип шаярта өстәлдәге брендига ымлап.

— Шулай эшләвегезгә сокланабыз һәм гаҗәпләнәбез,— дим.— Без инде шушы яшьтә дә язып бетергәндәй булабыз кайчакта...

— Кешене гүзәл гамь эшләтә! — ди ул.

— Димәк, зур уйлар белән янып эшләү гомерне кыскартмый, озайта икән әле, яшәтә, энергия бирә?

— Кеше әле ачылмаган гаҗәп бер нәрсә. Аңарда фән дә белмәгән мөмкинлекләр бар...

«Гүзәл гамь» сүзен Мәскәүдән килгән газета хәбәрчесенә «высокая боль» дип тәрҗемә итеп күрсәткәнен искә ала. Дөрес бит!

Сүздән сүзгә, вакыйгадан вакыйгага сикереп сөйләшә торгач, күп нәрсәләргә кагылдык...

— Магнитофон булса икән,— ди Хәсән абый.

— Бар ул,— дим, күрше бүлмәдә ачылмыйча торган тартмага күрсәтеп.

— Безнең сөйләшкәнне язып алырга иде! Соңыннан тыңлап карарга кызык булыр иде. Ниләр генә сөйләшмәдек! Әнә Андронников ниләр генә тапмый.

Бу гыйбрәтле сүзләрне тыңлап мин дә магнитофон турында уйлап куйган идем. Килешмәс, дидем. Ничек кунакның сүзләрен язып барасың? Аннары, колак салып торучы «каенана» булганда, сүз дә, мөгаен, бүтәнчәрәк агылыр иде.

«Тегеннән» алып кайткан, эшләнеп бетмәгән поэмасы булуы турында әйтте. Мин кызыксынып:

— Эшләп бетерергә иде, Хәсән абый, сузмаска иде! — дим.

— Шулай,— ди, үзе дә килешә.— Менә кайбер укучылар «фәлән геройлар хәзер кайда?» дип хатлар язалар бит. Әпсәләмгә дә күп килә андый хатлар. Нигә поэзия әсәре шундый кызыксыну тудырмаска тиеш? Поэманың геройлары турында да шулай язарлык булсын!

Хәсән абый язмышындагы поэмага да, шигырьләргә дә сыеп бетми торган хәлләр бар бит. Үзен тыңлаганда бигрәк тә шундый уйлар килә. Мин моны үзенә дә әйтәм. Аларын да теркәп куярга кирәк иде, дим. Каршы түгел. Әмма язар микән? Язмастыр... Стенографистка утыртып, йә магнитофонга сөйләтеп алсак инде һичьюгында.

— Урынга ятып үлү, трамвай астында калу берни түгел ул. Үлемеңне алдан белеп тору авыр. Бик авыр, яшисе килә! Мин Фучикның, Вапсаровның, Җәлилнең үлем алдыннан ниләр кичергәнен беләм. Мин шуның белән баерак.

Тормышта авырлыклар, сынаулар була икән, болар язучыны баета икән дип кара... Кайтуга өмет юк иде... Минем үзем язган җырларым бар — ноталары теркәлгән. Шуларны халык арасында җырлап йөрермен, фикерләремне җиткерермен дип уйлый идем. Егерменче съездга, партиягә рәхмәт...

Сөргендәге көнкүрешеннән, сыерлар көткән чагын искә ала. Сыерларның кешегә ияләшүе, аңлаулары турында сөйли. Мин чыбыркы аскан Туфанны күз алдына китерәм — кырда, ялгызы, чит җирдә...

— Кунып эшләргә туры килә иде. Ут ягасың. Ут янына сыерлар килә. Аларга орынып, җылыларын тоеп ятасың. Чәчеңне уңайга ялыйлар...

— Берсендә күрәм,— дип дәвам итә Хәсән абый,— ерактан ук сыерлар миннән читкә тайпылалар. Бер сүз әйтү юк әле үзләренә. Минем җил-җил килүемнән ачулануымны сизеп алганнар! Хәйләкәр дә соң үзләре! Иген басуы янында үлән шәп дип, шунда куып килдем. Үзем басу белән ике арада басып торам. Берсе дә керми игенгә. Яратканга күрә, тәртип бозарга миннән оялалардыр. Бер усалы күршесен төртеп кертә.Теге кергәч, үзе дә үрелә — янәсе, мин башламадым, әнә кем гаепле —бүтәннәргә сылтарга форсат була!

Бу очрашу, бу сөйләшү 1971 елның 29 сентябрендә булды. Өзек-өзек фикерләрнең кайберләрен, бик-бик кайберләрен генә, иртәгесен теркәп куйдым. Кич буе сөйләшүдән кәгазьгә ышанганнары шушы. Сакланырга, үзебезне дә, әңгәмәдәш фикердәшне дә сакларга өйрәткән иде шул яманаты чыккан заманнар. Кемнәр хәтерендә ни бардыр — хәзер шуларны бөртекләп җыярга кирәк. Бергә туплагач, заман хәтерендәгесе калсын, киләчәккә барсын иде.

## Гәрәбәле диңгез буенда

Балтик буеннан гел генә кеше өзелми. «Йодалы һава» сулаучылар агылып кына тора. Гомәр ага Бәширов та иртән чыгып йөрүчән. Күпләр арасыннан җиңел табып була аны: бөкрәебрәк атлаган яшьләрдән ул туры-төз гәүдәсе белән әллә каян аерылып тора. Хәсән абый диңгез буена чыкмый. Бу арада сырхаулап тора. Өченче каттагы җылырак бүлмәгә — җилсезрәк, тынычрак якка күчте. Яңа бүлмәсен котлап, күрергә кердем. Хасиятләп, тәмләп чәй пешереп йөри.

— Яңа бүлмәдә уңайлымы, Хәсән абый?

— Әйбәт.

Тәрәзә пәрдәсен ачыбрак карыйм: диңгез дә күренә, наратлар да якын гына.

— Агачлар матур күренә икән.

— Беләсеңме нәрсә, пәрдәне корып куйдым мин — уют булсын дип. Игътибарны тартмасын дип...

— Өйрәткәннәр кешене томалап тотып...— дим, шаяртып. Хәтере калмасын дип, үзем уңайсызланып та куям. Мәзәкне аңлый ул — елмайды гына.

Мондый чакта сүзнең сүзгә ничек ялгануын сизми дә каласың. Хәсән абый Тукай шигырен әйтеп биргәч, мин дә, әткәй-әнкәй «Көзге җилләр»не менә болай укый иде дип көйләп күрсәттем:

> «Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
> Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый...»

Хәсән абый да балачак хатирәләрен сөйләп алды:

— Аркасына китаплар асып, авылга китапчы килә торган иде. Китапларны сәкегә тезеп сала. Теге зимагур абый китапны алдына куя да, үзе түбәнгәрәк утырып, көйләп укый Тукайны. Ничек көйләгәне истә калмаган, мин әйтеп күрсәтә алмыйм. Ике китап алган иде, берсе Тукайның «Җан азыклары», лирик шигырьләре, әнисе турындагы шигырьләре анда. Шул чаклардан хәтердә калган Тукай,— ди дә, яттан сөйләп-сөйләп ала.

Беркөнне Гомәр абый белән икесен Дубылты иҗат йортында эшләүче якташыбыз Роза ханымның ире машина белән шактый ерактагы көзге ярминкәгә алып китте. Кайткач:

— Нәрсәләр бар? Ниләр күрдегез? — дип кызыксыналар кешеләр. Хәсән абый ашыгып-ашыгып сөйли:

— Анда бик кызык типлар бар! Күзәтеп йөрергә кызык! Караган саен карыйсы килә. Латышлар, безнең якта очрамый торган, үзгәләр...

Гомәр абый белән килүе дә тикмәгә түгел. «Хәсән, болайрак итәсең мәллә?» — дип, йомшак кына көйләп йөри ул аны. Нарасый күңелле өлкән шагыйрь үзен кайгырта белми. Аша, димәсәң, ашауны да оныта. Гомәр абый үзе дә үтә сабыр, бар булганы күңеленә йомылган. Бер тапкыр шулай, безнең бүлмәгә телефоннан шылтырата. Кәефләр ничегрәк дип, җай гына, сораштыра башлый. Үземнең хәлне дә белешә, «хәләл җефетне» дә онытмый. Языламы, дип тә кызыксына. Аннары гына, бик гадәти нәрсәдәй әйтеп куя:

— Карале, кем, шәфкать туташын таба алмассыңмы икән? Телефоны дәшми, берәрсе чакыргандыр. Йөрәк бераз чыгымчылап тора — аритмия. Хәсәнгә сиздереп тормабыз...

Без булсак кабаланып-каушап төшәр идек, ул мон-

дый хәлдә дә тыныч. Тизрәк йөгердем, шәфкать туташы да табылды, укол ясады, кузгалмыйча ятып торырга кушты.

1975 елның көзе иде бу. 30 сентябрьдә автобус белән Курляндиягә сәяхәткә чыктык: Юрмала-Тукумс-Кандава-Сабиле-Талсыларны әйләнеп кайттык. Бөтенләй көньяктагы сыман булды: кояшлы көне, саф һавасы, тыныч табигате, тар урамлы, үрләргә урнашкан җыйнак шәһәрләре... Гомәр абый кайда булса да, яңа романы уңае белән гел табигаткә бәйләнешле нәрсәләр белән кызыксына. Яшьләр сыман йөгереп кенә йөри. Хәсән абыйның тауга күтәрелгәндә аягы авырта, аңарда — артрит.

Кайткач, кичен бергәләп, бик иркенләп сөйләшеп утырдык. Бусы үткәннәргә сәяхәт булып чыкты. Хәсән Хәйри дә кушылды, ул да монда. Өлкәннәрнең бергә үткән гомерләре, уртак танышлары, каләмдәшләре күп. Мавыгып гәпләшә торгач, төнге уникे тула язды. Күп нәрсәләр турында сөйләшенде. Теркәп кенә куясы иде дә бит, юк шул, шуңа вакыт тимәгән. Иҗат йортына тулышып җиткән әсәрләреңне язарга ашкынып киләсең бит.

Иҗат йортыннан китәр алдыннан бергәләп карточкага төштек. Шаярышып-көлешеп сөйләшкәндә туктап калган шул мизгел, караган саен, җанлана да китә.

Менә без бүлмәләргә таралышабыз. Хәсән абый да язу өстәлендәге яшел кара белән гарәпчә шигырь теркәлгән тар-тар кәгазьләр өстенә иелә, пөхтәләп кенә яза башлый. Балтик буенда бүтәннәр гәрәбә эзләп киләп-сарып йөргәндә дә, пәрдәләрне корып, ут яктысында эшләгәне үзгә аның. Күңел диңгезеннән хис дулкыннары каккан уй-тойгыларын шигъри юллар-муенсаларга сак кына тезә...

## Күңел таянычлары

Уфа Туфанга үзенең кайнар мәхәббәтен сиздерә алды, кайткач кабат очрашуда легендар шагыйрь итеп каршылады. Андагы дуслары, укучылары белән үзе дә яратып күрешә иде. 1958 елның язында миңа да элек Галия мәдрәсәсе урнашкан 15 нче мәктәптә бер очрашуда катнашырга туры килде. Атаклы мәдрәсәнең элекке шәкертләре — Хәсән Туфан белән Нәкый Исәнбәт Г.Ибраһимовны, Ш.Бабичны юксынып искә алдылар.

Уфа күбрәк ягымлылык күрсәтмәде микән дип бер

дә көнләшәсе юк. Уфа — шагыйрьнең яшьлек шәһәре, аңа карап: «Мин асылда синдә тудым, Уфа»,— дияргә урыны бар иде шагыйрьнең. (Укучыга таныш булмаган ул юлларның ничек язылуы турында соңрак әйтермен.) Ә бит бу хәл бик табигый булган. Татар әдәбияты классикларын үз иткән, якын иткән калалар, мәгърифәт үзәкләре илебезнең төрле якларында булган: Уфа, Оренбург, Троицк, Уральск, Пермь, Әстерхан һәм башкалар.

«Мин асылда синдә тудым, Уфа»,— дип башланган шигырьнең язылу тарихы мондый. 1978 елның февралендә Әнгам Атнабаев безне үзенең 50 еллык юбилеена чакырды. Туфан Миңнуллин белән барырга булдык. Илдар Юзеев чакырулы, әмма ул санаторийда иде. Менә шул сәфәр алдыннан, Фатих Хөснинең иҗат кичәсендә күреп, мин Хәсән абыйга ниятемне әйттем: «Атнабайны яратканыгызны беләбез, иҗат мәҗлесендә котлар өчен берәр теләк-тәбрик язмассызмы? Сезнең сүз кадерле булыр иде»,— дидем. Берничә көннән Хәсән абый шигырьләрне язып та бирде. Мин аларны Уфаның әдәби җәмәгатьчелеге алдында өлкән шагыйребезнең котлавы итеп укып тапшырдым. Анда мондый юллар бар:

Мин асылда синдә тудым, Уфа,
Бүген менә — килеп каршыңа,
Ике энем, менә бу зал аша
Сәламемне сиңа тапшыра.

Синдә минем
Каләмдәшләр байтак,
Һәм һәрберсе хөрмәт итәрлек:
Әйтик «А»дан-Атнабайдан башлап,
Янбулатка барып җитәрлек!

Бабичка хас юмористик нур бар
Синең, Әнгам, көләчлегеңдә.
Такташтагы нәфис тирәнлек бар,
Төгәллек бар, шигъри телеңдә...

Әнгамгә шушы соңгы дүрт юл да, мөгаен, кырык елдагы иҗатына бәяләрдән иң бәһалеседер, иң кадерлеседер. Теләкнең икенчесе Әнгамнең хатыны Сәвия ханымга багышланган:

Фәрештәкәй дигән мифик җисем
Юк та үзе — күктә һәм җирдә,
Әмма бар ул Әнгам тормышында:
Син ул, син ул безнең шундый сеңел,
Сабыр җанлы, изге Сәвия!

Шул сыйфатың белән котлап сине
Шигырь бүген сиңа баш ия.

*Сәлам белән Хәсән Туфан.*
*24 февраль, 1978*

Олы шагыйрьнең йөрәге географик чикләргә сыймый. Туфанның да Казахстанда, Үзбәкстанда, Әрмәнстанда, Мәскәүдә һәм Ленинградта, илнең төрле якларында ул яраткан, аны яраткан төрле халык уллары бар. Тарих тирәнлегендә дә, заман киңлегендә иде аның күңел таянычлары, фикри теләктәшләре. Э.Чаренц, Г.Голәм, М.Кәрим, М. Дудин, О.Сулеймановларны кан кардәшләре кебек якын күрә иде. Р.Гамзатовка «Безнең Рәсул» дип шигырь белән яратып эндәшүен хәтерлик. Бу хакта бер очрашуда искә төшергәч Рәсул Гамзатов үзе дә:

— Сезнең иң зур шагыйрегез Хәсән Туфан! — дип олылап әйтте. Иҗаты белән дә, язмышы белән дә аның олы шәхес булуын якын күреп, горурланып сөйләде. Мактау сүзләрен күбрәк үзе ишетергә өйрәнгән күренекле шагыйрьнең нык ышанып шулай раславын тыңлавы күңелле иде.

Дуслык җепләрен киләчәктә дә туганнарча саклау, күп милләтле илебездә бердәм яшәү — Туфанның безгә үз гомер үрнәге, иҗаты белән калдырган васыяте.

## Шагыйрь бүләге

Хәсән Туфан чәчәкләр ярата иде. Чәчәкләргә ул балалар кебек итеп карый, йөзе яктырып, тагын да мөлаемләнеп китә иде.

Хәсән абый балаларны бик ярата иде. Ул аларга, чәчәкләр сыман итеп, сокланып һәм сөенеп карый, алар дөньясына ихлас кушылып китә белә иде.

Язучыларның Аккош күлендәге дачасында Хәсән Туфан беседкасы дип телгә кергән чатыр бар. Ә аның тарихы болай. Шул тирәдә уйнап йөргән балалар күтеп, чамалап кына тора — Хәсән абыйлары күрендеме, тизрәк аның янына йөгереп киләләр. Мондый җыелышып утырулар бик еш булып тора. Ә шарты һаман бер: матур итеп, үз телебездә шигырь сөйләп күрсәтергә кирәк! Бу, үзенә күрә, җәй буена сузылган сабан туе — шигырь сөйләп ярышу иде. Бүләге дә алдан ук әзерләп куелган: Туфан

шигырь сөйләгән балаларның һәркайсына чәнти бармак хәтле генә, балык кылчыгы сыман пәке бүләк итә иде.

Безнең дә бала чакта иң кызыкканыбыз пәке иде. Әмма ул нишләптер кулга төшми иде. Бәлкем, Хәсән абыйның да чынга ашмый калган балачак хыялы булгандыр ул. Ә хәзер нәни дусларына бүләк өләшүе дә сабый чагын искә төшерүедер. Үкенечләре калмасын дигәндер.

Туган телне нарасый чактан күңелгә сеңдереп калырга омтылуы да гомерлек үкенечләре калмасын дигән теләк булган бит. Кызлар, малайлар Тукайның «Туган тел», «Гали белән Кәҗә», «Бала белән күбәләк»тән башлап, үзләре ярат-кан тагын бик күп шигырьләрне ятлап киләләр дә, Хәсән абыйлары мактавын ишетергә теләп, аның күзенә карыйлар иде. Шагыйрь абый сизгер күңелле, барысын да тигез күрә — бүләксез нәүмизләнеп калучы булмый иде. Бүген булмаса, иртәгә өйрәнер, өмет бар, өмет!

Урман арасында яшәгән балага пәке кирәк чаклар күп була: таяк юнарга, сыбызгы ясарга, гөмбә кисәргә..-.Ул пәкеләр югалып та беткәндер, тиктормас бала кулында әйбер сакланамы! Әмма шунысын беләм, инде үсеп буй җиткән ул балаларның үзләреннән ишетеп тә беләм — Хәсән Туфанның шигъри сабакларын онытмаган алар, гомерлек истәлек итеп күңелләрендә саклаганнар. Алар, пәкегә кызыгып кына җыелмаганнар, аларны шагыйрь янына җан җылысы тарткан, аның белән очрашу үзе иң зур бүләк булган.

Хәсән Туфанның балалар арасында утырып төшкән бик мөлаем бер рәсеме бар. Мин аларны илебезнең төрле якларыннан шагыйрь чатыры янына җыелган укучылары итеп күрәм. Шагыйрь аларга үзенең Юкмыш бабай малае турындагы үлемсез әкиятен сөйли. Ул әкиятне мин Татарстан районнарында, илебезнең бик күп төбәкләрендә — Башкортстанда, Мари АССРда, Әстерхан, Горький өлкәләрендә очрашулар вакытында шагыйрьнең үзеннән кат-кат ишеттем. Әкият үзе дә туган телгә мәхәббәт уята торган тылсымлы көчкә ия.

Хәсән Туфан чәчәкләр ярата иде, балаларны ярата иде, табигатьне табигый хәлендә ярата иде. Мин аны Аккош күлендә, табигатьнең үзендә, чәчәк аткан чагында итеп күз алдына китерәм. Ә бит ул үзе ел тәүлегенең иң салкын вакытында декабрьдә туган. Гасыр тәүлегенең дә салкын чагы булган ул. Шагыйрьгә үз гомерендә салкынлыкларны, салкын якларны аз күрергә туры килмәгән.

Өлкән шагыйребезне соңгы юлга озатканда июнь ае иде. Елның иң җылы, иң ягымлы, иң матур чагы. Хәсән абый үзенең җан җылысы, якты елмаюы, шигырь-җырлары белән дөньяны җылытып, күңелләрне яктыртып китте...

## «Менә, мә, кара!»

Туфанның балалар өчен язган «Юкмыш бабай малае» турындагы әкияте алтын фондка кергән классик әсәр. Һәр яңа буын өр-яңа итеп укый аны, 1940 елны язылганын белмиләр дәдер. Әсәрдә миңа иң ошаганы — торна аякларына ябышкан Бәлкәй атлы малайның төшеп калу сәбәбе. Берничек тә аңардан ычкына алмагач, торна хәйләгә керешә: «Син дә бабаң акчасын сыпырдың бит бүген»,— ди. Юк, дип малай башта бер кулын күрсәтә, анннары икенчесен. «Ике кулны берьюлы күрсәт»,— дигәч: «Менә, мә, кара!» — дип ике учын да җәеп күрсәтә һәм түбәнгә төшеп китә. Хаксызлыкны күтәрә алмый, син аның намусына кагылма!

Хәсән абый бу әкиятен балалар алдында сабыйларча ихлас итеп, очынып-канатланып, «рольгә кереп» сөйли иде. Һәр сүзенең интонациясе әле дә истә. Балаларга кушылып без дә инде ничәнче кат, шагыйрьне кинәнеп тыңлыйбыз, нарасыйлар күк сөенәбез. Белмим, үзе укуында радио язып кала алды микән?

Әкият болай тәмамлана:

...Сез дә, бәлки, шулайдыр,
Яратамын борчакны:
Шуның аркасында бит
Дөнья күрдем ни чаклы.
Анысын, исән-сау калсам,
Туган илгә кайталсам,
Берәр язда, йә көздә
Сөйләрмен әле сезгә...»

Шигырь 1940 елны язылган, дидек. Әлеге саубуллашуда үзенең киләсе язмышын сизгән шикелле шагыйрь. Әйе, олы әдипләр иҗатында мондый алдан күрү —пәйгамбәрлек булгалый торган хәл.

Бер язда исән-сау кайтты шагыйрь, ә менә әкиятенә кире кайтмады, сөйләп бетермәде. Тыңлаган саен: дәвамын язсагыз иде! Ачкычы табылган бит, чын балаларча, яңа маҗараларны ялгап китүе дә җиңел, дип кыстый идем. Ризалашкан да кебек була иде дә, юк шул, языл-

мады әкиятнең дәвамы. Тормыштагы дәвамы артык кырыс, фаҗигале булуы комачаулагандыр.

Туфанның әлеге шигырьне укыганда: «Менә, мә, кара!» — дип сузган куллары күз алдында. Учларында тирән сызыклар пәрәвезе, әйтерсең лә бормалы-бормалы үткән авыр юллары. Ул юллар турында күрәзәчедән юратасы түгел, алар күз алдында — шигырь юлларында, шагыйрьнең җырларында.

## Кинорежиссер белән сөйләшү

Казанның бер балалар бакчасында кышкы салкын көндә җәйне сагынып микән, нәниләр сабантуе оештырганнар, кинога төшереп алачаклар икән. Ул чакта телевидениедә эшләгән Роберт Миңнуллин мине дә чакырды. Бергәләп без дә ихлас уеннарга чынлап торып катнашып киттек. Балалар белән таныштык, дуслашып алдык. Кайтырга чыккач та сүз шул хакта булды:

— Сабыйлар янында үзең дә алар кебек булып китәсең! — дибез.— Ихласлыкка көйләнәсең...

— Кино тасмасына да бик табигый төшәләр алар,— ди кинорежиссер,— риялана белмиләр. Хәсән Туфан кебек!.. Кайсыбер иптәш ничек кенә мәгънәлерәк күренергә тырышмасын, барыбер тасмадан чын йөзен яшерә алмый, чын үзәге-үзлеге ачыла. Яхшы кешеме ул, яманмы — үтәли күренә. Менә шундый гаҗәеп хикмәте бар кино тасмасының. Балалар да кешенең ихласлыгын шулай тиз тоеп ала.

Алайса, кино тасмасы да, галәмнән объективлар карап, җир асты байлыкларын ачык күргән сыман икән. Кешенең җаны йөзенә тирән язылганы күренәдер.

— Хәсән Туфанны төшергәнемне оныта алмыйм. Сабыйларча ихласлыгына, яктылыгына сокланган идем. Менә кем ул чын, саф кеше, дип торасың...

— Һиндстанда борын-борыннан изге кешенең баш тирәсендә нурланыш күргәннәр. Бәлкем шушы хикмәттер, яхшы күңеллелек нурланып чыгадыр...

Тормышның кырыс күзле объективы нинди елларда ничек кенә карамаган шагыйрьгә. Ми кайнарлык утлы чүлләрдә дә, себернең зәмһәрир суыкларында да, сыңар күзле шомлы камера «күзеннән» караганда да бер үк Кешене күргән ул!

## «Йөрәк әллә нишләде...»

Хәсән Туфан йөрәге авыртып больницага кергән, аны ашыгыч ярдәм машинасы алып киткән... Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, бергәләп, хәлен белергә бардык.

— Артык эшләп ташладым. Төнге дүртләрдә йөрәк әллә нишләде... Үземнеке шикелле түгел,— ди. Мондый чакта, әлбәттә, сакланырга кирәклек һәм режим хакында әйткән буласың. Белеп торасың инде, шагыйрь берни белән санашмый, сигез дистәне тутырып килсә дә йөрәге үз холкын оныта алмый, «үзенеке шикелле булмавы»н сәерсенеп әйтә. «Йөрәге тузган» дигәндер табиблар. Белгәннәр гаҗәпләнмәс — гасыр давылларын кичергән йөрәк ул!

Кызыл канәфер чәчәкләренә катнаштырып, ак ромашкалар китердек. Ул аларны йомшак кына итеп кулларына алып, сак кына күкрәгенә кысты. Авырткан йөрәгенә шифа булсын, ял булсын саф чәчәкләр...

Палата ишеге янында туктап, кул изәп озатып калды. Текәлеп карап калды. Сүзсез карашлар күңелгә күбрәк сөйли андый чакта.

Июль азагы иде бу. Көзен Туфанның 80 яше, иҗат бәйрәме. Камал театрында халыкның дәррәү аяк өстенә күтәрелеп, яраткан шагыйрен, легендар кешесен алкышлыйсы бар әле. Мондый бердәм рух, күңелләрдән ташыган ихлас мәхәббәтне бу бинада Сәйдәштән соң бүтән күрүче булмагандыр!

## Туфан каеннары

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр,
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавыннан асып киттеләр.
Асучылар киткәч сорый каен:
— Авыртмыймы муенын, Хәйбулла?
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла...

Шушы сүзләрне тетрәнеп дәрестә җырлаганыбыз истә. Класс белән күмәк җырлый идек, еш кабатлый идек. Авыл читендәге ак каен күз алдына килә, каен белән егет сөйләшүенең серенә төшенергә тырышам.

Хәсән Туфан шигърияте белән беренче очрашуым шушы булгандыр. Җырны көйләгән саен: «Ах, аз гына иелә алсачы каен — егет исән калыр иде!» — дип өметләнгәнем истә.

Шигырь 1933 елны язылган. Без аны дүрт-биш елдан соң җырлаганбыз. Фаҗигаләр ерак үткәннәрдә дип белгәнбез, ә урамда утыз җиденче ел каеннары саргайган...

Яфраклары коела ак каенның,
Яфраклары коела яшь кебек...—

дигән сүзләрнең шагыйрь язмышына да туры киләсен кем белсен? Бик күп еллардан соң очрашкач әлеге тәэсирләр турында үзенә дә әйттем. Ул чактагы нарасыйлар кичереше, җырның тәэсире турында ул күзләре дымланып тыңлады.

Шагыйрь исеме тынып калган елларда да моңланып күңелдә шаулады, телгә килеп күңелне көйләде «Ак каен». Гомер буе кабатлаганмын, ә менә җыр башындагы «килделәр», «киттеләр» дигән сәер рифмага игътибар итмәгәнмен. Беренче юлларыннан ук фаҗига бөтереп алган! Көйле тормышны дошманнар бозып киткәч, егетнең сулышы өзелгәч, ничек анда төзек рифма булсын ди...

Туфан иҗатында каен образы дип, тәнкыйтьчеләр кызыклы күзәтүләр белән фәнни хезмәт яза алырлар иде. Мин әле дә шагыйрьне каеннар арасында итеп күрәм. Замана җилләре кагылып кара тутлары арткан каеннар арасында аклыгын, пакьлеген җуймаган шагыйрь йөридер күк.

Казанның Аккош күленә якын төбәгендә бер урамга Хәсән Туфан исеме бирелгәч, урамның бер очыннан икенче очына кадәр күзәтеп әйләндем. Урам очындагы, сул яктагы йортка беркетелгән «37» саны нинди дер мәгънәгә ия, ишарә сыман тоелды. Агачлардан көзге яфраклар коела, миләшләр утлы күмердәй яна. Ә урам тимер юлга терәлгән җирдә, урамның уртасында колачларын җәеп ялгыз каен тора. Шагыйрь урамыннан китмәгез, дигәндәй басып тора ул. Шигырьләрендәге күп фаҗигаләр кичергән каен булып тоелды ул миңа. Җырдагы сыман сөйләшә торган каен дип карадым. «Исәнме, Хәсән абый каены!» — дип дәштем. Каендай ак такталарга шагыйрь исеме әле соңрак язылачак, исән чагында, мөгаен, үзе дә күрмәгән бу аулак, тын урам гаҗәеп якын, үз булып китте.

## Өмет йолдызы

Галлей кометасы турында элек тә укыганым бар иде. Сирәк була торган хәл, әле кайчан була ул дип, әкият кебегрәк итеп карый идем. Реаль җисем, үзебез күрү ихтималын әйткән кеше Хәсән Туфан булды. Комета 76 елга бер күренеп уза икән. Киләсе сәфәре 1986 елда дип, җае чыкканда әйтә килә иде:

— Мин аны бала чакта күрдем. Тагын әйләнеп килүен күрергә тиешмен! — дия иде кистереп. Ул елларга шактый ерак булса да, без дә куәтли идек,— бик ышандырып әйтә иде шул! Соңгы елларда алай ук дәртләнеп әйтми иде инде.

— Күрәсез әле, Хәсән абый, ул бит Тукайга 100 ел тулганда була! — дигәч, ризалашкандай, сабыр гына елмаеп ала да, тынып кала иде. Уе нинди булгандыр...

Хәсән атлы малай әлеге кометаны, үзебезчә әйтсәк, «койрыклы йолдыз»ны ун яшьтә күреп калган. Тукай әле исән, Тукайның әле өч ел гомере бар.

Тоткын елларда Туфанның кометаны кабат күрүгә өмете ирек «капусы» ачылуны көтү белән кушылгандыр. Бәлкем шушы эчке ышаныч исән-имин кайтырга ныклык биргәндер, киләчәкне күрергә тиешлек яшәткәндер аны, рухи көч өстәгәндер. Ә өмет йолдызы — шигърият булган аның, хаклыкка, халкына ышаныч.

Комета Җиргә якынлашканда бөтен дөнья шул хакта сөйләде, азрак сагаеп, күбрәк кызыксынып, мәңгелек галәм чиксезлегенә текәлде һәм уйга калды. Тукай елы иде ул безнең өчен. Тукай исеме дөнья дәрәҗәсендә яктырды. Галлей яңадан күренгәндә Тукай, Туфан исемнәре янәшә булды. Әдәбиятыбыз күгендә, халык күңелендә алар әйләнеп-әйләнеп, яңара-яңара яшәрләр.

Кометаны өйрәнүче галимнәребез триумфаль җиңүгә ирештеләр. Гасырларны уятып йөргән «койрыклы йолдыз»ны койрыгыннан тотып зәңгәр экраннан кешелеккә күрсәтүче академик Роальд Зиннур улы Сәгъдиев булды. Кометадан күкрәгенә Ватан бүләге — Алтын йолдыз куныл калды! Ул көннәрдә Туфан турында уйладым мин. Әй сөенер иде...

— Үзебезнең егет — Татарстан егете! — дияр иде.

Халыкның легендар уллары туа тора. Галлей кометасы 76 елдан кабат әйләнгәндә дә шигърияттә, төрле фән-

нәрдә, тормышта даннары йолдызларга җитәрлек атаклы уллары балкып күренер. Җиребез сау-имин булсын!

## Сурәте аша чор карый...

Сынчы Әнвәр Бәширов мемориаль такта өчен Хәсән Туфанның барельефын эшли икән. Рәис Даутов аның остаханәсендә булган. Инде әзердер дип, бергәләп карарга киттек. Барганда уйлыйм: скульпторы әллә ни таныш түгел, классик шагыйребезнең катлаулы язмышын, ай-һай, күрсәтеп бирә алыр микән? Турысын әйтми булмый инде. Бәхеткә каршы, Әнвәр ага үзе дә ихлас кеше булып чыкты, иҗаты да. Күңел күзе белән күрә белгән, җанын аңлаган шагыйрьнең. Сынмас рухын, тирән ихтыяр көчен, шул ук вакытта дөньяга ачынып-сызланып, моңланып каравын җиткерә алган. Гүя шагыйрь сурәте аша чорыбыз карый...

Мемориаль такта ачуга багышланган митингта сынчы оста сүзсез генә басып торды. Сүзен инде ул ташны җанландырып, сәнгать теле белән, гомергә җитәрлек итеп әйткән. Бер-бер артлы сүз алып, төрле буын әдипләре классик шагыйребезгә олы ихтирамнарын белдерделәр. Мин сүземне шагыйрьнең 1962 елның маенда Ялтадан җибәргән, әле басылмаган, җан әрнүе белән язылган шигыреннән өзек белән тәмамладым. «Коммунарга» дип аталган әсәрендәге ул юллар Хәсән Туфанның нәкъ үзенә төбәп әйтелгән сыман:

Истә синең
Якты гомернең
Текә таулы, кырыс юллары:
«Янчык»лар да сине, Коммунар,
«Сандык»лар да кызыктырмады.
Истә синең якты гомерең.

Йолдыз идең юллар өстендә,
Идеал идең, тирән мәгънәдә.
Маяк булып калдың безгә син
Һәм бездән соң килгәннәргә дә:
Йолдыз идең юллар өстендә.

Яктыртасың әле син һаман
Заманалар аша илемне,
Үзе инде сүнгән булса да
Нуры калган йолдыз шикелле,
Яктыртасың әле син һаман...

Соңгы сүз урынына

## «Туфан турында мифлар һәм чынбарлык»

Кибеттә бер китап күреп сискәнеп киттем: «Туфан турында мифлар һәм чынбарлык» диелгән! Бу ни хикмәт —Хәсән Туфан турында истәлекләрме? Аны әле Татарстан китап нәшрияты әзерли генә, китап 1989 елда чыгачак ич! Алып карасам — табигать күренешләренә багышланган. Шулай да исеме туры килеп тора.

Хәсән Туфан — легендар шәхес. Аңа багышланган шигырьләр үзе бер китаплык. Пьеса, роман язылып ята. Безнең бурыч — атаклы шагыйребез турындагы чынбарлыкны бүгенге укучыларга җиткерү, киләчәк өчен теркәп калдыру. Туфан турындагы чынбарлык — үзе легенда. Ышанам, әле күп кенә нәрсәләр ачылыр, табылыр, мәгълүм булыр. Киләчәктә аның тормышы белән кызыксынучылар тагын да артыр, шагыйрьгә бәйле һәр урын кадерле, изге булыр. Казандагы мемориаль такта куелган соңгы фатиры, Аккош күлендә шагыйрь яшәгән дачада эш бүлмәсе дә үзе исән чактагыча саклана. Әнә, өстәлендә соңгы тапкыр ачкан календаре, шкафта — китаплары, стенада мандолинасы. Бер очрашуда әйткән сүзләре искә төшә: «Кайтуга өмет юк иде... Минем үзем өчен язган җырларым бар — ноталары теркәлгән. Шуларны халык арасында җырлап йөрермен, фикерләремне җиткерермен дип уйлый идем...» Үзеннән соң, туган көнендә искә алып, бер төркем каләмдәшләр баргач, бу бүлмәдә булдык, мин мандолинага үрелдем. Кемдер ашыгып әйтте:

— Кагылмаска кирәк. Үзе уйнаганча торсын...

Кылларын чиртеп өлгергән идем, уңайсыз булды, үземне гаепле сиздем. Инде менә, шушы истәлек-уйлануларым белән дә кадерле кылларга кагылдым түгелме соң? Ә бәлкем мандолина да елга бер тапкыр, шагыйрь туган көндә телгә килергә тиештер? Күңелләрдә музасы һаман көчлерәк яңгыраганны белгертсен. Мандолина — булачак музей экспонаты. Туфан музее, шәхес культы елларында нахакка гомерләре өзелгән, авазлары тынып калган язучыларга багышланган музей да булыр әле. Булыр. Халык теләгән эшләр чынга аша торган мәгънәле вакыт хәзер. Илгә, халыкка хезмәт иткән тугрылыклы уллар истәлеге югалмас.

*Гыйнвар, 1988 ел.*
*Переделкино*

## Нәкый Исәнбәткә бару

**Егерменче гасыр — Туфан гасыры, Исәнбәт гасыры. Икесе дә 1900 елда туган. Нәкый абый — 10 гыйнварда, Хәсән абый — 9 декабрьдә. Милли әдәбиятыбызның данлы һәм фаҗигале гасыры, бөек шәхесләрен дөньяга күрсәткән дәвер. Әсәрләре белән бергә алар турында хатирәләр, фотолар, гадәти күренгән тормыш мизгелләре де югалмасын иде. Әлеге язмам 1971 елның 7 октябрендә теркәлгән.**

Мәскәүдә, СССР Язучылар союзында эшләүче Хава Галиевна Хөсәенова, съездда күрешкәч, Нәкый абыйга әманәт тапшыруымны үтенде. Казанга кайтып, шул йомыш белән барырга җыенганымны әйткәч, Хәсән абый Туфан елмаеп:

— Мине дә алып барасыңмы? — диде.

Шатландым:

— Бик әйбәт! Әйдәгез, киттек.

Хәзер үк булмас шул. Бүген булмас әле... дип икеләнә калды.— Суза башлагач булмый ул, әйдәгез, барып кайтыйк.

Машина чакырдык та киттек. Аягым авыртып тора дип, Әмирхан абый Еники дә утырды. Нәкый абыйларга аны да чакырдым.

— Бүлмәсе бәләкәй, өч кеше сыярлык түгел,— ди.

— Хәзер классикларда бер бүлмә модада шул,— дим, Хәсән абыйга карабрак. Елмая. Без Р.Зорге урамына килеп төштек. Йортын эзләп таптык.

Бер рус карчыгы:

— Вы к писателю? — дип, подъездын күрсәтте.— Хатыны кибеткә китте бугай, өендә микән?

Шылтыраттык. Җавап бирмиләр.

— Звонoклары йомшак икән,— дип Хәсән абый эндәшеп тә карады. Җавап юк. Хатынын каршыларга урамга чыктык. Кайтып та килә. Шунда гына белдем — Нәҗибә апа Хәсән абыйның кодачасы икән.

— Горчичник куеп чыгып киткән идем,— ди.— 15 — 20 минут сиздермичә генә көтеп торыгыз.

Урамда йөреп керергә булдык. Салкынча. Колакларны чеметә. Мин артыгы белән җылы киенгәнмен. Хәсән абый плащтан, яланбаш.

— Салкын тияр бит, сакланырга кирәк иде.

— Кышка җылыга күнегеп керергә ярамый. Әкренләп чыныга барырга кирәк.

Хәсән абый куен сәгатен алып карый, вакытны чамалап куюы.

— Синең күпме? — ди.

— Алтынчы дүрт минут.

— Минем өч кенә. Туктаган икән.

— Әле Нәҗибә апага сәгать биш дидегез бит?

Ялгышып дөресен әйткән булып чыкты...

Әдип язмышы турында булып алды сүз. Дан шаушуыннан өстен булырга тиешлеге. Халыкның тануы, халык мәхәббәте таяныч булу.

Казакъстанга язучылар съездына баруын искә алды. Зурлап каршылаганнар. Алкышлап, хуплап тыңлаганнар. Бүтән делегацияләргә караганда бик җылы булган мөнәсәбәт. Кунаев килеп кулын кыскан. Бу олылауны күреп: «Ул бит политбюро члены!» — дип сөенеп әйткәннәр Хәсән абыйның укучылары.

Кибеттән «Чапахи» дигән коры шәраб алып чыктым. Хәсән абый белән киңәшкәннән соң, билгеле.

Ишекне матурланып-ясаныбрак өлгергән Нәҗибә апа ачты. Нәкый абый килеп каршылады. Бер бүлмәдә өчәү торалар икән. Нәҗибә апаның кызы да («Баштарак төрле сүзләр ишеттергәннәр иде дә, хәзер әйбәт торабыз»).

Каршы як диварны тутырып стеллаж тора, Нәҗибә апа үз чертежлары белән эшләткән булган. Подписной изданиеләр. Мин Нәкый абыйның байлыкларын — борынгы китапларны эзләп текәләм.

— Болар Нәҗибәнеке. Минем теге фатирда.

Өстәлендә «Альпинист» радиоалгычы. Ике ингалятор. Дәфтәр бите хәтле берничә кәгазь.

— Менә, яңа гына мичтән чыккан, тыңлап карагыз әле.

Нәкый абый Г. Чыгтай турында яза башлаган мәкаләсен укый. «Чыгтай кем ул?» дигән урынга хәтле язган. Гарәп хәрефләре белән. Чыгтайны без Тукай эпиграммалары аркылы гына беләбез. Хәсән абый искә төшерә:

— Аның белән килешмичә, бәхәсләшеп, ачудан китапның читләренә яза-яза укыганым хәтердә. Әмма тора да искә төшә бит сүзләре.

Шуның тәэсире булгандыр — революциягә кадәр ук, унбишенче елларда ук...

Мондый чакта сүзнең бер-берсенә ничек бәйләнеп киткәнен кем абайлап өлгергән. Эзлеклелек булмас, кайберләрен языйм.

— Сәйфи (Кудаш) авырып киткән икән, син сәламәт кеше, барып кайтыр идең, Туфан. Мин йөри алмыйм инде.

— Без Гомәр белән (Бәширов) сөйләшкән идек тә бер.

— Төшенкелеккә бирелгән, ди. Ярамый, күңелен күтәреп җибәрергә кирәк.

— Инкогнито барып кына, үзенә туры төшсәң инде? Киткәндә генә сиздереп? — ди Хәсән абый уенын-чынын кушып. Кунакчыллыгын белә уфаларның! — Иртәгә үк хат язарга кирәк.

— Ул бит ялгыз,— ди Нәкый абый.— Хатыны да инфаркт белән ята.

Өлкәннәр ничек бер-берсен кайгырталар, дип уйлап куям. Өлкән кешенең ялгызлыгын уйлыйсың, төшенәсең. Япь-яшь ялгызлар да булгалый, хәер.

— Хәле авыр диләр...— Нәкый абый тагын бер кат басым ясап әйтеп куя. Аннары, телевизорга күрсәтеп:

— Наҗар Нәҗми Пушкин бәйрәмендә бик кызык чыгыш ясады. Сөйләде, шигырь дә укыды... Пушкинның гарәп нәселеннән икәнен әйтеп, Нәкый абый чәен капкалап ала. Ингаляторны да кыскалап куя. Ак сакал тибеп чыккан. Бумаҗи күлмәк өстендә тагын бер җылы кием.

— Афзал (Шамов) синең режим нинди, ди, режим белән яшәргә куша. Иртән ике сәгать йөреп кер, ике сәгать ярым эшләсәң, җиткән. Син бит инде хәзер җитмешнең югары ягында. Тагын дүрт сәгать йөреп әйлән. Төштән соң тагын дүрт сәгать, ди. (Көлә.) Эшлим мин, эшлим, сәгать санамыйм.

— Әнә Ибрай Гази гомер буе режим белән яшәде. Сәламәт көе. Алдагысын күздә тотып. Инфаркт екты барыбер...

Нәҗибә апа табын әзерли. Миләш вареньесы, гөмбә, помидор. Диетик винегрет — сугансыз. Итле бәрәңге пешереп китерде.

— Тавил Хаҗиәхмәтов сезнең күршедә яши. Аны беләсезме, Нәкый абый?

— «Ялкын»да бик әйбәт рәсеме чыккан әле. (Журналны табып китерәләр.) Кайсыннан канәгать түгеллеге сизелә. Һәммәсен дә Тавил эшләмәгәнен әйткәч, җиңел сулап куя:

— Бер дә ошамаганнары бар иде шул.

— Тукай премиясенә тәкъдим итәргә кирәк ул егетне! — ди Нәкый абый, Тавил турында. Үзенең балалар өчен язылган күп кенә әсәрләре булуын әйтә.

— Нәшриятта теге Шамил дигән егет бәлкем әйбәт егеттер ул — астан гына карый. Бишьеллык план төзелде инде, ди. Минем балалар өчен язылган пьесаларым бар. Үз кулым белән төзеп, биреп калдырасым килә. Без бит инде картлар! «Балалар фольклоры»н да сигез ел йөрткәннәр иде...

— Җыеп, туплап китерегез, балалар секциясе дә булышыр,— дидек.

Нәкый абый архивта эшләгәндә быел Хәсән абыйның бер шигырен очратуын сөйли. Соңгы җыентыкларында чыкмаган икән. Утызынчы еллар башындагысында бар, ди. Беренче тапкыр 1927 елда хәзерге «Социалистик Татарстан» гәзитендә басылган.

— Кайчан томнарыңны әзерләп бирәсең инде, Хәсән?

— Газета-журналларның тиражлары бик зур. Күп укучылар укый бит. Мине язасылары кызыксындыра! Күп бит, бик күп язасы килгән шигырьләр! Ә булганын аның җыеп та чыгара алалар.

— Алай түгел, үз кулың белән әзерләп бирергә кирәк!

— Яңадан карыйсылары да бардыр шул. Рәхмәт җылы сүзегезгә... Аңарчы минем лирик шигырьләр генә туплап чыгарасым килә! Әнә Лермонтовның да шундый китабы бар. Җилкән турындагы шигырен дә кертмәгән хәтта.

Мондый китапны бик күрергә теләп, канатланып сөйли Хәсән абый.

Тәмәке тартырга мин аны озата чыгам. Берничә суыра да, тартмага салып куя папиросны. Организмны алдавы!

— Син тартынма, сора Нәкый абыеңнан кызыксынган нәрсәләреңне. Өлкән кеше. Белеп булмый...

Нәкый абый без килгәнгә бик сөенде:

— Телефон да юк, бернәрсә белмичә яшим. Баргалар идем. Соңыннан гына ишетәм. Идрис Туктарга да 75 тулган икән.

Комачаулаукбыз, эшеннән аерырбыз, дип тартынасың. Ә аңа, кешеләр тансык, аралашу кирәк икән. Сәгать алтыдан төнге унбергә хәтле утырдык. Арыганын да сиз-

дермәде. Утырыгыз әле, утырыгыз, ди, ихлас җибәрәсе килми.

Нәкый абый соңгы вакытта шактый сәфәрләрдә булган.

— Авыру йөртте! — ди шаяртып.

Кая барса, шунда архивка чума икән. Климат килешкән урында озаграк тора.

— Мин бит мәдәният тарихы белән дә кызыксынам. Әдәбият турында язганда шунсыз булмый. Хивадагы манараларда безнең сөлгеләр орнаментын күрдем. Менә кайлардан килә икән!

Әле егерме җиденче елда пароходта сәфәрне искә төшерәләр. Болгарда да булганнар. Элегрәк анда сөякләр өем-өем торган. Алып китеп селитра ясаганнар патша вакытында.

Болгарның, дәүләт булгач, дәүләт документлары кайдадыр калган булырга тиеш. Имеш, Иван Грозный Мәскәүгә алып киткән. Мәскәүне поляклар алгач, алар үзләренә талап киткәннәр. Алардан Ватиканга эләккән, дигән гипотеза бар икән. Кем белсен.

Хәсән абый бер уе белән уртаклаша:

— Мин гомер буе халык җырлары җыеп килдем. Шуларның иң әйбәтләрен генә җыеп чыгарасым килә. Юк, «Халык җырлый»дагы ишеләрне түгел!

Нәкый абый хуплый:

— Бик әйбәт булыр. Минем үземдә дә күп алар. Аларны мин кайта-кайта өйрәнәм. Комментарийларың белән чыгар син аларны.

Төрле жанрларда эшләү кирәклеге турында сүз чыкты:

— Син, Хәсән, пьеса яз, ник язмыйсың?

— Проза язам әле мин.

— Ә син балалар өчен пьесалар яз! (Бусы миңа.) Төрле жанрларда эшләү кирәк. Минем баштан кичте инде... Берсендә юл бикләнгәндә икенчесен эшләп торасың.

Нәкый абый «Чаян»да чыккан «Сәер кеше» дигән шигыреңне ошаттым, диде. Укып бара икән. Күңелне күтәреп җибәрүедер...

6 октябрь иде бу, 1971 ел.

*Октябрь, 1971*

## «Хәким бар!»

### Рухи бөеклек

Халык күңеленә, рухына тәңгәл килгән әдипләр күп булмый. Аларны халык үзе сайлап ала. Ул иҗат итеп яшәгән четерекле дәверләрдә кемнәр генә телгә кереп, телдән төшмәгән. Сибгат Хәким исә һәрвакыт үз урынында. Шагыйрь язмышы гыйбрәтле. Ул беркайчан да вакланмады. Тукай, халык язмышы — гомер буе шушы биеклектә булды, рухи дәрәҗәсе шул югарылыкта булды.

Безне шигърияткә Тукай китергән, Тукай очраштырган, җан берлегебез дә Тукайда. С.Хәкимне дә мин Тукай белән хәтерлим. Тукайга багышланган поэмаларын ярты гасыр элек китапханәдән алып укуым күз алдымда. Тәэсирләрем дә истә.

Тукайга якын — күңелгә якын! Аны олылау, халык рухы белән бер итеп күрү С.Хәкимнең иҗатында гомере буе яңара торды. Тукай дип кабатласа да, шигъриятендә кабатланмады. Татар күңелендә Тукаена мәхәббәтне яңартып торган иң тугрылыклы шагыйрь ул. Бу аның рухи халәте, яшәү мәгънәсе, илһамы-януы, иманы иде.

Исемнәрен телгә дә алырга ярамаган Җәлилсез, Туфансыз чорларда Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзиләр Тукай-Байракны шигъриятебез символы итеп югары тотты. Чордаш, каләмдәш дуслары «онытылудан» кайта башлагач, Сибгат абый аларга киң күңелле булды — Җәлил, Туфан дип олылап күтәрде! Кирәк өчен генә түгел, яратып, җаны-тәне белән үз итеп, әдәбият даны итеп күтәрде. С.Хәкимнең олылыгы да шунда.

Татар поэзиясенең югары дәрәҗәсен кайгыртты. Әйе, аны борчыган, җанына тигән нәрсәләр аз түгел иде. Ачынып, кайчакта нәфрәтләнеп сөйләр, әмма төп бәясен югалтмас иде. «Үзем!» дип, кайберәүләр сыман бүтәннәрне төшерү хисабына күтәрелүне түбәнлек санады. Шигърият аңа — намус, вөҗдан эше, халык рухына гасырлардан килгән мираска тугрылык. Хәзер кайбер бәя бирүчеләр шагыйрь иҗатында тапларны күбрәк күрергә тырышалар. Шигърият — яктылык ул, яктысын күрә белик, яктылык кирәк күңелләргә!

Галәм тормышында «кара упкын» дигән төшенчә бар. Ул хәтта кояш нурын да тартып ала, йота, кире кайтар-

мый икән. Бу хәлне галәм дәрәҗәсендәге эгоизм, комсызлык билгесе дип атарга мөмкин. Бәхеткә каршы, кояш — юмарт! Әлеге ярты гасыр эчендә поэзия язмышын хәл итү бүтәннәр ихтыярында түгел, Тукай рухын саклаган, үстергән Хәкимнәрдә иде. Юкса бик күпләр язмышы, әдәбиятыбыз хәле дә үзгәрәк булыр иде.

Шагыйрь аралашуда, көнкүрештә дә вакланмады. Тумышы белән авылдан, балта остасы малае, әмма затлылык, зыялылык хас иде аңа. Чөнки табигате шундый иде, миссиясе таләп иткән җаваплылык дәрәҗәсе шулай куша иде. Кырык елга якын аралашып, серләр уртаклашып, бер-беребезгә ышанып, үз булып яшәсәк тә, «Сез» дип эндәшүдән түбән төшмәдек. Төрле мәҗлесләр, ял вакытларында шаярып сөйләгән чакларда ул ачылып китә, шаян сүзне тансыклаган була. Алай да ул барында шаяртуның чиген белеп, чамадан ашмыйлар. Саф, чиста авыл өенә пычрак итек белән кермисең шул.

Тышкы һәм эчке пөхтәлек хас иде аңа. Бер тапкыр шулай аккош күлендә дачада яшәгәндә, таушалганрак пижамадан күргәч, игътибар иткәнебез истә. Үзебез дә бакчада шулай йөрибез. Әмма Сибгат аганың эчке сафлыгына ятышмый сыман. Бәлкем, ул язу өстәле яныннан торып чыккандыр. Әйткән сүзе хәтердә:

— Язарга җыенганда мин бүлмәдән артык әйберләрне сөреп чыгарам, иләнгәннәрен генә калдырам,— дигән иде.— Тәнгә ятып торган, күнегелгән киемнәр киям. Шунсыз эшләп булмый. Дан да, купшы кием кебек, эшләргә комачаулый. Ишетмәскә, аңа бирелмәскә кирәк.

Ничә буын яшьләрне С. Хәкимнең кай ягы тартты икән? Әнә шул җан пакьлегедер. Шигърият тә сафлык таләп итә, рухи гамәлләр тирәсендә саф күңелле булырга кирәк.

Яңа бистәдә татар зиратына кергәч тә, Хәсән Туфанның ак мәрмәр һәйкәленә якын ук Сибгат Хәким табутын җиргә куйдык. Шигърияттәге кебек, мәңгелек урыннары да янәшә туры килде. Тагын бер охшашлык: табуттагы Туфан сыман, ул да тере чактагыдай пакь. Шул тойгы кайгыны бераз оныттыра. Җиргә күпме сафлык, яктылык биреп калдырган ул, Җир куенына күпме чисталык алып китә.

Әти-әнине югалткач, аптырап-гаҗизләнеп каласың: ай-кояштай мәңге яшәрләр кебек иде. Сибгат абыйдан

аерылу да кинәт булды. Әти белән чагыштыру арттыру түгел, без сугыш ятимнәрен әдәбиятка сыендырган якын кешебез иде ул. Кайгысын уртаклашканда Мөршидә ханымның:

— Әтисез калдыгыз...— дигән сүзләре үзәкне өзеп алды. Яшәвебез аерылгысыз булган — истәлек язарга туры килер дип кем уйлаган?! Безнең беренче һәм соңгы очрашулар арасында кырык елга якын ара бар. Әдәбият казанында бергә кайнаганбыз, тормышның кайсы өлешен аерып алырга да белмисең. Бу әле уйлану чорыдыр, уртак яшәешнең мәгънәсенә төшенергә теләү чорыдыр.

*

Язның төсләре ачык, яшьлектә хисләр җитә. Шигъри яшьлегебез язындагы уй-тойгыларның хыялый сафлыгын хәтерлим. Әдәбиятка мәхәббәт җанга якын әдипләрдән башлана. Аларны сихри балкышлар уртасында күрәсең. Фаҗигале, кырыс еллар — сугыш еллары иде. Илаһи илһам, ирешмәстәй ерак максатка омтылу булып, киләчәк могҗизасына ымсындырып, җан-рухны саклап калгандыр.

Һай, ул төсләрнең, хисләрнең җете-яшь чагы: шигырьне изге сүз итеп тетрәнеп укыган заманнар. Тәэсирләремне күңелдә яңартырга яратам, шул халәтемне сагынам. Шигъри сүз нинди кадерле булган. Һәр буынның шигъри яшьлегенә туры килгән, сокланган замандаш әдипләре бар. Тукай, Такташларны әйтмим, алар бар буыннарга уртак, аларны изгеләштереп карыйсың. Ә менә замандашлар арасыннан тәэсире, йогынтысына үтә бирелеп, ияреп яза башлаганнары була.

Фронтовик шагыйрьләрнең адресы «Хәрәкәттәге армия» дип куелган шигырьләрен эткәйдән көткән хаттай күреп укыйм. Алар да ут эченнән килгән, өметсагышлары гаҗәп якын. Ф.Кәрим, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, С.Хәким, Ш.Маннур, Г.Хуҗи, Ш.Мөдәррис шигырьләре... Җан тарта икән, рухи уртаклык, гашыйклар күңеле шикелле, бер-берсен таба, әдип белән укучы бәйләнешы, күңел җепләре дә шулай ялганып, гомергә каладыр. Саргылт кәгазьле «Совет әдәбияты» журналы үзе дә, ут эчендә өтелеп, окоптагы шагыйрьләр кулыннан килгән шикелле. Бәлкем, шул өзелгән шигъри җепләр, безнең күңелләргә ялганып, дәвам эзләгәндер.

*

Казанга килгән чакларда Бауман урамындагы атаклы матбугат йорты аеруча хикмәтле тоела иде. Хыял омтылган урын — язучыларның Тукай исемендәге клубы шунда бит. 1948 елның декабрендә яшь язучыларның Беренче республика конференциясе дә шунда булды. Катнашучыларның кайберсе хәрби гимнастеркасын да салып өлгермәгән. Әдәби консультация бюросына килгән шигырьләр арасыннан минекен дә күреп алганнар. Беренче шигырьләремне шул чакта «Совет әдәбияты»нда чыгаручы да С.Хәким булган. Аның да демобилизацияләнеп кайтуына икенче генә ел. Әле үзен күреп белмим. Язучылар союзы председателе К.Нәҗмине күрдем. Аның секретаре Салих Вәлиди, китель өстеннән киң каеш буган көләч, шаян сүзле, җитез хәрәкәтле, уйнап кына эшли, җитешмәгән җире юк. Сокланмый, яратмый мөмкин түгел.

— Әйдә, Сибгат Хәким белән таныштырам, ул яшьләргә ярдәмчел,— дип Нур Шәриф чакыргач, яраткан шагыйремне дә шул Вәлиди кебегрәктер дип күз алдыма китердем. Икенче каттагы бер ишекне ачты Нурулла. Караңгырак бер бүлмә. Түрдәрәк, зур өстәл артыннан чак кына калкып, агайдан бигрәк малайга тартым бераү утыра. Шагыйрь чыгып киткәндер дисәм, С.Хәким шул үзе икән. Нур мине әйтеп таныштырды. Сүзсез генә кулын сузды Сибгат ага:

— Шигырьләреңне җибәреп тор,— диде шактый көттереп кенә. Шуның белән сүз бетте. Коридорга чыккач, Нурулла: — Менә үзең элемтәдә тор инде моннан соң,— диде. Яшьләрне, ай-һай, ярата микән бу сүзсез агай дип, икеләнебрәк, эчтән тындым. Әдәби язмышымда нинди канат буласын әйтсәләр, ул чакта ышанып та бетә алмас идем. Яңа шигырьләремне укып, киңәшләрен районга язып торды; сайлап матбугатка бирә килде. Беренче китабымны да үзе төзеп, нәшрият планына кертте, редакторы булды.

— Иң әйбәтләре белән күренергә кирәк. Ашыкма,— дип, дистәләгән шигырьләрдән бик азын — ярты табак кына сайлап алды. Шул иде аның «танышлык белән» эшләве — үтә таләпчәнлек. Чыннан да, уч төбедәй «яңа көйләр» исемле китапчыкны Ә.Фәйзи күреп алды, хуплады.

Беренче очрашуыбыз турында шактый еллардан соң, Сибгат абыйның үзенә дә кызык итебрәк сөйләдем. Әмма ирен чите белән дә елмаймады. Рәнҗеттемме әллә? Безнең тел тик тормый инде дип, үкенеп тә алдым. Күңелсез чорын яңартканмын шул. Хатыны Мөршидә апа әйткән: «Хәле авыр. Сугышка киткәндә 75 килограмм иде, хәзер 45...» — дигән еллары булган. Бәхеткә каршы, кешенең рухы «кг» белән үлчәнми. С.Хәкимнең рухы нык, көчле булган, сугыштан кайткач тагын бер үлемне җиңгән ул, үзен генә түгел, сугыштан соңгы беренче буын яшьләрне туплаган, әдәбиятка хезмәткә күтәргән.

## Остаз сабаклары

Ул чакта Сибгат абый Тукай урамындагы фатирында яши иде. 1949 елда командировкага килгәч шунда булдым. Аннан соң кырык ел үткән. Бүген нәрсә хәтердә соң?

Авыл кешесенә шәһәр болай да яңа-ят дөнья, өстәвенә, син әле шагыйрь өендә. Сибгат абый аз сүзле. Ул үзе уйлана, кичерә, шул халәт аңа дәшми торуын сиздермидер дә. Минем уңайсызлануым тагын да арта.

Мөршидә апа манный боткасы пешергән иде. Сибгат абыйның бик тә режим саклаганын ишетеп беләм. Соңыннан шуңа инандым: түземлек, тыела белүе белән гомерен озайтты ул. Әлбәттә, хатыны Мөршидә апаның шәфкать туташы булуы да хәлен җиңеләйткәндер. С.Хәкимнең иҗаты һәрвакыт беренче планда, какшамас тәртип, аны бозарга беркем базмый. Мөршидә апа шушы «Сибгат эшли» культын бик катгый саклый. Яшьлегендә үзе дә шигырь язган шул, иҗатның ни икәнен белә. Яшерен-батырын түгел, кайбер фронтовик шагыйрьләргә С.Хәкимдәге характер ныклыгы җитмәде, талантлы ул шәхесләр, һичшиксез, ачылыр иде әле. Ул чордагы җәмгыять тормышы күңел тупигына китереп, кайсы кемне шешәгә терәвен дә аңлыйсың. Тик шулай да, шулай да. Малеевка иҗат йортында Мостай Кәрим әйткән сүзләр хәтергә килә: «Кешегә талантны табигать бирә, ә менә шәхесен үзе тудырырга тиеш»,— дигән иде ул.

Бу урында мин ерак киләчәккә — С.Хәкимнең 60 яше тулган көннәргә күчеп алмакчы булам. 1971 елның азагы иде. Арча педагогия училищесыннан кайтып киләбез.

— Сибгат абый, кайчан гына илле яшегезне үткәргән идек. Сезгә дә тиз үткәндәй тоелдымы?

— Шул ике арада эшләгән эшләрне уйламасаң, вакыт узганы сизелмәгән дә кебек. Эшләрең — шул еллар билгесе...

Сүз режимлы яшәүгә күчкәч, әйтеп куйдым:

— Фронттан кайткач яшәвегез — үзегезнең җиңү. Шундый төгәл режимга һәркемнең сабырлыгы җитмәс иде.

— Әйе, сәламәтлек кирәк. Шунсыз эшли дә алмыйсың. Соңгы елларда язылган әсәрләремне бетерә алмам дип куркып яшәдем...

Сибгат абый белән әңгәмәне соңыннан сөйләп бирүе читен икән. Ымлап баш кагуы, елмаеп куюы, күз карашы еш кына сүзләрен алыштыра. Син сөйлисең, ул исә сүзсез генә сүзгә кушылып бара. Хуплавын, йә ризасызлыгын шуннан сизәсең.

Тукай урамындагы ул йортта шигъри сүзнең табигыйлеге, халыкчанлык хакында сөйләгәндә Сибгат абыйның бер мисалы истә:

— Авыл агае беркайчан да «тырышып эшли», «нормасын арттырып үти», «биш»ле билгеләренә укый», дип әйтми, бер сүз белән «булдыра» дип кенә куя...— дигән иде. Купшы сүз хөкем сөргән заманда шаукымга бирелмәскә, халык иҗатыннан, рухыннан аерылма дип искәрткән шагыйрь. Ул чакта район газетасында эшлим, анда әзер әйләнмәләр, ялган пафос, буш оптимизм сагалап тора. С.Хәким сабагы бик вакытлы булган. Шигырьләрнең берәрсенә «булдыргансың» кебегрәк ишарә эләксә, безгә зур бәя булып яңгырый иде.

Тукай урамындагы ул йорт шагыйрь тормышында онытылмас бер хатирә булган икән. Мин моны соңрак белдем. «Минем сугыш алдындагы туйда» исемле шигырендә Сибгат ага шул хакта язды. Анда Җәлил, Туфан, Кутуйлар табындаш булган. Әле ун ел гына узган. Истәлекле өстәлдә миңа да иртәнге чәй насыйп икән.

Тукайда очрашканбыз. Шагыйрьнең нәкъ менә шушы урамда яшәве язмыш ишарәсе булгандыр. Фатирларын алыштырса да, гомере буе Тукайдан китмәде ул.

*

1950 елның мартында, миңа, Кайбыч район газетасы адресына, С.Хәкимнең «Дуслык турында поэма» исемле яңа китабы килеп төште. Сөенеп, рәхмәт әйтеп җавап

яздым, күчермәсе әле дә саклана. Эпиграфым Сибгат абыйның Тукайга багышланган шигыреннән: «Булды ул иҗат юлымда иң якын күргән абый...»

Без аның беренче шәкертләре идек. «Дүрт шагыйрь» дип, зур мәкалә дә язып чыкты. Шуннан соң И.Юзеев, Х.Камалов һәм мин остазыбыз белән фотога да төшкән идек. 1958 елның июнендә булды бу. Баштарак Сибгат абый тәэсирендә, аның «музыкасына» ияреп язылган шигырьләрем дә булды. Әмма бу вакытлы хәл иде, шагыйрь үпкәсен белдермәде. Һәркем иҗатында үзенчәлек күреп, хуплый торды. Әнә бит ничек төрлебез төрлечә язып киткәнбез. Инде әдәби «балигъ» булгач та без аның кайгыртуын, «Пушкин бар!» дигән шигырендәгечә, «Хәким бар!» дип, таләпләрен тоеп яшәдек. Кешеләрне таслый, торган әдәби тормышта бергә гомер үтсә дә, беренче автографлы китапка җавап юлларын әле дә кабатлый алам: «Булды ул иҗат юлымда иң якын күргән абый».

Яңа шигырь язгач, мактау көткән бала шикелле, Сибгат абыйга укытасы килә иде. Сөенеч тою өчен дәртләнеп эшлисең, аның бәясе, хәзергечә әйтсәк, «госприемка» үтү: кайсы матбугатка барсаң да, кызармаслык дигән сүз... 1957 елның сентябрь башында лирик, юмористик парчалар язып Сибгат Хәкимгә бирдем. Юморда кыскалыкны хуплады, лирикада тукталып калды.

— Һәр фикернең үз чамасы бар. Ник аны сигез юлга кысрыкларга? Менә монысын болай гына әрәм итмә, иркенрәк язып кара,— дип, сугышта һәлак булган әткәй турындагы сигезьюллыкны күрсәтте. Бу очрашудан үземне бурычлы тоеп киттем. Булдыра алганымны раслыйсым килде. Кавказга санаторийга җыена иде Сибгат абый, ул кайтканчы «Әткәйгә хат» поэмасын яздым. Теге парчадан канәгать булса яки дәшми уздырса, бәлкем, әсәр язылмый да калыр иде. Шул ук елның декабрендә С.Хәким СССР Язучылар союзына рекомендациясен: «...соңгы вакытта язып бетергән «Әткәйгә хат» исемле әсәре лирикасының ачыла баруын күрсәтә»,— дигән сүзләр белән башлады.

Поэманың тууына Сибгат абый үзенең «Югалган эзләр» шигыре белән дә тәэсир иткән иде. 1939 елны язылган ул, ачлык елларда югалган балта остасы — этисенә багышланган. Уртак сагыш, уртак язмышлы әткәйләр икесе дә Украина җирендә хәбәрсез югалган. Күптән күңелдә йөргән әсәрнең моңын табарга «югалган эзләр» дә булышты дип, шагыйрьнең үзенә дә әйткәнем булды.

Икенче бер мисал. Бусы 1958 елның языннан. Алексеевск районында, үзләренчә матур итеп әйткәндә — Аләскәйдә укучылар белән очрашудан дистәгә якын шигырь язып кайткач, ашкынып Сибгат абыйга бирдем. Беленер-беленмәс тамгалар салган, карандаш белән кыеклап язган бер җөмлә: «Менә дигән җырлар чыга синнән!» Әле дә саклыйм. «Тамчылар тамар чаклар», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Утыр әле яннарыма» кебек шигырьләр иде анда. Остазның җыр югарылыгы белән бәяләве сүзгә, моңга игътибарлырак булырга өйрәтте.

*

Кешеләргә ярдәмчел булу — талант, юмартлык. С Хәким юмарт булды, җырларын халыкка өләште, рәхәтен күрегез,кинәнегез! Сөенерсез дә, әрнерсез дә — гамьсез генә булмассыз. Еллар үткән саен хискә байый, тормыш фәлсәфәсе тирәнәя барган борчулы, уйчан шигырьләре, поэмалары...

Шагыйрь әдәби алмашка ярдәмгә юмарт булды, әдәбият чикләрен үтеп жырчылар, композиторлар, сәнгатьнең барлык өлкәләрен кайгыртып, күз уңыннан төшермәде. Ни өчен вакытын, кәефен сарыф итә-итә бар тармакны колачларга тырышкан ул? Җавапның берсе шулдыр: аның күз алдында, утызынчы еллар азагыннан башлап, Ватан сугышы чорында дәвам итеп, әле соңыннан да милли мәдәниятебезгә хезмәт итүче күпме фидакарьләр кырылган. Тормыш бушлыкны кичерми, бушлык халык күңеленә күчмәсен, алмашка яңа буыннарны — яңа яшьләрне үстерү кирәк, дигән. Әлбәттә, мондый уй аны гына борчымагандыр. Җаваплылыкны үз өстенә мәшәкатьле эш итеп алучылар сирәгрәк. С.Хәкимнең исә ул иҗатыдай җан тарткан вазифасы иде. Бик күпләргә ярдәм кулы ссузды. Таләпчән иде, талантларны күрә килде. Киң күңеллелеген файдаланучы әрсезләр дә булмады түгел. Тик алар бер нәрсәне оныты: шагыйрь сүзен акларлык итеп яшәргә, иҗат итәргә кирәк — шуңа омтылганда гына үсә кеше. Остаз әнә шул омтылышка стимул тудыра: үс, күтәрел, миннән фатиха, ди. Күренсен сәләте, тырышсын. Һәркем үзенчә ачылырга мөмкин, бәлкем әдәбиятка өлеше булыр? Син инде үзең кара, кайсын сайлыйсың: зур таләпле кыен юлнымы, әллә түбәнрәк планка куеп, тәбәнәк «биеклек»неме?!

Әйе, күпләребез С.Хәкимгә бурычлы, өметле яшьләргә ярдәм рәвешендә генә кайтара алабыз. Милләт үзенең халәтен яңа ул-кызларының вөҗданы, намусы, уйлануы, тынгысызлыгы аша әйтеп яшәргә тиеш...

1958 елда куен дәфтәремә шундый сүзләр теркәп куйганмын:

«Сибгат абый: «Поэзиянең, шагыйрьләрнең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк!» — ди. Үз йортын кайгырткан крәстиян кебек инде, валлаһи!» Өлкән шагыйребез шигърият абруена күп эшләде, иҗаты белән дә, әдәби-публицистик мәкаләләре белән дә. Әйе, поэзия — үз йорты иде, шагыйрьләрне үз балаларыдай күрде. Аяз Гыйләҗевнең: «Прозада, драматургиядә С.Хәким кебек остазыбыз юк шул...» —дип кызыгып та, ачынып та әйтүе бик аңлашыла.

Поэзия абруе турында бүген дә сүзләр куера тора. Моны онытучылар, ата малын бүлешә алмаган әрсезләр сыман поэзиягә, аның классикларына тентү ясап, үз дәрәҗәләрен дә төшерүләрен уйламый микән?

### Әрнүләре-янулары

1959 елның маенда безне СССР язучыларының III съездына делегат итеп сайладылар: М.Әмир, Г.Бәширов, С.Хәким, А.Шамов, Р.Ишморат, З.Нури... «Татарстан яшьләре» газетасы фотографы Җәүдәт Акчурин Тукай клубы балконында фоторәсемгә төшереп алды: иң алда Сибгат абый, биектән Бауман урамына караган. Рәсем газетада чыкты, шунда ук Сибгат абыйның ун еллык иҗатыма күзәтү, йомгак итеп язылган «Өметләр һәм теләкләр» исемле мәкаләсе. «Киләчәктә, бәлкем, иҗатының бөтенләй икенче яклары ачыла төшәр», дигән. Әлеге съездда мин делегатлар арасында иң яше — алдагы язда СССР Язучылар союзына алынган идем. Иң беренче рекомендацияне С.Хәким язды.

Съездга барабыз. Поездда кич йокларга урын-җир әзерләр вакыт җитте. Купеда пөхтә, ак җәймәләр. Баш очында гына, кирәксә, кабызырга уты да бар. Миңа бусы да кызык. Сибгат абый урынын рәтли, сыйпап куя:

— Фронтта мондый әләксә инде...оҗмах дисең.

— Чагыштырыр нәрсәң булганда, яхшыдыр ул. Югыйсә бүгенге көн кадерен ничек белер идең,— дим, сүзне дәвам итәргә теләп.

— Шунсыз, гомумән, язучы була алмый... Фронтта

күргәннәрне көне-сәгате белән хәтерлим. Күпне күрелгән.

— Әзер әсәр кебек сөйлисез... Язсагыз иде?

— Ләкин алар шигырьгә дә, поэмага да сыймый. Ничек булган, шулай язарга кирәк. Гел вакыт тими менә...

Бераздан өстәп куя:

— Язылասы әйбердән беркая качып булмый ул. Өлгерсен генә...

Күрәсең, «өлгерү» тиз булмагандыр. 1965 елның көзендә дә, фронт хәлләрен сөйләгәндә, язсагыз иде, дип кыстадык.

— Прозага тотынсам, шигырьләрдән читкә алып кереп китәр дип куркам,— дигән иде.— Мин бирелсәм бөтенләй бирелəм, ярты-йорты булдыра алмыйм...

Бу нияте турында әйткәли килде, бик беләсе килә иде ул хәлләрне. Язмышының ут эчендә кайнаган еллары иде. Ният эшкә ашар вакыты җитте, язды ул аларны, прозага да сыймаганнары күңелендә киткәндер, чоры шундый иде.

Ватан сугышы еллары. Шагыйрь һәр тумыш көнгә шул кичерешләр аша карады, ваемсызлыкка тарткан елларда да бирешмәде. Язучы биографиясе — иҗатына нигез, киләчәге, колачы шуңа бәйле. Сибгат абый яшьләр иҗатын бәяләгәндә дә шул җирлекне барлый, ничек үсәсен күрә белә иде.

Мәскәүгә килеп урнаштык. Съезд ачылды. Кремльнең Зур Сараен тәүге кат күргән яшь шагыйрь дулкынлануын, горурлануын да аңлап буладыр. Атаклы язучыларны берьюлы шулхәтле очрат инде! Рәсемнәрдән күреп белгәч, алар сине дә таныйдыр кебек — исәнләшмәсәң, килешмәс сыман.

Съездда Н.С. Хрущев чыгышын тыңладык. Кәгазьдән укып башлаган иде, читкә этәреп, күзлеген салып куйды да, башта тотлыгыбрак, аннары дәртләнеп-кайнарланып сөйләде. Тыңлата белә, шаян сүзләр дә кыстырып җибәрә. Яшьлегендә шахтада эшләгән һәвәскәр шагыйрь Пантелей Махинның шигырьләрен яттан сөйләп китте.

Безнең делегация бер рәттә урын алган иде. Менә Сибгат абый, яңалык әйтергә теләгәндәй, елмаеп:

— Җыр яздым,— ди. Кәгазь ала да язып суза: «Күңелем Ленин белән сөйләшә»... Ул аны Казанда язып, композиторга биреп тә калдырган. Сибгат абый шәрехләп тормас, әмма ишарәсендә мәгънә булыр. Җырны әле

күрсәтүен шулай аңладым: кемнәрне тыңласам да кыйбдам Ленин, дигән ишарәдер. Моңа хәтле язылганнардан үзгә буларак, Ленин исемен ихлас күңел җыры итте ул, Татарстан, татар язмышы белән аерылгысыз итеп күрсәтә алды. Торгынлык елларында әлеге җырның «Казан әле, Казан уянмаган», дип башлануы очраклы түгел иде. Шөкер, инде Казанга, илгә дә уяныр көннәр килде!

Тәнәфестә Үзбәкстан, Казахстан, Башкортстан һәм башка тугандаш республика әдипләре белән очрашабыз, өлкәннәрнең танышлары шактый. Әнә бер төркемдә аеруча ихтирам иткән язучыларыбыз — Твардовский, Симонов. Җәлилнең данлы исемен, намуслы исемен илгә кайтаруда изге эшләрен онытырлыкмы! Сибгат абый шунда таба әйдәде:

— Әйдәгез, барып сәлам бирик. Алар безнең теләктәш, фикердәш. Безнең халыкка яхшы карыйлар.

Чыннан да, Татарстан делегациясен атаклы язучылар дустанә каршылады. Күреп торасың, Сибгат абый съезддагы бәхәсләр, проблемаларга караш уртаклыгын ачыклый — бер-берсенә таяныч икәннәр. Ул чакта РСФСР Язучылар союзы оешмаган иде әле, турыдан СССР Язучылар союзы белән эш йөртә идек. 1953 елның көзендә беренче китаплары да чыгып өлгермәгән дүрт яшь язучының (Р.Гәрәй, М.Хәсәнов, Р.Саттаров һәм мин) Сибгат Хәким тәкъдиме белән анда кульязмалары тикшерелгән иде. П.Антокольский, Е.Долматовский, безнең юлга-юл тәрҗемәләр белән танышып, бик җентекләп фикерләрен әйттеләр. Сибгат абыйның: «Анда бару файдалы, тәҗрибәң үсәр!» — дип хатка язуы бик дөрес булып чыкты. Әйе, «зур союзда» булу зур әдипләргә якын иткән...

Моннан соң да С.Хәким белән төрле съездларда катнашырга туры килде. Әдәбиятыбызны белгән, бәяләгән фидакарь шәхесләр белән багланышны яңарта тора иде. Андый чакта кайгыртканы — классикларыбыз әсәрләрен чыгару, йә шуңа кагылышлы оештыру эшләре. Мәскәүдә юллаганы иң әүвәл шул гомум эш иде, шул мәнфәгать иде.

*

Халыкның җаны — миллионлаган балаларында. Әрнү-янулары исә, берәмләгән моңлы күңелләрдән вөҗдан-нерв җепләре булып тоташадыр. Үтә дә киеренке,

нечкә тоядыр ул җаннар, ул бәгырьләр милләт хәлен. С.Хәким шундый иде. Шул гамь аны халык шагыйре иткән, рәсми указдан алда, әсәрләре белән халыкта расланган шагыйрь иткән, бәхетле иткән. Әмма милләтебез хәле «Бер горурлык хисе» белән бергә, бетмәс-тынмас әрну-сагышы да иде...

Үзгәртеп кору, хәбәрдарлык шикләну-сагаю богауларын алып ташлады, күңел карынында яткан уй-тойгылар да дөнья күрә. Теге чакта аулакта уртаклашкан фикерләр шул иде бит: туган телнең хәвефле хәле, бетә барган милләтнең язмышы. Туган тел даирәсенең тараячикләнә баруына әдипнең өзгәләнүе табигый: укучысы булса гына язучы бар. Язучысы булса гына укучы да бар. Югалтуга исә ике як бердәй офтану белән карамый. Укучылар бүтән телне иркенрәк сайлый ала. Кайбер яшь әдипләр дә, ярашучан җәнлек сыман, ата-баба исемнәрен алыштырып, өйрәнгән тел әдәбиятына китә. Рухлары имгәнеп, адашып калуларын күрү татар язучысына җиңелме? Шигырь тәрҗемә ителү бер хәл, иманы-җаны белән шагыйрь «тәрҗемә ителү» гамәлгә кереп бара. Милләттәшләребез яшәгән чит өлкәләрдән әдәбият-сәнгатькә килүчеләрнең юлы киселгән.

Балалар бакчалары, мәктәпләр хәле бик борчый иде Сибгат абыйны. Очрашуларда юньләп тыңламыйлар, аңламыйлар, дип күңеле төшүен әйтә иде. Мәгариф министрлыгында соңгы очрашуы булгандыр:

— Андый мәктәпләргә муенга муенчак салган кебек барасың...— дип уфтанып сөйләгән иде. Шуңа күрә дә сабый күңеленә бишек җырыннан башлап туган тел сеңеп калуны кайгырта, балалар әдәбиятының шул хасиятен бәяли иде.

Борчулы җан, әрнүле күңел. Үзеннән соң чыккан китабы «Яшә, борчулы җаным!» дип аталуы бик төгәл һәм өлкән әдипнең шәхесенә тәңгәл. Табигате белән нык рухлы, оптимист кешенең дә ахыр чиктә бер тапкыр:

— Бу дөньядан разочарование белән китәрмен, ахры...— дип сыкранып куюы бәгырьне сызып, сискәндереп җибәргән иде. «Разочарование» диюе, югары трибунада бәхәсләшеп, җиткерергә теләп әйтү шикелле. Бу сүзләрне ул Аккош күленең аулак юлында әйтте. Кичке эңгер-меңгер иде, алдагы өметләр дә шул чама. 1966 ел әле. Бәхеткә каршы, егерме елдан соң булса да, шагыйрь

үзгәртеп кору таңын күреп өлгерде, өмете яңаруын уртаклашып мәкалә дә язды. Алдан көткәнгәдер, үзгәрешяңарышка үтә сизгер иде ул.

Халык шагыйре, аның нечкә күңел кыллары халыкка төшкән авырлыкларны үзе аша уздырып, күтәреп яшәгән. Әсәрләрендә тулы бушану тапмаган елларда йөрәк ничек чыдасын.

Торгынлык елларымы, бүтәнме, С.Хәким беркайчан да бәйрәм-тантана кәефе белән яшәмәде. «Халык язмышы язучыны үзе үлгәннән соң да өч көн борчырга тиеш»,— дигән иде Аккош күлендәге бүтән бер сөйләшүдә. Бу сүзләрен «илһамым-мәхәббәтем» китабыма да керттем. Үзенә бүләк итеп кенә өлгерә алмадым. Әлеге, улы Рафаил төзеп чыгарган китабын да күрә алмады. Шагыйрьнең борчылу, янулары исән, ул әле дә халык язмышын кайгырта, каләмдәшләре, иҗат яшьләре рухи дәрман алырдай сүзләр ул китапта. Үзе үлгәннән соң да борчырга тиеш дип әйткән уе гомере белән расланып, гыйбрәтвасыять булып тора.

Шуларның тагын берсе, үзем шаһит булганын искә төшереп үтим. 1985 елның 19 сентябре иде. Тукай клубында җыелышта утырганда дивардагы портретларга күрсәтеп, Сибгат Хәким елмаеп әйтеп куйды:

— Ибраһимов күрсә, җене чыгар иде — монда да Тукайны алга куйганнар! — дияр иде...

— Ничек шулай тыныша алмадылар икән? — ди, моны ишеткән Әхсән Баянов аптырап.

— Андый мисаллар хәзер дә бар, еракка йөрисе юк,— дип мин дә кушылдым.— Дәрәҗәләре генә Тукай, Ибраһимов түгел...

Бу сөйләшү Сибгат абыйда да эзсез узмаган икән. «Яшә, борчулы җаным!» китабында күрдем: «Безнең язучылар клубында стенада портретлар. Башта Тукай, аннан соң Ибраһимов...Твардовскийның «Һәркемне замանвакыт шүрлектә үз урынына куя», дигән сүзләре бар. Заман Тукайга да, Ибраһимовка да үз урыннарын күрсәтте. Бәхәсләр ачыкланды».

Яшермәскә кирәктер: Тукайга саксыз кагылган өчен Ибраһимовка рәнҗү барыбер күңелдән китми. «Салкын сугыш» түгел, «салкын сулыш» та араларны суыта шул... Гыйбрәт бит?

## Җанның җылы почмагы

Олы шәхес киң күңелле була. С.Хәкимнең балалар әдәбиятына аерым бер ягымлылык, ярату белән каравын әйтергә кирәк дип саныйм. Л.Н.Толстой шул мөнәсәбәтне кыска кыйсса-хикәяләренә салса, С.Хәким мәкаләләрендә әйтте. Классик элгәреләрне искәртү белән бергә, варисларын күзәтте, һәр яңа исемне сөенеп барлап торды. 1985 елның декабрендә «Социалистик Татарстан»дагы җан җылысы белән язылган «Гөлҗәүһәрнең оныклары» дигән мәкаләсе соңгы мәрхәмәте булган икән. Роберт Миңнуллинның талант чыганакларын күрсәтеп, чын балалар язучысы сирәк зат икәнен ассызыклап, татарда «бер миллионга бер балалар шагыйре туры килә»,— дип язды.

С.Хәким миңа да бу жанр төп эшем икәнне сиздерә килде. Шәвәлине күреп алган да — ул булды. «Балаларга «Шәвәли» кебек бер китап та язып булмады. Укыгыз, балалар, «Шәвәли»не укыгыз»,— дип язды 1965 елда «Яшь ленинчы»да. Менә нинди була икән олы җанлылык дип, күңелең нечкәрерлек иде шул. Ике елдан сүзен тагын җөпләде: «Шәвәли — авторның озак еллар буена үзе белән бергә яши торган, ләкин картаймый торган образы булыр дип ышанам»,— диде. Ә бусы 1978 елда язганы: «Әйтерсең, Шәвәли,«Җиргә алтын төшә» дип яңгыр астыннан йөгереп йөргән малайларның берсе. «Әйтерсең... Тукайдан чабып чыккан. Елмаюы, шуклыгы, теленең үткенлеге шул «Алтын төшә»дәге чая малайныкы».

Балалар әдәбиятының ихлас табигатен яхшы белә иде өлкән шагыйребез. Андый шигырьләрнең «артык гади, юл араларындагы фикерләр үтәдән-үтә күренеп тора» диюче «бик тирән итеп уйларга өйрәнгән кешеләр»гә җавап итеп, болай дип язды: «Нурлар да бит үтәдән-үтә күренеп тора. Бала күңеленә үтеп кергән нурлар. Тукайның бала чактан күңелгә сеңеп алган юллары искә төшә:

«Яз, газиз угълым, кара тактаны сыз ак нур белән...»

Ак нур — туган тел нуры, туган тел яктысы нарасый күңеленә кечкенәдән сеңеп калуын теләде халык шагыйре, балалар әдәбиятының бар жанрлардан элегрәк җитүенә, милләт язмышына бәйләп, стратегик бәһа бирде.

*

С.Хәким кебек тә гел туган авылына тартылган, еш кайтып йөргән әдип юктыр. «Ни генә таба шул Күлле-Кимедә» дип гаҗәпләнүчеләр бар иде.

Шулай да, гадәти бер авыл ничек гомер буе тарткан, әледән-әле шигырьләренә ургылып кергән? Игътибар иткәнегез бардыр, халыкчан язучыны укысаң болар авылында икән җыен бай күңелле, җор телле, ихлас кешеләр дисең. Хикмәт — сурәтли белгән сизгер баласында икән. Шәһәр шау-шуыннан гарык булып туган стихиясенә кайткан шагыйрь күңеле, үз чиратында, әлбәттә, шул Фазыл-чишмәләрдән «тере суы» алган.

Шагыйрь авылдашларыннан үзгәлек эзлисең. Көткәнгә түгел, булганга күрә табасың. Үзенә хас моңы, тойгысы белән ул кешеләрне танып-белергә сине күптән әзерләгән икән, бар иҗаты аларга таянган икән...

Күлле-Кимедә Сибгат абыйның үзеннән соң булырга туры килде. Күңелне сызып, күзне дымландырып сабыр өянкеләр каршылый. Минем Олы Бакырчымда да су буйларына шулай өянкеләр сыенган. Таныш өянкеләр. Бу минем дә балачагым, җанымның җылы почмагы лабаса! Шагыйрь күңеле монда тәңгәл үз урынында булгандыр. Кая барса да татардан калмый ияргән тыйнак, моңлы өянкеләр. Берзаман алар да картаер, башларын җиргә тәрәп, ятып калыр... Әмма җыр картаймас — Күлле-Кимене киләчәктә дә өянкесез күз алдына китереп булмый.

Шагыйрь музееның маяклары алар — яңалары өстәлә-күтәрелә торыр.

Авылдашлары яратып, кадерләп оештырган мәктәп музеенда без дә булдык. Шагыйрьнең шәҗәрәсе гел балалар күз алдында. Нәсел-нәсәбен белгән, горур балалар үссен. Мин аларның шигырь укуларын йотлыгып тыңладым. Болар — үзгә, үзләренчә — С.Хәким авылдашлары! Гел кайтып йөрүе балалар күңелендә дә эз калдырган — шигырь моңын-җанын аныңча тоялар. Бу минем зур сөенечем булды, шагыйрь рухының яңа буында яңаруын күрдем.

Мәшәкатьле тормыш-көнкүрештә төрлесе булыр. Әмма бихисап шөгыль-мәшәкатьләрдә югалмый торган югарылык, рухи дәрәҗә бар. Борын-борыннан килгән шул иман адәмне кеше итеп тоткан. Түгелми-чәчелми буыннан-буынга күчә килгән, хәвефле чорларда да рәсми йо-

гынты-шаукымнарга бирешмичә күңелен саклый алган милләт. Шагыйрь миссиясе кешелек океанында гольфстрим агымыдай шул җан җылысын суытмыйча, яңа куәт өсти торудадыр.

С.Хәким туган нигездә булдык, кан кардәшләре арасында, шагыйрь кайтып тәгам җыйган өстәл тирәли утырышып искә алдык, монда төшкән рәсемнәрен карадык. Әти-әни йортыннан, әби-баба нигезеннән башлана туган җир. Рәхмәт яусын мамыклы-моңлы изге ояга, бу җылы ояга, халыкта яшисе күп җырлар, шигырь-поэмаларның җаны шушында яралган. Меңләгән күңелдәшләрен каршылар бу нигез, олылап баскан саен сайгаклары җиргә иңмәс, күтәрелә барыр, дип ышандык.

«Минем таныш өянкеләр, сезгә баш ияр кемнәр...»

Күлле-Киме шагыйрь улының моңлы аһәңнәре белән озатып калды, тууына 75 ел тулу унае белән без дә олылап, С.Хәким җиренә баш идек.

*

Сетунь елгасы буенда да өянкеләр үсә, «татарча белмәсә дә», болар да күңелгә якыннар. Ярдан өстәрәк, өч нарат төбендә К.Чуковский, Б.Пастернак каберләре. Ил сукмагы өзелми аларга, шигърияткә мәхәббәт бик ераклардан — чит илләрдән дә китерә. Истәлекләремне әнә шул атаклы әдипләр яшәгән, Мәскәү янындагы Переделкино иҗат йортында язам. Уем да, сүзем дә бу арада гел Сибгат абый турында. Башкортстаннан килгән шагыйрь һәм галим Гыйлемдар Рамазанов аның Уфага килүен сөйли. Бер генә булды ул анда. Гыйлемдар ага шул хакта язарга вәгъдә итте. Көн дә иртән урман юлында очрашабыз:

— Әйдәгез, Егор Исаев сукмагыннан алып барам,— ди ул берсендә.— Әнә үзе дә килә!

Исәнләшәбез. Гыйлемдар агай шаяртып таныштыра:

— Татарның бөек шагыйре...

— Татар дигәч, бөек икәне мәгълүм инде! — дип, шул тонда дәвам итәм. Исаев форсатны көткән сыман, иңгә кагыла да, илһамланып-дәртләнеп сөйли башлый:

— Сезнең алда әйбәт күренер өчен әйтүем түгел... Татарлар — сезнең халык гомер-гомергә сабыр, тыйнак булды... Бәлкем, аңа бу хәлгә булышканнардыр да? — дип кинаяләп, елмаеп күз кысып ала.— Язучыларыгыз

да үзләрен күрсәтергә атлыгып тормыйлар. Тик... артык тыйнаклык та ярамый — әрсезләр заманы! — дип шаулап-көлеп куя.

Уем — Сибгат абыйда дидем, бу өлгегә ул да туры килә бит. Аны Мәскәүдә беләләр, иҗаты бәяләнгән, китаплары чыга тора,шулай да анда күренергә ашкынып тормады. Татар әдәбияты өчен кирәкле чын эшне лаф ормый гына кайгырта килде. Кемдер чәчрәп торган чаялык, үткенлек күрергә теләр иде. Әмма Сибгат абый «бөтенсоюз аренасында» балкырга омтылмады. Үзенә ышанып җитмәүдән түгел, нәкъ менә киресенчәдер — иҗатына ышанганнан дип беләм, әйтер сүзе туган халкына җитүен күреп разый булгандыр. Юкса бит Күлле-Кимегә түгел, Мәскәүгә ешрак йөрер иде. Х.Туфан да шундый хәлне кулайрак күрде. Бүтән халыклар алдында күренү, әлбәттә, кирәк эш. Шулай да, Мәскәүләргә җиткәндә әйләнеп карау да ярый: туган телдә укучыларың ерак калмаганмы, күпме алар?

Икенче бер күрүдә Е.Исаев дача капкасы төбендә бик тәмләп кар көри иде. Мәскәүдә дә безне авыл җанлылык якынайта. Сүз уртаклыгы да шундадыр, ул үзенең авыл киңлекләренә ашкынган җаны турында, иң мөһиме эш — җир эше, игенче эше, әхлакның, тормышның тоткасы шунда дип, дәртләнеп сөйли. Җир кешесенә якын әдипләр дип С.Хәким, күрше чуаш шагыйре Я.Ухсайны искә ала.

«Литературная газета»да С.Хәким белән Я.Ухсайның некрологлары янәшә чыкты: монда да күрше булдылар. Төрле төсләр белән сөенгән җәй аенда рәсеме кара кайма белән уралыр дип кем белгән...

*

Сибгат абый авырып больницага, йә операциягә кергәндә хәл белергә элек тә бара идек. Бусы да шундый күрешүдер дисәк, соңгысы булган икән... Илдар Юзеев белән икәү кердек. Кулларын баш астына куеп яткан. Сулыш алуы авыр.

— Җиңәсез әле сырхауны. Сез бит фронтовикларча җиңә килдегез! — дип юатып, дәртләндермәк булабыз. Моңсу карый, тавышы хәлсез:

— Арылган. Ял иткән юк. Талчыгылган...— ди сузыбрак, җиңен сызганып кулларын күрсәтә: укол кадый торгач буйдан-буйга кара янып беткән, энә төртерлек урын

калмаган. Туры мәгънәсендә кул сугышыннан чыккан солдат хәле — сырхау белән көрәшү тамгалары, ерак сугышның тирән эзләре. «Арылган» дигәнен дә тән ару түгел, җан ару дип тыңладым — сәбәпләр булгалады шул.

Янында гына иртә өлгергән викторияләр. Тулышып пешкән саф, яңа гына өзеп алынган җиләкләр. Мөршидә апа өметләнеп:

— Менә шуны авыз итте әле,— ди.

Сүзне озынга сузарга уңайсызланабыз, өзлекмәсен дип, китәргә кузгалабыз. Саубуллашканда, хәлен җиңеләйтергә теләгәндәй, кулын сыйпап куям. Күзебезгә текәлеп карый да:

— Эшләгез. Бирешмәгез...— ди. Соңгы сүзләре шул булды. Күзләре дымланып, иреннәре дерелдәп китә. Без терелү турында юатып сөйләсәк, ул бәхилләшкән икән. Моны урамга чыккач, тәэсирләр уртаклаша торгач төшенә башладык. Анда да бер-беребезне ышандырырга, тернәкләнер дип өметләнергә тырыштык — хәвефне яшермәкчебез...

Шул көнне ул бер шагыйрьне, күрешеп чыгар идем дисә дә, кабул итмәгән. Мөршидә апа әйтте моны, авыраеп китмәсен дип саклавы булгандыр. Бәлкем, Сибгат абыйның мондый хәлдә күренәсе килмәгәндер. Ихтимал, күрәсе дә килмәгәндер. Соңгы минутларына хәтле шәхес үзе булып кала: кичерелмәс рәнҗүләр сәбәбен үзе белгәндер. Без шулай сизендек.

Яңа гына түтәлдән өзелгән җиләкләр мөлдерәшеп тора. Чайкаган суы саркып бетмәгәнме — яшьле күзләр сыман иде алар. Хәсән Туфан чәчәкләре янәшәсеннән — Аккош күленнән килгән җиләкләр. Шагыйрьнең соңгы язында чәчәк атып, җимешләрен авыз иттереп өлгергән алар. Соңгы җиләкләр, туган җирнең бәхилләшү җиләкләре булган икән.

*

Үлем үкенечсез булмый, диләр. Минем дә үкенечләрем калды. Шагыйрьнең фатирында эш бүлмәсендә бер сөйләшү истә.Сүз җае чыгып:

— Сезгә багышланган шигырьләр үзе бер китап булырлык! — дигәч, Сибгат абый:

— Менә ул, бар инде — Равил Фәйзуллин җыйган. Төпләгән дә. Әлмәттән, алтмыш яшемә, юбилеемда бүләк

итте,— дип алып күрсәткән иде. Йөзенә карыйм — рәхмәтле елмая, күңеленә хуш килгәнен күрәм. Мин бурычлы, акланырга теләп:

— Китап булып чыкканчы минем шигырь дә өстәлер әле,— дип куйдым. Сезгә багышланган шигырь иң әйбәте булырга тиеш ич...

Ни үкенеч — мин андый шигырьне язып, остазның үзенә укыта алмадым. Җөрьәт итеп, язып караган чаклар булды, әмма каралама хәлендә кала бирделәр.

Идел буенда, Займище-тугайлыкта, бакчада яши идек, шәһәр хәбәрләрен белмим. 5 июль иртәсендә радиодан иртәнге концертны тыңлый башласак — Сибгат Хәким истәлегенә...диләр. Сискәнеп, тетрәнеп киттем: «истәлегенә...» ялгыш түгел микән?! Мондый зур югалту ачысы ир гомерендә дә сирәк була. Ак каеннар арасында йөреп, күз яшьләремне йотып яздым шигырьне. Җеназасында укырга насыйп булган икән ләбаса...

**Сибгат Хәким белән хушлашканда**

Энеләргә күз-колак бул, диеп,
Сине Җәлил, Кәрим җибәргән —
Үлемнәрне җиңеп илгә кайттың,
Аталарча сөйдең иңнәрдән.

Без этисез моңлы балаларның
Җан, рухына терәк идең син,
Шагыйрьләре үлеп ятим калган
Халкыбызга кирәк идең син.

Уттан чыксаң да син утта булдың —
Һәр көнеңне янып озаттың.
Януларың, моңың, җырың белән
Татарның син гомерен озайттың.

Соңгы сүзең безгә дә шул булды:
«Бирешмәгез,— дидең,— эшләгез!»
Васыятең киләчәккә бара —
Изге эздән синең төшмәбез.

Бер тынычлан инде, шагыйрь абый,
Борчуларың безгә калсыннар...
Ә җырларың мәңге саф, безнеңчә,
Ил күңелен көйләп барсыннар.

Илдар Юзеев та Сибгат Хәкимгә багышланган шигырен укыды. Наҗар ага Нәҗми, Уфадан очып килеп өлгергән, гадәттә, көләч шагыйрь, тирән кайгыда. Безне тыңлагач:

— Ант биргән шикелле булды шигырьләрегез,— дип иңнәрдән алып үзенә сыендырды.

Татар зиратында Хәсән Туфанның ак мәрмәр һәйкәле янында Сибгат Хәким... Яраткан шагыйрьләре арасында милләтнең тагын бер мәхәббәте — композитор Сара Садыйкова. Язмышның туры китерүен кара: сүзләреннән көе аерылгысыз...

Өлкән шагыйрьләр икесе бергә хәтердә калган күренешләр күп. Тик нигәдер берсе кайта-кайта искә төшә. Хәсән Туфанның 75 яше тулган көнендә, хәзер мемориаль такта куелган Вишневскийдагы фатирында. Без анда өчәү: Сибгат абый, Илдар бергәләп барган идек. Ул көнне Туфан табынында бүтән кеше күренмәде. С.Хәким юбилярга багышлап язылган бер бәйләм шигырьләрен укыды. Озак утырдык, декабрь булса да, ак сирень чәчәкләре коелгандай җылы йомшак буранлы көн иде. Электр яктырткан, буран аклаган урамнар иркен, бу сәгатьләрдә ул буп-буш. Арча кырыннан өчәүләп җәяү киттек. Шигъри төн иде. Туфан төне, күңел бәйрәмебез. Сибгат абый яшәгән йорт — Ирек мәйданында. Ирек... Кайтып җиттек, әмма аерыласы килми. Сөенечле, күтәренке рухлы бу көн кабатланмас, аны озаккарак сузасы килә. Татарның Туфанлы, Хәкимле еллары да кабатланмас. Әмма аерылырга туры килә. Җырларыннан халыкны аермасын, дип теләргә кала. Сибгат абый минем өчен әле дә шигъри ак бураннар арасында гына сыман...

*Февраль, 1989,*
*Переделкино – Казан.*

## *Ятим бала моңлы була*

Гомергә аралашып яшәгән кешеләр дә күңелдә мәгълүм бер сурәттә урнашып кала, шул рәвештә күз алдына килә. Рәссам да шәхескә хас шундый мизгелне эзли һәм табадыр.

Заһит Хәбибуллинны мин көзге җилдә, елга кичкәндә скрипка уйнаган хәлдә күрәм. Романтика өстәү, шигъриләштерү түгел, үзем күргән вакыйгасы бар...

1970 елның сентябрендә без Киров өлкәсенең Нократ Аланы (Вятские Поляны) районына укучылар белән очрашуга бардык. Татарстанга орынып торсалар да, чит өлкә,

читтә булсалар да үз-милли аһәң, әдәби сүзне сагынып-тансыклап яшәүче кан кардәшләр, дуслар, туганнар. Ул чакта рәсми оешмалар, читтәге татарлар безнең эш түгел, сагаеп караса да, җае чыкканда төрле төбәкләрдән урап кайта торган идек. Бу юлы сәбәбе дә бар: хөрмәтле язучыбыз Ләбибә Ихсанованың туган ягы, ул өндәде. Заһит ага скрипкасын алды, Илдар Юзеев белән без шигырь китапларын кыстырдык. Каләмдәшебезнең туган авылы Түбән Шөндә, шул тирәдәге авыл клубларында, мәктәпләрдә күңелле очрашулар булды. Казаннан чыкканнан бирле яңгыр да яңгыр, гел бата-чума дигәндәй йөрергә туры килде. Әмма болдыр басмалары гәрәбәдәй сары итеп юылган иде, милләттәшләрнең мөлаем каршылавы болытлы көннәрне онытырды — елмаюлар якты иде.

Менә эшне тәмамлап кайтыр юлга чыктык. Нократ елгасын паромда кичәбез. Котсыз көн, әче җил — сентябрь димәссең. Ышыкланыр урын да юк. Паромда берничә агай. Эш кешеләре: сырма кигәннәр, аякларында резин итек, салкыннан бөрешкән бер малай да бар. Кешегә юлыккан Заһит абый эндәшми калмас, әлбәттә инде, хәл-әхвәл сораша башлый. Ул әле кичәге бәйрәм тойгысыннан суынып өлгермәгән, күңеле күтәренке. Агайларга да шуны искә төшерә:

— Шәп булды бит, ә? Сезгә дә ошагандыр?

Нинди җавап буласын белә инде, елмаеп тора. Тик бүтәнчәрәк килеп чыкты... Сыңар куллы агай тартыныбрак:

— Без концертта була алмадык шул...— диде.

— Ничек инде?! — ди Заһит абый гаҗәпләнеп. Агай көрсенә:

— Улым белән көтүдә без. Соң кайтылды...

Мондый сәбәптән Заһит абыйның кәефе килеп:

— Ә без сезнең өчен кабатлыйбыз! — дип, скрипка тартмасына үрелде, сәхнәдәгедәй җитдиләнеп, уйнарга керешә. Тукай сүзләре әргән телендә илаһи көч белән кодрәтле яңгырый:

«...Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы...»

Елга уртасы, як-якта иркенлек, бушап калган кырлар, болыннар. Көзге җил дә сизелми, салкын көн дә юктыр... Агайларга күз төшерәм: көтелмәгән олылауга

уңайсызланып, хәйран калып тыңлыйлар. Музыканың сүнмәс дәрте, бабайлардан килгән моң, пычрак ерып йөгерткән дөньяви йомышлардан аерып, күңелләрен күркәм сабырлыкка көйләгән...

Заһит абый көйдән-көйгә өзмичә күчә бара, кеше ымсынганда нәүмиз калдырмас ул, тыңлагыз, агай-энеләр. Үзе эшкәрткән халык көйләрен уйный, челтерәп чишмә-җырлар агыла, гомер чыганаклары башланган хатирәләрне уята. Әнә үзенең «Сагыну» көе шушы табигать, җәйге сандугачлары белән бу җирдә мәңге булгандыр ул. Кайчан ишеттем икән беренче тапкыр?

Нократ елгасын искә төшереп соңыннан да кат-кат уйландым. Мәскәүнең мәшһүр композиторын, музыкантын шулай күз алдына китереп кара әле? Нәфис бармакларын куеныннан чыгармас, скрипкасын да өф итеп кенә торыр. Безнеке — үзгә, үзгә халык улы, үз багырь кисәге. Шул бергәлек аңа һәр кешесен якын иттерә, җилдавыл, салкыннары уртак...

*

Кем ничектер, Заһит Хәбибуллинны мин «Сагыну» җырыннан башлап беләм. Сугышка хәтле үк, балачак тәэсирләре белән күңелгә сеңеп калган.

Муса Җәлил ул шигырьне 1936 елның сентябрендә язган. Музыкаль канатлар алган җырны халык бик тиз үзенеке итә. Җыр шаулаган ул елларда әле Заһит Хәбибуллин белән Фәрит Яруллин Мәскәүдә укый, тулай торакта бер бүлмәдә яшиләр. Муса Җәлил аларга килеп йөри. Бу җыр егет белән кызның — гашыйк йөрәкләрнең бер-берсенә омтылуы гына түгел, «Сагыну»ның миллионнар язмышына тапкырланып яңа тойгылар белән көчәясе 1941 ел дәһшәте бик якын булган...

Бик сагындым,бәгърем,  
Бик сагындым сине,  
Әле дә ничек түзәм мин!

Сагыну — аерылулар юлдашы. Безнең дәвер фаҗигале аерылулар шаһиты. Җир тетрәү куәтен белерләр, ә миллион йөрәкләр тетрәнүен кем үлчәгән? Җыр үлчидер, җыр юатадыр... «Сагыну» җырын онытылмас иткән хасият —кешеләр язмышында яңара баруында.

«Ай, бормалы, бормалы, бормалы су буйлары...»

Һәркемнең истәлекле үз елгасы бар. Сагынуларны яңартып, бүген белән үткәннәр арасыннан тын гына ага ул. Нократ кайда да, Җаек кайда. Әмма аларның икесендә дә безнең милләттәшләр яши. Ике кыйтганы аерып-тоташтырып торган Җаекның бер яры Азиядә, икенчесе — Европада. Шул ярда, Оренбурдагы бер мәйданда Чкаловка һәйкәл бар. Гагарин да шунда канат ярган, тарих галәменә шуннан юл алган. Ике канаттай күтәрелгән йортларның сул тарафында Җәлил эшләгән, үлемсезлеккә шуннан юл алган. Берлинда «Сагыну» көенә көрәштәшләре белән моңланганда шушы ярларына атлыккан, Заһит Хәбибуллин искә алгандыр. Уртак җырлары Мәскәүдә туса да, күңел кыллары монда көйләнгән. Ай, бормалы, бормалы, язмыш юллары — икесе дә шушы Җаек-Уралдан бит. Шагыйрьнең 80 еллыгында Татарстан делегациясе исеменнән Җәлил эшләгән йорт мемориаль тактасына хөрмәт белән чәчәкләр куйдык. Ак кар өстендә уттай канәфер чәчәкләре янып калды — үз язмышы сыман... Шәһәрдә шагыйрь исемендә урам бар, һәйкәле дә булыр дигән өмет бар.

Кайларга гына таралмаган безнең халык. Әмма кыйтгалар, елгалар аермаган, сәбәпләре үзгә булган язмышын, тарихын мәрхәмәт ияләре язмаган шул. Оренбур якларының кайнар дала сулышын тойганым, чатнама кышын күргәнем бар. Андагы милләттәшләр читкә сибелеп-бүленеп, өзелеп-йомылып калган җыр-чишмә сыман...

«Сагыну»... Заһит абый турында хатирә язарга да шушы моң, шушы тойгы-аерылулар әрнүе сәбәпче булды. Үзе өздереп уйнаган скрипкадай мулыгып-сулыгып җанны кузгата ул. Сагынырлык кешеләр, юксынырлык шәхесләр.

*

Олы җанлылар киң күңелле була. Заһит Хәбибуллинга бу сыйфат бик ятышып тора, табигате шундый иде. Менә балалар тулы мәктәп залына килеп керәбез. Уза-узышка ук күптәнге таныштай гәпләшеп килә. Гадәттә, сүзен исем сораудан башлый:

— Исемең ничек әле, энем?

— Айрат.

— Бик әйбәт. Рәхмәт, рәхмәт! Ә синең?

— Альфред!

— Әйе... Безнеңчә Әлфәрит буладыр инде...

— Кайсын «ярый икән», «Һем-м...» дип кенә уздыра. Чын үзебезчә исемнәргә:

— Рәхмәт, рәхмәт! Бәхетле бул! — дип аркасыннан сыйпап куя. Кая барсак та шулай. Без моны көтеп, күзәтеп торабыз. Сизенә, безгә ымлап, ишарәләп мөнәсәбәтен белдереп бара. Шактый чит-ят исемгә юлыкса, иясен юаткандай:

— Иван түгел икән әле! — дип йомгаклый. Бусы татар совет композиторы, җитәкче абзый малаена ишарә — «абзыйның» милли хис дәрәҗәсенә...

Нократ ягыннан кайтышлый Кукмара районына кагылдык. Зур Сәрдек авылында яңалык — музыка мәктәбе ачылган! Сөендек моңа, Заһит абый аеруча дәртләнеп карап йөри. Скрипка тоткан малайдан сорап узмакчы:

— Исемең кем дибез әле?

— Заһит...

— Заһит?! Ә фамилияң? — ди тукталып композитор.

— Хәбибуллин...

— ?!

Заһит абый, булмас дигәндәй, аптырабрак тора. Гаҗәеп бу адашлыктан кызык табып елмаеша башлыйбыз. Заһит абый уйчан:

— Рәхмәт, рәхмәт,— диде.— Исемне аклыйк...

Әллә күңеле тулды... Үзе кичергән ятимлек елларын, кулына скрипка алган сабый чагын хәтерләдеме?

Ятим бала моңлы була. Сыеныр җылы почмак, газиз кочак булмау, кайгы-хәсрәт ачысы, ташны эшкәрткән сынчыдай бәгырьне кыргычлый. Нерв җепләренә җиткәнче... Тәмам кеше иткәнче! Ятим күзләр, үксез күңел дөньяны ачыграк күрә, югалту ачысын да, табу шатлыгын да яхшырак белә!

Тормышта ачысын-төчесен яшьли күргән Заһит ага. Төчесе — аз эләккән, әти-әнисез балачакны бәхетле дип әйтеп буламы?! Детдом-ятимханә — туган йорт түгел. Әмма ул анда беренче тапкыр скрипка күрә. Мәшһүр Солтан Габәши белән очраша. Хыялы чынга әверелә башлый. Бусы бәхет елмаюы түгелмени? Җанга аваздаш серле скрипка. Нәни куллар, нечкә күңел әргән кылларына тотынган, җыр-моң җайсыз көннәргә юаныч булган. Бал корты шифалы ширбәтен матур чәчәкләрдән генә җыймый — шайтан таягыннан да ала. Композиторның җанны иркәләгән җырларында үзе кичергәннең агы да, карасы

да гүзәллеккә әверелгән: елмайткан да ул, уйландырган да — кешеләргә ни кирәген белгән.

Ятим бала моңлы була. Нарасый Заһит ятим булса да, Заһит Хәбибуллин моңы үксез булмады — халык үзенеке итте.

Кукмарадагы адаш малай үсеп зур булгандыр, әлегә исеме яңгырамады. Хәер, тарих алай шаяртмый: һәр талант үз исеме белән, үзен танытып мәйданга килә. Фамилияләре үзгә булса да, милләтнең сәләтле балалары күренә тора — Заһит Хәбибуллин җырлары да илһам уятышкандыр...

*

Заһит ага импровизация остасы. Менә «Бала белән бал корты»... Бу әсәрен тыңлаганда скрипка кыллары арасыннан бал корты быжылдап чыккан күк була! Таныш ул — радиодан бер генә ишетмәгәнсең. Монда тере композитор үзе уйнап тора! Болын белән бала арасында элемтәче ул бал корты. Бал бит ул чәчәк тәме... Бала, бал —аваздаш, «Авыздаш»! Әхмәт Фәйзинең дә «Бал корты» шигыре таныш балаларга. Композитор да, шагыйрь дә баланың ни яратканын белеп алганнар! Балны димим әле, чын музыкаль аһәң турында әйтәм. Менә кызык булыр иде берәр сәхнәдә очраштырсаң аларны — шигырь белән музыка парлашып «очса»? Ә бәлкем кемнәрдер тырышып та карар? Музыка яратучылар, әдәбият сөючеләр, җырга гашыйклар аз түгел лә!

«Чикерткә» исемле пьесасын, «Бишек җыры»н да йотылып тыңлый балалар. Заһит абый да хәйләкәр, ул арада музыка турында сөйләп тә ала, чикерткәдәй тиктормаслар да авызын ачып кала. Тормыш, яшәеш турында сөйли ул, әйтер киңәш-табышлары күп. Уйнавын онытып, скрипка урынына үзе сайраган чакларда:

— Әргәнгә сүзне күбрәк бирсәң иде,— дип искәртә идек.

— Ярар,— ди,— дөрес,— ди. Сәхнәгә чыктымы — элеккечә. Баксаң, ул хаклы да: күпме нарасыйда сәнгатькә мәхәббәт уятып калдырган.

Күңелле җырлары, «Раушан» балеты калган. Ул бит беренче булып Тукай сүзләренә — шагыйрьнең вафатына утыз ел тулган 1943 елда — Ватан сугышының хәвефле бер чорында җырлар циклы иҗат иткән.

Төрле музыка кораллары өчен язылган әсәрләре балаларның музыкаль сәләтен үстерергә булышкан.

Очрашуларда кат-кат тыңлап, сәхнәдә тынганнан соң да колагыңда музыка яңгырап тора. Күңелдә үк икән — ихтыярсыздан көйләп йөрисең. Хәер, кунак ашы кара-каршы, безнең кайсыбер шигырьләр дә «бәйләнчек» икән, Заһит абый да Илдар шигырьләрен кабатлый. Минем «Онытылган, өйдә калган», «Майламасаң майлама», дигән сүзләрне искә ала, музыка язарга теләвен әйтә иде. Бер мәктәптә шулай, мин шигырь укыганда, көтмәгәндә скрипка кушылып китте: әвеш-тәвеш шыңгырдап барган арба тәгәрмәчләре таудан түбән ничек кызулавын уйнап күрсәтте. Казанга кайткач та, матбугат йортында күрешкәләгәндә, язам, дигән ниятен искә төшерә иде. Тормыш-көнкүреш без дигәнчә генә барса икән... Тау-каршылыклар күбрәк, гомерләр исә түбән таба тәгәри — вакыт дигәнең җитми калучан.

*

Пианино — кукраеп түрдә утырган кара фраклы аксөяк. Скрипка ирекле кош, сандугачмы, тургаймы диик... Кешегә якын булырга ярата, йөрәк өстенә үк кунаклый. Тальян белән скрипка гомер-гомергә халык арасында, аһзарына, куаныч-юанычларына да бик якын әргәннәр. Скрипка — ялгыз моңланучы нечкә күңел. Сихеренә бирелеп кара — көйлиме ул, сөйлиме? Туган телендә көйли ләбаса, күңел телендә сайрый!

Заһит абый пианиносын да әпипәгә биетә, әмма моңдашы-сердәше-юлдашы скрипка иде. Охшашлар да — икесе дә җиңел сөякле, икесенә дә сәйярлек хас. Заһит абыйны скрипкасыз күз алдына китерә алмыйм: күңеле ачылып, рухы ирektә кинәнгән чагы... Күбрәк авыл сәхнәләрендә, авыл өйләрендә тыңладым мин аны. Ничәмә-ничәнче булса да, тәүгедәй дөньяңны онытып, музыка әсирлегендә каласың. Үзе дә беренче кавышкандай бирелеп уйный — шуңадыр. Илнең төрле якларында күңелдән-күңелгә күчкән, атаклы җыр һәм бию ансамбле белән дөньяны ураган музыкасыннан үзе дә калышмады — гел халык арасында булды.

Клубта шактый киеренке очрашудан соң кичке чәйгә утырышкач та — һәр авылда яңа кешеләр бит — тагын уйнавын сорыйлар. Ала ул скрипкасын, иягенә җайлаштыра, кулъяулыгын пөхтәләп куя, сызгычын сыный, үзе дә көйләнә. Бер башласа, чәең ни дә мәең ни — табынны оныта: мавыгып китә, канатланган күңелен тыя ал-

мый. Мондый чакта кызык әмәле бар — ялгыз скрипкадан оркестр ясый! Берәр нәрсәне, әһә, әнә нәни тоз савыты —шуны ала да кылларга терәп куя. Бу уеннан нинди «уймак» чыкканны күрсәгез! Хикмәтле яңгырашның «тозы» шунда икән. Адәм түгел, сихри зат галәмәтедер бу — шашкын өермә уртасында каласың. Заманында скрипканы шайтани көчкә ия дигәннәре шушыдыр, мөгаен! Шаяртып, гади-гадәти кеше сыман йөргән Заһит абыең менә кем икән ул, менә нинди могҗиза иясе! Бу минутларда шаярту куәсең бетә, ихлас сокланып, гаҗизлектән:

— Паганини! — дисең. Куегыз әле, дигәндәй, уңайсызланып елмая, әле тынычланып җитмәгән. Кыллар да «Тәфтиләү» дулкыннарыннан тетрәнеп-дерелдәп торадыр. Сабантуйда очу дәртен тойган юртак шикелле! Сызгычның ат кылларыннан булуы очраклы түгелдер: ир канаты ат булыр, җыр канаты моң булыр. Заһит абый Такташныкы сыман сибелгән чәчләрен чөеп куя да әкренләп безнең ыбыр-чыбырлы дөньяга кайта. Шагыйрь белән охшашлык матур сибелгән чәчләрдә генә түгел, халкым рухы дип кабынган күңелләрдә икән.

Әйе, Заһит абыйның чын сәнгать әһеленә хас булганча тәмам бирелеп китә торган гадәте бар. Берсендә шулай, инде шактый соң, кичәдән карын ачып кайтканны да онытты бугай. Тәкатебез бетеп, шыпырт кына тавыкка үрелгән идек, абзыебыз сызгычын сызган уңайга безгә авышты да:

— Сыпырасызмы? — дип пышылдап куйды. Үзе уйнавын дәвам итә... Моннан соң, җае чыккан саен, Заһит абыйга охшатып: «Сыпырасызмы?» — дип шаярта торган идек.

*

Ул елны оешып алган төркемебез — Заһит абый, Ләбибә ханым, Илдар һәм мин янә авылларда йөреп кайттык. Арытса да күңелле сәфәр, вокзалга кайтып төшүгә:

— Тагын кая барабыз? — дип таралышабыз. Инде бераздан матбугат йортында очрады исә, Заһит абый күрешергә кулын суза, үзе, җиңел бәдәнле кеше, баскан урынында тик торалмый:

— «Өйгә кайткач... Өйгә кайткач!» — дип күзен кысып мут елмая — мине үртәп, очрашу саен укып интектергән шигырьгә кинаясе. Шунда ук:

— Чыгып керәсе иде бергәләп? — дип куя.

Йөрергә ярата идек, өндәү көтми идек! Әйтер сүзеңне укучыга җиткерү, ихлас теләктәшлек күрү арган рухыңа да дәрман бирә. Кызык итеп йөри идек. Сүздән мәзәк ясап та кинәнәбез: беребез башлый, икенчебез күтәреп ала. Юл иреге, күпсанлы вазифа-мәшәкатьләрдән арынып тору, яңа җирләр, яңа кешеләр күрү ихтыяҗы иде. Җитди сүзләрдән соң кызык ясарга тормыш үзе булыша. Менә Азнакай истәлеге. Ул якта яшәүче Мәхмүт Хәсәнов каршы алды. Карамалы авылында, Тымытыкта, Урсайда, Чаллыда очрашуларда булдык. Самолетта килдек, поезд белән кайтасы иттек. Сүзем шул кайтыр юлга борылсын...

Билетны алдан кайгырткан идек тә, очы-очка ялганып җитмәгән икән — йомшак вагон дипме, өстәп түләргә туры килде. Ә без булган акчаны тәгаенләп, тотып бетерә язганбыз. Кесә төпләрен кырып дигәндәй, билетка җиткердек җиткерүен. Юлга — дүртебезгә ике урынҗирлек кенә акча калды... Проводниктан оят — Бөгелмәдән Казанга төн кунып кайтасы ла, ни диярбез? Вагонга килсәк, усал апа ишеккә аркылы баскан:

— Урын-җир әйберләре икегезгә генә! Бирмәделәр! — дип, кемнедер ачуланып ташлый. «Котылдык!» — дибез эчтән, ә тыштан:

— Икәү генә? Бу ни хәл? — дигән булабыз.

Кердек, утырыштык та көлештек. Аннары тынып калдык — кайтасы бар, буфетта чәйләрбез дигән акчаны билет йотты — «йомшакка утыртты»... Кайтабыз шулай, кызык сөйләшәсе дә килми. Заһит абыйның күзе тәрәзәдә. Гомергә көләч Ләбибә ханым серне белгәндәй безгә карап елмая. Чыннан да, Илдар белән икәүләп алдан әзерләп куйган хикмәт бар. Сүз башларга вакыт бугай:

— И-их, шунда берәр тавык булса...

Заһит абый тәрәзәгә карап безгә кул гына селти, тагын да үҗәтләнәбез:

— Тавык үзе генә дә булмаса...

— Янына бәлеш тә кунакласа!

Ниһаять, тәмам авыз сулары килгәч, хәттин ашмыйк дип, букчаларга сузылабыз...

— Әле бусы да бар икән... — дигән булып, район үзәгендә алдан алып куйган нәрсәләрне өстәлгә тезәбез. Заһит абый да борылды — монда «пейзаж» матуррак тоелды бугай... Күңелле кайттык, арыганнар беткәндәй

булды. Ә урын-җир каты булып истә калмаган — дөнья күрмәгән кешеләрмени соң?

*

Иҗади халәттә яшәүче буларак, Заһит Хәбибуллин тормыш шартларына талымсыз иде, аерым игътибар көтмәде. Гадәттә, андый дәгъвасыз кешеләрне кайгыртырга онытalар. Әрсезләр исә тынгы бирми, йолкып ала! Тиешле даирәләрдә үзен «куя белгән», абруйлы кабинет яулаучылар да шулардан чыга. Дәрәҗә баскычын күзәтеп, һәркемгә урын билгеләп тора андыйлар. Иҗат бюрократиясе үзен ирешмәслек югары, алыштыргысыз зат итеп ышандыру өчен кирәк булган бу тәртип. Андый «абзыйлар» талантларны үстерү түгел, узып китмәгәйләре дип кайгырта.

60 яшьлек юбилеена З.Хәбибуллин илгә танылган, халык яраткан композитор булып килде. Тукай премиясе лауреаты, ТАССРның халык артисты. М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында иҗат кичәсе әзерләнә, әмма... булмый кала. Кем аркылы төшкән дисәң, үз иҗат оешмасы... Сәбәбе — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе түгел, мондый сәхнә югарырак, янәсе. Исем бирү кемгә бәйле соң? Шул ук түрәләргә ләбаса! Әлеге исем З.Хәбибуллинның соңгы юбилеена гына «өлгерде». Лаекмы, түгелме икәнен нинди мыскаллар белән үлчәнгәндер, чын бизмәне бер генә — халык мәхәббәте, халык тануы. Ә З.Хәбибуллин милләтнең сөекле исемнәре арасында: С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарев йолдызлыгында балкый иде.

Заһит ага «аерым игътибар көтмәде» дигән идем. Анысы шулай, тик горурлыгына кагылгач, юбилей үткәрүдән баш тартты. Рәнҗүен сиздек — хаксызлык нечкә күңелгә каты кагылгандыр: сулкылдап җыр туган бәгырь лә ул, күңел кыллары әргән кыллары түгел. Нократ елгасында агайлар кәефен күреп скрипка сайратканда алтмыш яшенә нәкъ бер атна калган иде. Паром палубасы затлы сәхнәне алыштырган...

Һәрнәрсә үз вакытында мәгънәле. Әнә җитмеш яшенә багышланган юбилее Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узды. Инде «РСФСР»ы да бар. «Миңа ул моңсурак күренде, элекке сыман дәртләнеп тормый... Кичәсе үзе кебек ихлас, матур булды»,— дип язып куйганмын ул көнне. Җылы сүз вакытында кирәк. Үзе бит

ул бар илаһи кайнарлыгын җырларына бирә, үзеннән соң халкына калдыра...

Мондый мөнәсәбәткә, санламауга бер ул гына дучар булмады. Дусты Салих Сәйдәшевнең дә җәберләүләр гомерен озайтмагандыр. Фәрит Яруллинның 50 еллыгын хәтерлим. Аның да юбилее дөньяга танылган классик «Шүрәле»се яшәгән төп йортта — опера һәм балет театрында түгел, янәшәдәге Композиторлар союзында гаилә бәйрәме сыман гына уздырылды. Ф.Яруллинның этисе Заһидулла абыйга Җиһановның «аталарча җылы карашлы» роль уйнавын күпләр хәтерлидер.

Бу хәлләрне әле кузгату кирәкме? Яхшы янында яманы да онытылмасын. Йөрәктә сызылган хәтердән җуелмаска тиеш. Әйе, иҗади талант бер нәрсә, кешелеклелек таланты икенче. Гел бергә йөрми шул алар! Заһит абый бәхетле: иманы камил, иҗаты камил, керсез җаннарга тартыла кешеләр. Административ командалык кырыслыгын татыса да, җырларының төсе-тәме үзгәрмәде, ихласлыгын югалтмады. Киресенчә, иҗатчысын халык хәленә якын иткән. Холкы белән дә сынатмас, сер бирмәс кеше иде ул. Җырларында да татарга хас җорлык, хөр күңеллелек, яшәү дәрте ташып тора!

Бездә, «җәмәгать эшлеклесе» дип, югары, түбән киштәләргә бүлеп мавыгу бар. Эшчәнлекнең биеклеге трибуна-мөнбәр, комач өстәлләрдә түгел, «түбәндә» — чын тормышта, халык арасында гамәлгә ашканы кирәк юкса. Заһит абый җыр-көйләре туган бормалы су буйларына тартыла иде. Сәләтленең күңелен күтәрә белә иде:

— Рәхмәт, рәхмәт! — дип, яраткан сүзен кабатлар иде. Мондый киң күңеллелек, һай, сирәк очрый... Үзенә дә бурычлыбыз.

Заһит Хәбибуллинның зур гомерендә иҗат эшчәнлеге киң колачлы һәм үзенчәлекле төрле жанрларда ачылган. Ул әсәрләр мөстәкыйль тормыш белән яши. Аларны барлап, күзаллап карыйсың да, мәдәниятебез казанышы итеп бәяләп, мөгаен, тәкъдир итеп тулы күрсәтә алмаганбыз. Бөекләрне үз биеклегендә күрәсе иде.

*

Иң матур урында өзелгән җыр нинди үкенечле... Шул җырлар чишмәсенең туктап-тынып калуы нинди фаҗига икәнен уйлый башлыйсың.

Кешене соңгы юлга матәм музыкасы озата. Кайбер халыкларда йола бар — җеназада махсус елаучылар була. Музыка шул вазифаны үти. Күңелләрдә әрнү, үксү булып ташып чыга: кайгыны ата-баба догасы урынында юата, сабырлыкка өнди, сафландыра.

Заһит Хәбибуллинны үз көйләре озата. Үзе исән чактагыдан үзгә — моңсулык белән өртелгән сыман. Бигрәк тә скрипка үкси: ятимлекне тирәнрәк кичерә микәнни?! Консерваториянең актлар залы, 1983 елның 24 ноябре. Казан үзенең яраткан композиторы, зур бер тарихи чорда, ярты гасыр диярлек, милләтнең җанын тыңлап иҗат иткән талантлы улы белән хушлаша.

Мәңгегә аерылу минутлары, дөньяви шөгыльләр чырчуын оныттырып, уйландырып ала. Ул минутларда З.Хәбибуллинның соңгы алыплардан берсе икәнне ачык тойдык. Кемнәр китә, нинди шәхесләр, нинди рух һәм җан олылыгы! Скрипка кыллары сыман күпме гомер бергә-янәшә яңгырады алар, үткәннәр кайтавазы булып түгел, яңа чорның үз өне булып яшәячәк!

Дәвам итүче варислар, талантлы исемнәр бар, алар бүтән калып, үзгә дәвер җимеше. Табигать кабатлауга көйләнмәгән... Бер чагыштыру күңелгә килә: Идел буенда, инде төпләре генә калган әллә ничә колачлы, борынгы заманнардан килгәндәй, галәмәт дәү өянке төпләре бар. Сынып, янып әкияти кыяфәтләргә кергән өлешләре вакыт ераклыгын тоярлык итә, аларның кабатланмас икәнлегенә инандыра. Яр буенда сыбызгыга ярарлык сыгылмалы талчыбыклар тирбәлә. Алар да яңа гасырда тегеләр сыман үсәр микән?

Заһит Хәбибуллинның «Скрипка өчен поэма»сы яңгырый. Үзенең кырыс язмышы, шигъри гомере дә скрипка өчен поэма — моңлы да, дәртле дә. Тормышның үзе кебек, иҗатчының үз тормышы кебек!

Безнең көннәрдә берсеннән-берсе гаҗәбрәк фәнни ачышлар, фараз кылулар булып тора. Имеш, кешелек тарихында сөйләнгән-яңгыраган сүзләрнең барысы да галәм хәтерендә саклана икән... Ул кадәресе ничектер, әмма кешелек хәтере дигән — Җирдәге галәм бар. Бусына ышанам, анда сүзләр-фикерләр дә, музыкаль аһәңнәр дә югалмый — милләт яшәгәндә моңы, җырлары яши. Алар арасында Заһит Хәбибуллинның көйгә күчеп калган гомере — күңеле дә бар.

*Гыйнвар, 1990.*

## *Илаһи Илһам*

### Илһамлы язлар

Өч студент Мәскәүдән кайтып киләбез. Илһам Шакиров белән Фасил Әхмәтовның консерваториядә, минем Югары әдәби курсларда укыган чагым. Тукай клубында иҗат кичем буласы, шул чакыру белән кайтам. «Художество бүлеге»н ничек оештырырга? Дуслар-юлдашлар шул хакта кайгырта.

— «Утыр әле яннарыма», «Шалт, Мөхәммәтҗан»... Болар янына өр-яңа җыр да кирәк бу көнгә! — диде Илһам. Фасил дә күтәреп алды:

— Кызык булыр!

— Син музыкасын язасың, мин — җырлыйм! — дип рольләрне бүлеп куйды Илһам.— Хәзер бер шигырь табып бирәм!

— Ничә генә көн калды, син нәрсә, Илһам, шаяртасыңмы?

— Кызык дигәнең шул булыр — өлгертәсең, Фасил! Язмасаң мин җырлый алмыйм бит! — дип рәхәтләнеп көлде дә, эзләгәнен тапты:

— Менә «Тамчылар тамар чаклар»,— бигрәк туры килеп тора! — дип, тамчылар сыланган поезд тәрәзәсенә ымлады.

1960 елның 28 апрелендә булды минем кичә. Истә калганы шул: Фасилнең яңа җырын Илһам беренче тапкыр сәхнәдән халыкка җиткерде:

— Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар,
Бергә булган вакытларны
Сәгатьләп санар чаклар...

Моңнары күңелне кузгатты, минем бит яңадан Мәскәүгә китәсе, сагынасы, юксынасы — «язларында ялгыз йөрсәң, йөрәкләр яна инде...» 1958 елда Кама буенда язылган шигырьгә көй дә әнә шулай язын туды.

1959 елның язында бер төркем артистлар, язучылар, Илһам белән бергәләп, Тукай-Кырлайда, Кенәр якларында булдык. Шигъриятебез кәгъбәсенә икенче сәфәребез иде бу. Шул тәэсирләр белән берничә шигырь дә яздым. «Сөенечкә дисәм»не Илһам күргән дә, җыр өчен азагын үзгәртүне сорый:

Арта уйлар һаман,
Тарта сиңа табан,
Кыен миңа ялгыз көннәрдә.
Сөенечкә дисәм,
Көенечкә икән
Сине очратуым Кенәрдә,—

дисең. Кенәргә бәйләп куйма, һәркем һәркайда үзенеке итеп җырларлык булсын!

— Ярар, уйлап карармын,— дигән булдым, кагыласы килми иде ул сүзләргә.

— Хәзер үк кирәк. Көе бар, гастрольгә алып чыгам. Ә менә болай булса: «Кыен миңа ялгыз чакларда... Күрешүләр сезнең якларда...»

— Көен таптың, шигырьгә дә өлешең керде, рәхмәт!

Моңсу бу җыр белән Илһам миңа сөенеч китерде. Ул җырны әле дә тыныч кына тыңлый алмыйм. Әмма кем җырласа да Илһамны ишетәм — күңелгә ул язылган. Атаклы композиторыбыз Җәүдәт Фәйзи күңеленә дә хуш килгән Илһам аһәңе белән кергән бу җыр. «Халык җәүһәрләре» дигән китабында «Сөенечкә дисәм»гә мондый искәрмә бар: «Шәүкәт Галиев шигыре белән җырлана торган бу көй үзенең мелизмнарга бай булуы, ритмик төрлелеге, настроениесенең дәртле булуы белән иске көйләр традициясен дәвам иттерә. Бу җырны мин беренче Илһам Шакиров башкаруында ишеттем».

1961 елның апреле, язларның рәттән дүртенчесе дә истәлекле булды. Әтнәгә, Тукайның 75 еллык бәйрәменә барырга чыктык, анда Илһамны бик көтәләр. Бозлы-сулы, юллар өзелгән чак, трактор тартып та машиналар уза алмый. Дөбьязга кире кайттык. Анда да Тукайга багышланган кичә икән. Илһамны күргәч, чат ябыштылар, клуб тулы халык, нишләмәк кирәк, монда үткәрдек. Ул арада Әтнәдән өч машина белән райком секретаре Хәниф Сафиуллин килеп төште. Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк иде ул чагында, бата-чума, йөзә-калка дигәндәй, шушы кешенең гайрәте белән Әтнәгә барып та ирештек. Төн уртасы, клуб яны тып-тын, бер кеше күренми. Көткән-көткән дә, таралгандыр халык...

— Безнең кешеләрне белмисез әле сез! — диде секретарь. Клуб ишеген ачсак, шыгрым тулы, сабыр гына көтеп утыра егетләр, кызлар, апалар, абзыйлар, хәтта балалар да бар. Алкышлап каршыладылар. Озак барды ул кичә. Тукай рухы көч бирде. Илһам җырлары канатлан-

дырды. Кешеләрнең мәхәббәтле карашын күреп шигырь укуы да рәхәт, һәр сүзеңнең җыр дулкыны белән барып җитүен күрәсең.

Менә шулай, онытылмас язлар булды. Илһамлы язлар! «Яшьлек яздай шаулар-китәр», дип җырлаган иҗат кичәмдә яраткан җырчыбызга егерме ике генә яшь иде. Еллар үтә, әмма ул чактагы Илһам, бу чактагы Илһам дип бүлгәли алмыйм — гомергә бөек моң иясе ул, милләт күңеленең илһамлы язы, яшьлеге.

## Алтын сәгатьне кем отты?

«Уналты метр»да сигезәү яшибез. Гаиләбезгә фатир тар булса да, күңел киң — форсат чыкканда дуслар, туганнар җыела. Барыбыз да җыр-моң белән бертуганнар. Илдар Юзеев көйләрне шигъри күңеле белән баетып, дәртләнеп-канатланып гармун суза. Бу юлы Илһам Шакиров та килде. Үзе вакыйга ла, үзе бәйрәм, күңелле табыныбыз. Җырла, дип ашыктырмыйбыз, көткәнне беләә. Бер мәлне ул торды, шкафка таянып җыр башлады. Бүлмә — кечкенә, тавыш — зур. Йөгәнләгән, тыйган сыман кулын алдына тотып җырлый. Буйсынмый җыр, канатланып иркенгә атлыга. Илһамның да, безнең дә авылдан килгәнгә алты гына ел, үзебез дә таш читлеккә ябылган җыр-кош сыман... Рәхмәт Илһамга, диварларны тылсым иясе дәй як-якка этәреп, сагынган, ашкынган иркенлеккә алып чыкты! Дөньябызны онытып тыңлыйбыз. Яшә, туган, татар җаны синең моңыңда. Илһам уңайсызланып ишеккә карый — күршеләр ни әйтер, дидер. Чыннан да, җыр тынуга ишек шакыдылар. Бер хатын чакыра, таныш та сыман, нинди ашыгыч йомыш микән?

— Гафу... Теге подъездан мин, беләсездер — Нурания... Илһам Шакиров пластинкасын уйнатасызмы?

Ашыгыч йомыш икән... Ни дисең инде моңа?

— Үзе монда ул.

— Алайса, алтын сәгать минеке!

Аптырап калганны күргәч,ашыгып сөйли башлый:

— Үлепләр яратам Илһам җырлаганны! Ишеттем дә, әйтәм иремә, безнең йортта Илһам җырлый!

— Каян килсен, радиодандыр,— ди.

— Бу вакытта Казан сөйләми,— дим.

— Пластинкадыр.

— Илһам үзе! Әйдә, бәхәс!

— Түгел,— ди ирем,— башымны кисәргә бирәм.

— Башың сау булсын, икебезгә дә кирәк булыр. Алтын сәгать алып бирәсең! «Алам»,— диде. Урамга чыгып, Илһам тавышын тыңлый-тыңлый килдек. Тәки таптык!

Кем әйтмешли, Нураниянең сөенече эченә сыймый.

— Зинһар, ишек ярыгыннан булса да, Илһамны күрик әле, ирем ышансын.

Коридорда икән ире дә, табынга чакырдык.

— Рәхмәт, Илһам, алтын сәгатьле иттең,— диде чая хатын.— Җырлы истәлек булды бу, караган саен сине уйларбыз!

Бәхетле иде ул. Алтын сәгатьтән бигрәк, яраткан җырчыны якыннан күрүе белән бәхетле иде. Ире дә сөенгән, бер дә оттырган кешегә охшамаган. Хәер, оттырмады ла. Барыбыз да алтын сәгать оттык ул көнне. Илһам белән бергә узган алтын сәгатьле булдык. Яңа кунакларның ымсынып, өметләнеп көткәнен күрә, янәдән шкафка таянып, тавышын кулы белән тыярга теләп җырлады Илһам:

— Кадерен белгән кешегә
Минутлап санар чаклар...

Алтын сәгатьләр була. Әмма гомернең алтын минутлары кадерлерәк. 1960 елның җәе иде...

### «Ишеттем мин читтә «Туган тел»не...»

Мәскәүдәге тулай торакта бүлмәм Казандагы фатирым чаклы. Бүлмә тулы аулак! Сөенә-сөенә язам, мондый форсат чыкканы юк иде. Ике ел шушындый хөррият көтә! Берзаман шигырь дә арый, шул чакларда иң читене. Иҗатның менә шушы хәле-халәте үзеңне сыгып алганнан соң калган бушлыгы авыр. Ике ел шушындый газап көтә бит әле.

Әле генә күңелем күкнең җиденче катында иде, инде тулай торакның җиденче катында, аста — бушлык. Әрлебирле йөренәм. Әллә радио тоташтырасы? Монда шул өзмәс-куймас русча булыр, бер кәлимә сүз татарча юк. Гомер буе читтә яшәгәннәр хәлен аңларсың... Силос салу, дуңгыз карау турында булса да үзебезчә сөйләсә икән! Радионы боруым булды, ни могҗиза — бүлмәмә газиз моңнар агылды! «Туган тел» — Илһам җырлый! Ишек

яңагына сөялдем дә, җыр иркенә бирелеп тыңлыйм, яңагымнан тамчы тәгәри, сизәм...

Ишеттем мин читтә «Туган тел»не,
Халкым, нинди моңлы көең бар...
Тукаемны йотылып тыңлаганда
Тамагымда кайнар төен бар.

Кем ничектер, әмма мин бу җырны
Тыңлыйм да гына тыңлыйм, туялмыйм.
Әсәрләнәм сабый бала кебек,
Ир булсам да яшем тыялмыйм!

Тукаемны йотылып тыңлаганда, Илһамымны йотылып тыңлаганда... Баксана, шигырь язганымны сизми дә калганмын! Илһам җыры белән илһам килгән. Шигыремнең өстенә «Илһам Шакировка» дип багышлап куйдым. Бигрәк үзәкләрне өзеп, күңелләрне нечкәртеп җибәрә шул «Туган тел». Бу җыр, бу моң дөньяга сибелгән канкардәшләрне барлап-юатып йөри, терәк-таяныч булып көч бирә. Туган як дигән кыйблаңа карап иман яңарттырган дога булып дәшә, югалмагыз, югалтмагыз туган телне, дип туплый! Теле киселеп, манаралар тынган елларда азан авазыдай моң йөргән, өметен җуйган татарны да уятып моң илчесе Илһамыбыз йөргән. Моңы белән саклап калды ул милләтне. Гомер буе юл газаплары чигеп кайларда гына булмаган ул, татар бар җирдә Илһам булган, җанга дәрт-дәрман биргән. Туган телгә бетү куркынычы янаган, һәркем тел яшергән афәтле елларда Илһам Шакиров сәхнәләрдән өндәп йөрде:

— Туган телне онытмагыз! Туган якка кайтыгыз!

Ах, шул чакларда колак салган булсалар, бүгенге качаклар агымы бу чаклы ук булмас та иде дип уйлыйсың...

Курыкмый-тайчанмый, үзенә хас турылык белән авыз тутырып әйткән ул, туң йөрәкләрне эретерлек итеп җырлап та әйткән. Бу сүзләрнең кайтавазы таулар-үзәннәрдә генә яңгырап калмаган, Казандагы кызыл флаглы биек бинага җырчының үзеннән алда кайтып ирешкән — ялланган «күз-колаклар» җитез эшли! Кисәтәләр Илһамны:

— Сәхнәдә син җырла гына, сөйләмә,— диләр төче елмаеп, ә күзләре салкын, күзләрендә моң юк, сүзләре Мәскәү телендә...

Сөйләмә, җырла гына. Җырчы авызына да цензура бар... Илһамның сүзсез җыры күбрәк сөйләми микән әле? Әнә нинди әчке әрнешү, иңрәү белән көйли ул —

туган телне аңлаган күңелгә моң күбрәк әйтә ул, тел белмәгәннәр дә аңларлык. Моң телен онытмаганнар әле.

Мин Сәйдәшне күреп беләм. «Чаян» редакциясенә кереп утыра иде. Юмор-сатира иреге булган бу почмакта бик мәгълүм әһелләребез була. Берәүләр нидер сөйли, ә ул тын гына утыра иде, ирен читләрендә сизелер-сизелмәс елмаю тирбәлеп ала. Моңнары белән сөйләгән, илгә шаулатып әйткән лә! Күңел күзе диләр, күңел «колагы» да бар — җаны саңгырау булмаганнар ишеткән. Үзе исән чакта бөеклеген халык таныган шәхесләр сирәк була. Безнең буын гомерендә, безнең гасырда да аз алар. Илһамда Сәйдәш язмышы кабатланмыйммы? Һәммәсе ил күзендә — баш бирмәслеге, яратмавы өчен үчегеп югары даирәләр «югары» исем өләшкәндә читләп үтсә дә, халкыбыз үз җырчысын мәхәббәте белән олылады. Сәйдәше язмышын уйлый-уйлый Илһамын яратты, иманын яңартты.

Уйлыйсың, уйланасың... Үз җиреңдә изгеләр булмый, дигән урыс. Татарның булмый да булмый инде. Әнә Рудольф Нуриев чикләр аша сикереп дөньяга күренде. Аякларның «теле» интернациональ шул, «милләтем минем — сәхнә» ди... Җыр-моң туган телдә генә «бии», безнең кошлар җылы якта да сайрамый. Якташыбыз атаклы Шаляпин да ностальгия — туган җирен сагынудан үлгән. Туган җиребезне зурлап, оча-оча сайраган бердәнбер кошкай — тургайның кадерен белик...

Читтә зарыкканнар хәлен үз башына төшкәннәр генә белә дә, гомере буе күреп өзгәләнгән сизгер бәгырь — Илһам белә... Каян килә җырларына мондый илаһи моң дисәң,— өнсез меңнәрнең, бүгенгенең, үткәннәрнең,— милләт авазы ул...

Бөек уллар тудырган халык бөекме? Бөек улларының кадерен белгән милләт бөек! Бөек була бел татар, сине үлемсез иткән улларың да озак яшәрлек булсын!

> ...Илһамымны йотылып тыңлаганда
> Тамагымда кайнар төен бар...

### Язылмаган җырлар

Ә беркөнне, тавышы яңгыраган Мәскәүдәге бүлмәмә Илһам үзе килеп керде! Шигъри илһамны — каләмне куеп торып сөйләшкән мәгънәле кичә булды.

— «Әткәйгә хат» поэмасын яздың, әткәйләр турында җырны да син язарга тиеш! — ди. Без бер язмыш ке-

шеләре шул, сугыш чоры газапларын тылда күрдек. Ил тулы сагыш, моң иде ул елларда.

— Әнкәй белән чабата ясап утырган озын кичләрдә озын-озын көйләргә җырлый идек,— дип искә алды Илһам. Моңлы бала бәхетсез була, диләр иде, бәхетле бала да моңлы була икән — бәхетен монда тапты ул. Шаяртып та өстәмәсә, Илһам буламы, көлеп куя:

— Җырлап тамак туймас, эшеңне онытма! — ди иде әнкәй ул чакта. Хәзер эшем шул. Әнкәй дә орышмый...

Илһамны тыңлыйм, аның белән сөйләшүе рәхәт, җаның ачылып китә. Эчендәге — тышында, диләр мондый ихласлык турында. Эчендәге моңы — тышында — моңына тәңгәл шәхес ул — нәфислек, затлылык хас аңа. Сөйләвен тыңлыйм да:

— Илһам, син бит — язучы, боларны язарга тиеш! Кәгазьгә төшерәсе генә калган! — дип үзен кыстыйм. Нияте дә юк түгел, повесть турында уйлавын әйтте. Кызганыч, Мәскәүдәге ул очрашу турында теркәп куймаганмын. Онытылмас очрашуның да бар сүзләре дә истә калмый икән. Ә менә алты елдан — 1966 елның октябрендә Казанда очрашу хакында кыскача язмам бар: «Илһам Шакиров белән очрашырга сүз куешкан идек — яңа программа әзерли. Яңа җырлар кирәк, ди, җыр язарга өнди. Темаларын, нәсер дәрәҗәсендә, детальләренә хәтле уйлаган. Үзе шагыйрь егет! Сөйләгәндә тәэсирләнә, күзләренә яшьләр килә.

— «Тыңладым мин тургай җырларын», дип исемләргә була берсен...

Җир яшәрә... Күктә тургайлар. Алар җырын мин аңлыйм. Менә нәрсә дип җырлый алар: «Күктә үзебез генә буласыбыз килә. Шомлы козгыннар очмасын иде. Без иркенлек, тынлык яратабыз. Без бу юлларның шаһитлары булып гомер-гомергә өстән карап очабыз. Барысы да безнең күз алдында...

Авыр елларда — черегән башак, бәрәңге чүпләп балалар йөрде монда. Шуны ашап агуланган аналар егылып калды.

Сугышка китүчеләрне, басу капкасын чыккач, озатучылар туктап калганнан соң, без озата бардык.

Әнә авыл читеннән бер карчык чыгып килә. Алты улы китте аның. Берсенең дә кайтканын күрмәдек. Җиденчесе — ире... Улларын, ирен каршыларга чыккан ул кар-

чыкны гел күрәбез. Шомлы җырлар җырлыйсыбыз килми. Шатлыклы моңнар сузасыбыз килә. Шатлыклы моңнар.

Икенчесе — «Арышлар дулкынлана». Арыш арасында йөргәндә синең бер кайгың да юк. Хет ятып үл!.. Арышлар нәрсә сөйли? Миллионлаган кулларын изәп сине әллә кайларга чакыралар кебек. Алар болай диләр: «Без булсак — сез дә яшәрсез. Сугыш вакытында нарасыйлар, аналар, без үскәнне көн саен карап йөрделәр. Безнең үскәнне көтеп күзләре күгәрде.

Бернинди көйче дә мәңге көйләмәгән көйне көйли алар.

Аларны әле отып алып булмый...

Безнең хәзер иңнәр — иңнәргә терәлгән, ызаннар белән аерылмаган без».

Өченчесе: «Ватаным минем». Нәрсә өчен ярата кеше туган җирен? Бабаңның туфрагыннан үлән үскән. Әткәң каны шушы туфракка тамган. Абыең кабере кайда икәнен дә белмисең... Ни өчен газиз бу җир? Болгарым, син ни өчен якын? Һәйкәлләрен яхшы белсә кеше туган җирен ярата. Кайбер уйсыз яшьләрнең дә күңеленә үтәсе иде...

Октябрьнең 50 еллыгына багышлап дисәләр дә, лаф орулы, ялган пафослы җырларга йөз тотмавы ошады. Илһам боларны санап чыкты да:

— Мәскәүдәге бурычың да өстәлә,— дип куйды.

— Нинди бурыч?

— Әтиләр турында җыр да тиеш бит әле синнән!

Мин дә, шаярткан булып, ниятләгән повестен искә төшерәм. Юл-сәфәрдән кайтып кермәгән артист тормышы әдәби иҗатка көйләмидер шул. Радиодан чыгышларын тыңлап, мәкаләләрен укып, күреп торам — җыр хакына язучы талантын корбан итә. Кеше бер максатка бар булганын бирергә тиеш шул, бар гомерен. Шулай да өметне өзмим әле, микрофонга күнеккән бармаклар каләм алыр, дим...

Илһам сүзе гел истә. Әткәйләр турында җыр кирәк иде. Роберт Миңнуллинның әнкәйләр турында яңаданяңа җырлары илгә танылган саен уйлап куя идем: изге хөрмәт-ихтирам, яратуның икенче канаты турында да җыр булсын иде. Сизгер җанлы композитор Әкрәм Даутов та уйланган икән, ул да әнкәйләр турында җанга якын җырлар язган кеше бит. «Әткәйгә хат» поэмасыннан өзек алып көй дә язган иде, миннән җавап көтте. Кызганыч, шартын үтәп булмады, әткәйгә әйтелгән

сүзләрне үзгәртә алмадым. Рәхмәт төшкере, Роберт дустым күңелемдә торган бурычтан коткарды — гармун уйнаган этисе турында язылган җырында уртак сагышыбыз, югалту-әрнүебез...

### Тост

«Яшь ленинчы» редакциясе истәлекле бәйрәменә чакырды, 1971 ел — гәҗитнең яңадан чыга башлавына ун ел тулды. Күңелле табын: Илдар Юзеев, Гәрәй Рәхим, Роберт Батуллин, Марс Шабаев, Ренат Харислар булсын да, түрдә мөлаем елмаеп хуҗабикә-редактор Венера Ихсанова утырсын да, күңелле булмасын ди! Иң кадерле кунак — Илһам Шакиров, ихлас, көләч егет, редакциянең, барыбызның уртак дусты. Бик дустанә табын, үзара мөнәсәбәт бик гадәти, әмма Илһамны ничек кенә гади булмасын, илаһи олылыгын, талантын, шәхес зурлыгын тоеп торасың. Әдипләр — тел бистәләре җыелган табында көтелмәгән кызыклар күп була. Шулай да сүзнең үз урыны, җырның үз вакыты — Илһам җырлаганны көтәбез. Менә ул торып басты, елмаеп тамак кырды:

— Гел җырларга димәгән, сөйлим әле... Бер елны авылга кайткач, агайне малаен — энекәшне алып килдем. Бик шәһәр күрәсе килә. Әйдә, минәйтәм, рәхәтлән, теләгән җireңә алып барам! Цирккамы? Зоопарк дисеңме? Парктагы «көлке бүлмәсе»нәме? Малаемның күзләре елтырап китте: «Аю да, маймыл да түгел, син миңа Шәвәлине күрсәт»,— ди...

Энекәше турында сөйләде дә, көтмәгәндә Шәвәлинең «этисе»нә атап тост әйтте Илһам... Ни дигәнен инде хәтерләмим, мактаганны шунда ук оныта торган гадәтем бар. Уңайсызланып, шаяртуга бордым:

— Илһам Шакировка җавап нотасы,— дигән булып, туган телне яраткан укучылар — «Илһам энекәшләре»нә исәнлек теләдем, алар яшәсә — без яшәрбез!

Бик тыйнак идем шул ул чакта — Шәвәли сыман. Инде менә вакыт узгач мактанам бугай — атаклы җырчыбызның бәһасе бит ул!

Дөрес, ул күтәргән касәдә минераль су иде. Кыстамадык: безнең өчен тавышын саклый ла — сүзен җыр белән тәмамлады.

Балалар ихлас күңелгә тартыла, энекәше дә шул җылы-җырлы карашны тоеп Казанга килгәндер. Илһ-

амга мин дә балалар өчен язылган китапларны бүләк иттем. Ул чакта җиде яшьлек Шәвәли җиде китапка кереп өлгергән иде.

**«Кара да гынай урман...»**

Шөкер, моң чишмәсе саекмай, милләт күңеле бай, яңадан-яңа җырчылар күтәрелә, яратканнары да бар. Әмма ишетүгә йөрәгең дерт итеп киткәне, тылсымлы көч белән ияртеккәне, күңелне көйләгәне сирәктер. Нинди могҗиза бу аһәңдә? Хикмәт — сердә, сер — хикмәттә, талант —табышмак ул. Моңында гасырлардан килгән йөрәк хәбәре, тарих авазы, борынгылар эндәшүе: әрнү— иңрәү һәм мәхәббәт сагышлары, язмышлар, дәрте-дәрманы көйгә күчеп ерак киләчәктә — бүген яңгыравы. Борынгы моңнарда халыкның җаны, үлемсезлеге...

1976 елны Ригада Домский соборда орган тыңлаганым онытылмас. Куәтле аһәңнәр белән рухың күкләргә ашып канатлана! Бах, Гайдн, Брамс, Моцарт әсәрләре башкарылды. Органны тыңлыйм, үзем «Карурман»ны сагынам, Илһам Шакиров — үзе кодрәтле орган икән, йа Аллам, шушы биек гөмбәзләрне тетрәтерлек рух бар бит аңарда. Тыңлаган саен гаҗәпкә калам — «Карурман»ны музыкасыз җырлаганда берүзе оркестр лабаса!

Экстрасенслар дип шашалар, татар күңелен Илһамдай көйләгән, моң-иманны яңарткан көч бармыни ул! Әнә нинди бердәм талпыну белән күтәрелде зал: алкыш аккошларын кулларыннан очырды! Күзләр яшьләнгән, күңелләр сафланган мизгелләр... Мондый тәэсирне мин сәхнәдәге Сәйдәшне алкышлаганда кичергән идем. Бәхетле минутлар, бәхетле замандашлар, бәхетле Сәйдәш! Натан Рахлин дирижерлык иткән «Совет армиясе маршы»ннан соң да Камал театрында шундый триумф кабатланды. Татарның егерменче гасырдагы җыр-музыкасындагы бөек уллары — Сәйдәш, Илһам...

«Иске карурман»ның искермәү сере — әлмисактан бирле өзмичә, буыннан-буынга тапшырып килүче моң ияләрендә. Тагын бер хикмәте шундадыр: «Кара да гынай урман, караңгы төн»,— гаҗәеп күтәренке рухлы, авырлыкка бирешмәскә, чорлар карурманында юл ярып барырга чакырган маяк та ул!

Урман эчләрендә урман, дигәндәй, «Кара урман»ның бүтәнендә бу мотив тагын да ачыклана: «Типсен йөрәк,

сүнмәсен дәрт, дәртлеләргә якты юллар бар». Бу гыйбарәне мин девизым итеп көйлим... «Зәңгәр шәл»дәге «Кара урман» да Сәйдәшнеке, Илһамныкы. Кәрим Тинчуринга «Кара урман шаулый, эчтә ут кайный», «Кара йөрәк патша» дигән сүзләрне дә гаепкә санап, хөкем иткәннәрдер...

Тау ягының радио-телефонсыз карурманнар арасында яшәгән авылга безнең — Олы Бакырчыга да, әле без бала чакта, бер хәбәр килеп ирешкән иде:

— Гөлсем Сөләйманова ник ишетелми дисәң, «Заманалар авыр, еллар ябык» дип, элеккечә җырлап җибәргән ди, шуңа туктатканнар...

Булган икән андый хәл дә. Әмма җыр өзелмәде, милләтнең яңа Илһамы күтәреп алды, татарның яшел байрагы ул җыр, елның-елында яңарып торган яшел карурманы!

Борынгыдан килгән Гимн-Җырлар... Әнә җырчылар бәйгесендә «Карурман» белән «Гөлҗамал»ны башкару беренче шарт итеп куелган. Илһам Шакиров тәкъдим иткән моны — эстафета дәвам итсен!

## Хәтерсезлек хәтәр

«...татар дөньясын таң калдырган легендар җырчы...», «Аның исеме халык теленнән төшми...», «...бөеклегенә сокланып искә алалар», «милләтебезне милләт итүче зур шәхес». Рәшит Ваһапов турында Илһам Шакиров сүзләре бу. «Ул бөек җырчы иде» исемле мәкаләсе «Татарстан хәбәрләре»ндә чыкты. Бер җырчының икенчесен шулай зурлаганы бар микән? Моның өчен үзең дә олы җанлы булырга кирәк! Кайгыртып, борчылып язды Илһам. «Башка халыкларда андый җырчылар исеме белән урамнар атала, сәнгать оешмаларына исемнәр кушалар, һәйкәлләр салалар, мемориаль такталар куялар». Рәшит Ваһапов онытылган...

Исән чакта кадерен белдекме соң? Гастрольдән кайткач ул да «Чаян»га кереп ял итә торган иде. Егетләрчә каш сикертеп елмаюын, кызыклар сөйләвен көтеп алабыз. Берсендә шулай, Урта Азиядә уңышлы сәфәрдән соң, таныш җырчыда кунакта булуын сөйләде: квартирасында бүлмәләр адашырлык, өстәвенә, ничә катлы дачакоттеджы, искитмәле икән... Моннан соң ул күренми торды.

— Бу юлы кайларда булдыгыз? — дип сорыйм килгәч.

— Өйдә яттым...качып! Ташкенттан теге җырчы килгән иде. Кунак ашы — кара каршы, дияр чакта өйдә утырдым,— диде ачынып.— Кая анда чакыру — фатирны күрсәтергә оят, гарьлек — прокатка алган пианино бердәнбер бүлмәне тутырган... И-и, татарның хәле, димәсеннәр әле...

Сер бирмәскә тырышса да, елмаюы сүрелгән иде...

Күп тә үтмәде, атаклы җырчыбыз вафат булды. Ә үзе радиодан дәртләнеп-канатланып җырлый... Үлгәч тә халыкка хезмәт итә талант иясе. Бәгырьләр телгәләнеп тыңлыйм — күңелгә тулышкан сагышым шигырь юлларына сыймый. Ахыр чиктә, язганнарымны аркылы-торкылы сызып, ике юлын гына калдырдым:

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел!

1963 елның 16 мартында яздым, килер елның 15 ноябрь санында гына «Социалистик Татарстан» гәҗитендә басылып чыкты. Мөстәкыйль шигырьгә санамыйча матбугатка бирми тордым, анда да, акланган сыман, исемен «Нәсихәт» дип куйдым...

Шигырь язылганнан соң утыз ел узды, мәкаль-әйтем булып телгә керде, Рәшит Ваһапов исәннәр рәтеннән һаман да моңлы яңгырый, яратып, юксынып тыңлыйбыз. «Моңа кадәр Рәшит Ваһаповның сәнгатьтә булган олы әһәмиятен онытып торуыбыз безнең хөкүмәтебезнең зур хатасы»,— дигән иде Илһам Шакиров әлеге мәкаләсендә. «Моңа кадәр...» Моннан соң, шәт, үзгәреш булыр инде...»

«Ул бөек җырчы иде» дигән язмадан туган тагын бер уемны әйтми калдыра алмыйм. Милләткә хезмәт итүдә Рәшит Ваһапов турында әйтелгән «легендар», «титаник эш», «бөек җырчы» дигән сүзләрне Илһам Шакировның нәкъ менә үзенә төбәп әйтергә була. Шулай ук кадерен белеп җиткермәвебез дә туры килеп тора.

## Дәгъвәлигә җавап

Гомер буе ил күзендә, сәхнә яктысында. Яратып, һәр хәрәкәтен, тын алуына чаклы йотылып күзәтәләр. Гомер буе тансык бул, көтеп алсыннар... Ә бит, ярарга тырыша торгач, арзанаеп, җыры да, үзе дә сәхнәдән төшеп калганнар аз булдымы? Сикеренгәләп, күзгә төтен-томан җиб-

әреп ниләр генә кыланып бетмиләр. Вагон-вагон техник җайланмалар төягән сәхнә индустриясе барлыкка килде. Җырга ялгап, җәлеп итеп шәрә кызлар мәш килә...

Илһам хәрәкәткә саран, тән хәрәкәте түгел, җан хәрәкәте аның максаты — барысы да моңында. Ничә тыңласаң да өр-яңа тәэсир, кадерле, якын. Биргән икән Хода талант дигән могҗизаны татарның моңлы баласына. Бу күркәм затлылык, сафлык, инсафлык... Адәм фәрештә булмас, ә менә аңардан шуны көтәләр, таләп итәләр!

...Ул кеше белән без мәктәптә очраштык. Малае баянда уйный, шуны озата килгән. Таксида эшли. Исемен сорамадым, тыңлый торгач, Дәгъвәли дип куштым.

— Артист халкын беләм мин! Илһам Шакировны өенә кайтарганым бар. Бик йончылган иде...

— Гастрольдән кайтуыдыр?

— Һе, беләбез инде! — ди Дәгъвәли кистереп.

— Бәя биргәндә иң әүвәл шәхесен, илһамлы хезмәтен — бөеклеген күрү кирәк! Яратабыз, сокланабыз, рәхәтләнәбез — ул безгә бар күңелен сыгып бирә, үзе бушап кала, иҗат кешесен беләм. Шундый чакта читен аңа! Саудык, саудык та, түбәнсетәбезме?! Ни гаҗәп — ятратканына үчле кеше. Илгә танылганнарны гаепләү дә җиңел — һәркем белә, ахрысы, яшерен көнләшүе чыга: син дә безнең сыман икән, ди.

Җавабым Дәгъвәлигә генә түгел, яшь укытучы кыз да бар, аның өчен дә әйтүем. Дәгъвәли киреләнеп, үз дигәнендә тора:

— Ә икенче юлы — кәефле иде! Артист халкын беләм мин.

— Кәефсез дә — гаепле, кәефле дә — гаепле. Кызык сез, агайне! Коточкыч юлларда ватылып — ул бит такси җилдергән такыр түгел — кадерсез гомер уздыра җырчыларыбыз. Татарның кабатланмас моңлы авазы бит ул Илһам! Әнә мәркәзнең опера җырчылары йомшак шарфларга уралып, авыз-борынны томалап, өф-ф итеп кенә саклый тавышын!

Моны мин Дәгъвәлинең сүзсез генә чыгып баскан малае өчен дә әйтәм. Әтисе сүзе булса да — гайбәткә ышанмасын, дим. Хәер, бер генә ишетмәгәндер, үз уе бардыр баланың, тикмәгә баянга ябышмаган.

Талантына тиң түземлек тә биргән табигать Илһамга. Гомерлек сәфәрдә нинди хәлләргә тарымаган, юлыкма-

ган дисең. Хәтер калыр, рәнҗер чаклар да булгандыр. Изге күңел шуларга да ярату белән җавап биргән, моңын саклый алган.

Теләнче Тамакка барганда юлдашлар карлы басулар артындагы авылга күрсәтте:

— Илһам Шакиров авылы «Яңа бүләк» шунда гына!

Горурланып әйттеләр. Аннары, сөйләгән бер вакыйганы ишеткәч, озак тынычлана алмадым...

— Бер авылга Илһам Шакиров килгән. Колхоз сатып алган концерт, өч авылдан җыелганнар, клубка сыймыйлар.

— Давай урамга! — дип даулыйлар. Кышкы салкында бит, артистлар ризалашмый. Автобусны чолгап ала яшьләр:

— Җибәрмибез! Тәрәзәгезне коябыз! — дип әтәчләнүчеләр дә була. Ахыр чиктә «җиңәләр» — концерт урамда була...

Белеп сөйлиләр, булган хәлдер. Менә шундый ул кайбер кеше, акча түләгән вакытка артистны сатып алдымга саный. Андыйлар рухны тиен белән үлчи. Халыкны ничек бар шулай күрергә кирәк. Тормыш кырыс, тупас шул... Казанга барып, «Илһам» җыр театрында гына күрә алсалар, кадерле булыр иде!

Шундый уйлар белән сыкранып кайттым. Күпмедер вакытлар узгач, үпкәм таралды, ачулы күңел эреде — ашыгыбрак гаепләдем бугай. Кирәкми, тыңламыйбыз, дип кумаганнар лабаса, сагынып, тансыклап киткәнгә, нәкъ менә үзләрендә якыннан күреп тыңлыйсылары килгән. «Бездә Илһам булды, мин дә күрдем!» — дип мактаныр өчен дә. Демократия заманы бит, чыгырдан чыгулар да булыр инде.

Нәфис моңны сакларга да ныклык кирәк шул. Тимерче малаенда бар икән ул. Тормыш сандалга салып сынаганда да бирешмәгән, нәфислек белән җиңә килгән...

Гүзәллек дөньяны коткарыр, дигән гыйбарә хак бит. Әнә карагыз, җырчыларын тыңларга ничек ябырылып йөри безнең халык. Җанына тынычлык эзләп моңга сыена, рухы сафланырга килә. «Җырлап ачыла күңел» — җырда ачыла күңел. Татар җырының берсендә дә усаллык юк. Бу да замана тупаслыгын нәфислек белән җиңү. Нинди ихлас соклану, ярату белән тыңлыйлар, йөзләрчә мөлаем карашлар җырчыга текәлгән. Залга агылган сихри

моңнар рәхмәтле күңелләрдән изге хисләр булып сәхнәгә кайта. Җырны мәхәббәт тудыра, җырчыны милләт мәхәббәте яшәтә. Без Илһам замандашлары булу белән бәхетлебез.

## Илһамны тыңлаганда

(Төрле еллар дәфтәреннән)

Бу минутларда дөнья тулы моң. Җаныңа аваздаш, күңелдәш моң...

1962.

Туган җиргә җитеп килгәндә, җыры поездда каршылады. Сагынып зарыккан күңел тулып ташыды.

1969.

Атаклы җырчыбызның исеме Илһам булуы бик мәгънәле фал. Тукай, Сәйдәшләрнең рухи игезәге ул.

1985.

Халкымның җырлары югалса, җирдә яшәргә теләмәс идем. Моң булмаганда күңелең ни суласын, ничек тереклек итмәк кирәк?

1986.

Бу арада Илһамны радио-телевидение безнең белән сирәк очраштыра. Сәйдәшне дә аз тапшыралар, дип язган иде бер абзый. Сәнгать әһелләрен халык мәхәббәте дәрәҗәсендә зурларга кирәк.

1987.

Җыр — иң үтемлесе, телен оныткан да көйли әле. Иң соңгы җыр бердәнбер көнне чынлап өзелерме? Ә бит тынган милләтләр бар инде... Илһамнары барда — югалмас!

1988 .

Тереклек ияләре аваз бирмәсме дип, галәмнән җавап көтәбез. Үткәннәрдән хәбәр килә — борынгы көйләрдә ул. Моң-аһәңдә кан дәшүе бар, мәгънәсе сүзләрдә генә түгел, тойгы кабынуында. Җырчы тавышындагы өзгәләнү шулкадәр әсәрләндермәс иде...

1991.

Ашыгып туган җырлар телдән тиз төшә — сагыздай әвәләп ташлыйлар. Җырчылары да онытыла. Милләт илһамыннан туган җан — Илһам һаман үз мөнбәрендә. Яраткан җырчылар бар. Илһам — бер, Илһамнар сирәк була...

1993.

*Ноябрь, 1993*

## «Ах, нинди яшисе килә!»

*Абдулла Алишның туусына 90 ел*

Фашизмга каршы көрәштә дөнья алдында якты эз калдырган, исемнәре онытылмас тарих булган балалар язучылары күп түгел. Менә алар: поляк патриоты, үзе тәрбияләгән ятимнәрдән аерылмыйча газ миченә атлаган Януш Корчак, батырларча һәлак булган легендар Аркадий Гайдар һәм тагын икесе безнең татар әдәбиятыннан: фашизмның үз оясында — Берлинда яшерен оешма төзеп, дошманга каршы көрәшкән Муса Җәлил һәм аның кыю көрәштәше Абдулла Алиш. Алар тыныч елларда гомерләрен балаларга багышлаганнар, батырлыкка өндәп язганнар, сугышта шул сүзләрен гомерләре белән раслаган кешеләр... Менә ни өчен без алар язганны җаныбыз белән тоеп укыйбыз, кат-кат күңелдән кичереп, мәгънә тирәнлеген, серләрен ачарга омтылабыз. Көчле рухлы, батыр йөрәкле абыйларның соңгы сәламе, рухи васыяте ул әсәрләр. «Бик күп уйланылган һәм язылган әсәрләр безнең белән мәңгелеккә китәләр»,— ди А. Алиш урау юллар белән илгә кайтып ирешкән соңгы хатында. М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»нә теркәгән сүзләрендә дә шундый өзгәләнү-офтану бар. Әнә шул үкенечле рәвештә өзелгән җырларны хыялың белән табарга, гомерләренә ялгарга тырышасың. Тойганыгыз, уйлаганыгыз бардыр — сугышта һәлак булган М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Х.Мөҗәйләрнең гади сүзләре дә күңелләрне тетрәндерерлек көчкә ия. Андыйны бүтәннәр дә әйткәндер, осталыкта да калышмагандыр, шәт, әмма бу шигъри юллар артында — канлы һәм утлы сугыш юллары. Алишның: «Ах, нинди яшисе килә!» — дип иртә өзелгән гомер юллары.

Ә бит исән кайтса, экиятче абый белән үзебез әдәбиятка килгән елларда очрашкан булыр идек, бүген дә балалар әдәбиятында бергә эшләр идек. Дуслары, замандашлары аның турындагы хатирәләрен яңарта. Минем дә А.Алиш турында истәлекләрем бар икән ләбаса! Үзе исән чакта «Пионер каләме» журналыннан, «Яшь ле-

нинчы» газетасыннан түземсезләнеп көтеп алган әкиятләр, китапларыннан укылган хикәяләр, алардан туган тәэсирләрем бар. Матур әдәбият белән беренче очрашкан чаклар онытылмас, кадерле хисләр ул. Күңелне кузгаткан ул сүзләр, вакыйгалар, образлар бала чагымның аерылмас бер өлеше булып күңелне җылытып тора. Һәр әсәрендә тәҗрибәле, киң күңелле абыйның әкияттә түгел, тормышта дөрес яшәргә өйрәткән, ялгыш адымнардан кисәткән, оста гына кинаяләп әйткән ихлас киңәш-теләкләре бар. А.Алиш җитәкләгән әдәбият түгәрәге Казан каласында эшләсә дә, ерак авылларда да йогынтысын тойганбыз, безне дә әдәби сүзгә кызыктырып, күңелгә ымсыну-теләк салган ул, татлы хыяллар кузгаткан. Хәзер уйлап карыйм да, әкиятләрендә төрле-төрле уй-тойгылар балкышы күрәм, лирик та алар, сатирик та. Халык әкиятләредәй җыйнак, коеп куйгандай төгәл, тапкыр алар, һәркемгә таныш. Шулай булуы бик табигый — инде ничә буын кечкенәдән укып-сеңдереп үсә — әнә, бүгенге балалар кулында да яңа китап булып чыккан шул әсәрләр ич!

Үтә сабыр холыклы, тыныч кеше булган Алиш абый. Якын дусты, каләмдәше, балалар журналында аның эшен дәвам иткән Абдулла абый Әхмәт тә шулай искә ала иде. Ә бит балачакның төп сыйфаты шул: иң тыныч, якты, бетмәс-төкәнмәс озын һәм тоташ сөенечле көннәрдән торган бәхетле бер гомер ул...

Әле дә күңел «Нечкәбил» әкиятендәге сыман: «Зыңзың... Еракта-еракта бакчаларга, кырларга, урманнарга, болыннарга...» сагынып кайта. Әле дә шул балачак болыныннан хис-тәэсирләр ширбәтен-шигъриятен җыеп салабыз... Безнең балачак дөньясын шушы тыныч, якты көйгә салып яшәгән мөлаем әкиятче абый бәхетебезнең бер өлеше икән, ул безгә сүз-чәчәкләр хуш исен тойдырган, гүзәл манзараларын күңелгә иңдергән. Әйтерсең лә сугыш гарасатында югаласы балачакның тәмен-рәхәтен тулырак татып калыгыз, дигән.

Сабыр, тыныч дигән абыебыз бер дә гамьсез булмаган. 1933 елда «Берлин» хикәясендә әйтелгән, рейхстагка фашистлар салган утның шомлы шәүләсе дөньяга сугыш афәте булып төшкәнне абайлаган.

1944 елның 25 августында гомерләре өзелә җәлилчеләрнең. «Ничек килер үлем» шигырендә Алиш моны да сизенгән. «Гильотинмы кисәр газиз башны...» дигән. Һәм: «Күпме кәгазь языла безнең хакта. Бәлки, кабат килеп аны укырлар»,— дигән өмете дә чынга аша. Әлеге шигырьнең азагы М. Җәлилнең мәгълүм юлларына охшаш булуы очраклы түгел — арада мизгелләр генә — гомер юллары бергә тәмамланган. Бер батырлык, бер үк ышаныч, юаныч һәм горурлык анда:

Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

«Сугыш ул — янган шәһәрләр, кан белән туенучы коточкыч хәшәрәт»,— дигән заманында бөек әкиятче Г. Х. Андерсен. Кешелеккә янаган атом сугышының шәһәрләрне, илләрне генә түгел, Җир шарының үзен дә көл итү куркынычы бар. Мондый хәлләрне уйлап чыгарырга әкиятче хыялы да җитмәс. Без бүген илебез тормышында гына түгел, бар дөньяда яңача фикерләү канат җәйгәнне күрәбез: «ялангач король»ләр фаш була тора, әкиятләр исән калыр, җирдә әкияти тормыш-чынбарлык өстенлек алыр дигән өметләр ышанычка әверелә. Әйбәт әкиятләр яхшылыкның җиңүе белән тәмамланучан. Тәмамлану белмәс Яшәү яңадан-яңа әкиятләр тудырып мәңге дәвам итсен. Киләчәктә: «Ах, нинди яшисе килә!» — дип, шатлыгы ташып әйткән бәхетле яшьләр атаклы әкиятче Абдулла Алишның да шул көннәр хакына гильотинага атлавын онытмасын иде...

*Октябрь, 1998*

## Сабан туе өстендә салават күпере

Бари Рәхмәткә кадәр дә безнең балалар шигърияте бар иде. Бари Рәхмәт килде, аның мөстәкыйльлеген арттырды, офыкларын киңәйтте, олылар сәхнәсенә күтәрде, күк капусыдай ачылып, сабыйларны үстергән-сөендергән, өлкәннәргә сабыйлар шатлыгы биргән шәхес — вакыйга булды.

Бари Рәхмәт килде, балалар күңелендә салават күпере балкытып, көннәрен чын сабан туе итте, гади-гадәти көнкүрештә кызыклар тулып ятуын тыйнак елмаю белән яктыртып күрсәтте.

Бари Рәхмәт килде, гомер буе җыелган мәхәббәтен оныкларына биргәндәй, үз итеп эндәште, күңелләре уртак дулкынга көйләгән нарасыйларны авызына каратты. Аның шигырьләре үзе бер дөнья, балалар тормышын гаять дәрәҗәдә табигый чагылдырган шигъри дөнья. Тәэсир көченең сере дә шунда — бала белән сөйләшү ифрат та ихлас, берничә авыз сүздән үк үз була, уртак тел таба ул.

Бари Рәхмәт, Әхмәт Фәйзи белән бергәләп, безнең балалар шигъриятендә яңа бер чор башлап җибәргән әдип, аны тергезеп, җан өреп, шуклык, тапкырлык өстәп җибәргән шагыйрь. Иртәме-соңмы, мондый үзгәреш булырга тиеш иде, бу жанрның киң сулышы белән үсеп, тирәнәеп китүе өчен шундый яңарыш булырга тиеш иде.

Бари Рәхмәт мәгарәдә тылсымнар өйрәнеп яткан хикмәт ияседәй, кинәт пәйда булды. Балалар шигъриятенә гомер буе хезмәт итеп, бөртекләп байлык җыйган каләмдәшләрен гаҗәпләндереп, көтмәгәндәрәк килеп чыкты, тылсымлы капчыгыннан кызыкларны мул сипте, бүтән мавыгуларын ташлап балалар аның янына җыелды.

Бари Рәхмәт кинәт пәйда булды. Балалар өчен Тукай исән чакта каләм тибрәтә башлаган шагыйрь язучыларның Тукай клубының сәхнәсенә менеп халыкны елмайтканчы кырык ел гына вакыт узган икән... Шул арада. Совет Армиясе туган елны кулына мылтык алган кызылармеец, батыр солдат булып, Берлинга барып, Җиңү байрагы кадап кайтты. Балаларга тынычлап елмаерлык якты көн яулап кайтты. Кабат балалар өчен яза башлавына нәкъ менә шул Җиңү шатлыгы сәбәпче булмады микән? Мөгаен, шулайдыр. Утлар-сулар кичкән, күп үлемнәр күргән кеше генә тыныч тормыш күренешләрен өр-яңа итеп, тансыклап һәм сагынып, яратып карый аладыр, шигърият итә аладыр.

Бари Рәхмәт унтугызынчы гасыр азагында фани дөньяга килеп, егерменче гасыр уртасында татар балалар шигърияте ирешкәннәргә бер йомгак ясады. Бу серле

йомгакның тапкырлык, зирәклек белән генә чишеләсен, «Сим-сим, ачыл!» дигән хикмәтле сүзләрне туган телдән, мәңгелек халык иҗатыннан эзләргә кирәген тагын бер кат исбат итте.

Нәкъ кырык ел элек, әдәбият-сәнгатебезнең сабан туе булган, Мәскәүдә үткәреләсе декадага нарасыйларча сөенеп барды, сәфәр чыкмаска кисәткән табибларны малайларча шуклык белән алдап китүе турында сөйләгән иде. Мондый җор кеше сабан туеннан каламы! Сабан туйларында туган рухы соңгы бәйрәменә ашкынгандыр. Алтмыш яше тулырга өч кенә көн җитмәде: халык алкышына бәхетле елмайган хәлдә, сәхнәдә йөрәге тибүдән туктады.

Балалар әдәбиятында күңелле сабан туе ясаган шагыйрь Мәскәүдә дә, Казанда да сабан туе батыры булып калды, һаман да мәйдан тота. Миңа калса, ул шигырьләре белән үлемне дә алдады. Бари Рәхмәт үзенең геройларын гомер буена эзләде — ул аларны балаларда тапты: шагыйрь үзен дә шунда тапты, мәңге яшь булып калуның серен тапты.

Бари Рәхмәт дигәч, суда «коймак ашатып» таш җибәрүче малай күз алдына килә. Ул шаярып озаткан шигырьләр күңелләрдә наян дулкыннар уйнатып, еллар өстеннән сикергәләп, гел киләчәккә очалар!

...1957 елда Бари Рәхмәт табутын алган самолет Мәскәүдән Казанга юнәлде. Балалар язучысы Гариф ага Гобәй белән икәүләп без шагыйрьне туган җир өстеннән, йолдызлар арасыннан озата кайттык. Бари аганың күккә соңгы күтәрелүе иде бу, минем исә беренче очуым булды. Ул чакта минем балалар өчен бер юл да язганым юк иде. Бу хакта уйлыйм да хәзер ниндидер мәгънә күргәндәй булам. Әйтерсең лә шул биеклектә Бари Рәхмәт үзенең сүзсез васыятен иңдергән...

Бари Рәхмәт елмаюы бездән соң килгән шагыйрьләрдә дә сүнмәсен — сабан туе өстендәге салават күпере кебек гади дә, үлемсез дә булып яшәсен иде.

*Май, 1997*

## Кояшлы кеше, якты шигырьләр

Сәбәпсез шатлык кагылгандай, кинәт күңелең яктырып китә. Мөлдерәмә кояш балкыган яп-якты дөньяда басып торасың икән ләбаса! Тирә-ягыңа гаҗәпләнеп, сокланып карыйсың — ташып торган сөенечеңне уртаклашып аваз саласы килә!

Каян иңде әле бу сөенечләр күңелгә, нинди тылсым тормышыңны яктыртып җибәрде? Сәбәбе шул — син Бари Рәхмәт шигырьләрен укыйсың.

Үзем очраткан кешеләрне ике төрлегә бүлеп карар идем мин: кояшлы һәм болытлы кешеләргә.

Болытлы кешедән күләгә төшә, күңелсезлеге сиңа да йога. Бала чагыннан аерылган ул, ихласлыгын тәмам оныткан. Бала күңелен аңламый: нәрсәгә ул чыркылдау-пырхылдау, өндәү билгесе кебек туры һәм төз генә йөрсеннәр!

Кояшлы кешенең күзләреннән, сүзләреннән елмаю яктысы сибелә. Әйе, «сабыйлар акылы чыкмаган» алардан, балалык бәйрәме һәрчак үзләре белән. Очраган кыенлык бозларын шаян сүз, кайнар елмаю белән эретәләр. Дөньяның гел яктыра барасын, Кояшлы киләчәктә тапкыр сүзле, киң күңелле кешеләр яшәячәген беләләр. Бари Рәхмәт әнә шундый Кояшлы кеше. Шигырьләре дә «кояш куяннары» кебек күңелеңә уйнаклап үтә, тормышка якты күз белән карарга, яхшы булып үсәргә булыша.

Бари абыйның сәхнәдән шигырь укыган чакларын хәтерлим. Әле бер сүз әйткәнче үк, күзләре, ирен читләре белән елмаюга, халык җанланып куя, рәхәт бер дулкынга көйләнә. Соңыннан төшендем — укылачак шигырь, офык артындагы кояш нурлары кебек, шагыйрьнең йөзендә чагыла башлаган икән, халык шуны тойган... Очрашуга кем нинди кәеф белән килгән, нинди халәттә булмасын берьюлы көйләде дә куйды бит. Бигрәк үз, бигрәк ихлас һәм табигый сүзләр белән көйләде. Һәркемнең күңелендә өлгергән, тулышкан, тел очында гына торган тансык сүзләрне әйтеп бирә ул! Балалар шигъриятендә яңа сәхифә ачкан ул үзенчәлекле шигырьләр нәкъ менә бүгенге тормыштан алып, нәкъ менә безнең

хакта язылган. Балаларга да, олыларга да бердәй кызык алар.

Мин ул шигырьләр белән кабат очрашкан укучылар өчен сөенәм. Алар таныш шатлык хисен кабат кичерерләр, туган телнең тәмен һәм ямен тоярлар, яраткан шагыйрь белән сагынып күрешерләр.

Мин ул шигырьләр белән беренче тапкыр очрашасы укучыларга көнләшеп карыйм — нинди кызыклар, нинди рәхәтләр көтә аларны! Гомергә онытылмас, гомергә юлдаш буласы шигырьләр көтә!

Мин ул шигырьләрне укымаган кешеләрне кызганам. Гаҗәеп бер яңа дөньяга сәяхәттән мәхрүм булганнары өчен кызганам. Хәер, андыйлар булмас та, тылсымнар, серләр иленә үз теләге белән кем генә бармый калыр икән!

*1971*

## Тел ачкычлары

Бари Рәхмәтнең «Бәйрәм котлы булсын» исемле беренче шигыре балалар журналы «Ак юл»да 1914 елда басылып чыга. Чак кына Тукайга укытырга өлгерми кала. Бер генә елга соңара, бер генә елга...

«Ак юл»да башланган иҗат ак юллардан гына тәгәрәми... Чын-чыннан ачылып киткәнче, балалар әдәбиятында үзен тапканчы утыз биш ел үтә. Шагыйрьнең иҗат бәйрәме балалар өчен яза башлагач килде. Менә монда инде аның үзен «Бәйрәм котлы булсын», дип тәбрикләргә була иде.

Иҗат серләрен, илһам хикмәтен кем белсен? Күңелендә яңа халәт өлгергәнче әнә нинди тарихи чорлар үтәргә кирәк булган: Октябрь революциясе, Кызыл армиядә хезмәт итү, редакцияләрдә эшләү, Бөек Ватан сугышында Болгария, Венгрия җирләрен азат итүдә катнашу. Иң тыныч хезмәттә — башта төзүче, аннары трестта бухгалтер... Шушы елларда, шушы юлларда күңелендә һаман әйтәсе сүзе йөргән...

Шагыйрь күңелендә илаһи илһам кабыну бер дә очраклы булмаган. Бөек Ватан сугышының Җиңү салютлары аллы-гөлле фейерверклар булып балкыды — күңелдәге шатлыкның күкләргә ашуы иде бу. Сугыш

авырлыгыннан арынган олылар балаларча сөенделәр. Җиңү шатлыгы олыларча җитдиләнеп калган нарасыйларның да күзләрен яктыртты. Нәкъ менә шушы елларда фронтлар кичеп кайткан шагыйрьнең балаларны сагынып сөю-сөендерүе, җанга якын сүзләр белән күңелләргә үтүе, канатландыруы бик табигый булган икән. Балалар шигыренә Җиңүнең оптимистик рухы, җиңүче халыкларның көр авазы килеп керде. Балалар әдәбиятында яңарыш, җанлану чоры башланды. Балаларны читтән күзәтеп түгел, бер җан, бер сулышта булып сурәтләгән шигъри дөнья иде бу...

*

— Бари абый турында сөйлә әле, ниндирәк кеше иде? — дип сорый Роберт Миңнуллин. Уйлап куям — буыннар алмашына, күреп белмәгән яшьләр килде шул. Ә тере Бари Рәхмәт минем күз алдымда... Гадәттә, атаклы кешеләр турында, сакланып калган кинотасмалардан документаль фильм әзерләнә. Бари абый турында күңелдә истәлек күренешләре генә калган. Шуларны хәтердә кабат яңартам. Истә-хистә калган истәлек-хистәлекләр алар...

Сугыш вакытында тукталып торган «Чаян» журналының яңадан чыга башлаган еллары иде. Сагынылган, тансык бу редакциядән әдәбият, сәнгатьнең атаклы кешеләре өзелеп тормый. Йомышы булмаганнар да «ут яктысына» — шаянлык җылысына җыела иде: Салих Сәйдәшев, Таҗи Гыйззәт, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Шәрәф Мөдәррис, Гамир Насрый... Җырчы Рәшит Ваһапов, атаклы шахматчы Рәшит Нәҗметдинов еш булалар иде.

Б.Рәхмәтне беренче күрүем «Чаян»да эшләгәндә, әлеге уртак зур бүлмәдә булды. Хәтер тасмасындагы беренче кадр шул: өстәлемә таянып кечкенә генә, сабыр карт утыра. Йөзе җитди, борчулы... Халык яңалыкны күреп, яратып, сөенеп өлгерде, ә матбугат тирәсенә елышкан кайберәүләр шагыйрьнең балалар өчен язганнарын «вак-түәк» дип ышандырмакчылар. Б.Рәхмәткә моны да кичерергә туры килде. Әмма яңа агым үз юлындагы чүпләрне язгы ташкындай чөереп барыбер юл сала!

Минем ул чакта әле, олылар өчен шаян шигырьләр язсам да, балалар өчен язганым юк иде. Бари абыйга укытып өлгермәдем. Бер генә елга соңардым, бер генә елга...

Кешенең һөнәре йөзендә чагыла. Замандашларын хәтерлим — үзен эре тотарга тырышмаса да, һаваланмаса да, эчке горурлыгы белән башкалардан аерылып торган язучылар бар иде. Бари абый исә гадилеге белән аерылып тора. Аз сүзле, мыштым гына йөрер, йомшак кына атлар. Озак еллар төзү трестында бухгалтер булып эшләгән Рәхмәтуллин Бари... Хәер, гомере буе язучы булса да кыяфәте үзгәрмәс иде — табигате шундый булгандыр. Балалар язучысы өчен бик табигый — нарасыйларча ихлас һәм эчкерсез...

Гадәттә, юмористны шаян сүзләр сибеп йөрүче көләч кеше итеп күз алдына китерәләр. Бари абыйның мин кычкырып көлгәнен дә хәтерләмим. Күзләре көлә иде, йөз сызыкларына елмаю яктысы тарала, иреннәре саран гына сөенә башлый — аның көлүе шушы.

Сәхнәдә берничә тапкыр күргәнем булды. Исеме әйтелүгә, халык җанланып ала. Менә ул үзе чыга — уртача буйлы, тыйнак кына бер татар абзые. Атлаулары да: мин сезнеке, менә мин шундый абзый инде, дигән сыман. Сәхнә алдына килеп баскач чак кына елмаеп, авызын мимылдатып, сөйләргә әзерләнә, бераз көтеп тора —халык тыңларга көйләнсен, өлгереп җитсен, янәсе.

Очрашуда аның ни укыйсын беләләр, шуны укысын иде, дип көтәләр. Шаян шигырьләр укый шагыйрь, тулы зал шаркылдап рәхәтләнә, ә Бари абый тын гына басып тора. Әйтерсең лә: мин аны сезнең өчен яздым, кызыгын үзегез күрегез дип торуы...

Безнең гомердә әдәбият һәм сәнгатебезнең иң олы бәйрәме, мөгаен, 1957 елның маенда Мәскәүдә үткәрелгән декада булгандыр. Моның шулай булуы аңлашыла да — әзерләнеп җиткән бәйрәмне сугыш бүлгән.

Декадага бару һәр язучының хыялы иде. Әмма исемлектә Б.Рәхмәт юк — табиблар рөхсәт итмәгән: ул-бу булмагае, йөрәгең андый сәфәрне күтәрә алмас дип турыдан-туры әйткәннәр. Әмма Бари абый поездда иде. Та-

библарга сиздерми генә, шыпырт кына киткән. Шул хакта сөйли, әле генә чыгарган такмакларын әйтеп көлдереп тә ала. Моны ул балаларча наянлык белән сөйли, шушы көннәрдә алтмыш яше туласын әйтеп куя, бәйрәм итәрбез әле, ди. Табибларны «кызык итеп» китүнең хәтәр дуамаллык икәнен дә белгән, госпитальдән фронтка качкан солдаттай ашкынган. Сугыш бетәр алдыннан гына яраланып госпитальдә ятып чыккан кеше бит ул.

Бик күңелле булган иде юлда. Тик Бари абый өчен соңгы юл булган икән...

Б.Рәхмәт белән бер кадрга кергән бер генә фоторәсемем бар. Декада көннәрендә Союзлар йортының колонналы залында Мәскәүдә яшәүче укучыларыбыз белән очрашу вакыты. Сәхнәдә барыбыз да елмаешып утырабыз, ә Бари Рәхмәт аягөсте, ул җитди, ул шаян шигырь укый. Имән бармак белән өстәлгә таянган, стаканда су ялтырый. Менә, укып бетерер дә, үрелеп бер йотым су эчәр һәм әкрен генә урынына утырыр.

Бу аның соңгы мизгелен төшереп алган соңгы рәсеме. Үзе күрмәгән рәсем...

Бари абый шатлыктан үлде. Врачлар урынлы кисәткән икән — шатлыкны да күтәрә алмаган йөрәк. Әлеге кичәдә иң зур алкышлар белән каршы алынган, зал иркенләп көлеп-гөрелдәп, үз итеп тыңлаган шагыйрь иде ул — халык юморга зарыккан. Кат-кат чакырдылар, җитми калды, тансык булып калды.

...Урынына килеп утыргач та кинәт хәлсезләнеп күзләрен йомган шагыйрьнең хәлен аңлап, халыкка сиздерми генә, сәхнә артындагы бүлмәгә алып чыктык. Ашыгыч ярдәм килде, әмма соң иде...

Ә очрашу дәвам итә, залдагы халык әле берни белми. Гали Хуҗи «Гражданин, солдат, шагыйрь» исемле поэмасыннан өзек укый. Фатих Кәримгә багышланган сүзләрнең Бари абый язмышына туры килүен күреп тетрәнеп тыңлыйбыз:

— ...Кайнар яшем сөртеп күзләремнән
Һәм тезләнеп башың очына;
Әйтер идем:
— ...Син үлмәдең, дустым!
Син үлмәдең, шагыйрь, яшисең!

Синең гомерең — илең өчен яну,
Ә җырларың — Гомер чәчәгең;
Безнең йөрәкләрдә ялкынлану,—
Бу синең дә җирдә яшәвең.

Әнвәр Давыдов укыган, Муса Җәлилгә багышланган шигырь дә әле генә сәхнә артында булган фаҗигале минутларга аваздаш иде. Кичәне алып баручы Сибгат Хәким аягөсте басып, кайгылы-әкрен тавыш белән:

— Әле генә сезнең алда чыгыш ясаган, яраткан шагыйрегез Бари Рәхмәт...— дигәч тә зал дәррәү кузгалып кул чабарга керeште, сөенү авазлары ишетелде. Сибгат абый сүзен дәвам итеп:

—...вафат булды...— дигәч, зал бер тынга авазсыз калды, аннары берьюлы фаҗигане төшенеп, «а-ах!» дип куйды.

«Декадага бармаган булсачы...» — дип офтанучылар аз булмады. Нишләмәк кирәк, соңгы сәфәренә ашкынган шагыйрь, сугыш бүлеп торган иҗат бәйрәменә ашкынган. Ә үлемне барыбер алдады ул — елмаеп, шатлык дулкынында каршылады. Шагыйрь сөенечләрен балаларга калдырып китте. Гомер озайта торган сөенечле шигырьләрен калдырды...

...Б.Рәхмәтнең табутын самолет белән Казанга озата кайтырга танылган балалар язучысы Г.Гобәй белән мине билгеләделәр. Ул чакта әле балалар өчен язганым юк иде. Әйтерсең лә язмышның бер ишарәсе булган. Чәчәкләргә күмелгән табут янында уйланып кайттым. Беренче тапкыр самолетка утыруым — күккә күтәрелүем иде. Бари абыйның соңгы очуы... Май күгендә чекрәеп янган йолдызлар арасында үз җырын дәвам итүне тапшырган сыман булган икән. Балалар әдәбияты күтәрелгән биеклектән төшмәгез, дигәндәй...

*

Еллар үткән саен Б.Рәхмәт шигырьләрен, бик таныш булсалар да, кат-кат күздән кичерәм. Шунысы хикмәтле — һаман яңа алар! Могҗиза шунда — баланың саф күзләре белән күрелгән дөнья анда, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк — «гөлгә кунган чык кебек» саф!

Балага охшатып тавыш үзгәртүче оста артистлар була. Бари абыйның шигырьләре андый артистлык җимеше түгел, анда балаларның чын үз сулышы, күзне камаштыргыч якты дөньядан хәйраннар калып, кызыгып тәүге тапкыр күреп сөенгән бала тавышы!

«Сабан туенда» дигән бер төркем шигырьләрне карагыз — үзе бер хикмәт, халыкның рухи йөзен, күңелен, холкын күрсәтә торган көзге ул. Татарның җорлыгы, шаянлыгы, тапкырлыгы ул шигырьләрдә. Шагыйрьнең бар иҗаты — үзе шундый сабантуй!

Язмый йөргән озак елларда Бари абый әйтерсең лә эчтән генә көйләп яңа аһәңнәр эзләгән һәм аны тапкан — бернинди ясалмасыз саф яңгырый торган үз җырын тапкан!

Балалар шигъриятендә Б.Рәхмәт шигырьләре белән теле ачылган шагыйрьләр киләчәктә дә була торыр әле. Әнә арабызда иң яше Афзал Нигъмәтуллин шигырьләрендә дә шул сулыш сизелә. Ә бит Афзал 1957 елда дөньяга килгән — Б.Рәхмәт соңгы сүзләрен әйткән елны, сүзләре бүленгән елны... Шигърияттә буыннар чылбыры өзелми.

Бари Рәхмәтнең «Язучы абыйларга» дигән, сәхнәдән укып йөргән шигырен искә төшерәм. Анда бер нарасый болай ди:

Мин хәзергә шуып йөрим,
Озакламый мөкәлим.
Яңа елда тел дә чыга.
Китап кирәк,
Язгыз тизрәк,
Язмасагыз үпкәлим.

...Язын торналар балаларга тәпи алып килә, шуннан соң нарасый йөреп китә, диләр. Бу бала да тәпи йөреп китәр. Ә тел ачкычын аңа Бари бабайлары әзерләп куйган... Туган тел тәмен тоеп алса, бүтәннәрен дә табар китапларның. Ачылган телләр «ябылмасын» өчен, бала җаны имезлектәй зарыгып-сусап көткән яңа китапларны да яза торырга кирәк, үпкәләрлек булмасын — Бари Рәхмәтнең яраткан укучысы көтә бит, XXI гасырда яшисе укучыбыз көтә!

*Февраль, 1987*

## Яңа бер чор башлап җибәргән әдип

Бари Рәхмәт шигырьләре үзе бер дөнья, балалар тормышын гаять дәрәҗәдә табигый чагылдырган шигъри дөнья. Тәэсир көченең сере дә шунда — бала белән сөйләшүнең бердәнбер дөрес, ихлас «дулкынын» тапкан, берничә авыз сүздән үк үз була, уртак тел таба ул.

Бари Рәхмәт, Әхмәт Фәйзи белән бергәләп, совет балалар поэзиясендә яңа бер чор башлап җибәргән әдип, балалар поэзиясен тергезеп, җан өреп, шуклык, тапкырлык өстәп җибәргән шагыйрь. Иртәме-соңмы, мондый үзгәреш булырга тиеш иде, балалар әдәбиятының киң сулыш белән үсеп, тирәнәеп китүе өчен шундый яңарыш булырга тиеш иде. Рус балалар поэзиясенең уңышлы үрнәкләре үсешнең шул юнәлештә булырга тиешлеген исбат иткәннәр иде.

Бари Рәхмәт — балалар поэзиясендә нәтиҗәле эшләгән зур шагыйрь. Балалар поэзиясенә килергә хыялланган һәр каләм иясе өчен үзе бер мәктәп ул. Балаларыбыз да дөрес шигъри зәвык тәрбияләүдә оста булышчыбыз. Күрсәтә белгәндә, исеме бөтенсоюзга мәгълүм шагыйрьләр белән янәшә торырдай шагыйрь ул.

*Октябрь, 1970*

## *Кара болытлардан — Салават күперенә чаклы...*

Васыять тарихы минем өчен 1971 елның 25 августында башланды. Шул чакта куен дәфтәренә теркәп куйганмын: «Илдар Шәйхи Маннурдан хат китереп бирде, үземне очратмагач аңа калдырган икән. Язучылар союзы конвертын ачсам, тагын бер конверт. Таныш почерк:

«Шәүкәт дус.
Хәзергә сер булып торсын.
«Сәгать суккач...»
Ачып укырсың.
Яратып: Шәйхи абзыең.»

Илдар Юзеевкә дә шундый ук әманәт икән. Васыятедер, дип уйладык.

*11 июнь 1980.* Иртән кайгылы хәбәр — кичә Шәйхи ага Маннур вафат... Мондый чакта соңгы очрашуны хәтер-

лисең... Пицунда иҗат йортыннан кайткач, анда ризыкны бигрәк әче әзерлиләр, шунда ашказанымны боздым, дип, грузин кухнясыннан зарланган иде. Бер аена түзеп була, ике айга киткәч ярамый икән, диде. Борчулы иде: операциягә керергә кушалар... Былтыр үткәргән кеше буларак, мин: курыкмаска кирәк, дип тынычландырмак булам. Картайгач, икеле инде ул, дип көрсенеп куйды... Юкса һәрвакыт көләч йөзле була иде.

Васыятен ачып укыр көн килде. Машинкада басылган, Гомәр ага Бәшировка, Хисам Камаловка, Илдар Юзеевкә, миңа адресланган. Датасы: 12 гыйнвар,1970 ел.

Язучылар союзында рәис урынбасары Мөсәгыйтъ Хәбибуллин үзе генә калган икән. Мәрхүм белән хушлашуны оештырып йөри. Яңа Бистәдәге зиратка тәгаенләгәннәр. Мөсәгыйть ашыга — хәл итү өчен обкомга барасы. Көннәре дә бит — 30 градус эссе... Мин васыять турында әйттем. Бүтән каләмдәшләр юк иде, исбатлау өчен тиз генә өйгә кайтып килдем. Васыятьне бирәсе килмәгән иде дә — обкомны ышандырасы бар. Мәрхүмнең соңгы ихтыяры үтәлсен — мәшәкатьле булса да, туган авылында җирләү зарур.

*12 июнь.* Актерлар йортында Шәйхи Маннур белән хушлашу. Мин дә сүз әйттем:

— Сугыш чорын кичергән кешеләр өчен июнь — мәңгегә озату, бәхилләшүләр ае булып хәтердә калган — июнь кердисә, күңел сискәнә. Быелгы июнь дә шулай булды — беренче көнендә үк Мирсәй ага Әмирне югалттык, Ватан сугышында катнашкан тагын бер күренекле, өлкән әдибебез белән хушлашабыз...

Шәйхи ага Маннур халкыбызның рухи тормышына ярты гасыр буе йогынты ясаган һәм тирән эз калдырган шәхес иде. Әдәбиятыбызның туры сүзле Гайҗан бабае шушы чорда ил язмышын күңеленнән кичереп, дулкынланып сөйләде, меңләгән укучыларын тапты, халык мәхәббәтен казанды. Аның балалар әдәбиятына күрсәткән хезмәте үзе генә дә бер язучының иҗат гомере була алыр иде. Моннан кырык ел элек «Олаучы малае» безне тарихи вакыйгалар эченә алып керде, халык гамен кайгыртып яшәргә өйрәтте, шигърият иленә китерде.

Шәйхи Маннур әдәбиятта туган телебезнең шигъри елъязмасын тудырырга булышты, аның әсәрләрен дәреслекләрдән үк ятлап ничә буын балалар чын кешеләр бу-

лып үсте. Бүген меңләгән укучылар яраткан язучыны моңаешып соңгы юлга озаталар... Ә Гайҗан бабай исән, Гайҗан бабай сөйли. Гайҗан бабайлар булып халык күңелендә Шәйхи Маннур рухы, иҗаты бик-бик озак яшәр...

...Мәрхүмне Мамадыш районының Тулбай авылына — туган авылына озата киттек. Машиналар кузгалганда яман каралып болыт килде, тополь мамыклары кар сыман очты... Мамадыш юлының, яңа салына торган урыннары күп — читләп үтү өчен шактый урап чыгарга туры килде. Алты сәгать бардык.

Шагыйрь үзе салдырган китапханә алдында комач япкан өстәл, авылдашлары җыелган, укучы балалар күп. Гомәр ага Бәширов митингны ачты. Илдар Юзеев Шәйхи абыйга багышлаган шигырен укыды, Рәис Даутов, Фәннур Сафин да сүз әйттеләр. Яңгыр сибәләп торды. «Шәйхелислам яңгыр алып кайтты...— диде кордашлары,— игеннәрне коткарыр бу явым». Илдар миңа ымлап, хикмәтле фал дигәндәй, салават күперен күрсәтте. Кызарып баеган кояшка карап, зиярәт ягына киттек. Оркестр уйный, тирә-якта яшел уҗым, күктә якты болытлар. Матәм гамәлләре шомлы булмады, якташлар мәхәббәте өстен чыкты. Казандагы караңгы болытлардан соң салават күпере балку илаһи ишарә сыман иде — шагыйрь тормышында болытлар аз булмады, әмма шигърияте халык күңелендә балкып калды.

Авылдашларына карыйм. Шушы кешеләр — минем халкым, мин хезмәт итә торган, гомеремне, хыял-өметләр, иҗатымны багышлаган халкым бит дип, кинәт үзәк өзгеч якынлык тоеп алдым. Таныш булмаган кешеләр шулхәтле кадерле икән, югалтырга туры килсә, һәркайсы шагыйребез сыман бәгыреңнән өзеп алу булыр иде... Кайгыдан күңел нечкәреп шушы хакта уйландым.

*16 июнь 1980.* Кич белән Шәйхи абыйның Галактионов урамындагы бер бүлмәле фатирында искә алу — җиделе. Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Рәис Даутов килдек. Хәсән абый «Агыла да болыт агыла» шигырен укыды. Моңаеп, сүзсез генә утыра.

...Яланаяк килдем дөньяга,
Шулай гына, бәлки, китәрмен.
Ә син, яңгыр, искә төшермә!
Зират бит ул сабантуй түгел.

...Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
...Агыла да болыт агыла...

Гомәр абый «мальчишник» дип, дүртәүләп (Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Хәмит Ярми белән) туган көннәргә җыелуларын искә төшерә. (Шәйхи абыйның нәкъ еллыгы җиткән көндә Хәсән абый да дөнья куяр дип кем уйлаган. Килер елның көзе дүрт дусның тагын берсе — Хәмит ага өчен дә соңгысы буласы икән. Агыла да болыт агыла...)

...Мин монда шагыйрь васыятенең бер шарты — бакый йорты туган авылында булсын, дигән өлешен үтәү турында гына яздым. Васыятьнең миңа адресланган нөсхәсе кире кайтмады... М.Хәбибуллин күпме эзләштереп тә, обкомда калгандыр, дип, очына чыга алмады. Бик тә үкенеч, әмма илтеп курсәтмәсәм, ул васыятьне үтәп тә булмый иде. «Казан утлары» журналына рәхмәт, ташка басып калдыру — саклауның иң ышанычлысы.

*Октябрь, 1994 ел*

## *Муса Җәлилне коткарган шагыйрь*

« — Каберенә баргач, «Исәнме, Зәйнәп?» — дип эндәшәм. Үзем исәнләшәм, үзем уйлыйм: «Исәнме, дим бит...» Әти каберенә баргач та шулай исәнләшелә. Сүзсез торып булмый бит...»

Хатынына багышланган шигырьләрен искә төшергәч, Әхмәт Исхак әйткән сүзләр. 1970 ел, 26 июнь. Шәһәр яны поезды.

«Исәнме, Әхмәт абый...» дим хәзер шулай үзенә...

### Чишмә

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез,
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

Таныш сүзләр бу, Әхмәт Исхакның, балалар өчен язган шигырьләреннән җыр булып киткәне, «Чишмә» исемлесе. Шаян-шук, ялкауларны чеметеп ала торган гыйбрәт-

ле әсәрләре бар аның. Минем өчен иң гаҗәбе шул иде: бала чагында үзе дә Тукайны күреп калган ул, ерактан булса да шигырь укуын тыңлаган. Ә Галиасгар Камалның күршесендә яшәгән, көн саен очрашканнар. Иҗатының чишмә башында ук Муса Җәлил белән дус булалар.

## Идел

Беренче тапкыр Яшь язучыларның Беренче республика конференциясендә күрдем мин Әхмәт абыйны. Бик күбәүләр җыелып Тукай клубы сәхнәсендә төшкән фотокарточкабыз бар. Якыннан танышу биш елдан соң, 1953 елда булды, яңадан чыга башлаган «Чаян» редакциясендә эшли башлагач. Мирсәй Әмир, Әхмәт Исхак редколлегия әгъзалары, сугышка хәтле үк танылган «чаянчы»лар. Икесе дә сабыр, тапкыр сүзле мөлаем абыйлар. М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндә дистәдән артык шаян шигыре кайткач, юмор-сатираның сулышы тагын да иркенәеп китте. Ул елларда Әхмәт Исхакның мәсәлләре, сатира әсәрләре халык арасында бик популяр булды. Туры сүзгә юллар ябык чакта да тынып калмаган шагыйрь ул — батырлык монда да кирәк иде. Әдипнең эшчәнлеге күп төрле. Дөнья әдәбиятлары шигъриятен, шәрык классикасын тәрҗемә иткәннәре күз иңләп бетерерлек түгел — үзе бер гомерлек зур эш, хәйран калырлык. Тукайның әдәби осталыгы турында китабы чыкты, М.Җәлилгә багышланган гыйльми хезмәте дә бар. Җырлар, опера өчен либретто да язган һәм тәрҗемә дә иткән ул. «Идел турында җыр»ын, әлбәттә инде, ишеткәнегез бар:

Идел суы-туган су,
Ярларына тулган су,
Рәхәт биреп йөрәкләргә
Җәелеп ага торган су.

Шагыйрьнең үз иҗатын да Идел муллыгына охшатып буладыр.

## Диңгез

Әхмәт абый белән кырык елдан артык бер әдәбиятта, бер үк жанрларда — юмор-сатирада да эшләдек. Сибгат Хәким, Гали Хуҗиев — якташым белән бергә мин-яшь

язучыны Язучылар союзына тәкъдим иткән иде. Беренче күргәндә ул чем кара чәчле, киң кара кашлы кырык яшен узган ир-егет иде. Сиксәнен тутырганда, нәкъ шундый булып калды. Һаман шулай сабыр, шаян сүзле акыл иясе.

Муса Җәлил белән бергә булган кызыкларны сөйли иде.

Дусларның нинди серләре булмас... Ә менә суга батканда коткаруын — бусы инде шаяру түгел — очраклы гына белдем. 1939 елда, язучыларның Одесса иҗат йортында чакта булган хәл икән. Диңгездә коенганда давыл кубып, таудай ябырылып ишелгән дулкыннар Мусаны һаман эчкә тарта, чыгармый. Чыныккан, таза булса да, читенләшә хәле... Тавышын ишетеп Әхмәт Исхак ярдәмгә ташлана, бергәләп ярга чыгалар. «Син җиңелдең, диңгез!» шигырен шунда язган икән ул:

Ярсынасың юкка, ачуланып,
Без бирмәбез аны тагын да...
Син җиңелдең, диңгез, көчсезләнеп
Чын дуслыкның көче алдында!» —

дип тәмамлаган Әхмәт Исхак. Шул көннең истәлеге итеп, ике дусның бергә төшкән фоторәсеме дә бар. Моннан соңгы рәсем бер ел үткәч, 1940 елның июнендә, Идел буендагы Васильево ял йортында алынган. Муса Җәлил белән Әхмәт Исхак янәшә, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи бергә төшкәннәр.

1941 елның июненә дә бер генә ел калган. Сугыш дигән гарасат упкыны миллионнарны тартып алды, корбаннар бихисап күп булды... Ә бит, уйлап баксаң, сугыш алдыннан гына Муса Җәлилне — язылачак «Моабит дәфтәре»н коткарган Әхмәт Исхак! Җәлил исә, үлмәс җырлары белән көрәштәшләренең якты исемен коткарып, батырлыкларын илгә кайтарган, милләтнең йөз аклыгын саклап калган.

...1981 елның көзендә берничә язучы Кара диңгез читендәге Пицунда иҗат йортында булдык. Абхазия бу, дөньяның әле иң имин, тыныч почмагы. Су коенганда хәтәр ишелгән дулкын таулары белән ярыша-ярыша йөзгәндә Әхмәт абыйдан шушы диңгезнең Одесса ярын-

да булган хәл турында янә сораштырдым. Ул чакта аңа 76 яшь, Муса Җәлилгә 75 булыр иде...

Ватан сугышын кичергән күренекле шагыйребез Әхмәт Исхакның туган көне 1905 елның 1 Мае. Җиңү көненең 50 еллыгы алдыннан якын итеп, яратып искә алабыз. Муса Җәлилне коткарып калган егетлеген милләт онытмасын иде. Тарихка күчкәч үзе дә коткаруга мохтаҗ була кеше, мәгълүм исемнәрне, иҗатларын Вакыт диңгезендә югалуга бирмәскә иде... Бүген дә, иртәгә дә. Менә ни өчен бу хакта мин киләчәккә китәсе яшь Хәтергә — балаларга атап, балалар гәзитенә язам...

*Апрель, 1995 ел.*

## *«Мин исән, мин үлмәм...»*

**1997 елның 6 январенда күренекле драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмирнең тууына — 90 ел. Танылган әдип балалар өчен дә иҗат иткән. Аның «Батыр малай турында хикәяләр», «Зур бүләк», «Алдакчы бозау», «Калку кырга кар ява» әсәрләре укучыларга яхшы таныш.**

«Без аның белән ике юморист ярым шаян тонда сөйләшә идек. Җитди, четерекле, әле илдә хәл ителмәгән проблемалар — әдәбият һәм тормыш хәлләре турында яшермичә икәү фикер уртаклашу да гадәткә кергән иде. Моның күңелгә тәэсире, иҗатка йогынтысы булган, ә кәгазьгә теркәлмәде. Сер саклау, бер-береңалдында җаваплылык...»

Бу юлларны Мирсәй Әмирнең вафатыннан соң гына язып куйганмын. Сагаерга, сакланырга өйрәткән заманнарда яшәдек шул. Мирсәй абый утыз җиденче елларны да искә ала иде. Юк гаепләрне бар итеп, үлемгә хөкем ителгәч, шул карарны укыганда ни кичергәннәрен әйткәне бар. Анда да елмаерга урын таба... Бәлкем шушы сыйфаты исән калдыргандыр да...

Мирсәй абыйны мин «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» повестеннан башлап беләмдер. «Агыйдел» повесте да балачагымның атаклы әсәре булды. Үзебез

исә 1953 елны мин «Чаян»да эшли башлагач якыннан таныштык. Күптәнге чаянчы, ул редколлегия әгъзасы иде. Юмор якынайта, яшь аермасын оныттыра, сердәшләр булып киттек. Мине журналга да аның хикмәтле «Хикмәтуллин»ы китергәндер әле!

Яраткан язучыма бүләк иткән «Әз-мәз мәзәк» китабым соңгысы булган икән. «Татар юморының атасына» дип язган идем. Шөкер, яратуымны белдереп тә, әйтеп тә өлгердем. Үзе дә «яраткан шагыйремә» дип яза иде автографларны. Бу сүзләрне искә алу тыйнаксызлык булып тоелмасын, ихлас абыйның мөнәсәбәте миңа бик кадерле. Такташ, Туфан, Җәлил, Ф. Кәримнәр замандашы — ул үзе дә бик шигъри җанлы иде. Алтмышынчы еллар башында Язучылар оешмасының рәисе чакта, Г. Әпсәләмов белән икебез аның урынбасарлары идек. Поэзияне тирән белүен, кайгыртуын шунда күрдем.

Мирсәй абый вафат булган көнне, 1980 елның 1 июнендә, теркәп куйган тагын бер язмам бар икән:

«Әле кайчан гына сөйләшеп утырган идек... Үлем турында да сүз кузгатканы бар. Йөрәк даруы капты да: «Карт кешене белеп булмый. Кайчан китеп барасын кем белгән?» — дигән иде. Моны ул, гадәтенчә, мөлаем елмаеп, йомшартып әйтте.

Һәр буынның өлкәннәргә мөнәсәбәте төрлечә була икән... Исәннәрдә таяныч тапмаган көннәрдә мин әдәби туганнарым, абыйларымны хәтерлим, алар миңа гомерлек терәк. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни... Замандаш кына түгел, фикердәш булуым белән да бәхетлемен.

Проза язучыларның да халыкта танылган бер җыры була. Әйтик, Габдрахман Әпсәләмовның «Гөлшаһидә җыры», Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә»се, Мирсәй Әмирнең ул — «Тормыш җыры». Моннан нәкъ илле ел элек язылган:

«Мин исән, мин үлмәм,

Мәхәббәт көчле салкын үлемнән!» — дигән сүзләре әдипнең әсәрләренә, милләт күңелендәге үз исеменә бик туры килеп тора. Укучылар мәхәббәте яшәтер аны.

*Гыйнвар, 1997*

## Язмышында гасыр танылa

*И.Рәмиевнең туууына 100 ел*

Кем ул Исмәгыйль Рәмиев? Язучы, журналист һәм биограф. Тукайны күреп белгән.

«Ашказарны җырла әле»,— ди торган булган аңа шагыйрь. Үзе дә җырга кушылган:

— Җанкай җанаш китте, ай, сунарга,
Ашказаркай буе чәшкегә.
Чәшкеләргә китеп вафат булды,
Башкынаем калды ла яшь көйгә...

«Шагыйрьнең җырлап юанган чагын да ишетергә туры килде. Бусы да хәстә күңелне күтәрү өчен бер дару — җан азыгы булгандыр»,— дип язды Исмәгыйль абый үзенең 1965 елда чыккан «Истәлекләр» китабында. «Амур» мосафирханәсендә хисапчы булып эшләгәндә шагыйрьгә чәй кертергә дә туры килгәләгән. Унҗиде яшьлек егет хәтерендә ул очрашулар онытылмас булып калган, безнең дә күз алдына китерерлек итеп сурәтли. Бу аның 1935 елдан соң чыккан бердәнбер китабы. Тагын нинди хезмәтләре бар? Ни сәбәпле утыз ел буе күренмәгән?

Исмәгыйль Рәмиевне беренче күргәндә мин дә унҗиде яшьтә идем, шулай ук хисап эшендә. 1945 ел бу — аңа инде илле тулган. Гражданнар сугышында катнашкан, Ватан сугышын кичергән. Заманында «Яңалиф» журналында, Татарстан дәүләт нәшриятында, «Чаян»да эшләгән мәгълүм журналист Тау ягына, Кайбыч район газетасына ничек килеп эләккән? Җавабы — фамилиясендә, атаклы Рәмиевләргә мөнәсәбәт шаукымы аңа да кагылган. Кага торгач, Урта Азия якларына ук җиткергән. Хәер, бусын ул үзе сайлаган. 1937 елдан, Казаннан, халык дошманы эзләү-эзәрлекләүләрдән мыштым гына ычкынырга акылы җиткән. Нәкый Исәнбәт тә, биштәр асып авылларга, халык арасына юл алган бит, мәгънәсез чордан борынгылар зирәклегенә чумган, халык иҗатын бөртекләп җыйган. «Эшнең башы михнәтле булса, төбе хикмәтле була» дигән мәкальне алар икесе дә яхшы белгән.

Беренче шигырьләремне татлы хыял итеп яшереп

йөргән чагым. Хисап эшенә барганда-кайтканда күзләрем серле йортта — район газетасы редакциясендә. Редакторы Әхәт Мөхәммәтшин, секретаре Исмәгыйль Рәмиев. Үзләре язып гәзит чыгара — аерым бер затлар — алар минем өчен. Стена газетасында күреп, Исмәгыйль абый сайлауларга багышлап шигырь язарга кушты. 1947 елның 20 декабрендә көндәлеккә язарлык вакыйга булган ул: «Беренче биттәге шигырь астына калын хәрефләр белән «Ш.Галиев» дип язылган... Шигыремне көчкә-көчкә таныдым: фамилиядән һәм баштагы ике юлыннан... Рәмиевне күрдем:

— Мин аны синең эчтәлекне саклап үзгәрттем,— ди.—Иң мөһиме — үзебезнең Кайбыч шагыйре язуы!»

Яңа ел, совет армиясе турында да язарга туры килде. Ул чактагы стандартка җайлап «киртәсенә кертә» иде, кызыгын-тәмен тоймадым. Үзем өчен язган яшьлек хисләрем сер — алары белән кызыксынмады да ул. Поэзиянең коргаксыган чагы, мәхәббәткә урын юк иде матбугатта, гәзиткә бүтәне кирәкми дә.

Яшь аермабыз шактый булса да, әдәбият якынайтты безне. Атаклы Рәмиевләргә бәйләнешен инкарь итми, үзең беләсең икән, дигәндәй, аска карап елмаеп кына үткәрә.

Беркөнне район үзәгендә хәбәр таралды:

— Рәмиев Кече Кайбычта каршы сүзләр әйткән!

— Хәтәр икән хәле,хөрт...

Болайрак булган. Колхозда хезмәт кеңәгәләре турында сораша журналист — вакытында язылмый икән. Җилгә эшләгән чаклар, берни түләнми инде үзе, ә матбугат кайгыртырга тиеш. Менә шуны «Михнәт кеңәгәсе» дигән Рәмиев. Клубта, халык алдында — тәнкыйть гәҗиттә чыкканчы дип, колхоз председателе райкомга җиткереп өлгергән. Баксаң, Үзбәкстанда «хезмәт»не «михнәт» диләр икән, үзбәкчәләп җибәргән абзый. (1980 елда Каракалпакстанда татар әдәбияты көннәре булды. Лозунгларда «михнәт»не зурлаганны күрдем дә, Рәмиевкә татарча михнәт китерә язган вакыйга искә төште. Әче көлү булып ишетелгән шул. Кызганычка каршы, агулы мамык җирендәге михнәттән дә гарык иде үзбәк балалары, авыр иде ул мамык...)

Исмәгыйль абый 1936 елга чаклы «Чаян»да эшләгән кеше, шулай хәтәр шаяртты микәнни? Юктыр, баш китәрлек уен бит... Сталин заманы, сагайган колаклар дәвере, бигрәк тә аның кебекләргә. Үзе дә сак, чишелеп сөйләшми иде. Чама-чикне беләм, мин дә кыен хәлгә куярлык, сагаерлык тирәнгә кермим. Кинаяләп күп нәрсә турында аңлашырга була ла! Очраштык исә, шундый уенның кызыгын табабыз, колак салып тыңларга тырышканнар төшенмәслек әдәби табышмак була. Шаян, тапкыр сүзне ярата, кызларча тыйнак кына учы белән авызын томалап көлер иде. Ә бит үз гомерен «Михнәттә үткән» дияргә була. Татарчасы да дөрес, үзбәкчәсе дә.

Хәле тотрыклы түгел иде аның. «Колхоз бригадасы» райком исеменнән чыга, партиясезләр пленумда катнаша алмый. Ә ул хәтта эсерлар партиясендә булган диме. Районның культура йортына инструктор кирәк икән. И.Рәмиев шунда урнашты — урнаштырдылар, пенсиягә дә күп калмаган... Гәзитче буларак эшен очлавы минем башлавыма туры килде: күпмедер вакыттан соң редакциягә мине күчерделәр. Өлкән журналистта күргән пөхтәлек, сүзне тою тәҗрибәсе миңа бик ярады. «Безнең Чаян» бүлеге ачып, Котбетдинне йөртеп, иҗади эшләү кызык иде. Фатирда Хәбибулла абый Яруллинда булды Исмәгыйль абый. Типографиядә гәзит басучы, фотограф, «Вакыт» гәзитендә бер чорда эшләгәннәр (бусын да мин генә беләидем бугай), серләре уртак. Йорты зур, аерым бүлмәләре бар. Тагын бер эстон карты яши, ул да сөрелгән, күзлек пыяласы бармак калынлыгы — начар күрә иде. Әмма үзен яхшы күрәләр, күз уңында — иленә кайтып яшәргә рөхсәт юк.

И.Рәмиев күбрәк үткәннәр белән яшәгәндер. Китап итеп чыгарырга өмете булмаса да, гомерлек эшен дәвам итте. Бер кергәндә әрҗәдән зур гына төргәк алды. «Вакытлы татар матбугаты. 1905 — 1925» исемле зур альбом-китап иде. 1926 елда басылган. Миңа ышанып, яшереп кенә күрсәтә. Сурәтләре төшкәннең күбесе халык дошманы саналып, исемнәре тыелган иде, матбугатта телгә алынмый. Үтә кызыксынып караганым— кульъязмалары булды.

Гадәти дәфтәр битеннән таррак, ипле-тыгыз кәгазьләр иде ул, китап күчерүче хаттатларча тигез тезеп язылган — басма сыман. Һәммәсе вакытлы татар матбугаты турында. Хәйран калырлык: никадәрле матбага, әдипләр, журналистлар — күренекле шәхесләр турында мәгълүмат анда, үзе бер энциклопедия, һаман кузгатып, өсти торган икән — юанычы, күңел таянычы. Мыек астыннан тыенкы елмаеп атлавының сәбәпчесе шушы хезмәттер. Бу аның сере иде, уртак серебезгә әйләнде. Ничә елның төрле фасылларын бергә үткәрдек, ә күз алдымда кышкы рәвеше. Анықыдай бөрмәле тун беркемдә юк иде, шуңамы? Аның өчен еллары салкын — кыш булгангадыр...

Казанга күчеп, заманалар җылына төшкәч, үзе машинкада күчертеп галимнәргә, язучыларга тәкъдим иткәч ачылды теге кульъязманың сере. Кыраулы еллар иде шул әле, матбугатка җитми калды. Әмма кайбер өлгер иптәшләр мәкаләсендә үз мәгълүматларын таный иде Исмәгыйль абый... Бусын да кичерде, бусын да күтәрде ул.

1953 елны радон газетасыннан мине «Чаян» чакырып алды — Котбетдинем булышты бугай. Бусы да Исмәгыйль абый эзеннән булып чыкты. Журналның җаваплы секретаре Габделхәй Хәбиб аның телгә кергән юморсатирасын искә ала. Җылы якларга китеп эз суыткан Рәмиевнең ничек табыла язуын сөйли:

— Казаннан барган берәү мунча чабынганда күреп ала:

«Бәй, син түгелме соң, Исмәгыйль?!» — ди гаҗәпсенеп.

«Син мине күрмәдең, мин сине күрмәдем», — ди дә, чигенә-чигенә пар болыты эченә кереп югала Исмәгыйль...

Хәбиб абый элекке «чаян»чының пар эчендә эреп югалуын кыланып күрсәтә. Рәмиевне яхшы белгән чордашлары яратып кына көлешеп ала.

Казанда яшәгәндә Исмәгыйль абый белән очрашкалый идек, шулай да узып баруынча гына булды сөйләшү, шаяртышып алулар. Берсендә ул, урамда күрешкәч:

— Синең шигырьләргә карап заманны танып була, — дип йомгак ясады. Юмор-сатирам турында әйтте. Тукай замандашыннан, яшьлегем шаһитыннан ишеткән бәя

истә калды. Рәмиевчә әйтелгән иде. Ә бит аның үз язмышында гасыр танылa. Шуны әйтергә ул чакта уйга килмәгән...

Бер йорт аша гына яшәдек соңгы елларда, әмма очрашу өйләргә кермәде. Шундый бит ул шәһәрнең матавыклы тормышы. Әллә минем базмау сәбәп булды, әллә аның тыелуы?

Хезмәт юлының башында Габдулла Кариевнең «Сәйяр» профессионал театрында суфлер булган Исмәгыйль ага Кайбычтагы тормышын культура йортында, пенсиягә чыгып тәмамлады. Заман-суфлер аны тормыш сәхнәсендә сәйяр итте. Әмма агай үзенә хас үҗәтлекныклык белән гомерлек мавыгуын дәвам итте — матбугат, әдәбият, мәдәният өлкәсендәге эзләнүләрен дәвам итте. Казанда төпләнеп яши башлагач та өлкән буын язучы —әдип дуслары киңәше белән, 1917 елга кадәрге чор мәдәният, әдәбият тормышына багышланган энциклопедик характердагы «Әдәби сүзлек» төзи. Ләкин, кызганычка каршы, заманның идеологик киртәләре ул хезмәтнең автор үзе исән чагында матбугатка чыгуын тоткарлап килә. Ә 1969 елны И.Рәми вафат булгач, аны искә алучы да булмый диярлек. Ниһаять, соңгы елларда мирасына карашның үзгәрүе нәтиҗәсендә бу хезмәт тә дөнья күрде. Әле дә изге җаннар бар бит ул. Гаяз Исхакый бүләге лауреаты, язучы, тәрҗемәче һәм мөхәррир Рәис Даутов каләмдәшенең васыятен үтәде — И.Рәми хезмәтен «Татарстан» журналында бастырды. Заманнар үзгәрүен искә алып, өстәмәләр белән баетты, җентекләп эшләде, көчен-вакытын кызганмады. Киләчәктә аерым китап итеп чыгару мөмкинлеге дә булыр, шәт.

— Иҗат мирасында юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр, пьесалар, әдәби тәрҗемәләр, әдәбият һәм матбагачылык, китапчылык тарихына караган күпсанлы мәкаләләр, истәлек язмалары, библиограф хезмәтләре бар,— ди үзендәге зур кулъязма архивның кыйммәте турында Рәис Даутов. Тарихыбызда калган «ак тапларны» тутырырдай кулъязма мираслар күп бездә. Кул гына җитсен дә, күңел җитсен варисларда...

Милләтнең хәтер чылбырлары буыннан-буынга ялга-

нып, өзелми килә. Ә бит өзәргә тырышканнар, гомерләр белән бергә югалтырга исәп тотканнар... Бәхеткә — тере хәтерне саклаган могҗиза-кулъязмалар бар. Намус эшенә тугрылыклы, әлегә бигүк мәгълүм булмаган фидакарь шәхесләр бар. Үзләрен дә онытмыйсы иде. Бу елларда яңадан-яңа бик борынгы исемнәр яктыга чыга,якын тарихтагылары да телгә килә. Шуларның берсе — Исмәгыйль Рәмиев, шәҗәрәсе атаклы Рәмиевләргә тоташкан язучы, журналист, библиограф, Тукай замандашы. Шигырь дип хыялланган яшьлегемдә очраткан шәхес. Очраткан кешеләр күп була, истә калганнары сирәктер. Аны бүтәннәр дә белсен иде.

*Декабрь, 1994 ел.*

## *Хәтер тәсбихы өзелмәсен*

Күз ачкысыз буран, адаштыргыч буран, таш юл катысын тоеп, аякларны шудырып кына атлыйм. Авылга борылган урын кайда соң... Югалттым. Кырдан кар ерып барам. Төнгә каршы, ичмасам... Буран тагын да ныграк шаулый дисәм, таныш каеннар шәйләнде — зират янына килеп чыкканмын. Башка вакытта булса, имәнеп куяр идең, мин куандым — шулар коткарды. Чү, рәшәткә буенда нинди шәүлә ул? Кулларын йөзенә якынайтып дога укый, адашып юл тапкан карт икән. Котылып, рәшәткәнең бу ягында — яшәү ягында калуына рәхмәтле булып тәңрегә инануы. Бабай мине күрмәде, догасы озын иде, бик бирелеп укый иде... 1950 ел бу — гасыр уртасы, ят күзләрдән качып кына дога укылган чор...

«Әбрар Сәгыйди — шагыйрь, журналист, Кайбыч районының Кече Кошман авылында туган, шул авыл зиратына күмелгән» дип укыгач, яшьлегемдә адашып юл тапкан теге төнне хәтерләдем: Кошман авылы каберлеге иде ул... Әлеге картымның әрвахларга дигән догасы якташ шагыйребезгә дә багышланган лабаса. Бабай, әлбәттә, авылдашы Закир мулла улы мөгаллим Әбрарны бик яхшы белгән. Мин белми идем шул. Соңгы китабы 1930 елны чыккан, китапханәләрдә инде юк, матбугатта исеме телгә алынмаган — оныттырганнар. «Кирпеч базларында» исем-

ле повесте һәм «Кырлар тавышы» исемле шигырьләр җыентыгы китап итеп чыгарырга рөхсәт ителгән көе кала. 1937 ел — шагыйрь тавышын ишеттермиләр.

1895 елның 14 апрелендә туган Ә.Сәгыйдинең беренче шигырьләре «Ак юл» журналында һәм «Кояш» гәзитендә 1913 — 1914 елларда дөнья күрә. Инкыйлаб чорында, һәм аннан соң исеме М.Гафури, Н.Исәнбәт, Ш.Фидаиләр белән беррәттән телгә алына.

«Ирекне кайнар котлый, ләкин аны тәңредән бүләк итеп саный» дигән тәнкыйть сүзе дә ишетә мулла улы... 1916 — 1917 елларда «Сугыштан абыем хатлары», «Ирек азаны» исемле шигырь җыентыклары чыгарган. Тагын өч китабы күренә: «Яшьләр иле» (1921), «Умарта бакчасы» һәм «Эш курае» (1930).

Тукай исән чакта, Тукай йогынтысы белән каләм алган шагыйрь балалар өчен дә яратып яза. Туган авылында, Кайбычта, Тау ягының бүтән төбәкләрендә мөгаллим булып эшли. Казанда «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» гәзитендә эшләгәндә Г.Ибраһимов белән якыннан таныша. Ә.Сәгыйди тормышында бер борылыш та булып ала: 1922 — 1924 елларда хәзерге Буа районы Килдураз авылында мулла була. Сүз уңаеннан әйтим, 1995 елның февраль башында берничә әдип ул авылда булдык без. Бизәкләп, кирпечтән ипле итеп салынган затлы мәчетне күреп сокландык. Шагыйрь тормышындагыча — мәктәпкә якын ул. Укучы балалар белән очрашканда шул хакта әйтергә кирәк иде дә, үзебез дә соңрак белдек: рәсми биографиясендә андый мәгълүмат юк иде, улы Мараттан белдем. Ә бит юкса руханиның мөгаллим булуы бик табигый... Инде бу хәлне белгән дин әһелләре элекке хәзрәтне догадан калдырмаслар. Укучылар да әдипнең иҗаты, тормыш юлын өйрәнерләр. Бик кызыксынучан алар, китапханәдә кулдан-кулга йөреп тауша-лып беткән китаплар шуны күрсәтә.

100 еллык... Бала чакта бу сан хәйран да зур булып күренә. Баксаң, алай искитәрлек ара да түгел икән. Йөз яшенә якынлашкан исән-имин әдипләребез бар. Без аларны инде шактыйдан күреп беләбез. Әбрар абый белән дә, шәт, әткәйгә ияреп Кайбыч ярминкәсендә йөргәндә очрашканбыз әле...

Кайбыч, Кайбыч... Шигырь дип хыялланып йөргән, гомергә онытылмас яшьлегем ул. Мин Кайбычка кайта алсам да, яшьлегем кире кайтмас. Ә менә Кайбычка яшьлеге кайтты! Янәдән район булып, мәстәкыйльлек алгач кайтты. Булдыклы хакимият башлыгы Азат Хәнифәтуллин җитәкчелегендә дәртләнеп эшләгән халык көче белән яңарып, терелеп Олы Кайбыч күтәрелә. Бу уңайдан рухи барлау, үз тарихын ачыклау да табигый. Күренекле әдип Әбрар Сәгыйдинең 100 еллыгын якташлары лаеклы итеп искә алырлар дип көтәргә була.

Юкса, бер онытылса онытыла бит ул. Әнә «Татар поэзиясе антологиясе»нең яңа басмасыннан Ә.Сәгыйди әсәрләрен таба алмадык.Тарихыбыз искиткеч бай, атаклы шәхесләр күп. Күплек — кадерсезлеккә китермәсен иде, барлап, яңа буыннарда хәтерне яңарта торыйк. Юбилей даталары — хәтер тәсбихы өзелмәсен, балаларыбыз дәвам итсен.

Якташ әдипләр аеруча кадерле була, кызыксынып укыйсың, мин дә шулай теләгемә ирешермен, дип инанасың. Карамасар авылында туып үскән фронтовик шагыйрь Гали Хуҗиев шигырьләрендәге «Кайбыч урманнары» сүзе дә ватанпәрварлык тәрбияләгән. Шул ук авылда туган Габдрахман Ильяснең «Горизонт» повестен мавыгып укый идек.

Мулла гаиләсендә туган әдип 1937 ел дигән «сират күперен» ничек кичәр иде, тәкъдире бүтәнчәрәк була. Ул елны, Кайбыч мәктәбендә укыткан чакта, каты авыру аны аяктан ега. Бәла аяк астыннан чыга диләр, фидакарь укытучы язгы юлда җәяүләп утыз чакрым юл үтеп салкын тидергән була. Вафаты 1939 елның I апрелендә дип теркәлгән. Улы Марат әйтүенчә, дөресе туган көне белән бер икән — 14 апрельдә вафат була.

Балалары әтисе юлыннан китә, кызы Зөмәррә укытучы, Марат бүгенге көндә Казан педагогия университетында туган тел дәресләре бирә, Фоат Санкт-Петербургта укыта, Илһамия Саратов өлкәсе мәктәпләрендә укытучы булып эшләгәч, Казанга кайтып, милициядә балигъ булмаган балаларны тәрбияләү инспекциясендә эшли.

...Күз ачкысыз бураннарда адашмаслык булып Кош-

ман белән Кайбыч арасы: яңа йортлар, яңа бистә Бәрле елгасының Кошман ягына салына, утлары ерактан күренер. Моннан соңгы тарихлар да мәгълүм шәхесләрен замана давылларында адаштырмаслык булсын берүк.

Әбрар Сәгыйдинең «Хөррият сәламе» шигырендәге шушы юллар бүгенге көнебезгә, илебезгә төбәп әйтелгән сыман:

«Сәлам хөр ил сиңа! Инде мөбарәк булсын иркенлек,
Хөкем сөрсен илем синдә гомергә, татулык, берлек.
Сәлам сиңа хөр ил! Мактыйм сине хәзер шулар берлән,
Яшә, син, мәңге-мәңге көчле батыр эшчеләр берлән.»

Шагыйрь бәйрәмендә тантаналы сәхнә түренә язып куярлык сүзләр бу. Шигърият әнә шулай, заманнар белән эчтәлеге яңарып яши. Онытмаска гына кирәк.

*1995*

## Хәтер хәзинәләре

*Нил Юзиевнең туууына 70 ел*

«Алар үзләре турында язганны ишетмичә китеп бардылар түгелме соң?!.»

*Нил Юзиев*
*(«Әдәби хәзинәләр» китабыннан.)*

Каләм иясе-фикер иясе арабыздан киткәч, аның язганнары янә бер тирән мәгънәле яңгыраш ала. Үз язмышына бәйле рәвештә үкенү дә, сызлану да кузгата ул сүзләр. Мин дә үземне бурычлы тоям: Нил дустыбыз турында язарга керешәм дә, туктап калам: иҗади эшчәнлеген күз алдына китереп, колач җитмәстәй киңлеккә омтылам икән, олы хезмәтләре, Нил Юзиев дигән шәхес алдындагы җаваплылык шуңа этәрә икән.

Безнең иҗатны өйрәнеп, күләмле мәкаләләр язды ул. Үз хезмәтләре турында бәябезне без дә әйтә килдек. 1967 елда «Традицияләр яңара» исемле китабы уңае белән дусларча шаяруым да чыккан иде:

Эзләнергә, уйланырга,
Шигырь диеп янарга,
Сау шагыйрьләр турында да
Мөмкин икән язарга!
Традицияләр яңара! —

дигән идем. Моңача тәнкыйтьчеләрнең классиклар иҗатын гына өйрәнеп, замандашларына игътибар җитмәүдән соң Нил Юзиев эшчәнлеген хуплау булган.

Нил белән беренче очрашуыбызга быел 50 ел туласы иде. Егерме яшендә XX гасыр уртасында булган ул. Атаклы университетта укыган, аспирантурада чагы, диссертация яза. Энесе Илдар беренче курста. Илбарис Надиров фронтлар узып кайткан, ул да диссертация белән мәшгуль. Менә шундый өч Казан кунагы белән Кайбычта, мин район газетасында эшләгәндә очраштык без. Хәзерге Галия Кайбицкая музеена җитәрәк, кечкенә күпер янында, Бәрле елгасына төшә торган чишмәле чирәмлектә танышып-фикерләшеп утыруыбыз гомерлек истәлек булды. Безнең сүзләр тел-әдәбият, шигърият турында булды. Матбугат буенча бер-беребезне тиз күреп ала торган яшь чак, хыялый-канатлы чак.

Аннан соң да бик күп очрашулар булган, болары инде Казандагы гомердә. Әлеге дә баягы, әдәбиятыбыз, аның проблемалары, иҗат психологиясе турында, конкрет мисаллар белән сөйләшү иде. Теоретиклар белән практиклар фикерләшүе ике як өчен дә мәгънәле һәм файдалы. Ә истәлекләр — үзгә жанр, монда шәхес буларак Нил турында кайбер күзаллау, хатирәләр рәвешендә штрихлар булыр.

Шау-шулы холыклар була. Гөрләтеп көләләр, тавышлары да көр чыга, үзләрен шулай тыңлаталар. Нил бөтенләй башкача иде. Сабыр гына тыңлап утырыр, каршы төшәргә дә ашыкмас. Аннары иплəп кенә, дәлилләп үз фикерен раслар. Аның белән сөйләшү, фикер алышу һәм сүз көрәштерү дә мәгънәле, мавыктыргыч иде. Шуның белән үзенә тарта, үзенә кирәк мәгълүматны да ишетә. Тәнкыйтьченең көче сүз-күсәктә түгел, фикер төгәллеге, тапкырлыгында. Үзенең хаклы икәнен белгән кеше генә шундый була. Кычкырышу көч билгесе бул-

магандай, йомшак кына елмаю да көчсезлек түгел — нәкъ менә киресенчә!

Ул беркайчан да рияланып, кемгәдер ярарга тырышып, намусына хилафлык китермәде. Ә бит язучылар тормышында, бәхәсләр кызган зур җыелышларда киеренке хәлләр була иде заманында. Хакыйкатьне күрәләр, беләләр, әмма эчтән тыналар. Сәбәпләре төрле була: йә ул югары дәрәҗәдәге җитәкче күрсәтмәсе, йә әле ярып салырга ярамаган кыю фикер. Инде дөреслек тагын күмелеп калды, дигәндә, Нил Юзиев сүз ала. Бүтәннәр җиңел сулап куя — көткән сүзләрен ишетеп тынычланачак алар... Ә ул үз фикерен логик эзлеклелек белән фәнни исбат итәргә керешә һәм ышандыра! Чөнки бу кирәкле кеше дип түгел, кирәкле хакыйкатьне яклау-раслау була. Тәнкыйтьченең камил фикерләве, рух ныклыгы, кыюлыгы. Аңа да ансат түгел, сабырлыгы кайнарлык тышчасы гына. Очрашуларда, күрәсең, дулкынланудан учына йөткергәләп, әрле-бирле йөренеп ала. Сүзгә керешкәч исә, итагатьле, зыялы, объектив бәяләүче акыл иясе булып кала. Тәнкыйтьче хискә бирелеп түгел, дөрес бәяләгән Нил Юзиев кебек булырга тиеш дип уйлыйм. Үзеннән соң аның урыны буш. Нилда булган асыл сыйфатларны берничә тәнкыйтьчедән җыеп та туплап була микән әле. Хак сүзне икеләнмичә, нигезләп әйткән очраклардан берсен искә төшерик. Урынсызга озак вакытлар кагылган, кыерсытылган олы шагыйребезне, турыдан яра торган дуамал шәхес Салих Батталны — партиянең үзәк комитетында да горур карышкан, баш имичә чыккан шагыйрьне яклап, матбугатта иҗатын югары бәяләү коткарды бит, әсәрләренә юл ачылды. Чагыштырып карасаң, икесе дә бердәй кыю шәхесләр, әмма нәтиҗәгә берсе шагыйрьчә кызулык, берсе галимчә зирәклек белән ирешә.

*

Милләттәшләр яшәгән ерак якларны — радио дулкыннары барып җитмәгән, туган илебездә китап та күрми яшәгән төбәкләрне йөреп чыгу максатым бар иде. Рәсми рәвештә бу чикләнде, юлны кисә тордылар — ярамый!

Шулай да форсат чыккалый иде. Шуларның берсе —Казан дәүләт университетының һәр елда була торган фольклор экспедициясе. Мин Нил Юзиев җитәкчелегендәге төркемгә кушылдым. Уй-фикерләр туры килә. Шәхес буларак та, галим буларак та ихтирамым зур, якын күрәм. Очрашкан саен, үзеннән-үзе башланып, тирәнгә кереп китә торган бетмәс-төкәнмәс сүзебез бар — шигърият, аның серләре. Ул теоретик, шигырь язып башлаган, мин практик буларак, тиз аңлашабыз, иҗат процессы серләренә конкрет мисалларда җитешәбез. Шулай итеп, өч ел рәттән — 1964 — 1966 елларда Пермь, Курган, Чиләбе, Свердлау өлкәләрендә халык иҗатын туплап, беренче курс студентлары белән йорттан йортка йөреп, милләттәшләр белән күңелдәш булып, моң-зарларын тыңлап, теркәп кайттык. Шигърият турында сөйләшү дә өзелмәде. Ул сәфәрләрнең миңа тәэсире, файдасы зур булды.

Нил Юзиевнең татар поэзиясе поэтикасын өйрәнеп, әдәби-фәнни эш белән шөгыльләнгән чагы иде — докторлык диссертациясен әзерли. Иҗат лабораториясе турында сораулары өстәлә торгач, төгәллек өчен мин кайберләрен аңа язып бирергә кирәк таптым. «Шигырь турында хикәяләр» шулай туган иде. 1965 елда яздым мин аларны, Нилга тапшырдым (33 елдан соң гына матбугатка бирдем: «Мирас», N 12, 1998).

Нил Юзиев әдәбият фәнендә зур вакыйга булган «Хәзерге татар поэтикасы», «Шигырь гармониясе» исемле иҗади хезмәтләрен язды, минем иҗаттан да мисаллар, үрнәкләр китерде, рәхмәт әйттем. Әлеге әсәрләре өчен 1974 елда әдәбият галимнәреннән беренче буларак Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды, фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗә алды.

Университет нәшрияты чыгарган «Шигырь гармониясе. Татар шигырь поэтикасы» дигән китабына 1972 елның 20 ноябрендә — туган көнемдә язган автографын ядкаре итеп саклыйм: «Шәүкәт дус! Бу китапны язганда син иҗатың белән дә, киңәшләрең белән дә булыштың. Чын күңелдән рәхмәт сиңа. Киләчәктә дә шулай иҗади дуслыкның һәм бәйләнешләрнең гармонияле дәвам итүен теләп.— Нил.»

1966, 1973, 1978, 1981 елларда чыккан китапларына язган кадерле автографлары бар.

Экспедициядә эш тәртибебез һәр көнне шундый: авылларда йорттан йортка йөреп фольклор җыябыз, кичләрен клубта әдәби кичә оештырабыз. Пермь өлкәсендәге Канабек авылына килгәч, күрдек — клубта күргәзмә суд бара. Клублары кечкенә, керә алмаган кешеләр күп. Шунда бер тәвәккәле тәкъдим итте:

— Әйдәгез, очрашуны болында уздырабыз!

Авыл читендә Шауба ярында сабан туйлары үткәрә торган урын елганың иске эзе икән. Шундый уңайлы итеп табигый амфитеатр ясалган — махсус әзерләсәң дә алай булмастыр. Ярым түгәрәк ясап халык тезелде.

«Сәхнәбез» янәшә куелган ике йөк машинасы кузовы, өченчесе фаралары белән яктыртып тора. Җирле вакыт белән төнге сәгать 11 туларга ун минут. Башта Нил экспедиция эше турында сөйләде. Иртәгә йорттан йортка йөргәндә күрешәсе, борынгы рухи хәзинәләрне, саклянып калган китапларны сорыйсы... Әдәбият турында Нил академикларча тәфсилләп, дәлилләп, ерак тарихтан башлап иркенләп сөйли. Сәгатькә караучы юк. Ярты сәгатьтән ким булмый чыгышы, әмма ялыктырмый. Саф туган телне тансыклаган кешеләр яшь галимнең әтрафлы, дәртле чыгышын беренче тапкыр ишетәләр бит.

*

Нил Юзиев 1973 елдан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторына җитәкчелек итте. Татарстан китап нәшрияты тарихында классикларыбызның күп томлы әсәрләре фәнни әзерлекле, иң күп дөнья күргән еллар иде. Һәркайсында Нилның турыдан-туры катнашы булды. Ул эшләр дә шома гына бармады, каршылыклар да аз түгел иде. Өлкә комитеты бик сизгер күзәтә иде. Һади Такташның өч томлыгын әзерләгәч, хатларын кертмәскә куштылар. Нил Юзиевнең кыюлыгы хәл итте, нигезли белүе, җаваплылыкны үз өстенә алуы коткарды.

Тәнкыйтьченең укучыларга күренмәгән тагын бер эш-

чәнлеге бар, ул — китап нәшриятына алынган әсәрләрнең язмышын хәл иткән эчке рецензияләр язу. Бу вазифаны теләсә кемгә тапшырып булмый. Авторны ышандырырлык абруйлы белгеч кирәк. Нил Юзиев мондый җаваплы эштән дә баш тартмады.

Нәшриятта унөч ел матур әдәбият редакциясе мөдире булып эшләү дәверендә Нил белән багланыш эшне җиңеләйтә иде, ул хуплаган хезмәтләр ышанычлы. Аның иҗади катнашында әзерләнгән әсәрләр яңадан нәшер ителгәндә, нигез-таяныч булырлык.

Нил Юзиевнең фәнни хезмәтләре әдәбиятка килүче яшь белгечләргә кулланма, дәреслек булып хезмәт итә. Аның ихлас игелеге, ярдәме инде бик күпләр язмышында хәлиткеч булды. Шунысы куанычлы, үзен дә олылап, рәхмәт хисе белән искә алалар. Үзе өчен дә, шәкертләре өчен дә сөенерлек хәл.

Нилның фикердәш дәвамчылары бар. Улы Айдар да шулар арасында икән. Таләпчән этисе хупларлык югарылыкка ирешүен сизми дә калганмын. Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе рәисе буларак, хезмәтләре белән танышканда: Нилның үзеннән соңгы шатлыгы, дип сокланып тордым. Борынгы әдәбиятны, атаклы шәхесләребез мирасын чын галимнәрчә өйрәнгән шәхес ул, Илдар улы Салават белән икесе башкарган, телевидениедән илгә, халыкка күрсәтеп яңарткан мирасыбыз өчен дә, киләчәк өчен дә тыныч булырга урын бар.

...Кайбычта очрашканыбызга илле ел булыр иде. Биектау районының Казансу буендагы Сасмак авылында мәңгегә хушлашуыбызга да бишенче ел шул инде. Үз сүзләре белән: «Алар үзләре турында язганны ишетмичә китеп бардылар...» — диеп әйтергә туры килә. Әмма хезмәтләре белән үзен һаман «ишеттерә» ул, бүгенге әдәби процесста кайбер мавыгучыларга үзенең дәлилле җавапларын җиткерә тора. Буыннар эстафетасында эзлеклелек турындагы сүзләре бик актуаль...

*Гыйнвар, 2001*

## Кушкөбәкле мылтык

(Детектив түгел, истәлек)

«Сабантуй»да күркәм гадәт яши: редакция яшәрә, алмашына килсә дә, өлкәнәя барган тарихын онытмый. Элек эшләп киткәннәрне барлый торалар монда. Баш мөхәррир беркөнне сорап куйды:

— Герман Огородниковны беләсең бит?

— Шәвәли сурәтен беренче эшләгән егет!

— Яз әле аның турында,— диде Роберт Миңнуллин.

— Нәрсә генә язармын икән соң? Ә-ә, шулай бер чакны... Мылтык искә төште! Чехов та әйткән бит, сәхнәдә мылтык булса, соңгы пәрдәдә ул атарга тиеш, дигән...

Тыңлап-тыңлап торды да саллы мыегы астыннан сабыр гына елмайды:

— Менә шуны яз.

Сөйләгәндә тиз лә ул — тыңлаучы үз белгәнен да куша. Утыз ел элек булганны укучылар белми бит...

...Яңадан терелгән балалар гәҗите ихлас җаннарны магниттай үзенә тартты. Ахрысы, күңелдәге тиктормас балалык балакларын сызганып сикереп үк чыкты! Үзе дә бала сыман, мари ягыннан — Карлыган авылыннан килгән җитез Герман кай арада күзгә чалынды әле? Үзеннән алда рәсемнәрен күрдем. Җан тартмаса, кан тарта — жанр тарткандыр, юмор кардәшлеге. Рәсемдәге һәр сызыгы елмая, кәкресе көлеп үк тора, күңелне кытыклый. Бакчы, уч төбедәй мәйданда ничәме бала мәш килә. Мультфильмдай, берәмтекләп карыйсың, һәр бала үзенчә, кыланмышыннан күренә, йөзенә язылган! Шатлык шаянлык булып ташый — балачак ихласлыгы. Кызык яши болар, күңелле дөнья бу, ах шунда булырга, кушылып китәргә!

Шигъри сүземне сурәт теленә күчереп, ак кәгазьгә кушучлап сипте рәссам! Шигырьгә яңа әкәмәтләр өсти, сабантуй тамашасы итә. Беренче булып Шәвәли сурәтен гәҗиткә Герман эшләве бер дә очраклы түгел иде.

Аваздаш безнең иҗатлар, таптым, минәйтәм, көткәнемне! Гантель күтәреп физзарядка ясаучы куян 1964 елда

чыккан «Тамаша» исемле китап тышына ук менеп басты. Ә сөйлисе тамаша 1965 елда булды. «Шәвәли»не төсле итеп, зур тираж белән чыгармакчы нәшрият. Тик инде үзенчәлекле рәссамга күпләрнең күзе төшкән, эше тыгыз. Вакытлы матбугатка, «Чаян»га, төрле якка тарткалыйлар, җитешә алмый. Байназар Әлменов борчыла:

— План яна! Китап яна! Бүтән кешегә бирәбез мәллә?

Художество редакциясе мөдиренең хәлен аңлыйм да...

— Герман эшләсен иде, Шәвәлине ул башлады бит,— дим. Байназар абый миңа да кул селти... «Мылтык кайчан булыр соң?» — дияр түземсез укучы. Хәзер, хәзер, Герман килер...

Ниһаять, егетебез «Шәвәли»нең макетын күтәреп килде. Бер күрүдә яраттым. Күз камашырлык төсләр белән балкый иде ул! Җете ачык бәйрәм төсләре! Беренче әле мондый китабым! Мин инде аны сөенгән балалар кулында күрәм...

«Яна, яна», дип кызган мөдирнең суынып җитмәгән мәле идеме, яшь егетне шелтәләп аласы килде бугай, тышлыкка төртте:

— Мылтыкның куш көбәге, түтәсе ничек инде бер якка карап торсын?!

— Аның мәзәге шунда! — ди Герман. Шәвәли сурәтендәге тыңламас-тырпайган чәчләр минеке дисәм, рәссам характеры да шундыйрак икән... Художество училищесыннан аерылып җитмәгән шәкерт атаклы остаз белән тарткалаша бит!

Ни белән бетәр бу бәхәс дип, рәссамнар мыштым гына тамаша кыла. Шигъриятне яраткан, борынгы шагыйрьләребезне яттан белгән, мине дә үз иткән зыялы Байназар абыебыз түзмәде, тагын берничә урынга туктап, «Шәвәли»не өстәлгә чәпәде:

— Төзәтеп китер!

«Шәвәли» нәрсә аңа, «Шүрәле»не, «Су анасы»н безгә бала чакта ук яраттырган ла. Тукай портреты классик дәрәҗәдә, нәшриятта ничәмә еллар эшләп, күпме яшьләрне үстергән ул! Германга сабыр гына тыңлап, ияк кагарга иде дә... Өстәлдә шуып килгән «Шәвәли»не эләктереп алды да, шытырдатып икегә аерып, кәгазь

эрҗәсенә томырды! Ягъни, мин тудырдым, үзем хәл кылам... Ишек шапылдап ябылды, рәссамнар төркеме гаепле сыман шома гына таралды. Чехов әйткән мылтык беренче пәрдәдә үк атты да, «Шәвәли»гә тиде...

Һай, матур иде китап... Яна, янды... Эрҗәдә калдыра алмыйм мин моны, чүпкә чыга ич. Әй, бәхетсез «Шәвәли»... Тукта әле, Шәвәли хәйләсез буламы — өйгә кайткач китапны үтә күренмәле кәгазь белән ябыштырып, ялгап куйдым. Беленми дә! Инде ике рәссам арасын ялгыйсы. Хәйлә — дөнья җилеме диләр, иртәгесен иң элек яшь әтәч Германны җайладым:

— Өлкән кеше кызыбрак та китәр... Ярар инде, үпкәләмә. Китап әрәм була бит. Мин аның белән үзем сөйләшермен!

Сүрелә төште егетем. Инде Байназар абыйга килдем:

— Яшь кеше кызыбрак та китәр... Ярар инде, үпкәләмә. Китап әрәм була бит. Мин аның белән үзем сөйләшермен!

Герман нидер эшләгән булды, Байназар абый, «менә болай ярый» диебрәк кул куйды. Ә тышлыктагы кушкөбәкле мылтык үзгәрешсез иде... Мәзәге дә шунда! Бәхәстә кем җиңде дисәң, үз көченә ышанган Герман җиңде, яшьләргә юл бирә белгән киң күңелле Байназар абый җиңде. Шәвәли дә җиңде — беркем дә җиңелмәде!

Огородников белән бүтән китап эшләү насыйп булмады. Шул елны аныерактан күреп алдылар, Мәскәүгә күчеп китте, «Крокодил»да эшләде. Франция, Америка матбугатында дан алды. Мәскәүдә очраттым мин аны, анда чыгасы китапка димләп тә карадым, күндерә алмадым. Төрле илләрдән эш кушалар, безнең буй җитәрлек түгел иде кечкенә буйлы чандыр егеткә... Биш елдан соң Тукай бүләгенә тәкъдим ителгән китапларым арасында «Шәвәли» алдан йөрде, тагын Тавил Хаҗиәхмәтов бизәгән дүрт китабым бар иде. Германнан соң гәзиттә Шәвәлине Тавил яңартты. Көмешче оста баласы — рәсемнәрне төпченеп-типчеп коеп кына куя, пөхтә-төгәл рәссам, шул сызыкларда милли рухның җылысы, җанга якынлыгы. Күз явын алырдай төсләрне салават күперед әй чөеп уйнатырга ярата. Унлап китабымны матурлап, балалар-

ны сөендерде, рәхмәтлемен аңа. Күп еллар буе эшләгән һәм, ышанам, эшлисе рәссамым ул.

Байназар абый Әлменов турында сүзне әлеге вакыйга белән калдырсам, күңелем тыныч булмас. Герман туган елда инде аның сурәтләвендә «Шүрәле», «Су анасы» дөнья күргән — Тукайның хыялы чынга ашкан. Нәшриятта бергә эшләргә дә туры килде. Аның белән сөйләшсәң, җаның ял итә иде. Китап бизәүче беренче милли рәссамнардан бит ул, җанлы тарихыбыз. Ш. Камал, Т. Гыйззәт, М. Җәлилләрне якыннан белгән, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, А. Алишлар белән дус булган.

1974 ел иде. Беркөнне ул мин утырган бүлмәгә кәгазь-карандашларын күтәреп керде дә, эчтән ишекне бикләде:

— Кайчаннан бирле әйтәм, качасың. Эләктеңме? — дип көлә үзе. Төшке ял вакытларында ул минем портретны ясады. Сузылып карамак булсам:

— Ашыкма. Өлгергәч күрерсең,— ди. Күрдем, ошады, охшаган...

— Шарфны җилбәгәй җибәргәнсең — Байрон кебек булсын диденме?

— Шагыйрь кебек булсын дидем!

Зур портретны, рамы белән миңа бүләк итте. Өстәвенә әле фотога төшереп, ретушлап кечкенәрәген дә кертте:

— Бәлкем китабыңа кирәк булыр? — диде, нәшрият тәртибен яхшы белә.

Бик кирәк булды, тик мин аны китапка бирергә базмадым. Әлеге шарф купшылык, кыланчыклык сыман тоелды. Тыйнаграк булса икән... Тыйнаграк эшләүче рәссамга әйткән идем дә:

— Һе, аңа бит аерым акча түләргә тиешләр! Шунсыз керешмим! — дип, күзләрен кысып, төбәп карады. Үртәлеп, алда яткан кәгазьне алдым да:

— Хәзер, бер генә минут! — дип үз сурәтен сызгалап кулына тоттырдым:

— Мә! Бушлай!

Алды, җентекләп карады — охшаган иде — кесәсенә салып куйды. Базар мөнәсәбәтләренә элегрәк күчкәннәр дә бар иде шул... бигайбә.

1988 елда китап кибетендә Байназар абыйга багышланган истәлек-альбомга юлыктым. Замандашлары, илгә танылган элекке шәкертләре туплап чыгарган. Рәссам булырга хыялланып йөргән чакларымда күңелгә сеңгән юмарт талант, ул яратып язган атаклы портретлар. Каюм Насыйридан башлап... чү, соңгы биттә әлеге «Байрон шарфы»... Ә нигә, ярый икән бу. Матбугатта чыкканын мәрхүм рәссам үзе генә күрә алмады... Ә бит көткәндер, күңеленә бер килмәсә, бер килгәндер. Ни кызганыч, мондый үкенү, оялулар булгалый шул...

Герман Огородников гәзитебездә 1963 — 1965 елларда эшләгән иде. «Сабантуй» юбилеенда аңа да 55 тула. Теге елдагы Байназар абый яше... Егет чагын онытмыйбыз, Герман үзе дә ул елларын сагынадыр. Сагындыра ул юл башы — хатирәләр кешенең гомерлек юлдашы...

Сүз башым бит «Шүрәле», дигәндәй, мылтык турында тәмам онытканмын. Чехов әйткәнчә булмаса-булмас, мылтыкның бу очракта атмавы хәерле иде. Сүзне алай башлау, укучыны кызыктыру өчен, Шәвәли хәйләсе булмады микән?

...Шәвәли сурәтен төрле рәссамнар эшләде. Ә менә укучы күңелендә калганы, без ияләшкәне — Юрий Денисов иҗаты булды.

*Ноябрь, 1993.*

## Үзеннән соңгы бәхете

Исәннәрнең кадерен бел,

Үлгәннәрнең каберен бел! — бу шигъри юллар телгә керде, «борынгы мәкаль», «халкыбызның зирәк сүзләре», дип тә язалар. Мәкаль икән, мәкаль, минем шигырь ул дип ачыкларга ашыкмыйм. Үзем дә халыкныкы бит. Шулай да, укучылар белән очрашуга баргач, сүз уңаеннан әйтеп куйган идем. Минем белән килгән яшьрәк каләмдәш:

— Нишләп синең шигырь булсын! Халык мәкале ул — бала чактан ук беләм! — дип кистереп әйтте.

— Бала чактан булуы бик ихтимал — утыз биш ел

элек язган идем,— дидем.— 1963 елның 16 мартында. «Социалистик Татарстан» гәзитендә 1964 елның 15 ноябрендә чыкты. (Нинди уңай белән, ничек язылуын да сөйләргә туры килде.)

Халкыбызның яраткан жырчысы Рәшит Ваһапов исеме белән бәйле ул шигырь. Бөек җырчының елмаю белән балкып күңелләрне әсир итеп, сәхнәләрдә сайраган чагы иде. Ил буйлап гастрольләрдә йөри, һәркайда сагынып көтәләр. Кайткан араларда «Чаян» журналы редакциясенә килә, сәфәрдә күргән-кичергән кызык хәлләр турында сөйли. Берсендә шулай, Урта Азиядән кайткач, зурлап каршылауларын әйтте. Андагы атаклы артист ничәдер бүлмәле зиннәтле квартирасына, ничәдер катлы дачасына кунакка чакырган. Гаҗәпсенеп сөйли, Рәшит абый үзе бер бүлмәдә кысылып яши бит.

Беркөнне эшкә барганда Бауман урамында ишетәм: Рәшит Ваһапов җырлый! Әмма җан өшеткеч хәбәр: вафат булган... Шул уңай белән язмасын тапшыралар икән. Бәгырь телгәләнеп тыңлыйм — ни үкенеч, исән чакта тиешле кадер булмады. Ә ул үлгәч тә халыкка хезмәт итә!

Тыңлаган саен әрнүләр яңара иде. Күңелгә тулышкан моңсулыкны шигырь белән әйтәсе килә. Язам, бозам. Юк, үзем теләгәнчә булмады. Аркылы-торкылы сыздым да, ике юлы калып торсын әле, дидем:

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел!

Рәшит Ваһаповның бакый йорты Яңа бистәдәге татар зираты диварында зур тутыкмас хәрефләр белән шул шигъри юллар тора. Халык мәкале урынлы булыр дип, бер бабай тәкъдим иткән булган. Ә бит Рәшит абыйның җырлары да халыкныкы хәзер: яратып тыңлыйлар, мәхәббәт сүрелми.

Заманында Хәсән Туфан, Мирсәй Әмирләр белән бергәләп бөек җырчының туган ягы — Сергач тарафларында булып, туганнары белән дә күрешкән идек. Әдәбият, сәнгатебезгә атаклы шәхесләрне биргән төбәк ул. Рәшит Ваһаповның данын күренекле якташы-җырдашы

Хәйдәр Бигичев эстафета буларак дәвам итә. Хәтер өзелми. Яңа буыннар килә, Рәшит Ваһапов истәлеген кайгырта. 90 еллыгы моны ачык күрсәтте. Талантлы журналист Рифат Фәттаховның изге эшкә алынып, бөек җырчының мирасын барлавы, укучыларга җиткерә килүе, аның турында истәлекләр туплавы куанычлы хәл. Бу гамәлләр Рәшит Ваһаповның үзеннән соңгы бәхете, иҗат гомеренең дәвам итүе, яшәве.

*6 август, 1998 ел.*

# ЭЧТӘЛЕК

**Гарантияле мәхәббәт**

Көлегез, көлегез *(Җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Оялчан кыз» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Мәхәббәт уставы турында . . . . . . . . . . . . . . . 10
Хупҗамал *(Сөйдергеч)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Үч итеп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Бар икән күрәселәр *(Җыр)* . . . . . . . . . . . . . . 18
Бозау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Йөргән идек ике дус . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Яшерен-батырын түгел . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Ник ташлады ул егет? . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Көзге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Гарантияле мәхәббәт *(Җыр)* . . . . . . . . . . . . . 23
Утлы күмер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Урладылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Үкенмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Җете-кызыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Тагып бирү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Мин ничек кәләш сайладым . . . . . . . . . . . . . 26
Гашыйк сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Йөрәк эше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30

**Өйдә бөтен шартлар туган**

Туйда сөйләнгән нотык . . . . . . . . . . . . . . . 31
Яңа өйгә яңа көй . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Үзгәреш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Сүзендә тора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Урамда һәм өйдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Экономия булмагач . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Бу көннәрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Будильниклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Алмашыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Никах җепләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Тыйнакландым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Морадына ирешкән Морат . . . . . . . . . . . . . 38
Куллары да куллары . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Яр эзләдем, яр таптым *(Җыр)* . . . . . . . . . . . 42
Җәһәннәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Шүрлекләр мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Фикер уртаклыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

Тимер һәм игәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Гармунчы язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Нәфес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Вокзал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Шундыйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Китә микән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Ике ут арасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Буш бармаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Өйгә кайткач». . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Өйдә бөтен шартлар туган . . . . . . . . . . . 47
Характер шундый минем . . . . . . . . . . . . 47
Хатынга булышам . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
«Оча торган тәлинкәләр» . . . . . . . . . . . . 49
Ачы тәҗрибә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Ул-бу булмагае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Бәхетле билет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Күршең белән тату торасыңмы? . . . . . . . . . . . 53
Бер балл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Үзебезнең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Үз байлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Гыйбрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Бер яшьлектә, бер картлыкта . . . . . . . . . 56
Яшем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
«Яшь» диеп сана . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Бакчада йөри бер бабай . . . . . . . . . . . . . 57
Төрле караш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Камашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Ярату нишләтми . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Озак яшәүнең сере *(Җыр)* . . . . . . . . . . . 59
Бәрәңге турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Тормыш тозы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Бабай сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Бабай зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

**Бала тәрбияләү тәҗрибәсе**

Куаныч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Кибеттә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Әнкәй белән бәхәс . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Юылган сөт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Әни кушканча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Юаттылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Урманчы Былтыр . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Буыннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Качышлы уйный Касыйм . . . . . . . . . . . 68
Һашим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

Тәмәкенең файдасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Кыскарта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Уздырган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Сөлек кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Яхшы мөгамәлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Бала тәрбияләү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . . . . . 73

**Каз ашады башымны**

Халык әйтсә — хак әйтә . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Җитешмәгән шөрепләр хакында . . . . . . . . . . . . 79
Бергәләп тотыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Каз ашады башымны . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Министрлар һәм без . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Тиле белән миле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Минем кебек беткәнче . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Җир әйләнә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Шешәдән чыккан гыйфрит . . . . . . . . . . . . . . . 88
Хәрам хәрәмләшә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Тигезләштек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Шешәдәш дуслар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Замана табышмагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Тизәйткеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Аерылмас тостлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
«Өч борын» чыларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Мәрт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Алкашларга алмашка . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Гадәт буенча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Аракы хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Ярты юлда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Чор чиреме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

**Шалт Мөхәммәтҗан!**

«Мөхәммәтҗан уңган кеше...» Элек һәм хәзер . . . . . 94
Килер заман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Безнең заман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Тәҗрибә уртаклашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Дәлил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Акыллы булсаң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Дошман елмаюы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Шәкүр язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Сәүдә ханым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Базарның файдасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Базар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Пышын-пышын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Дөп-дөрес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Сан һәм сыйфат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

Берәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Кире кагу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Сөттән авызы пешкәчтен... . . . . . . . . . . . . . . 101
Бер кассирга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Ишетмәсәң ишет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Берәү офтана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Сакаулану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Заграничный . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
«Үз «Волга»сы белән берәү...» . . . . . . . . . . . 103
Череп баеган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Май кап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Кызганыч козгыннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Диңгезләр һәм дуңгызлар турында . . . . . . . . 106
Көләсе килми — килә . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Төп башына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

**Кызганычка каршы**

Уздырыштан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Кыюлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Тегермәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Куштан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Ул елларда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Елдам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Тормыш иләгендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Үтереп мактыйм!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
    Юмарт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
    Елгырлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
    Принципиаль . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Белеп тор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Шапалак һәм чебен . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Ваклаучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Яраклашкан... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Борчылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Белгеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Юктан бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Актив . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Тырышып-тырмашып . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Җыелыштан соң... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Дөрес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Сыеклау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
«Үзем» дигәч... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Бер үк чара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Сере шул... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Үрмәкүч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Үзара тәнкыйтъ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Эш аксаса... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

Дөрес әйтә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Сөйрәлүчеләр классыннан . . . . . . . . . . . . . . . 117
Югары күрсәткеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Замана шаманнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Күнә-күнә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Форма һәм эчтәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
«Ачыктан-ачык биш минут...» . . . . . . . . . . . . 118
Бетсеннәр утырышлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Тел очында гына тора... . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Сөйләде Лотфи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Тормыш көрәшсез булмый . . . . . . . . . . . . . . 121
Төзәлер ул, төзәлер... . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Икейөзле димәсеннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Кыю Галләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Тешегезне саклагыз! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
«Чаян» ярдәм итте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Төшенде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Сер саклау мәсьләсендә... . . . . . . . . . . . . . . 128
Яңа ысул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Төзәлде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Форсат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Һаман да бер балык башы . . . . . . . . . . . . . . 132
Кызганычка каршы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Тәнкыйтькә ода . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Өйдәге чүп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Озатыйк! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Урыннан реплика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Операция . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

**Куркыныч «АЮ»лар**

Сәер кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Заграница мантосы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Көчле ягым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Үзе юкта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Куркыныч «АЮ»лар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Спекуляция турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Югары урында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Үз кешеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Битараф булсаң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Дәва . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Үз башыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
«Дошманнарга рәхмәт әле...» . . . . . . . . . . . . 156
Балта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
«Әйдә, чыгып сөйләшик!» . . . . . . . . . . . . . . . 157
Агымдагы ремонт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
«Штраф кына ал лутчы!» . . . . . . . . . . . . . . . 159
Ансыз дөнья сансыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

Үпкәләштән түгел монда . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Тәти кашык базардан . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Читләр читтән күргәнчә... . . . . . . . . . . . . . 163
Хәйләң шул булыр! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Бәйрәмдә булган хәл . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Ышаныч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Сабан туе батыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Тарафлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Гомердә булмаганны! . . . . . . . . . . . . . . . . 172

**Әдәбият тирәсендә**

Табиб бәйрәмендә елмаю . . . . . . . . . . . . . . 175
«Игенчеләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Көлке килә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Керпе хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Оныталмыйм сине... . . . . . . . . . . . . . . . . 179
«Барган юлдан...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Әз-мәз мәзәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
«Иң шәп экстрасенс» . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Шигъри рецензияләр . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Г.Әпсәләмовка . . . . . . . . . . . . . . . . 183
А.Гыйләҗевкә . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
И.Юзеевка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Х.Камаловка . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Р.Фәйзуллинга . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Н.Юзиевка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Р.Мостафинга . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Автоэпиграмма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Эпиграммалар *(Әдәбият түтәлендә)* . . . . . . . . . 185
Хикмәтле уңыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Чамалый... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Тактика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Танылу сере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Парадокс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Аныңча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Юл газабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Шигырьчегә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Бай традиция . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Мәкаль хөкеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Бер язучы юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Универсал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
«Регламент!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Бер газета редакторына . . . . . . . . . . . . . . . 188
Икәүләп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Без үзебез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188

Дөнья — куласа... 188
Хакыйкать 189
Ярты-йорты 189
Үзгәреш 189
Ник? 189
Тынычлан 190
Астыртын 190
Кәсепчегә 190
Юлдан язган 190
Актив 191
Сукранучы 191
Әдәбият түтәлендә 191
Турысы 191
Әдәбият дәрьясында 192
Үзең нинди... 192
Надан 192
«Кыскалык — талантның сеңлесе...» 193
Кыюлык турында 193
Сырганак 193
Кисәтү 194
Өлгер «шагыйрь» 194
Мактана торгач 194
Кызганыч хәл 194
Сүз кадере 195
Аңлашу 195
Сәхнә артында 195
Тел-теш 195
Тормыш өйрәнүче зары 196
Танышлык белән... 197
Аптырагач... 198
Очраклы хәл 199
Үз калыбына 200
Кемгә нәрсә... 201
Әшрафҗан китаплары 203
Ах... 204
Чират күреп сөендем 204
Бабай җыена җомгага... 205
Барабан йоткан мәллә? 206

**Аннан-моннан**

Әмин белән Дәмин 207
Ул да шундый... 208
Хикмәтле икмәк 208
«Кеше хәлен кеше белми...» 209
Бракчы ник шүрләгән? 209
Оста 210
Фокусник килгән авылга 210

Аннан-моннан *(Җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . 211
«Ай, дүдәк, дүдәк...» . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Чагыштыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Кырда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Ярдәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Килде-китте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Тырыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Лотерея . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Чир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Агай уе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Гыйбрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Кичке серенада . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Төшенгәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Читтән торып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Кысалар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Озын чираттагы кыска уйлар . . . . . . . . . . . 216
Кибеттә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
«Ансы безнең эш түгел» . . . . . . . . . . . . . . 217
Киләчәк, сиңа әйтәм, бүген, син тыңла . . . . . . . . . 219
 Председатель кайда? . . . . . . . . . . . . . 219
 Ферма отчеты . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
 Газета хәбәреннән . . . . . . . . . . . . . . . 219
 Сәер табылдык . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
 Яңа диссертация . . . . . . . . . . . . . . . . 220
 Суны нефтьләндерү проблемасы . . . . . . . . . 220
 Ай космодромында . . . . . . . . . . . . . . . 220

**Лично үзе**

Яңабаштан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
Һайтка тайт... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Бер директорның яраткан җырлары . . . . . . . . . . 223
Мөстәкыйль Мөстәкыйм . . . . . . . . . . . . . . 224
Акылсыз бүрек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
Доклад яздык начальникка... . . . . . . . . . . . . 225
Яхшы характеристика . . . . . . . . . . . . . . . 226
Лично үзе... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Эчтән зур... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Тәртип яратучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Мыегына чорнады . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Көтек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
«Кеше турында кайгырту» . . . . . . . . . . . . . 232
Хәтергә сал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Чын сәбәбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Графин белән су . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Башлык сурәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Җитми икән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Кирәк... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236

Ни Низамы, ни замы... . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Профоргыбыз уңмаган . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Сәбәпле мөнәсәбәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Булмады... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
Аңлашыла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Тау авыруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Дөресе шул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Күчә-күчә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Күтәрелгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Диләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Авырткан урын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Югалтсаң... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
! һәм ? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Баш Бармакның башсыз чагы . . . . . . . . . . . . 245
Дөрес кушамат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Могҗиза түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Эшләпә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Хаста . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Юату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Багана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Чамала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
Дөнья куласа... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247

**Сөзгәк үгез маҗаралары** *(Юмористик поэма)* . . . . . 248

**Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы** . 282

**Хикмәтле сүзләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328

**Сагыну**

Күренекле замандашлар турында
хатирәләр һәм уйланулар

«Истә синең якты гомерең...» *(Хәсән Туфан)* . . . . . 368
«Хәким бар!» *(Сибгат Хәким)* . . . . . . . . . . . . . 400
Ятим бала моңлы була. *(Заһит Хәбибуллин)* . . . . . 419
Илаһи Илһам *(Илһам Шакиров)* . . . . . . . . . . . 431
«Ах, нинди яшисе килә!» *(Абдулла Алиш)* . . . . . . . 446
Сабан туе өстендә салават күпере *(Бари Рәхмәт)* . . . 448
Кара болытлардан — салават күперенә чаклы *(Шәйхи Маннур)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 458
Муса Җәлилне коткарган шагыйрь *(Әхмәт Исхак)* . . 461
«Мин исән, мин үлмәм...» *(Мирсәй Әмир)* . . . . . . . 464
Язмышында гасыр таныла *(Исмәгыйль Рәмиев)* . . . . 466
Хәтер тәсбихы өзелмәсен *(Әбрәр Сәгыйди)* . . . . . . . 471
Хәтер хәзинәләре *(Нил Юзиев)* . . . . . . . . . . . . 474
Кушкөбәкле мылтык *(Байназар Әлминов)* . . . . . . 480
Үзеннән соңгы бәхете *(Рәшит Ваһапов)* . . . . . . . . 485

Литературно-художественное издание

Шаукат Галиев
(Идиятуллин Шаукат Галиевич)

**ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

В пяти томах

Том 2

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Л.С.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.12.2002. Форматы 84 108$^{1}/_{32}$. 65 гр. офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 26,04 + рәс. 0,84 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 27,20. Нәшер-хисап табагы 21,22 + рәс. 0,85 + форз. 0,36. Тиражы 3000. Заказ Б-644.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420266. Казан, Декабристлар ур., 2.